ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2009





**Нәкый Исәнбәт**
**(1899–1992)**

**К**азан утлары

**Q**azan utları

2009

# 12
**(1046)**

***ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:***
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

***НАШИРЕ:***
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

Казан утлары

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Җәяүле сәйран. *Роман.* ..... 5
Шамил МАННАПОВ. Аргамагын тыймый җайдагы... *Шигырьләр.* ..... 31
Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея.* ..... 36
Җәүдәт ДӘРЗАМАН. Тормыш–сәхнә. *Публицистик поэма.* ..... 56
Роза ХӘБИБУЛЛИНА. Зәйтүн илендә. *Повесть.* ..... 60
Шаһинур МОСТАФИН. «Җан җиләк»ле гомерем мизгелләре. *Шигырьләр.* ..... 88
Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА. Канат чыгарган йөрәк. *Шигырьләр. (Р. Фәйзуллинның кереш сүзе белән).* ..... 91
Лира ИБРАҺИМ-ВӘЛИДИ. Яңгыр кызы. *Хикәя.* ..... 96

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Нурулла ГАРИФ. Гыйбрәтле хикәятләр. ..... 101

**ХӘТЕР**

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Милләт каһарманы *(Нәкый Исәнбәтнең тууына 110 ел).* 106
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Синең сазың дөрес уйнады ..... 112

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Шигъри җан аһәңе. ..... 114

**ТАРИХ**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Чәрдән ханлыгы. ..... 120
Галимҗан ИБРАҺИМОВ. Дошманнар арасында дүрт ай *(М.Гайнетдиннең кереш сүзе белән).* ..... 144
Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. ..... 168

**СӘНГАТЬ**

Әзһәр ШАКИР. Милләтебезнең якты бер йолдызы *(Габдулла Шамуковның тууына 100 ел).* ..... 150

**ФӘН**

Сәйдәш ГАРИФУЛЛИН. Төркиләр шәҗәрәсе. ..... 159
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 162

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 165
Берлекнең яңа әгъзалары. ..... 171
«Казан утлары» архивыннан. ..... 172
Укучы сүзе. ..... 174
Юмор һәм сатира. ..... 176
2009 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ..... 180
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 186

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Пешие прогулки» (начало); роман-эпопея А. ХАЛИМА «Хунвейбин» (окончание); повесть Р. ХАБИБУЛЛИНОЙ «В стране маслин», рассказ Л. ИБРАГИМ-ВАЛИДИ, публицистическая поэма З. ДАРЗАМАНА, стихи Ш. МАННАПОВА, Ш. МУСТАФИНА, Л. ФАТХУТДИНОВОЙ (с предисловием Р. ФАЙЗУЛЛИНА).
«Публицистика»: Н. ГАРИФ. Поучительные сказания.
«Память»: статьи А. АХМАДУЛЛИНА, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, посвященные 110-летию Н. Исанбета;
«Литературная критика»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА о книге «Татарский фольклор».
«История»: Ф. БАЙРАМОВА. «Чердынское ханство»; Г. ИБРАГИМОВ. «Четыре месяца в вражском тылу» (с предисловием М. Гайнутдина); А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (продолжение).
«Искусство»: статья А. ШАКИРОВА, посвященная столетию народного артиста СССР Г. Шамукова.
«Наука»: С. ГАРИФУЛЛИН. «Родословная тюрков»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
Библиографический список произведений, опубликованных в 2009 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зима на Лебяжьем; писатель Анвар ШАРИПОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by MIR-HAYDAROV «Hiking» (beginning); epic novel by A. HALIM «Hunveybin» (ending); novel by R. HABIBULLINA «In land of olives», story by L. IBRAHIM-VALIDI, publicist poem by Z. DARZAMAN, poems by SH. MANNAPOV, SH. MUSTAFIN, L. FATKHUTDINOVA (with foreword by R. FAYZULLIN).
«Journalism»: N. GARIF. Instructive tales.
«Memory»: articles by A. AHMADULLIN, R. FAYZULLIN devoted to 110th anniversary of N. Isanbeta;
«Literary Criticism»: article by T. GALIULLIN about book «Tatar folklore».
«History»: F. BAYRAMOVA. «Cherdynsky khanate»; G. IBRAHIMOV. «Four months in enemy lines (with foreword by M. Gainutdin); A. HALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar origin» (continuation).
«Art»: article by A. SHAKIROV dedicated to centennial of People's Artist of USSR G. Shamukov.
«Science»: S. GARIFULLIN. «Genealogy of Turks»; F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Bibliographic list of works published in 2009.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Winter on Lebyazhie; writer Anvar SHARIPOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.11.2009, график буенча 27.11.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–1812. Тираж 2959.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Рауль
Мирхәйдәров

# ҖӘЯҮЛЕ СӘЙРАН

РОМАН

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### «Лас-Вегас»

### 1

Сентябрь урталарында, уйламаганда-көтмәгәндә бу чиллә илендә бик тә сирәк була торган яңгырлар яварга керешге. Озын-озакка сузылучы шәрык җәенең шәфкатьсез кояш нурларыннан тәмам уңып, төссезләнеп беткән тузанлы шәһәрчек, ниһаять, күзгә күренеп үзгәрә башлады: уалырга җитеп саргайган гәзитләр тәрәзә өлгеләреннән кубарып алынды, болай да килбәтсез-шыксыз биналарны тагын да картайтыбрак торган капкачлары киереп ачылды, төнге яңгырда юынган агач яфраклары исә үзләренә хас көзге төскә тиенде.

Тузанга баткан, челләдән әлсерәшкән бакчалар чолганышындагы йорт вә коттеджларның түбәләре дә үзләренең чын-асыл төсләренә—яшел, коңгырт кызыл һәм зәңгәр төсләргә кире кайттылар. Ак калай белән түшәлгәннәре исә, көзгедәй ялт-йолт килеп, тирә-юньгә көмеш нур чәчте. Югыйсә, әле һәммәсе дә моннан бер атна элек кенә бертөсле булып, бәрхеттәй йомшак вак тузан юрганы белән капланган иделәр. Бу тузан кала халкын һәр җирдән, төрле тарафлардан эзәрлекләде, хәтта шыплап-ныгытып ябылган ишек вә тәрәзәләрдән дә әчкә-түргә үтеп керде. Анысы, җәйге озын кичләрдә, әгәр дә вакыт табып су сипсәң, бу галәмәт тузан чирүеннән берникадәрле котылып та була торгандыр инде ул, әмма дә быел кала чын мәгънәсендә суга кытлык кичерә иде. Су халыкка билгеле бер сәгатьләрдә генә бирелә һәм бу хакта радио аша алдан хәбәр ителә. Әйе, быелгы җәй аеруча коры килде шул, тирә-юньнең сусавын баса торган Сырдәрья елгасы да кинәт кенә саегып калды.

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ (1941)—*язучы; төрле телләрдә чыккан дистәләгән китап авторы. «Иртәләгән сагыш», «Кара аксөякләр» («Карга короле»), «Һәрнәрсәгә—акчалата» романнары, «Игълан буенча танышу» повесте, байтак хикәяләре «Казан утлары» журналы битләрендә дөнья күрде. Мәскәүдә яши.*

Яңгырдан соң, каланың таш түшәлгән урамнары, тузып ашалган тротуарлары да үз төсенә кайтты. Бу якларда чыгарыла торган ачык аксыл таштан эшләнгән бордюрлар чип-чиста булып, ялтырап китте. Җәй буена бордюр төпләренә җыелган төрле чүп-чар, тузан өемен, кәгазь кисәкләрен, бихисап тәмәке төпчекләрен һәм сары яфракларны озын телле янгыр, әйтерсең лә, ялап кына алган. Әмма ул да тузан исен барыбер баса алмаган. Үзе белән салкынча рәхәт сафлык ияртеп килүче энгер-менгер генә иртәгәсен иртән тузан исен бетерердәй пакъ һава вәгъдә итә.

Бик тә тансык вә сагындыргыч бу янгырдан соң аруланып-янарып киткән кечке кала урамнарында хәзер инде үзенә бер шау-тантана белән музыка яңгырый, шаян-шук урам утлары тәрәзә пыялаларында уйнаклый.

Бу поселок әле моннан егерме еллар элек үк шәһәр статусына ия булса да, асылда исә ул барыбер чын калага әверелә алмады. Инде әверелүе дә бик икеле... Югыйсә, бар иде заманнар: геологлар мондагы бетмәс-төкәнмәс хәзинәләр—файдалы җир асты казылмалары ятмасы хакында бөтен илгә шау килеп хәбәр иткән иделәр. Ашыгыбрак әйтеп ташлаганнар икән шул... Имеш, биредә дөньядагы иң сыйфатлы, чыгаруы да бик арзанга төшәсе мәгъдән ятмалары бар һәм аларны эшкәртү әле йөз елларгача сузылачак икән ди. Менә шушы мәгъдән учагы аркасында, аулак кына бер район үзәге, гәрчә әле хәзергәчә чын мәгънәсендә шәһәргә әверелмәсә дә, ул чакта кала исемен алды да куйды бит, әй! Хәер, җир хәзинәсе эшкәртелгән ун ел дәвамында биредә чын калага хас күренешләр дә пәйда була башлады: кинотеатрлар, рестораннар, музыка мәктәбе, стадион, ике кунакханә төзелде, тау эшчеләренең мәдәният сарае һәм мәгъдән чыгару идарәсенең үтә зиннәтле биниһая зур бинасы сафка басты. Әлбәттә, бу төзелеш шаукымыннан җирле хакимият тә читтә калмады: биредәге халык «гадел хөкем йорты» дип йөртә торган шәһәр суды һәм прокуратурасының мондагыдай затлы бинасы, булса да, шул башкалада гына була торгандыр. Тиз арада партиянең шәһәр комитетын һәм башкарма комитетны да биналы иттеләр. Боларын шушы тирәләрдә чыгарыла торган ак таштан салдылар, фасадларын исә, һич җәлләмичә, кыйммәтле мәрмәрдән эшләделәр. Драма театры белән хастаханәне генә төзеп бетерергә өлгерә алмыйча калдылар—рудникның хәлләре мөшкелләнеп китү сәбәпле, төзелешкә акча салуны кырт кисеп туктаттылар. Киң колач белән башланып киткән бу төзелеш, шулай итеп, ярым-йорты хәлендә калды. Кайчандыр шәһәрчекнең никадәрле тиз үсү әмәленә, никадәрле дә финанс куәтенә ия булуын хәтерләтеп, азаккача төзелеп бетү бәхетенә ирешмәгән бу корпуслар хәзер инде аптыраштан куркраешып тора бирәләр... Кем-кем, ә менә тирә-юнь халкы һич кенә дә аптырашта калмады. Ташландык төзелештә нәрсә бар—һәммәсен, күтәрә алган кадәр, җаен туры китереп, өенә ташыды.

Әйе, дистә ел эчендә төземәделәр түгел анысы—хәл кадәри төзеделәр. Биш катлы йортлардан торган ике микрорайон да калкып чыкты. Гадәттәге хыял хәерчелеге сәбәпле, аларга «беренче» һәм «икенче Шомыртлык» дип исем дә куштылар. Ә берничә урамда мәгъдән комбинаты җитәкчеләре һәм техник интеллигенция өчен махсус йортлар, коттеджлар пәйда булды.

Көннәрдән беркөнне мәгъдән учагын ябып куйдылар. Белгечләр һәм эшчеләрнең бер өлеше башка җирдәге яңа казылмаларны чыгару урынына китеп барды. Бәгъзеләре исә шәһәрчектә калды. Күрәмсең, болары—шушы тирәдә туып-үсеп, гомер бакый биредә яшәгән һәм фәкать соңгы ун ел эчендә генә йә шахтерга әверелгән, яисә комбинатның ярдәмче тармакларында, төзелешләрендә эшләгән кешеләр иде булса кирәк. Һәрхәлдә, Шомыртлыктагы бер генә квартир да, хуҗасыз калып, буш тормады.

Әле шау-гөр килеп шәһәрчек төзелгән чорда, мәгъдән базы-рудник та дөбердәтеп эшләгән вакытларда һәммәсе дә теләгән кадәр су белән тәэмин ителә иде. Комбинатның куәтле су кудыру станцияләре су кытлыгын булдырмыйча, бу мәсьәләне һәрдаим хәл итеп килде. Шушы дистә ел дәверендә кала үсә барды, яшеллеккә чума, төренә торды. Яшелләндерү хуҗалыгына да таләпләр зурдан куелды, шәһәр башлыклары да бу эшкә житди карап, акчаны жәлләмәделәр һәм нәтиҗәдә кала чын мәгънәсендә мул яшеллеккә күмелде.

Мәгъдән чыгаручылар—күчмә халык кебек, кайда—азык, шунда—мал, дигәндәй, жыелыштылар да, билгесез тарафка табан юл тоттылар. Ә шәһәр урынында калды. Яңа пәйда булган бу шәһәрчек үзенең кырыкмаса-кырык төрле гамь вә мәшәкатьләре белән бергә-бер торып калды. Табышлы мәгъдән чыганагының ябылуы өлкә һәм хәтта республика хакимиятләрен дә шок хәленә куйды. Алар, бу халәттән әле тиз генә чыга алмыйча, каланың һәртөрле үтенеч-гозерләренә теңкәгә тиюче бәйләнчек чебенгә селтәнгәндәй генә кул селтәделәр. Шәһәрнең хәл итәсе мәсьәләләре исә елдан-ел ишәя барды. Кала икән, кала инде ул, хәзер аны янәдән элеккеге дәрәжәсенә—поселок статусына да төшереп булмый, тавыш чыгачак. Илдә күрелмәгән хәл ләбаса. Гәрчә бу үзенчә акыллы гына, төпле генә адым булса да, артка табан атлауны бездә яратмыйлар шул. Жирле түрәләргә дә моның һич кирәге юк. Соң, кем инде, йә, үзе утырган ботакка балта чапсын икән?!

Калада, анысы, кечкенә генә авторемонт заводы, салкын эчемлекләр житештерүче комбинат (сыра заводы да шунда), «жигули»ларга техник хезмәт күрсәтү станциясе, мендәр тышы-жәймәләр тегүче һәм керамик савыт-сабалар ясаучы фабрика, ефәк жеп чорнау цехлары бар. Әмма дә болар рәсми рәвештә завод-фабрика дип аталсалар да, исемнәре жисемгә һич тә туры килми, бу предприятиеләрдә кеше бик аз эшли, искереп беткән жиһазлары да фәкать вак һөнәрчелек өчен генә көйләнгән. Боларның шәҗәрәсе ерактагы утызынчы елларда ук ширкәт буларак башланып киткән дә, кала статусы алганга кадәр артельләр сыйфатында дәвам иткән. Куәтләре бик тә чамалы булган бу предприятиеләр, шул исәптән, жәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү тармагы оешмалары да, биредәге ярым кала-ярым авыл халкын, кыскартып әйткәндә—калавылда яшәүчеләрне тулысынча эш белән тәэмин итә алмый иде әлбәттә. Калавыл халкының өчтән икесе шәхси йорт-утарлары белән көн итә. Берәүләре йә сыер, йә кәжә-сарык асрый, дуңгыз тотучылары да юк түгел. Жиләк-жимеш һәм яшелчә бакчасыннан тукланып яшәүчеләре дә байтак. Әле теге дәверләрдә, бу поселок төпләнеп кенә килгән заманнарда, тирә-юньдәге бай жирләрен халыкка жәлләмичә, юмарт өләшкәннәр. Кайчан да булса шушы жирдән генә туеныргә калачакларын алдан ук чамалаганнар диярсең!—Кемгәдер унбишәр сутый, ә кемгәдер егермесе үк эләккән.

Мәгъдән учагы бетереләсе елны кала халкының башында бер генә уй бөтерелде: алга табан ни булыр да, алга табан ничек яшәрбез? Үз тормышларын шахтадан башка күз алдына да китерә алмаучылары (болары, нигездә, биш катлы йортларда яшәүче тау эшчеләре иде) әллә ни авырсынмыйча гына поселокны ташлап чыгып киттеләр. Монда калучылар исә яңа тормышка, яңа шартларга тизрәк жайлашу ягын карадылар. Ике ел үтте. Халык, ниһаять, әле кайчан гына гөрләп торган рудник хакында да, шахтерларның зур акчалар алып эшләвен дә акрынлап оныта башлады. Гомумән, шәһәрчек элеккесенә охшамаган өр-яңа тормыш белән яшәргә кереште. Кинәт кенә йорт бәяләре кыйммәтләнде, хәзер инде эшсез калган калавыл бүтәнчәрәк үсәргә тотынды: шәхси йортлардан гына торган урамнар пәйда булды. Кирпеч йортларны бу якларга—чиллә иле хасиятенә

туры китереп, иркен, ачык верандалы-балконлы итеп төзи башладылар. Хәтта тулы бер район калкып чыкты һәм аңа шундук Шанхай дип исем дә бирделәр. Уйламаганда-көтмәгәндә, ни сәбәпле—анысын үзләре белә торгандыр, бу тирәләргә бик күпләп кореялылар килеп урнашты. Биредәге йортларның күбесен шулар төзегәнгә күрәме, районга Шанхай исеме ябышты да куйды. Эшсез калган халыкны эшкә урнаштыру җәһәтеннән борчыла башлаган җирле хакимият тә тора-бара тынычланды. Җайлап кына, салмак кына, акрынлап, тормыш һәммәсен дә үз юлына кертте. Берзаманны калада эшмәкәрлек шаукымы купты: халык теплицалар, оранжереялар, парниклар, лимонарийлар, йорт инкубаторлары ачып җибәрде. Кайбер дәүләт предприятиеләрен дә көнләштерерлек колач белән халык эшкә чумды. Умартачылар да пәйда булды. Дөрес, поселокта умарта яисә теплица тотучылар элек тә бар иде анысы. Әмма бу эшкә хәзер һөнәрмәнд дәрәҗәдә җиң сызганып тотындылар. Кала халкының бер өлеше чәчәк үстерә башлады: берәүләре лалә һәм канәфер утыртса, икенчеләре кышкы калл белән язгы бульдонежларны хуп күрде, өченчеләре гөләпләрнең искитмәле төрләрен китереп чыгарды, дүртенчеләре исә хризантема һәм япон гөлен сайлады. Араларында фәкать орлык һәм суганча үстереп сату итүчеләре дә бар иде. Табигый ки, үзеннән-үзе, һәр эшнең башында торучы абруйлы кешеләре—әйдаманнары да пәйда булды. Сату-алуга кагылышлы бөтен мәсьәлә алар катнашында гына хәл ителә башлады. Көндәшлектән алып житештерү күләмен тәгаенләү, бәяләрне билгеләү—һәммәсе дә боларның хөкемендә иде. Кемнәрдер чәчәк үстерү белән ел дәвамында шөгыльләнсә, берәүләр чәчәкне аерым бер бәйрәм көннәренә—сигезенче мартка, яисә яңа елга атап үстерәләр иде. Ә инде парник һәм теплицаларда иртә өлгерә торган яшелчәләрнең ниндие генә юк иде! Хәер, монда да яшелчә, җиләк-җимеш һәм тәмләткечләр үстерүне бүлешеп алдылар. Февраль азакларында иң оста, иң уңганнарының помидоры пешеп житә, ә яшел кыярдан кыш дәвамында өзелмиләр. Иртә өлгерә торган төче торма, гади һәм төсле кәбестә, баллы болгар һәм әче мексикан борычы—боларның һәммәсен дә май аена кадәр килолап түгел, ә бәлки данәләп кенә саталар! Ә тәмләткеч үләннәр! М-м! Теленне йотарлык тәгамне алардан башка әзерләү һич кенә дә мөмкин түгел. Бу якларда бәрән-суган дип аталучы нәзберек-нечкә кыяклы яшел суган, укроп, әнис, киндза, кресс-салат (анысын әрмәннәр—кутен, ә грузиннар—цицмати ди), яшь сарымсак, тәүге кишер, кузгалак, бөтнек, хәтта җәен дә бер учмасы илле тиеннән ким тормаган тархун үләне—боларның барысы да шәхси хуҗалыкларның иркен кишәрлекләрендә тәрбия вә наз күреп, иркәләнеп үскән хезмәт җимешләре иде.

Ә үрентеләр, яшелчә үрентеләре! Уңышны иртәрәк тә, мулрак та җыеп алыр өчен көнне төнгә ялгап, тәрәзә төпләрен генә түгел, ә өйнең түрен биләп үстергән үрентеләр! Боларны үстерүчеләрнең белемен, тырышлыгын күреп, хәтта авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе дә көнләшерлек, шаккатырлык иде, билләһи. Гидропоникадан хәбәрдар, ягъни суда ничек үсемлек үстерүнең әмәлен-җаен бик тә яхшы белгән халык яши иде биредә. Үренте үстерүче гаиләләр бу белемнәрен аеруча киң файдаланалар иде. Яшелчәчелек совхозлары белән килешү төзиләр дә, сезонына теге яки бу үрентене йөзәр мең данәдә әзерләп саталар. Бер үрентенең бәясе ул чагында егерме тиен йөри иде. Һәммәсе дә дөрес, килешенгән—закон бозулар юк. Берәүләр исә, чәчәк һәм иртә өлгерүче помидор сатып мая туплыйлар да, лимонарий төзеп куялар. Ул чорда Ташкенттагы бер үзешчән селекционер Урта Азиядә өлгерә торган, тәме һәм зурлыгы белән башка мәгълүм төрләрен уздырып та җибәрүче лимон сорты китереп чыгарган иде. Сортын да чыгарган, шуны тулы бер кишәрлек итеп үстереп тә күрсәткән.

Теләге-нияте булган кешегә шунардан үсентесен дә, кинәш-табышын да алырга мөмкин иде. Ә инде бер дистә лимон агачы үстерден исә, ул инде үз-үзен һичшиксез аклаячак. Базарга чыгарып мәшәкатьләнмәсән дә була—тиз генә бозылмый торган бу продуктны кулланучылар җәмгыяте уптым сатып ала. Кала халкы өчен лимонарий хезмәт һәм акча җимеше, шул җимешне ышанычлы вә тотрыклы итеп саклау чарасы да, оттырышсыз лотерея булып та тоела иде.

Мөгаен, бу кечкенә генә шәһәрчектә яшәүчеләрнең тагын нинди һөнәр вә кәсепләр белән шөгыльләнүен санап та бетерә торган түгелдер. Әмма дә шунысы хак, шунысы мәгълүм: кала хакимияте халыкка эш эзләп һәртөрле проектлар әзерләгәндә, шәһәрдә нинди дә булса берәр эре предприятие, яисә завод төзетергә югарыдан рөхсәт сорап чабышып йөргәндә халык һич кенә дә кул кушырып утырмады, үз көнен үзенчә күрә бирде. Минәрчә кешене эш белән тәэмин итәрдәй завод-фабрика төзү өчен рөхсәт алулары да алай бик ансат гамәл түгел иде шул: иң әүвәле бишъеллык планына эләгү зарур, аннары исә—һәртөрле исәп-хисап, икътисадый нигезләмә, техник проектлар, Дәүләт планы карары, кыскасы, болар артыннан чаба-чаба ел арты ел үтә дә китә.

Түрәләр әнә шулай тыз-быз чабышып йөргән арада, кемнәрдер түбән өй-базларында, яисә иске бәрәңге чокырында шампиньон гөмбәсе үстереп, шуны иплэп кенә каладагы кунакханәләрнең рестораннарына тапшырдылар. Кемнәрдер исә, парник-теплицаларсыз, гидропоника-фәлән-фәсмәтәннәрсез генә кәбестәсен, кыярын, помидорын үстереп мәш килделәр. Сата алганын—сатып, калганын тозлап куйдылар да, кыш көне рәхәтләнеп саттылар. Көзен ун тиен торган кәбестә, кишер белән кушып та тозлангач, кышын инде ике сумга ук менде. Кишер белән кәбестәгә җаен кая куярга белмәгән алманы да кушып тозладылар, аш чөгендере белән бөтен кәчәнне кушып, гурийча да тозладылар, карбыз белән аралаштырып та җибәрделәр, кыскасы, халыкка мәгълүм бер генә рецептны да онытып читтә калдырмадылар.

Яшелчә, җиләк-җимеш һәм тәмләткеч үләннәр белән эш йөртүчеләр җитәрлек иде анысы. Вәләкин бу якларда алай ук киң таралмаган сирәк кәсеп ияләре дә юк түгел иде. Болары саз кондызы, ак төлке һәм йорт куяны үрчетү белән шөгыльләнә иделәр. Ә инде тиресе булдымы, аны эшкәртүче тиречеләре дә, бүрек тегүчеләре дә табылмыйча калмый. Берзаманны зиннәтле-шома шәп ир-ат һәм хатын-кыз бүрекләре тирә-юньдә гел модага кереп китте бит, әй! Ә менә бер гаилә хәтта токымлы этләр үрчетүгә ук кереште. Тирә-күрше кышлакларда болар үрчеткән бүлмә болонынннан алып, каравыл-сак овчаркаларына кадәр сорый башладылар. Көчекне сатып алу өчен чиратка бер ел алдан ук язылып куялар, әле анда да иң башта аванс түләү шарт. Бу иткитмәле эт үрчетүчеләрнең дан-шөһрәте якын-тирә шәһәрләргә генә түгел, хәтта күрше республикаларга ук таралган иде.

Шахтерлар китүгә, үзенең элеккеге икътисадый әһәмиятен югалткан шәһәрне, әлбәттә инде, дәүләтнең мул-юмарт тәэминатыннан шундук мәхрүм иттеләр. Вәләкин яна шартларга тиз җайлашып өлгергән халык үзен һич кенә дә кимсетелгән халәттә итеп сизмәде. Тик, шулай да, алар җәмгыятькә файда китерердәй хезмәт белән шөгыльләнмәүләрен искә төшереп, вакыт-вакыт, бигрәк тә сайлаулар алдыннан, булачак депутатларына үзләренең таләп-бурычларын, йөкләмәләрен искәртеп, шәһәргә йә завод, йә фабрика кирәк, диләр иде. Хәер, бу таләпнең гамәлгә ашмаслыгын да беләләр үзләре һәм шуна да, кул кушырып утырмыйча, хәл кадәри үз эшләре белән шөгыльләнүне хуп күрәләр иде.

## 2

Калада бер урам бар һәм ул иң төп, иң шау-шулы, иң тынгысыз, җанлы урам да түгел инде үзе югыйсә, әмма дә кичләрен, ә кайчагында хәтта төн уртасына чаклы аның бер очыннан икенче очынача музыка тавышы яңгырап агыла. Ничек шулай туры килгәндер, каладагы өч ресторанның өчесе дә шушы урамда урнашкан. Музыкаль эстафетада катнашкан сыман, бер көйдән бер көйгә күчә-күчә, урам буйлап атлыйсың да атлыйсың. Иң түрендә яшелләндерү хуҗалыгы урнашуын исәпләмәгәндә, бу урам шәһәр үзәгендәге башка урамнардан әллә ни аерылып та тормый иде. Шәһәр комитеты хуҗалыгының су сиптерүче бердәнбер машинасы шушы урамга да, инде янә төп административ биналар алдындагы мәйданга гына көнгә ике мәртәбә хезмәт күрсәтә иде. Шушы ике урам юлына, тротуарларга гына түгел, ике кунакханә каршындагы агачларга, чәчәк һәм гөл түтәлләренә дә суга тиенү бәхете эләгә иде. Мөгаен, бу урам иң унайлы-ипле урамнарның берсе булгандыр. Әмма дә халык шау-шулар тынып тормаган, утлар балкышы тантана иткән Ленин исемендәге төп урамны хуп күрә иде. Каладагы бөтен кибетләр дә, ни өчендер «Арарат» һәм «Арагви» дип аталган берәр заллы ике кинотеатр да биредә урнашкан иде. Кичләрен монда халык күп була. Калада кинога йөрергә яраталар, элеккегечә, бөтен гаиләләре белән киләләр иде. Әби-бабайларына кадәр, сеанс вакытында аларның тезләрендә йоклап китүчән оныкларына кадәр киләләр иде. Байтагының еллар дәвамында ияләнгән үз рәтләре, үз урыннары бар, читтән килгән кешегә яхшы-каттә фильмга, бигрәк тә аның соңгы сеансына эләгүләре, ай-һай, һич тә җиңел түгел иде. Каладагы халыкның күпчелеге, кем әйтмешли, «эш атлары»: кемдер көне буе үз хуҗалыгында тир түгә, кемдер җирле вак предприятиеләрдә бил бөгә, «бәйрәм» төсенә кергән затларны кинотеатр төбендә фәкать сеанс башланыр алдыннан гына күрергә мөмкин иде. Хәтта үсмерләр дә юкны бушка аударып, урамда тиктомалга җил куып йөрмиләр—өйдә болай да эш хәттин ашкан.

***

Һәр кичен урамга чыгып сәйран кылып кайтырга ярата торган бер кеше яши иде бу калада. Иң төп, иң үзәк урамнардан саналмаса да, ул нәкъ менә шушы—маршал Буденный исемен йөрткән урам буйлап йөрергә гадәтләнгән иде. Әйе, бик сирәк вакытларда гына музыка тавышлары тынып торган бу урамны ул бик тә үз итә иде. Музыка тавышлары өчен түгел, юк-юк, һич тә юк, ул аның төз буйлы көмешсу тирәкләр, мәһабәт тут, зифа чинарлар, яшь имәннәр тезелешеп буеннан-буена озата барган аулак тротуарларыннан атларга ярата. Көн саен үз вакытында су сибеп торгангамы, барча яшеллекнең, гөл-чәчкәләрнең үпкә күрекләрен иркәләүче искитмәле хуш исе бу урамның үз мохитен, үз һавасын, микроклиматын хасил итә. Үзе өчен бу һаваның никадәрле дә шифалы һәм хәтта зарур икәнлеген ул бик тә яхшы чамалый иде. Хәер, бу урамны да бит ул нәкъ менә шуңа күрә дә эзләп тапты лабаса. Тапты да, гашыйк та булды. Бирегә ул автобус белән дә килә алыр иде. Әмма дә ул нәкъ менә шушы урамнан атлар өчен җәяүләп озын юл үтә дә инде.

Ул үзе биш катлы йортта яши. Аның ише хөкүмәт фатирында торучыларны исә биредәге җирле халык каккан казыгы да булмаган бәндәләргә, ягъни мәңге эше уңмас бичаралар исәбенә кертә.

Бу урамга ул моннан бер ел элек йөри башлады. Җирле тәртип вә гореф-гадәтләрнең котырып чәчәк аткан чоры иде бу. Әйе, моннан бер ел элек аның тормышы кискен үзгәрде... Ул һәркөн кичләрен һава суларга чыга, җәяү йөри. Чираттагы йөрәк өянәгеннән соң табибләр шулай киңәш итте: һава сулап, даими җәяү йөрү фарыз, хәтта зарури!

Көн дә сәйранга чыгучы бу кешегә бер илле яшьләр чамасын бирергә мөмкин иде. Әллә ни төз-ыспай гәүдәсе белән дә аерылып тормый ул, үз яшеннән кимрәк күренүе белән дә мактана торган түгел. Әйе, аны һич тә үз яшеннән яшьрәк димәссен, киресенчә, бер биш-алты яшьне өстәргә дә була торгандыр әле ана. Үзләренең ишегалдындагы бала-чага юкка гына ана «бабай» дип эндәшми торгандыр шул инде. Хәер, ул үзе моңа бер дә үпкәләми. Кайчагында гына сагыш биләп ала анысы... Аккан судай, искән җилдәй гомер үткәнгә түгел, юк-юк... Чын мәгънәсендә бабай-бабакай була алмаганга күрә инә ул сагыш дигәннәре. Хатыны белән бала хакында никадәрле генә хыялланса лар да, Ходай Тәгалә аларга бала бирмәде шул, насыйп әйләмәде...

Озын гәүдәле, нык, эре сөякле бу кеше хәзер сизелерлек дәрәҗәдә бөкрәя төшкән, җилкәләре дә салынган. Әйтерсең лә күтәреп булмаслык дөнья авырлыгы ингән аларга. Вакыт-вакыт ул, бу авырлыктан котылырга теләгәндәй, буй-сынын, киң җилкәләрен калкытып, бераз чал кагылган башын турайта һәм нык, төз-төгәл адымнар белән юлын дәвам итә. Әгәр дә кем дә кем аның бу хәрәкәтләрен бик тә игътибар белән күзәтеп торса, яшь чагында бу адәмнең типсә—тимер өзәрдәй тазалыкка ия булуына төшенер иде. Гадәттә, табигать адәм баласының тавышы белән күз карашын гына үзгәрешсез калдыра. Бу кешенең исә талчыккан күзләрен сүрәнлек биләп алган... Югыйсә Себер якларында туып-үскән кеше ул. Ә Себер халкы таза-саулыгы, нык холкы белән дан тота. Тугыз буын бабасының исемен-атын белә ул. Гасырлар дәвамында Себер белән идарә иткән татар ханнарына барып тоташа аның нәсел җебе, шәҗәрәсе.

Халык аз йөргән аулак Буденный урамы буйлап ашыкмыйча гына атлаучы бу кеше кайсы ягы беләндер, барыбер игътибарны үзенә җәлеп иттерә иде. Кайсы ягы белән? Кием-салымы белән дияр идең—аның беркайчан да модага ияргәне булмады. Мөгаен, бу кала халкы белән ул үзе генә белгән билгеле бер ара—дистанция саклавы, башкалар белән үзе арасында күренмәс, әмма тоеп була торган бер дивар коруы нәтиҗәсендә әнә шулай үзенә җәлеп иттерә торгандыр да. Бу дивар артына ышыклануның кадерен-тәмен, кем-кем, ә менә ул бик тә шәп чамалый иде.

Әлбәттә, кала халкы аны таный. Ул үзе дә, һава сулап йөргәндә булсын, эшкә барганда булсын, таныш-белешкә йә чак кына башын иеп, йә эшләпәсен күтәрер-күтәрмәс кенә авыштырып, сәлам бирә.

Бу кеше янә дә бер ягы белән үзенә игътибарны җәлеп иттерә иде. Ашыкмый иде ул. Кайчан карама, салмак-сабыр гына, вәкарь белән генә атлавын белә. Ә инде эшмәкәрлек ыгы-зыгысына муеннан кереп чумган, чыраена бетмәс-төкәнмәс мәшәкать төсмере чыгарып, тегендә-монда чабышкан кала халкы өчен монысы да сәер хәл иде.

Төшке аштан соң эшенә кайтышлый ул еш кына юл уңаеннан китап кибетенә сугыла. Кала халкы китап уку кебек «эш калдыргыч» шөгыль белән мавыкмый, шуңа күрә дә китап кибете һәрдаим буш күренә.

Сатучы кызлар аның кибеткә керүен тәрәзәдән үк күреп алалар һәм тиз генә киштәдәге тузанны сөртеп, яңа китапларны күзгә ташланырлык урынга матур итеп тезеп тә өлгерәләр. Ләкин ул китапны бик сирәк сатып ала, әле анда да кызлар тезеп куйган киштәдән түгел... Үзенә кирәкне ул әллә каян эзләп таба. Мондый чакларда аны яңа китап белән сөендерергә теләгән кибетче кызлар гаҗәпләнүдән тел генә шартлатып куялар.

Берзаманны аның хакында: «Безнең шәһәрнең яңа килгән хакимият башлыгы икән ул» дигән сүзләр дә йөри башлаган иде. Гади киемгә киенеп үз биләмәләрен карарга чыккан гадел падишаһ хакындагы риваятьләр халыкның күңеленә тирән кереп урнашкан шул. Шәһәрнең яңа хуҗасы да

имеш, әлеге падишаһ сыман, һәммәсен дә тикшереп-барлап, һава суларга чыккан сыман гына җәяү йөри икән. Юл уңаеннан гына кибеткә кереп казылык ала, аннары шул казылыкны янәдән үлчәтеп карый имеш... Берәр автобуска утырып, соңгы тукталышка кадәр баруы да ихтимал икән. Монысы да юкка түгел. Чөнки хуҗа иртәгәсен иртүк автотрест директорын кабинетына чакыртып, бик шәпләп «мунча кертәчәк».

Ул, әлбәттә, үзенә төбәлгән кызыксынучан карашларны еш тоя, әмма дә үзен шәһәр хуҗасы дип кабул итүләрен һич кенә дә башына китерми иде. Бу хакта ул хезмәттәшләреннән ишетеп кенә белде. Белде дә, рәхәтләнеп бер көлде, һәм моны язмышының мәрхәмәтле килачәгенә юрады. Әлбәттә, бик тә кызыксынучылар аның биредәге җирле консерв заводында юк кына бер вазифаны башкаруыннан да хәбәрдар иделәр. Әмма, ни гаҗәп, алар аның бу вазифасыннан көлеп карамадылар, әле киресенчә: «гел җәяү йөрүче бу адәм элек бик тә зур кеше булган икән»—дип сөйләделәр. Аз сүзле, үз эченә бикләнгән бу адәмнең ниндидер бер сөйкемле сөяге бар иде бугай. Ашханәдә вә чәйханәдә утырганда булсын, базарда йә ләвәш, яшелчә-мазар, йә җиләк-җимеш алганда булсын—ул шуны анык итеп тоя—аны үз итәләр иде. Берәрсе: «Нинди кеше бу, кем?»—дип сораса, икенче берәүләр карашы белән күккә ымлап күрсәтә, янәсе: зур кеше. Шәрык дөньясында исә бу ике сүз бик тә зур мәгънәгә ия.

Төшке ашка ул, гадәттә, автостанция каршындагы чәйханәгә йөри. Үзе белән бер яшьләр чамасындагы чәйханә хуҗасын ул гел баш кагып сәламли, ара-тирә хәл-әхвәл сораша, һава торышы хакында бер-ике сүз кыстырып ала. Төшке ашны да ул бик тыйнак итеп китертә: ярты лагман да бер таяк кәбап, яисә ике таяк бавыр кәбабы белән бер кайнар сумса булыр. Кайчагында исә ике-өч мантый вә бер ләвәш белән дә канәгатьләнә ул. Чәйханәче малайлар аңа чәен дә, тәгамен дә һич көттермичә, шундук кап-кайнар килеш китереп бирәләр. Кәбаблары шәпләп кыздырылган, ләвәшләре алтынсу, шурпалары авызны өтәрдәй кайнар булыр. Аңа хәтта түләгәннән соң артып калган акчасын да, гәрчә биредә түләүне түгәрәкләү язылмаган кануннардан исәпләнсә дә, тиенен кадәр китереп бирәләр. Аннары ул, ашап-эчеп, урыныннан тора, төче телләнмичә генә чәйханәчегә рәхмәт әйтеп, чыгып китә. Бүтәннәр белән үзе арасында вәкарь аралык саклавын һәммәсе дә аңлый. Төче телгә күнегеп-туеп беткән чәйханәчеләр бу аз сүзле ялгыз кеше урнаштырган аралыкны хөрмәт итәләр. Әле хәтта кайчагында акчалы, бай клиентны чиратта бастырып, иң әүвәл аңа хезмәт күрсәтәләр. Алар аны бу калага очраклы рәвештә генә, вакытлыча гына килеп чыккан кешегә исәплиләр. Озакламый аны өстәгеләрнең үзләре янына—югарыга, бик югарыга менә-менә чакыртып алачакларына да ишарәлиләр иде.

### 3

Вакыт уза торды. Атналар, айлар үтте, әмма аны беркем дә беркая чакыртып алмады. Ул исә үзенең көндәлек җәяүле сәфәрләрен дәвам итте. Вакыт-вакыт аңа берничә көнгә командировкага барып кайтырга туры килә иде. Консерв заводы эшләре буенча ул йә өлкә үзәгенә, йә республика башкаласына ук юл тота. Аннан кайткач исә янадан гадәттәге җәяүле сәфәренә керешә. Ул янә сабыр-салмак адымнар белән Буденный урамыннан атлый, бер-бер артлы «Лидо», «Консуэло» һәм «Шәһрезадә» ресторданнарын узып китә һәм шунысына аеруча игътибар итә: менә кайда ул ичмасам гамьсез тормыш дигәннәре чишмә булып тибә! Югыйсә моннан берничә чакрымда гына кара тиргә батып мамык чәчәләр, чүп утап мәш киләләр, кышлакларда ачлы-туклы җан асрыйлар, мең вә мең

мәктәп укучысы, студенты-фәләне өйләреннән еракка аерылып китеп авыл хужалыгы эшләрендә тир түгә, каядыр жирне су баса, таулар тетри, ачлык, корылык, гарасат, янгыннар, яулар, кырылыш чыга... Ә биредә... Ә биредә исә һәрдаим ваемсыз бәйрәм мохите, туклык тантана итә. Әле кемгәдер Аурупа География жәмгыятенен шәрәфле әгъзасы булуга караганда, «Лидо» ресторанына даими йөрү дәрәжәлерәк тә санала торгандыр.

Вакыт Галижәнапләренең искитмәле тиз агышын, мөгаен, һәркем чамалый булыр. Әмма дә тормыш арбасыннан төшеп калуынны сизмәвең дә ихтимал. Шулай да, акрынлап кына, вак-төякләре белән үзен сиздерә башлый икән ул... Бермәлне яраткан урамы буйлап атлаганда моны ул да сизде. Рестораннан агылган музыка тавышына, жырга игътибар итте ул. Бу музыка-жырларны өч көн рәттән тынлап йөрде дә, үзе яшь чагында кичергән моңнарны ишетмәгәч, шундый нәтижә ясады: «Үзгәргән дөнья, үзгәргән.» Анын хәтта кәефе кырылды. «Айдан төшкән кеше ахрысы мин»,—дип гомер булмаганны, үз-үзенә әнә шундый бәя дә биреп ташлады.

Хәер, ул яшь чагында да музыка белән, гәрчә студент кичәләренә һәрдаим йөрсә дә, алай әллә ни мавыкмады. Бүгенге яшьләр, әнә, кырыкмаса-кырык төрле көй тынлый алалар. Анын дәверендә көйләр азрак иде кебек. Яшьлек чорынын ул тансык көй-аһәннәре әле хәзер дә хәтерендә анын, хәтерендә... Әмма алар бүген янгырамый шул инде. Менә шуна күрә дә тормыш арбасыннан төшеп калганлык халәтен уяталар да инде алар.

Әнә шулай үз уйларына чумып һава сулап йөргәндә, ул, бер көй ишетеп, сискәнеп китте. «Шәһрезадә» ресторанынын ачык тәрәзәләреннән агыла иде бу көй. Үзе таныш та кебек. Әллә ялгышамы? Өзек-төтек ритмлы, колакка «дан» да «дон» бәрүче замана көе ич бу! Әмма дә ләкин бу көйдә үзәкләрне өзеп-өзеп ала торган ниндидер бер таныш чалым да бар. Валлаһи, бар!

Ул, әлеге таныш аһәнне эзәрлекләп, шактый гына вакыт ресторанның ачык тәрәзәсе төбендә басып торды. Ниһаять, оркестр тынып калды.

Ул юлын дәвам итте, һәм бара-бара, үзе дә сизмәстән адымнарын ешайтты: туктале, тукта, теге көй янә ишетелә түгелме соң?! Әйе, нәкъ үзе! Бу юлы көй «Лидо» ресторанынннан агыла иде. Ул, ирексездән, елмаеп жибәрде: сон, әлбәттә, замана шлягеры ич бу, анын бер рестораннан икенчесенә күчүе һич кенә дә гажәп түгел: мода шаукымы. Тик менә шунысы гажәп: атлаган саен, ерагайган саен әлеге көй ачыграк ишетелә сыман иде. «Һа-ай, шайтан алгырысы, картаям ахрысы, дип йөргәндә генә колак шәрифләре сизгерләнеп, ачылып китте бугай»,—дип уйлады ул. Сон, дөрестән дә, менә хәзер... Менә хәзер саксофон авазы ишетеләчәк, аннары исә көй барабан вә чан-тәлинкәләргә бәргәләү белән, үрсәләнә-үрсәләнә, югарыга сикерәчәк.

Һәм, ниһаять, ул исенә төшерде.

Сон, әлбәттә инде, әлбәттә, Элвис Пресли ич бу, «Тәүлек буе рок»! Еракта, бик еракта калган мизгелләр—студент чаклар...

Әлеге көй ишетелгән «Лидо» ресторанына килеп керүен ул сизмәде дә. Колаклары боердылар, аяклары китерделәр.

Кичке ресторан тормышы әле кыза гына башлаган, шәраб вә музыка да үз «эш-вазифа»ларына әле генә ныгытып керешкәннәр иде. Чамадан тыш янгыравык, хәтта шашып көлү тавышлары, кызулана-кайнарлана гына баручы гәп сөрешләре, тирә-юньне биләгән шатлык вә куаныч тулы чырайлар—кыскасы, боларнын һәммәсе дә үзенә күрә бәйрәмне хәтерләтәләр иде. Гәрчә зур тәрәзәләр киерелеп ачып куелса да, биек түшәмдә зыр-р килеп әйләнгән алагаем жилләткечләр биредәге тәмәке-челем төтенен куып чыгара алмыйлар, кем әйтмешли, төтенгә балта элеп куярлык иде.

Төтен аша ул залны күзәтте. Зал—шыгрым, буш урыннар күренми. Инде

борылып чыгып китәм дигәндә генә аның янына метрдотель килде һәм итагатьле вә әдәпле генә исәнләшеп, кунакны зал түренә чакырды.

Киң-иркен залның иң түрендә, мәрмәр колонна янәшәсендә затлы савыт-саба тезелгән, «Буш түгел» дип язу куелган ике кешелек кенә җыйнак өстәл тора. Зал хуҗасы аңа әнә шул өстәлне тәкъдим итте. Гәрчә мәрмәр багана күләгәсендәрәк урнашса да, бу өстәл артыннан бөтен залны күзәтергә була һәм аеруча эстрада мәйданчыгы уч төбендәгедәй күренә иде. Мизгел эчендә официант та килеп җитте һәм кунакның меню каравын сабыр гына көтеп тора башлады.

Җирле халыкның эшмәкәрлек белән шөгыльләнүе аның өчен сер түгел иде. Шуңа күрә дә, менюда шампиньон, бөдәнә ите кебек затлы нигъмәтләрнең дә булуы аны һич тә гаҗәпкә салмады. Дөрес, аның әле бу ризыкларны моңарчы үз гомерендә бер тапкыр да татып караганы юк иде һәм инде менә хәзер, җае чыккач, тегесенә дә, монысына да заказ бирде, янә өстәп, бер чәйнек яшел чәй дә сорады.

Официантны озаткач, ул залны күзәтергә кереште. Аның игътибарын чәчәкләр куелган бай, зиннәтле банкет өстәле артында утыручы дүрт ир-ат шундук җәлеп итте. Шәп вә затлы киенгән бу адәмнәргә утыз биш-кырык яшьләр чамасы. Куллары белән кискен хәрәкәтләр ясый-ясый, болар ни-нәрсә хакындадыр бик тә кызып бәхәсләшәләр иде. Өстәлләрендәге төрледән-төрле бай кабымлыкларга, эчемлекләргә караганда, болар әле янә кемнедер көтәләр иде булса кирәк. Гәрчә залның һәр тарафында шампан шәрабе, кем әйтмешли, елга булып акса да, элеккеге прокурорның игътибарын ни өчендер нәкъ менә шушы төркем җәлеп итте. Ни өчен?!

Банкет өстәле артындагылар да аның кызыксынучан карашын сизеп алдылар. Югыйсә, күрше өстәлдәгеләрне ачыктан-ачык күз белән эзәрлекләп утыра торган беркатлы бәндә дә түгел бит инде үзе. Хәзер исә менә карашны читкә боруы да, ничектер, унайсыз.

Ул да булмады, тегеләрнең дүртесе тиң кинәт кенә урыннарыннан торып, аңа—элеккеге прокурорга—сизелерлек дәрәҗәдә баш иеп, сәлам бирделәр. Ул да башын кагып куйды, әмма урыныннан кузгалмады. Кемнәр икән соң болар, каян килгән ихтирамлылык билгесе икән соң бу? Бәлкем, ялгышканнардыр? Тик дүрт кеше берьюлы ялгыша аламы соң? Юк, юк... Еллар дәвамында туплаган тәҗрибәң ни дип әйтә?—Хәтер сандыгынны актар, ул тарафка карамыйча гына, фотосалонда төшерелгән сурәтләрне барлагандай, хәтереңдәге сурәтләрдән бу төркемне бүлдыр! Кемнәр икән соң шәп киенгән, тук чырайлы, һәр ым-хәрәкәтләреннән үз-үзләренә какшамас ышаныч бөркелеп торган бу бәндәләр? Кемнәр?! Үсеш, дан-дәрәҗә баскычларыннан нык адымнар белән күтәрелүче хуҗалык җитәкчеләреме, югары урындагы түрәләрме? Һәрхәлдә, ни генә димә, хакимият даирәсенә хас килеш-килбәт вә чалымнарны кем-кем, ә менә элеккеге прокурор бу бәндәләрдә тиз абайлап алды.

Мөгаен, алар белән элек—узган тормышында—республика башкаласында үткәрелгән пленум һәм киңәшмәләрдә дә очрашканы булгандыр аның. Тик менә кайсы өлкә-төбәктән, кайсы каладан болар? Типтереп яшәүче «тормыш хуҗалары», замана байлары ошбу каланы юкка гына «Лас-Вегас» дип атамый торганнардыр инде. Чөнки дә бу кала ике өлкә чигендә урнашкан, шәп юллар, шәп машиналар булганда, өлкә үзәкләреннән «Лас-Вегас»ка килеп җитү хәзер берни дә тормый. Димәк, шулай булгач, җирле рестораннарның көн саен шыгрым тулы булуы һич кенә дә гаҗәп хәл түгел. Бирегә хәлле кешеләр килә, аларга үз өлкәләрендә күзгә күренеп, типтереп, акча туздырып йөрү килешми дә, ярамый да. Ә «Лас-Вегас»—нейтраль, уртак нокта.

Бу фараз-гөманнары элеккеге прокурорны бер дә шатландырмады. Затлы банкет өстәле артында утыручы бу дүрт кеше кемне көтә? Бәлки заманында аның үзе белән дә аралашкан, хәтта дустанә мөнәсәбәттә торган бәгъзе затныдыр? Әгәр дә шулай икән, әлеге очрашудан, гәп-әңгәмәдән котылып булмаячак. Тик аның элеккеге тормышында аралашкан беркемне дә очратасы килми иде бүген. Ул, озын-озак сузмады, тиз генә капкалап алды да, биредән чыгып китү ягын карады. Башка вакытта булса, ул үзен янә бер чәйнек яшел чәй эчү ләззәтеннән һич тә мәхрүм итмәс иде. Әмма чын кытай чәе аның тегендәге, үткән тормышында калды шул инде.

***

Өенә кайткач та ул, гадәттәгечә, йөрәк даруын капты, бер унайдан йокы даруын да эчмәкче иде дә, әмма кире уйлады—эчсә, эчмәсә дә, бу төндә аңа барыбер йокы кермәячәк. Һәм ул ялгышмады.Әгәр дә арыганлык, төшенкелек һәм өянәкле йөрәге үзен сиздермәсә, мөгаен, ул, киенеп, янә урамга чыгар һәм төнге кала буйлап сәйран кылыр иде. Йокысызлыктан интеккән чакларында ул гел шулай итә иде. Аның йокысызлыгы тәүге инфаркт белән бергә башланды. Хәер, кайсысы беренчерәк—инде хәзер әйтеп тә булмый торгандыр. Йокысызлыгына ул әллә ни әһәмият тә бирми, әле, киресенчә, аны ул үз-үзенә анализ ясый алучы, уйлый белүчеләрнең өлешенә тигән көмеше кебегрәк кабул итә иде. Аның тормышында хәзер нәкъ менә шундый—уй-гамь дәвере, нәтиҗәләр чыгара торган чор башланды да инде. Шулай туры килде. Кайбер йокысыз төннәрдә ул әллә нинди тирән уйларга чума ки, яшь чагында ук йокысызлыкка дучар булмаганына хәтта үкенеп тә куя.

Бүген исә аның уйлары әлеге дә баягы «Лидо»га, анда янгыраган теге көйгә әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта. Яшьлек елларында ук гадәти хәят арбасы тәгәрмәчләрен бөтенләй башка юнәлешкә борып җибәрергә мәҗбүр иткән көй ләбаса ул!

Ул чагында, моннан утыз еллар чамасы элгәре, безнең бию мәйданчыкларында бик тә маһирлар ярым тыелган рок-н-роллга һәм буги-вугига биергә керештеләр. Элвис Преслидан тыш, джаз җырчысы Джонни Холидейга да үлеп гашыйк, вә мөкиббән иде алар. Студентлык елларының музыкаль мавыгуларыннан нәкъ менә шушы «Тәүлек буе рок» истә калган. Истә калырлык сәбәбе дә бар иде шул, бар. Менә хәзер, бүген, инде ничәмә-ничә еллар үткәч тә—бәгыреңне теләә торган сәбәп ул, гәрчә бүген аннан башка да күңел тулы мөлдерәмә сагыш, сагыш...

Аның инде күптәннән яшьлек хатирәләренә бирелгәне юк иде. Мөгаен, моның өчен яшьлекнең куанычлы вә кызыклы мизгелләрен күзаллау фарыздыр. Әмма, ни гаҗәп, Әмирхан студент елларындагы ни якты-бәхетле көннәре белән дә, яшьлегенең асыл мәгънәсен сыйдырган олы мәхәббәт-гыйшкы белән дә күңелен юата алмый. Әйтерсең лә, тормыш галиҗәнапләре моның өчен аңа вакытның үзгә бер өлешен вәгъдә итеп: «син, бахыр, сабыр бул, килер ул көн һәм синең дә мавыгулардан, уңышлардан вә чын сөю-сәгадәттән торган чорың башланыр!»—дигәндер. Хәер, вәгъдә—иман, дигәндәй, аларын да Әмирханга күрергә вә кичерергә насыйп әйләде. Баштарак ул болай дип уйлады: кемнәрдер бик иртә ачыла да, аларның яшьлек кичерешләре гомер буена күңелдә авыр таш булып кала. Кемнәргәдер исә бу кичерешләр соңлабрак, көттеребрәк кенә килә дә, озын-озак ләззәти халәткә сала.

Ерак-еракта калган яшьлеген искә төшергәндә, ул үз-үзенә янә бер ачыш ачты: үткән көннәр ерагайган саен, аларны ачыграк һәм хәтта үтәли күрәсең, үзең теләгән ишекләрне ачарга ниятләп бәргәләнгән, тилмергән

вә үрсәләнгән чакларыңны искә төшереп сагышланасың. Бүгенгеннең биек каланчасыннан кычкырасың килә: типмә бикле ишеккә, әнә бит, әнә—янәшәдә генә үзгәсе синең ачып кергәнеңне көтеп тора!—Вәләкин синең үз ялгышларың, үз ачышларың—алар синеке генә һәм шунысы белән бәһа биргесез кыйммәт тә. Әгәр дә Вакыт Галиҗәнапләре тора-бара синең хаклы икәнлегеңне дә расласа—бик шөкер, соң булса да, канәгатьләнү хисе кичерерсең. Ә инде, киресенчә, гаеп синдә, хаксыз икәнсең—анысы да кайчан да булса бер аяусыз рәвештә ачыкланыр. Әнә шул гаебең өчен үзең түләсәң—әле мең шөкер. Әгәр дә ки синең гаебең өчен башкалар түләсә? Гаделлек хакына яшәп, гаделлек өчен көрәшүеңә инанган килеш, кылган гаебең өчен башкаларның түләвенә ни дип җавап бирерсең!

## 4

Ул укыган дәвердә студентларның төзелеш отрядлары юк иде әле. Ул елларда Казакъстанның чирәм җирләрен эшкәртергә Советлар Союзының төрле төбәкләреннән студентлар агыла иде. Һәр җәй саен студентлар казакъ далаларында юллар, колхоз һәм совхозларда торак йорт, хастаханә, мәктәпләр, ындыр табаклары төзиләр, су алырга артезиан коелары бораулыйлар, кирпеч заводында кирпеч сугалар...

Беренче курстан соң Әмирхан Акмулла өлкәсенең төньягына эшкә эләкте. Кышның зәмһәрир салкыннары белән, көзге зәһәр җилләре белән, җәен исә чыдап булмаслык чиллә вә корылыгы белән дан тота торган як иде бу. Җәй буена сыңар тамчы яңгыр да төшмәгәнлектән, мәрхәмәтсез кояш нурларыннан янган-көйгән җир, әйтерсең лә, тәмам үле хәлдә иде. Иксез-чиксез киңлекләргә җәелеп киткән даладан көн дәвамында юл тотсаң да, кеше яшәгән торакны таба торган түгел. Нәкъ менә шул чагында алар илебезнең бинигһаялеген чын мәгънәсендә тойдылар.

Шулай көннәрдән беркөнне Әмирхан шофер белән өр-яңа «газик»та район үзәгенә азык-төлек алырга бардылар. Базада шактый ук тоткарланырга туры килде. Төн житәрәк кенә, инде тәмам караңгылык капкач кына юлга кузгалдылар.

Июль-август айларында казакъ далаларында аерата еш була торган күзгә төртсәң күренмәслек дөм караңгы төн иде бу. Юл такыр булган кук, даласы да такыр, димәк, кай тарафка юнәлсәң дә—юл... Алар адаштылар. Озын-озак кына урап-әйләнеп йөри торгач, туктап, таң атканын көтәргә булдылар. Әмма кинәт машина фаралары яктысы ерактагы корылмаларны яктыртты. Җанына җылы йөгергән шофер, шатланып, газга басты.

Куркыныч урын иде бу... Бер-берсенә сыланып диярлек казылган озын-озын берничә рәт землянка, әйтерсең лә, чиксезлеккә сузылган. Хәрби кинофильмнардан гына күреп белгән күренеш. Инде ишелә башлаган җир асты юллары җәнлек өнен хәтерләтә; анда-санда эленеп торган кыек ишекләргә йә яндырып, йә буяу белән тәртип саннары сугылган. Әйе, кайчандыр биредә чыннан да «тәртип» хакимлек итүе хакында саннар гына түгел, ә тыгыз землянка рәтләре аралап торучы киң «урам»нар да сөйли. Үзәктә—киң мәйдан, плац. Кайчандыр аны шул дәрәҗәгә җиткереп таптаганнар, такырайтканнар ки, инде ничәмә-ничә еллардан соң да биредә сыңар үлән бөртеге дә тишелеп чыга алмаган. Мәйдан читендә исә тактадан корыштырган иске барак үзенең имәндергеч буш тәрәзә—күзләре белән ыржаеп утыра. Заманында ашык-пошык кына ябылган түбәсе, сырты сынган җанвардай, ярым ишелеп төшкән. Фара яктысында ары таба сузылып киткән чәнечкеле тимерчыбык коймаларны да шәйләргә була иде. Кинәт, ут яктысыннан һәм мотор тавышыннан өркеп, якындагы землянкадан бер көтү шакал өерелеп чыкты да, җан өшеткеч итеп улый-улый, караңгылыкка

кереп тә югалды. Гомерендә тәүге мәртәбә шушындый күренешкә тап булган Әмирхан юлдашына гаҗиз карашын төбәде һәм ачынып:

—Кая эләктек без?—диде.

—Кайчандыр бу җирләрдә халык дошманнары өчен төрмә булган, дип сөйлиләр. Теге, утыз җиденче елны кулга алынганнарны бирегә тотканнар.—Шулай диде дә шофер, карангылыкка ымлады.—Якында гына карьер белән кирпеч заводы булырга тиеш. Кызуга чыдамлы махсус кирпеч ясаганнар. Карьерда—зираты да. Бә-әк зур зират, дип сөйлиләр...—Шофер, ирексездән көрсенеп куйды. Гәрчә чирәм җирләрдә инде икенче елын эшләсә дә, күрәмсең, аның да бирегәге күренешкә тәүге тапкыр тап булуы иде ахрысы.

Дөм каранғы тынчу төннең төбеннән, әллә инде күмелеп бетмәгән каберләрдәнме—һәрхәлдә, аларга шулай тоелды—черек исе, мәет исе, үлем исе килә иде.

Коточкыч, иманкергеч халәттән котылырга теләгәндәй, «газик» алга ыргылды, машина да, аның эчендәге ике яшь адәм баласы да, калтырана-калтырана, ошбу үлем базыннан хәл кадәри тизрәк ерагаю ягын карадылар. Һәм, ни гаҗәп, бер-ике сәгатьтән соң алар таныш юлга килеп чыктылар.

Соныннан бу төнге хәлләр турында ни шофер, ни Әмирхан—берсе дә сүз кузгатмады. Югыйсә, элеккечә үк, атнага ике мәртәбә алар шул ук базага азык-төлек алырга барып йөрделәр. Әмма дә, энгер-менгер эленә башлауга, юлга чыгарга җөрьәт итмәделәр, район үзәгендә кунып калу ягын карадылар.

Әйе, Әмирхан бу вакыйганы беркемгә дә сөйләмәде. Тик шәп-шәрә дала түрендәге бу күренеш—кешеләр өчен казылган җир асты өннәре—аның күз алдыннан китмәде. Кайчагында аңа боларны ул төшендә генә күргән сыман да тоела. Тик, ни кызганыч, аек аңы-акылы алай түгеллеген тәкрарлый иде.

Соныннан ул шунысына бик аптырады: үзен бар иткән ата-анасының язмышы белән әлеге сәяси тоткыннар зинданы арасында нинди уртаклык ята? Ни өчен соң әле бу вакыйга аңа шулай көчле тәэсир итте?! Иксез-чиксез кыргый дала, җир асты өннәре, каберләр, һәм—аның ата-анасы... Монда нинди уртаклык, бәйләнеш булуы мөмкин? Ә шулай да... Бу хакта күбрәк уйланган саен, аның фикере ныгый барды: балчык карьерындагы каберлектә аның әнисе, йә булмаса, әтисе күмелүе дә ихтимал ич! Икесенең берсе. Чөнки ир-ат һәм хатын-кыз мәхбүсләрне аерым төрмәләрдә саклаганнар. Инде менә, ниһаять, Әмирханны тәкъдир ата-анасының югалган эзләре буйлап бирегә китергәндер. Әлеге уйларын ул беркемгә дә, хәтта бергә эшли торган студент дусларына да әйтмәде. «Атам да, анам да—халык дошманы»,—дип, бала чагыннан ук куркып үскәнгә, әлеге курку еллар үткәч тә кимемәде. Хәтта аларның исемнәре акланып, аларга халык дошманы тамгасы сугуның бинһая зур фаҗигале ялгыш икәнлеге ачыклангач та кимемәде бу курку. Чөнки ул аның канына ук сеңгән. Бу бетмәс-төкәнмәслек курку, бүтәннәр алдында кимсенү хисе егетнең бәгырен, вөҗүден кимерә, аягында нык басып, үз-үзе булып калырга комачаулый иде.

Мөгаен, чордашларының күбесе, һай, бик күбесе өчен ошбу курку хисе гомерлек юлдашка әверелгәндер. Соң, үзе дә еш кына—балалар йортында чагында, флотта хезмәт иткәндә, университетта укыганда, мәсәлән, аның үзенә сабакташы Гәрәйнең хаксыз хөкемдары булырга туры килгән комсомол җыелышында—кыскасы, гомеренең иң кискен вә текә мизгелләрендә ул һәрдаим йөзенә бәреп сорау бирүләрен көтә иде: «Кем синең ата-анаң? Халык дошманнарымы? Акландылармы? Бәлкем, аларны да, һәммәсе белән бер очтан, уптым-илаһи, тикшереп тормыйча гына, ялгыш аклаганнардыр?»

Әгәр дә ки бу сорау маңгаена бәреп әйтелсә, ни диеп җавап биргән булыр иде икән? Ул заманда бу турыда—кем гаепле дә, кем гаепсез—алай сүз куертулар юк иде. Төрмәләрдән, сөргеннәрдән кайтучылар үзләре дә бер сәбәпсезгә, теләсә кемгә бу хакта сөйләп йөрмәделәр. Менә ул да, Әмирхан Азлархинов та, теге төндә шоферга бер сүз дә әйтмәде. «Биредә, мөгаен, минем ата-анам да һәлак булгандыр, шушында күмелгәндер...»—дияргә теле әйләнмәде. Әмма дә ул төн аның өчен эзсез генә юкка чыкмады, киресенчә, янәдән ул тирәләрне барып күрү теләге көчәйде генә. Зонадагы «урам»нар буйлап атларга, плац-мәйданчыкта басып торырга, землянка-өннәр эчен күрергә, төртсәң аварга җиткән баракка керергә теләде ул. Үзен бар иткән затларның соңгы эзләре шунда, фәкать шунда гына сакланадыр шикелле тоела иде аңа.

Һәм менә, көннәрдән беркөнне, район үзәгеннән кайтышлый, базардан бер кочак гап-гади кашкарый чәчәкләре сатып алды. Шоферга исә: «Кичен күрше совхозга кызлар янына барам»,—дип аңлатты һәм төнгә машинасын биреп торуын сорады, чөнки, ни генә димә, иксез-чиксез чирәм җирләрдән җәяү генә тәпиләве бер дә җиңел вә күңелле эш түгел.

Кайткач та, кызлар янына барырдай көяз-фырт киемнәрен киеп, кашкарыйларын кыстырып, машинага утырды да, далага чыгып та китте. Шофердан үзенә кирәкле юлны сиздермичә—читләтеп кенә булса да сорарга җөрьәт итмәде ул.

Теге урынны Әмирхан далада эңгер эленгәнче үк эзләп тапты. Ишелеп бетә язган кирпеч заводы белән аның янәшәсендәге бинаһая зур карьерны да күреп алды. Карьерның бер өлеше каберлекләрдән тора иде. Күзгә янгырларда инде шактый ук утырган, җиргә сеңгән рәт-рәт бихисап калкулыкларнын ичмасам ник берсендә исем-фамилия, сан, тамга булсын! Егет аларга берәр кашкарый салып чыгарга керешге. Кочак тулы чәчәген ул бик тиз таратты. Һай, монда бер түгел, ун да түгел, мең кочак кашкарый кирәк ләбаса!

Аннары, ашыкмыйча гына, алты «урам»ның барысын да йөреп чыкты, иң зур һәм иң караңгы землянка—өнгә дә керде, азактан такыр плацта басып торды. Китәр алдыннан, ядкарь итеп ни дә булса алырга уйлады. Берәр җиз төймә, тәлинкә, кашык, шәм төпчеге—ни бар? Вәләкин, боларның берсенә дә юлыкмагач, баганалары авышкан чәнечкеле тимер-чыбык коймадан күгәреп беткән бер кисәк тимерчыбык сындырып алды. Гомере буе саклар өчен!

Ул кузгалганда тәмам караңгыланган иде инде. Машинасын кабызып, ике чакрым да китмәде, кире борылды, барак янынарак барып туктады. Имәндергеч, котсыз баракның төрле почмакларына бензин сибеп чыкты да, шырпы сызды. Ут, ялкын, учак күкне-һаваны явыз көчләрдән арындыра! Мәҗүсилектән ислам диненә дә күчкән бер ышану бу. Шуңа күрә дә, зират вә мазарлыкларда кайчагында учак яндыралар. Биредәге котсыз, җанны парә-парә телүче күренешне хәл кадәри юк итү теләге дә көчле иде егеттә.

Ул, юлга чыгып, ерагая барган саен, иксез-чиксез даладагы учак зурайганнан-зурая гына сыман иде.

***

Университеттагы тормышының беренче елында ике ай арасында булган ике төп вакыйга иде бу: башта—комсомол комитеты җыелышы, аннары—Акмулла даласындагы янгын. Тегесе дә, монысы да Әмирханның күңелен телеп, йөрәген яндырып үтте.

Төнге дала уртасында дөрләп янган баракны күзәткәндә, ул әле үзенең кимсенүләр комплексыннан бөтенләйгә арынуын чын мәгънәсендә тоеп,

анышып та бетермәгән иде. Анысын ул соңрак төшенер. Моннан ары анкеталар һәм «ата-анаң» графасы алдында коелып төшмичә, ачык күңелле, аралашучан вә ихлас кешегә әверелүен дә аңлар.

Нәкъ менә бирегә, казакъ далаларында иптәшләре белән «Жана жол»—«Яңа юл» совхозына сарык абзарлары салганда, ана чын мәгънәсендә гамь керде. Ул үзе, ата-анасының язмышы, «дөнья—куласа»дагы урыны хакында фикер йөртте. Беренче вакыйганы—фамилиядәше, сабакташы Гәрәйне хөкем итүләрен дә ул онытмады. Әйе, нәкъ менә—хөкем! Гәрчә, комсомол комитеты утырышы» дип аталса да, хөкем итү иде ләбаса ул. Кем белә, бәлки аның ата-анасына да, әнә шулай, үз-үзләрен яклау, яисә башкалар тарафыннан яклану хокукыннан мәхрүм итеп, тикшерүсез-нисез генә хөкем карары чыгарганнардыр? Шулайдыр. Ә хөкемдарлары кемнәр булды икән? Кануннарны изге санаучы, гыйлемле, гомер буе туплаган тормыш зирәклеген вә гыйбрәтләрен чал чәчләре белән аклаучы кешеләрме? Әллә инде кичәге тире жыючы вәкилләр хөкем итте микән? Бик мөмкин.

Ә менә курсташларын—музыкаль мода тарафдары Гәрәйне алар үзләре—комсомол комитеты әгъзалары белән ничек хөкем иттеләр соң? Менә син үзең, Әмирхан, өйгә дә, рәешкә дә бердәнбер ыштаның булган килеш, моданың ни-нәрсә икәнен дә чамаламаган башың белән ни өчен музыканы хөкем итәргә алындың? Соң, «буржуаз», «зарарлы», «бозык», «әхлаксыз», «таркатучы»—боларны чын музыкаль гыйбарәләр дип атап буламы соң?! Ә бит комсомол жыелышының төп доклады шушы сүзләрдән генә тора иде. Нинди музыка кешене чын мәгънәсендә кеше итә, аңа шифалы йогынты ясый, шәхес итеп үстерә—боларын белә идеңме?!—Юк...

Әмма никадәрле генә чит илнең заманча, модалы ритмнарын һәртөрле жыелышларда пыр туздырып сүкмәсеннәр, тыймасыннар—ул музыка барыбер үлмәде бит. Ул беркемгә дә буйсынмый, чын музыкага аңа чикләр юк!

Әлбәттә, син инде хәзер, саллы тормыш тәжрибәсе туплаган шәхес буларак, музыкаль әсәрнең язмышын билгеләргә, хөкем итәргә алынмыйсың. Ә ул чагында?

Ул чагында хөкем ителгән жырлар менә хәзер, бүген дә, утыз елдан соң да яңгырыйлар. Алар онытылмаган. Чын, асыл жырлар—мәңгелек!

Ә ул чагында, ни-нәрсә хакында сүз йөрткәнеңне дә асылда аңламаган килеш, иптәшеңне «чит музыканы пропагандалаган» өчен хөкем иттең. Югыйсә, аның бар «гаебе»—студе нтлар кичәсенә рок-н-ролл көйләре язылган тәлинкә алып килүендә генә иде. Моның өчен Гәрәйне, комсомол жыелышы фикеренә таянып, университеттан да куулары ихтимал иде. Әмма Гәрәй үзе китте. Шул жыелыштан соң. Ә жыелыш азагында ул, «мондыйларга безнең арада урын юк!»—дип кычкырулар тынгач та, сүз сорады. Аңа сүз бирделәр.

—Сезнең чыгышларны мин игътибар белән тыңладым,—дип башлады сүзен Гәрәй Азлархановъ.—Үзем өчен кайбер нәтиҗәләр дә ясадым. Алга табан мин сезнең белән укый алмаячакмын. Бүгенге бу комсомол жыелышы алдан ук хөкем карары чыгарылган суд утырышын хәтерләтә. Теләсә нинди рок-н-роллардан да йөз тапкырлар жинаятьчелрәк эшкә тиңлим мин моны. Без... Сез—булачак юристлар лабаса. Менә шунысы куркыныч. Сез мине башкаларга охшамаган өчен, бүтәнчә булган өчен хөкем иттегез. Әйбәтме мин, әшәкеме—хикмәт анда түгел. Сезгә бит гомер буе үзегезгә охшамаган, бөтенләй ят кешеләрне йә якларга, йә хөкем итәргә туры киләчәк. Миңа охшамаган, димәк, бу—чит кеше, гаепле кеше—шулмы сезнең

мантыйгыгыз?! Менә бит хикмәт нидә! Менә хәзер генә, үзем гаепләнүче буларак (тик шунысын гына төшенмәдем—минем гаебем нидә)—мин бер нәрсәне бик яхшы аңладым. Нәрсәнеме? Үзебезнең бөтен гомеребезне багышларга җыенган бу һөнәр—гаять житди, утә җаваплы вазифа. Мин үземне, мәсәлән, башкаларны хөкем итәргә әхлакый яктан әзер түгел, дип исәплим. Ә моннан башка исә гадел хөкем мәнфәгатьләренә тугры хезмәт итү мөмкин түгел, хәтта бу—җинаять. Юридик факультетта укуымны ташлауның төп сәбәбе дә әнә шунда.

Шулай диде Гәрәй.

Югыйсә бит, һәммәсе дә Гәрәйнең университеттагы беренче май кичәсенә Элвис Пресли җырларының язмасы язылган тәлинкәне, шулар арасында, әлеге дә баягы «Тәүлек буе рок»ны алып килүеннән башланып китте.

Утыз елдан соң Буденный урамында дөнья шаулатып яңгыраган бу көй прокурорның хатирәләрен анартканнан-анарта гына барды.

Әле укырга кергәнче, флотта эсминецта хезмәт иткәндә үк ул үз-үзенә сүз биргән иде, ант иткән иде—һичшиксез юрист булырга, гомерне гаделлек өчен көрәшкә багышларга! Акмулла даласында үзе кабызган янгыннан соң ул, әлеге антын исенә төшерде һәм бер нәрсәне аңлады. Бер теләк кенә, гәрчә ул чын, ихлас, пакъ вә садә булса да, житми икән, һай, житенкерәми икән шул. Чын юрист, гаделлек сакчысы булу өчен бишлегә укып, кызыл диплом алу гына да житми. Гыйлем белән бергә шәхес тә формалашырга тиеш. Кирәк чагында «юк» дип әйтә ала торган шәхес. Үз вакытында ихлас күнелдән «юк» дип әйтә алган кешенең генә намусы чиста кала. Ин мөһиме—шул! «Юк!»—дип әйтә алмыйча, кемгәдер тәлинкә тотып, ялагайланып, булдыра алмаган эшенә керешүчеләр югарырак күтәрелгән саен, алардан чыккан бәланең дә чиге-күләме зурая гына бара.

***

Җәяүле сәйраннан бүген иртәрәк кайткан Әмирхан үзенең бу төндә йоклый алмаячагын бик яхшы белә иде. Инде йорт тәрәзәләрендә утлар сүнде, кала тузанын басып, төн вә таң сафлыгы—чык төште.

Йокысызлыктан интеккән ир әрле-бирле йөренде, әле кухняга, әле бүлмәсенә керде. Кабинеты да, ятагы да—шушы бер бүлмәдә. Ул әле бер тәрәзәдән, әле икенчесеннән төнге ишегалдына бакты, сыек кына төшкән ай нурында ул ишегалдының котсызлыгын, ташландыклыгын искәрде. Чүп-чар өемендә актарынган эт-мәчеләрне күзәтте. «Бу йортларда яшәүчеләрнең һәммәсе дә—вакытлыча торучы кешеләр, хәер, юк-юк, транзит пассажирлары болар,—дип уйлады мескен йортларга карап.—Менә-менә чемоданнарын эләктереп, каядыр кузгалып китәргә торалар. Әмма кая? Кемгә кирәк алар анда?» Беркем дә беркая китмәячәк һәм китәргә җыенмый да. Моны прокурор үзе дә яхшы белә. Тик менә каян килгән битарафлык соң бу кешеләрдә? Язмыш һәм табигать тарафыннан бүләк ителгән бердәнбер гомереңне син шушылай әрәм итәргә тиешсеңме?!

Йокысызлыктан интегүче ирнең уйлары бүгенгедән үткәнгә күчте, еракта калган студент елларына янә әйләнеп кайтты. Күптән болай булганы юк иде. Ул үзенең яшьлеген, эшендәге уңышларын—һәммәсен-һәммәсен, көнен-көнгә аерып дигәндәй, исенә төшерә башлады. Ул чоры үзенең төсләре, исләре, шау-шуы вә аһәңе белән аның хәтерендә яңара иде.

Әйе, өченче каттагы кысан гына буйдак өендә төне буе ут янып чыкты, өй хуҗасы өчен чыннан да үтә мөһим вакыйгага куера иде анда.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## Лариса

### 1

Өченче курсны тәмамлаганда, Әмирхан Ликургнын дәүләт төзелеше турындагы хезмәтләрен һәм «Римнын хосусый хокуклары»н өйрәнеп бетерде. Моның өчен ул махсус латин телен өйрәнде. «Рим хокуклары» цитаталарга, философ һәм шагыйрьләрнең канатлы сүз вә гыйбарәләренә шулкадәрле дә бай иде ки, мавыгып укый торгач, егет үзе өчен антик әдәбиятны ачуын сизми дә калды. Борынгы дәвернең фикер ияләре һәм тарихчылары белән танышты. Әле котырып китап уку чоры башланмаган иде, шуна күрә дә, университет китапханәсенең уку залында бер чиратсыз-нисез Монтеньнең өч томлык «Тәҗрибәләр»ен укып чыкты. Плутарх, Цицерон, Фрейд һәм Шопенгауэр әсәрләрен исә букинистика кибетләреннән сатып алды. Шәхси китапханәсенең тәүге китаплары иде алар. Балалар йортында үсү, флотта хезмәт итү аны төгәл-катгый көн тәртибенә өйрәттеләр. Анын һичшиксез тормышка ашарга тиешле теләк, ният, максат вә гамәлләре өчен, киләсе атнанын һәр сәгатен-минутын исәпләп куйган булуына да карамастан, тәүлекнең егерме биш сәгате дә җитәрлек түгел иде.

Анын төп вакытын, әлбәттә инде, уку «ашый» иде. Үзенең беренчел максатына—университетны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлауга—ул хыянәт итмәскә тырышты. Өстәвенә, ул төрле яклап белемен тирәнәйтү өчен шәхси система булдырды. Моннан тыш, өс-башны карау, тамак ягын кайгырту җәһәтеннән, ул әле төрле оешмаларда йөкче булып та тир түгә иде. Рәхәтләнеп ял итәргә, яшьтиләре белән аралашырга, кыз-кыркын артыннан чабарга да анын вакыты калмый иде. Университет мохитенен, студент тормышынын куанычлы вә сөенечле көннәрен, мизгелләрен ул тоймый да калды бугай. Хәер, кем белә, бәлки нәкъ менә шуна күрәдәдер, ул бик тә юмарт бүләкләнде: алар курсын тәмамлаучылар арасында фәкать ул гына Мәскәүгә—аспирантурага махсус юллама алуга иреште ләбаса. Хәзер генә ул—«Мәскәү»—диюгә, беркемнең дә керфеге селкенми. Ә ул чагында, ул заманнарда... Мәскәү! Башкала! Ошбу ике сүзне әйтүгә үк сулуын каба, йөрәген дөп-дөп кага, күккә күтәрелгәндәй, башын әйләнә башлый иде. Уйласан, исен китмәле: өч ел буена Мәскәүдә торып укырга бара ләбаса ул! Мәскәүнең үзенә!

***

Мәскәүдә өч ел буе уку чоры анын өчен бер бәхетле көндәй булып кына үтте дә китте. Сизми дә калды.

Аспирантлар өчен әле янарак кына төзелгән шәп йорттан үзенә аерым бер бүлмәгә, өр-яңа мебельгә, хәтта суыткычына тиклем тиенде ул. Боларнын һәммәсе дә анын өчен үтә зиннәтле, үтә затлы тормышнын аерылгысыз чалымнары булып тоела, ә инде аспирант стипендиясе исә кичәге студент өчен чын мәгънәсендә күктән төшкән зур акча сыман иде. Ә Мәскәү, Мәскәү үзе! Ул ярты төнгә кадәр башкалада сәйран кылып йөрергә ярата һәм өч ел эчендә каланын үзен кызыксындырган һәр урамын диярлек җәяүләп йөреп тә чыкты. Иң әүвәле ул Мәскәүнең тулы-тәфсилле картасын булдырды, шуна карап, истәлекле урыннарнын маршрутын төзеде. Вакытнын кадерен белү гадәте биредә дә бик ярап куйды. Ана уку авыр бирелмәде. Торабара, үз көченә ныгытып ышанып беткәч, ул махсус юридик журналларда мәкаләләр дә бастыра башлады. Алардан килә торган каләм хакы да егеткә шактый зур булып тоела иде.

Буш вакытларында ул театрларга, һәртөрле күргәзмә-музейларга йөри

башлады. Атаклы Политехника музеенда, Герцен урамындагы язучылар йортында да булды ул.

Театр институтының сәнгать бүлегендә укучы Лариса белән дә ул әнә шундый сәйраннарының берсендә очрашты, таныштты. Тора-бара исә бу танышлык тагын да тирәнәеп, һәр икесендә сөю-гыйшык чаткылары пәйда булды. Ә инде чаткыдан дөрләп-дөрләп учак кабынуы беркемгә дә сер түгелдер.

Егетнең, тимераякта шуарга яраткан Ларисага ияреп, тәүге мәртәбә бозда шуарга җөрьәт итүенә дә, әлбәттә инде, дөрли башлаган әнә шул учак кына гаепле иде. Үзенә күрә бер сихри яктылык бөркеп ялтыраучы боз өстенә талгын гына күбәләк-күбәләк кар ява. Ә син, жан сөйгәненнең бармак очларыннан гына тотып, күңел түрендәге хисләр ташкынын отыры көчәйтә барган дәртле, яисә моңлы музыка тибрәнешендә боз өстеннән каядыр еракка—илаһи киңлекләргә юл аласың. Могҗиза ич бу! Моннан да ләззәтлерәк вә тылсымлырак халәтнең башкача булуы мөмкин түгел!

Асылкошны эләктереп, атаклы Чиста буа бозында шуган озын буйлы чибәр егет, (һич тә ышанасы килми) синме соң бу—кичәге шыр ятим детдом баласы, дәүләт һәм хокук институтының элеккеге аспиранты Әмирхан Азларханов?!

...Төн йокысы качкан прокурор җәйге ай нуры агылган шакшы-пычрак ишегалдына карый, әмма дә ул фәкать Чиста буадагы сихри кышкы кичне, көмеш бозда хикмәтле бөтерелешләр ясап әйләнүче егет белән кызны гына күрә. Күпереп торган ап-ак, җиңел вә йомшак киемле, алсу йөзле, сыгылмалы сылу сын-хәрәкәтле кызыйның сөю-сәгадәт тулы күзләрен күрә ул. Ә егетнең йөзен күрми. Өченче каттагы төн ката янган утлы тәрәзәләргә борылып та карыйсы килми ахрысы аның. Әйтерсең лә, алар арасында бернинди дә уртаклык юк! Кәефе киткән прокурор, төбенә кадәр ачып куелган тәрәзә яныннан кырт кузгалып, аш бүлмәсенә чыга, газга чәйнеген утырта. Төнге уйлар вә хатирәләр өчен иң шәп чара—кара яндырып чәй эчү. Һәм инде менә Мәскәү истәлекләре каядыр китеп гаип булды дигәндә генә, кинәт кенә кино йорты күз алдына килде.

...Мәскәүнең атаклы Воровский урамындагы иске кино йортында аның әле беренче мәртәбә генә булуы иде. Билетларны Лариса тапты. Сәнгать дөньясы белән тыгыз бәйләнештәге кодрәтле туган-тумачалары байтак иде кызыйның, шуңа күрә дә, аларга кайчагында премьераларда утыру бәхете дә елмая иде.

Ул чагында кино йортында әллә яңа фильм карау, әллә фестиваль алды программасы идеме—анысы истән чыккан—һәрхәлдә, француз картинасы иде ул. Инде исеме дә онытылган, ә менә режиссеры—француз киносы авангардчыларының берсе булган Бюффо иде. Фильм күңелдә бәхәсле, икеле тойгы-кичерешләр калдырды. Хикмәтле асыл аның эчтәлегендә дә түгел, ә бары шул эчтәлеккә салынган көтелмәгән фикердә. Сискәндергеч фикердә!

...Фильмның төп каһарманы Парижның Төньяк вокзалына килеп төшә. Ә поезд-экспресс инде кузгалып бара. Тормышын куркыныч астына куеп, бар булмыш әйберләрен ташлап калдырып, ул поезд артыннан чаба һәм, ниһаять, иң соңгы вагонга сикереп менәргә өлгерә. Фильм дәвамында шунысы ачыклана: каһарманга берничек тә сонга калырга ярамаган икән ләбаса, соңга калган очракта, бу аның гына түгел, аңа мөнәсәбәте булган һәркемнең фаҗигасына әверелер иде. Кырыс чынбарлыкка корылган фильмның азагында вәзгыять барыбер фаҗигага әзерләнә. Зал исә, дулкынланудан тын да алмыйча, әсәренеп, төп каһарманның гына түгел, башкаларның да язмыш төеннәрен күзәтә. Экран вакытының инде бер

сәгате үткән. Һәм, менә, кинәт кенә, нәкъ кыл үзәк-кульминациясендә, инде, ниһаять, чишелешкә чират житте дигәндә генә... янәдән фильмның тәүге кадрлары пәйда була: вокзал, төп каһарман, ул фильм башындагыча— япь-яшь һәм янадан поезд артыннан чаба. Бу юлысында ул поездга өлгерми, чемоданын тотып перронда басып кала. Хәзер инде бөтенләй икенче төрле тарих башланып китә. Персонажлары да үзгә, хәер, тамашачыга танышлары да юк-юкта күзгә чалына, тик алар төп каһарманыбызның язмышында әллә ни зур әһәмияткә ия түгелләр инде. Аның, поездга өлгереп, бәхетле булуында да, яисә, киресенчә, сонга калып, үз-үзен югалтуында, тормышы жимерелүендә дә түгел бирелә хикмәт. Режиссер үзе дә болай итеп чагыштырырга теләми. Бирелә хикмәт башкада. Тәкъдир кушуы белән, шушы бер минут эчендә поездга сонга калуы аркасында, каһарман бүтән тормышка, бүтән язмышка дучар ителә. Әлеге фильмнан сон Әмирханның башына бер фикер килде: әгәр дә ки, ул демобилизациядән сон ук, башка иптәшләренә ияреп, сәүдә флотына, балык тотарга, китауларга киткән очракта, аның язмышында инде беркайчан да ни Мәскәү, ни Лариса, ни университетның юрфагы, ни аспирантура—берсе дә булмас иде.

Әйе, әгәр дә ки, әгәр дә ки...

Ул чагында аның тормышы ничегрәк оешып киткән булыр иде икән? Үзенең дә, әлеге фильм каһарманы сыман, икенче язмышка дучар булу ихтималы хакында, үзен көткән балыкчы—дингезче тормышы турында ул Ларисага беркайчан да сөйләмәде. Фильмдагы теге фикерне дә онытмады. Менә бүген дә ул тәрәзә аша күренеп торган тузанлы-шакшы ишегалдын түгел, Чиста буадагы кышкы боз мәйданчыгын күрә, еллар аша күрә, янәдән дә—инде әллә кайчан караган француз фильмын исенә төшерә. Әгәр дә ки... Әгәр дә ки, ул теге чакта Мәскәүдә калса, аның тормышында янә бер текә борылыш булган булыр иде бу. Әгәр дә ул үзе киреләнмичә, «турыдан-туры кешеләр белән эшләргә телим, теория укыту, кәгазь кортына әверелү—минем эш түгел»—дип кырт кисмәгән булса, ул һичшиксез, Мәскәүдә каласы кеше иде. Ана Лариса да мен ялварды, «бирелә калыйк»,—диде. Кызыйның әти-әнисе исә буш торган биш бүлмәле иркен квартирага да ишарәләделәр. Ул Ларисаның бабасыннан, Мәскәү дәүләт университеты профессорыннан калган иде. Башкалада тамыр жибәрү өчен бүтән мондый да шәп мөмкинлекнең чыкмаячагын да искәрттеләр ана. Әгәр дә ки, алар сүзен сүз итсә, хәзерге көндә ул атаклы Чиста буа тирәләрендә, «Современник» театрының яңа бинасы янәшәсендә яшәр иде, инде әллә кайчан хокук фәннәре докторы, ә кем белә, бәлки әгъза-мөхбире үк тә булган булыр иде кана.

## 2

Менә хәзер ул, төн уртасында кара яндырып чәй пешергәндә, хыялланып утыра. Әгәр дә, аспирантурадан сон Мәскәүдә калган булса, аның тормышы кайсы юлдан киткән булыр иде икән?! Кем белә бит... Чал чәчле кафедра профессоры итеп тә, әле югары Суд әгъзасы итеп тә, СССР Прокуратурасы вәкиле итеп тә күрде ул үзен. Бит Ларисаның бабасы әле революциягә кадәр үк университетта хокук фәннәре профессоры булган. Картлачның биниһая зур йортындагы кабинетын да, китапханәсен дә яхшы хәтерли ул. Аспирантурада уку чорында әлеге гажәеп бай китапханәнең үзе өчен дә файдасы зур булды лабаса. Ларисаның әти-әнисе, әллә чынлап, әллә шаяртып, ана болай диләр иде: «Бу китапханәне юкка гына саклап тормаганбыз икән, нәселебезгә булмаса да, юрист киявебезгә кирәге чыгар, дигән фараз-күрәзәбез чынга аша, насыйп әйләсә». Кызыйның күпсанлы туган-тумачасы да Әмирханны тиз арада үз итеп өлгерде. Зур-зур

гаилә бәйрәмнәрендә, туйларда, женазаларда, булачак бабасы аны бөтен туганнары алдында «безнең себер ханыбыз» дип тә атый һәм үз нәселләренең чишмә башы да татар ханнарыннан килүен кабатларга ярата иде. Үзләренең Турганов фамилиясенең исә дала татарларыннан ук килүен дә искәртергә онытмый иде ул. Әгәр дә Мәскәүдә калса, Ларисаның да язмышы бөтенләй үзгә булыр иде.

Лариса Урта Азия республикаларының декоратив-гамәли сәнгатенә багышланган кандидатлык диссертациясе язды. Аеруча керамика белән ныгытып шөгыльләнде. Көньяк республикаларны аркылыга-буйлыга гизеп чыкты. Балчык, керамика белән көн күргән халык осталары яшәгән кышлакларның һәммәсендә дә диярлек булды ул. Бик тә сирәк эләгә торган ял вакытларында Әмирхан үзе дә хатынын озатып йөри иде. Хәләл җефетенең нечкә зәвыгына, сәнгатьне шулай тирән тоемлавына шакката иде ир. Борынгы Шәрыкның инде онытылып беткән сәнгать тармакларын, юнәлешләрен вә мәктәпләрен үтә сизгерлек белән эзләп таба белә иде аның Ларисасы. Тырышлыгы, үҗәтлеге дә хәттин ашкан иде. Көньяк республикаларның борынгы һәм хәзерге гамәли сәнгатенә багышланган гаҗәеп тә шәп, затлы альбом вә китаплар чыгарырга да өлгерә иде әле ул. Кайда диген—Мәскәү нәшриятларында! Урта Азия керамикасы күргәзмәләренең төп оештыручысы да булды. Мәскәүдә, Ленинградта, Таллинда, Тбилисида гына түгел, ә Цюрих, Стокһольм һәм Туран кебек чын Аурупа калаларында да узган әлеге күргәзмәләр гаять зур уңыш казанды. Лариса Турганова—Азларханованың исеме-аты сәнгать дөньясына таныллы, үзенең лаеклы урынын алды. Аны һәртөрле халыкара семинарларга, коллоквиумнарга чакыра башладылар. Еш кына бу җыеннарда аңа жюри әгъзасы буларак та катнашырга туры килә иде. Чит илдә нәшер ителүче абруйлы-затлы сәнгать журналлары исә аңа мәкалә язарга заказ бирә иделәр.

Менә шушы бәхетле вә уңышлы елларны кичкән көннәрнең берсендә Лариса Әмирханга болай диде:

—Әле ярый Мәскәүдә калмадың, мине дә үзеңә ияртген. Кирелегеңә рәхмәт! Синнән башка мин сәнгатьтә берни дә эшли алмас идем, исемем дә чыкмас иде.

Шулай дигән иде Лариса.

Югыйсә, керамика белән ул уйламаганда-көтмәгәндә очраклы рәвештә генә кызыксына башлады. Базардан өч сумга бер балчык ләгән сатып алганнар иде. Моның ише яндырып катырылган балчык савытларны һәр кышлакның һәр гаиләсендә диярлек табарга була һәм аны ясаучы осталар да—меңләгән. Лариса гап-гади бу йорт кирәк-ярагы савытында—балчык ләгәндә—буыннан-буынга тапшырылып килгән гаҗәеп тә үзенчәлекле символ-билгеләрне, чалымнарны күреп алды.

Балчык гомер-гомергә ярлы кешенең иң яраткан материалы булган һәм ул әнә шул балчыктан үзе ясаган әйберләргә бар булмыш җан җылысын салган. Гасырлардан-гасырларга, буыннардан-буынга осталыгын арттырган, хәтта ки, үз мәктәбен тудырган. Кайчагында ул мәктәпләр, бергә кушылып, бер-берсен баеткан, ә кайчагында исә киресенчә—үзенчәлеген, юнәлешен югалтырга дучар иткән. Лариса исә нәкъ менә чит сәнгать тәэсиренә бирешмәгән, борынгыдан килгән үзенчәлеген саклап кала алган агым-юнәлешләрне күрде-тапты, ачты, дөньяга чыгарды. Ларисаның җинел кулы белән, карап торышка гап-гади булган балчык ләгән, төбенә ике тишек тишкәч, диварга элеп куярдай затлы декоратив предметка әверелде. Хуҗалык ләгәне икенче гомерен яши башлады!

Ләгәннән башланган кызыксыну Ларисаны суырып-бөтереп борынгы

шәрык керамикасына алып кереп китте һәм ун ел эчендә ул берүзе егерме кешегә житәрдәй биниһая зур эш башкарды. Урта Азиядә табылган үзенчәлекле керамиканың жентекле картасын төзеде. Әлеге карта белән күргәзмә каталогларын күздән кичергән белгечләр аның гаять зур хезмәт башкаруына шаккатып, тел шартлаталар иде. Инде дә иң мөһиме: бөтен дөньяда ук булмаса да, илдә, Ауропада Урта Азия республикаларындагы шәрык керамикасы белән кызыксыну артты, хәтта модага әверелде. Сәнгать салоннарына исә чит илләрдән заказлар агыла башлады. Нахакка онытылган борынгы кәсеп вә сәнгатьнең яңадан тууы, үсеш кичерүе иде бу!

***

Аспирантурадан соң алар хатыны белән икәү килеп төпләнгән төбәктә тотрыклы гореф-гадәтләр хөкем сөрә иде. Йорт-жир бөтенлеге, гаилә учагы, туган-тумачалык, бала-чага—боларның һәммәсе дә биредә яшәешнең беренчел шартларыннан исәпләнә иде. Янарак кына әнисе белән әбисенең куен жылысыннан аерылган Ларисага йорт учагын саклау, хужабикә булу ошый иде. Хужалыкта, аеруча аш-су әзерләү җәһәтеннән әллә ни маһирлыгы сизелмәсә дә, яшь гаилә моннан зур фажига ясарга тырышмады. Иң мөһиме—аларның яраткан эшләре бар һәм һәр икесе дә шул эш вә һөнәрләрендә уңышка ирешергә телиләр иде.

Лариса башта туган якны өйрәнү музеенда сәнгать белгече вазифасын башкарды. Берничә елдан республика матбугатында аның сәнгатькә багышланган язмалары даими дөнья күрә башлады. Тынгысыз-тырыш ханымның хезмәтен тиз арада күреп алдылар. Ташкенттагы сәнгать музее аны зуррак вазифага билгеләде һәм, нәтижәдә, Ларисага үзенең эзләнүләре, фәнни хезмәтләре белән мөстәкыйль шартларда шөгыльләнү мөмкинлеге туды.

Әмирхан үзе исә һөнәри хезмәт баскычларыннан, хатынына караганда, бик күпкә тизрәк күтәрелергә кереште. Инде өч ел дигәндә, ул өлкә прокуратурасын житәкли башлады. Утыз алты яшендә өлкә прокуроры булган кеше ул чагында республикада гына түгел, ә илендә дә берәү генә һәм аның исеме-аты—Әмирхан Давыт улы Азлархановиде. Илнең Генераль прокурорына тәкъдим ителү өчен Мәскәүгә баргач, тегесе аның яшьлегенә шаккатты.

Инде менә хәзер, кара төн ката әрле-бирле йөренгәндә, үзенең гаилә хәлләрен искә төшергәндә, аның уйлары бөтенләй үзгә юнәлеш алды. Ай нурыннан яктырган тузанлы ишегалдына карый да ул, юк-юк, хәзер инде һич кенә дә Чиста буа бозларын түгел, башканы күрә. Ун елга якын яшәгән кеп-кечкенә квартирадан шәп, иркен коттеджга күченгәннәр иде алар. Әнә шул тирә-юне гөлбакчага күмелгән зур йортны күрә ул хәзер...

Өлкәнең иң эре төзелгән тресты башлыгы Ташкентта зур урынга билгеләнгәч, гаиләсе белән шунда күченде. Кем-кем, ә менә төзелеш тресты башлыгы, үзенә дигәндә, йортны шәп итеп, килештереп, жиренә житкереп сала инде ул!

Менә шул йорт Азлархановларга калды. Бирегә алар июль урталарында гына була торган саратан чилләсенең иң кызган мәлендә күченделәр. Терекөмеш баганасының кырыктан да югарыга сикергән һәм төшә алмыйча интеккән көннәрендә жәннәт багына тиң урын иде бу.

Йортта хәзергедәй паркет идәннәр дә юк, диварлары да такта белән эчләнмәгән. Ул заманда әле хәтта зур вазифа биләгән затлар да, бүгенге чор түрәләре шикелле,зиннәтле яшәү шаукымына бирелмәгәннәр иде. Модасы башланмаган иде әле.

Сап-сары тактадан эшләгән зур, ачык верандаларында кичләрен чәй

эчеп утырырга яраталар иде алар. Талгын гына искән тансык җил үпкә күрекләрен, тәнне иркәли, бакчадагы йөзем яфракларын лепердәтә. Бу бакча гаҗәеп зур булып тоела иде аларга. Хәер, сигез сутый җир хәзерге кала кешесе өчен дә аз түгел анысы. Бакчаның таҗы, төп мактанычы, әлбәттә инде, йөзем агачлары иде. Карасу-шәмәхә «Чораза», һәр тәлгәше кило ярым-ике килога тарта торган «җину» сортлары... Ә кызгылтсу-аһак «Тайфи», йөземнәр ханбикәче—алтынсу «Ханым бармаклары»—монысын җирле халык «Хөсәйни» төре дип тә йөртә—оҗмах багы нәкъ менә шундый була торгандыр да инде ул.

Ул елларда кала әллә ни зур түгел иде әле. Соңрак, дистә елдан соң гына, кинәт үсә, киңәя башлады һәм аларның аулак-тын урындагы йортлары үзәктә калды. Әйе, анысы әле аның соңрак. Ә бүген, бүген алар—икәү. Икесенә бер—зур йорт. Бакчаларында—җәйге душ, бассейн...

Көннәрдән беркөнне, җәй азакларындарак, ул верандада табын көйли, ә җәмәгате бассейнда йөзә-чума ләззәт кичерә иде, шунда Ларисаның тавышы ишетелде:

—Беләсеңме, кадерлем, миндә искиткеч бер шәп фикер туды бит әле! Әйтимме?—Бакчабызда, ачык һавада керамика музее булдырырга кирәк! Яшелчә-мазарны җыеп алгач та! Аларын алга таба базардан гына сатып алырбыз. Базары да яп-якын, очсызлыгын әйткән дә юк.

Мөгаен, ул җәйдә аларның сөю-мәхәббәте үзенең иң югары ноктасында, иң кайнар мизгелләрендә иде сыман, шуңа күрә дә, ир, хатынының ни-нәрсә хакында фикер йөрткәнен тәгаен аңлап-төшенеп тә бетермәс борын, аның сөйкемле тавышына-гозеренә шундук ризалыгын белдерде:

—Фикерең туган икән, нишлисең үзең беләсеңдер,—диде ул.—Мин, җаный, синең зәвыгыңа ышанам.

### 3

Нишләптер, бакчадагы ачык музей хакында алга таба байтак кына вакытлар сүз чыкмады. Бу якларда озын-озакка сузыла торган җылы көз җитте, яшелчәләр өлгерде. Хәзер иртәләрен бассейнда коелган яфраклар вә гөләп таҗларының аерчалары гына йөзеп йөри.

Әмирханга өч көнгә эш буенча Ташкентка барып кайтырга туры килде. Кайтып төшсә... ни бакчаны, ни ишегалдын танырлык түгел иде.

—Син берүк борчыла күрмә тагын,—дип елмаеп каршы алды аны хатыны.—Җәе буе Аурупа архитектурасын өйрәндем ләбаса. Алманныкын да, инглизнекен дә, французныкын да... Һәм менә японныкына тукталдым. Безнең сигез сутыебызга шуннан да кулаен тапмадым.

Ашап-эчкәч, алар икәүләп үзгәрешләрне карый башладылар. Хатыны сөйли, ире исә, аңласа да-аңламаса да, хуплап башын селки. Ишегалды каяндыр китерелгән ямь-яшел кәс белән капланган иде. Әле иртәгә янә ниндидер агачлар, төрледән-төрле гөләп куаклары киләчәк икән. Аларны кай төшкә ни рәвешле утыртачаклары хакында мавыгып, хыялланып, бик тә тәмләп сөйли иде Лариса. Әмирхан аны игътибар белән тыңлады, ниятләрен хуплады. Хатынын бик яхшы белә иде ул. Шуңа күрә дә, елмаеп куйды да, бер генә сорау бирде:

—Мине эштән алганчы, бакчадагы музеенны төзеп бетерергә өлгерәсеңме, юкмы?

Бәхете тулып ашкан көләч йөзле хатын ирен кочып алды.

—Хатынкаенны бик начар беләсең икән әле син,—дип, ул да елмайды.—Яшелләндерү тресты белән бөтен шартына туры китереп, законлы рәвештә, смета буенча һәм касса аша исәп-хисап ясадым. Хәтта, кирәге чыкса дип, квитанциясен дә җыеп куйдым. Әллә син трест хезмәткәрләре өлкә

прокуроры өчен тырышканнар икән, дип уйлыйсынмы?—Юк, юк! Ачык һавада музей оештырасым килә дип аңлаттым да, аларга бу фикер бик тә ошады. Әле хәтта бу музейга кайбер керамика үрнәкләрен дә бүләк итәргә уйлап торалар. Тик менә... Бер гаебем бар, кадерлем... Теге чакта синен белән икәүләп йокы бүлмәсенә гарнитур карап куйган идек бит, исеңдәме?.. Бер-ике ел гарнитурсыз гына яшәп торырбыз инде. Ниятләр зурдан, музейга акча күп кирәк булачак.

Әмирхан, көлә-көлә, хатынын кочаклап үпте.

—Ир—баш, хатын—муен,—диде ул.—Син борсаң, борасың инде. Ничек телисең, шулай булыр!

—Юк, юк, бетмәде! Әйтеп бетермәдем әле!—диде Лариса.—Сина, өлкә прокуроры буларак, бөтен элемтәләреңне, кодрәтеңне файдаланып, мина бер зәңгәр чыршы табып бирергә туры киләчәк. Яшелләндерү хуҗалыгы мина бу бүләкне вәгъдә итмәде, ә ул биредәге ландшафтка бик тә кирәк, аннан башка булмый...

4

Әлеге зәңгәр чыршыны күрергә бүген дә мөмкинлеге бар лабаса аның! Менә хәзер үк, рәсемнән! Теге чакта хатынына биргән вәгъдәсен үтәде ул—зәңгәр чыршыны эзләде, тапты, кайтартты.

Үткәндә калган бәхетле тормышыннан бу калага ул, көнкүреш өчен иң мөһим кирәк-ярактан тыш, хатыны нәшер итәргә өлгергән китапларны, альбом-проспектларны да алып килде бит әле. Хәер, бүтән төрле байлыгы болай да юк иде анысы. Иң зур хәзинәләре, мөгаен, әнә шул музей, төгәлрәге—керамикалар тупланмасы булгандыр. Ул альбомнарның берсендә—аның карашынча, иң яхшысында, Мәскәүдә нәшер ителгәнендә—нәкъ менә ачык һавадагы музейда төшерелгән сурәтләр дә бар.

Карап-нитеп тормыйча гына әнә шул альбомның бер битен ачкан иде, менә сина вәйт—күпереп үскән затлы зәңгәр чыршы янәшәсендә, ямь-яшел чирәмгә утыртылган имән өслек тә су савыты—хум куелган сурәт.

Ерак сәфәрләрдән нинди дә булса кызыксынуга лаек керамика әйбере алып кайтуга, Лариса бакчадагы музейны үзгәртергә тотына, биредәге һәр экспонат хәрәкәткә килә иде. Аларның урыннары алышынуга карап, тирә-юньдәге күренеш тә үзгәрә, камилләшә.

Керамика белгече буларак, абруе-шөһрәте арткан саен, Ларисага чит илләрдәге музей вә галереялардан да чакырулар отыры ешайды. Цюрих белән Стокһольмда оештырылган күргәзмәләргә алар, мәсәлән, икәүләп бардылар. Әмирханга, әлбәттә, моның өчен туристлык юлламасын юнәтергә туры килде. Иң мөһиме, ул хәләленең уңышларына шаһит булды, аның гаҗәеп бәхетле йөзен күрде, аның белән бергә сөенде.

Мәскәүдә нәшер ителгән альбомнарны аеруча яратуының сәбәбе дә бар. Чөнки ул бу альбомнардагы фотосурәтләрне төшерүдә үзе дә катнашты лабаса. Гәрчә еш кына яктырткычлар, һәртөрле аппаратура-җиһазлар төялгән дистәләп чемоданлы сурәт төшерү төркемнәре килеп торса да, иң шәп, иң кәттә рәсемнәрне Лариса үзе төшерә иде. Чит илләрдә йөргәндә ул Көнбатыш Алмания һәм Япониядә эшләнгән фотокамералар да сатып алып кайтты. Хәер, аның юлга бирелгән бөтен акчасы фотокәгазь һәм реактивлар алуга сарыф ителә иде. Таң тугач та, күзне чагардай көн яктысында да, кояш баеп барганда да сурәткә төшерә иде ул. Һәм беркайчан да бу эшкә үзе генә керешмәде—Әмирханны көтте. Ул исә хатынының һәр уен, һәр ымын, һәр адымын сүзсез дә аңлый иде. Менә шуна күрә дә бу альбомнардагы һәр фотосурәт аның өчен бик тә кадерле иде. Аларның ничек туганын ул бик яхшы хәтерли.

Альбомда сурәтләнгән һәм аларның өйдәге тупланмаларында саклanган бүләк нөсхәләр дә бар. Бу якларда әүвәл балчык савыт—керамика җыю белән мавыгучы ир белән хатынга сәерсенеп карыйлар иде. Ярый да соң, әгәр дә борынгы көмеш, бәллүр, бронза, кулдан тукылган келәм, кыскасы, матди кыйммәте булган әйберләр җыйсаң. Ә болар—каткан, яндырылган балчык белән мәш киләләр. Биредәге халыкның күбесе әнә шулай фикер йөртә иде.

Аларга чын күңелдән, милли керамика сәнгатен үстерүдә ярдәм итү теләге белән бүләк итүчеләр дә булды. Алмасан—үпкәлиләр дә: янәшәдә генә комган җыючы яшәгәндә, миңа бу комганның нигә кирәге бар, янәсе. Бабайлардан калган булса да, сезгә җәл түгел, бәлки мин бүләк иткән комган сездәге комганның ише—парыдыр? Шулай диләр иде.

«Алма, кабул итмә бүләкләрне!»—кайчандыр борынгы латин кануннарыннан укыган бу зирәк сүзләрнең асыл мәгънәсен ул, әлбәттә, бик яхшы белә иде. Үзенең нинди вазифа биләгәнен һичкайчан онытмаганлыктан, бу гыйбарәнең мәгънәсе отыры киңәя генә иде.

Әйе, идәнгә куелышлы биниһая зур чин вазалары да, ике чиләк су сыешлы борынгы бакыр кувшиннар да тәкъдим иттеләр аңа. Мөгаен, араларында чын-ихлас күңелдән тәкъдим итүчеләре дә булгандыр. Әмма ул: «чин (кытай) фарфоры, хәтта кулдан эшләнгән булса да, мине кызыксындырмый»—дип аңлата иде. Кытай фарфорын аңа берничә ел рәттән бүләк итәргә маташтылар. Шәрык ләгәннәренә бик тә охшаш, киңлеге-диаметры метрга житкән тәлинкәләр аны аеруча әсәрләндерде. Соклandыргыч, үтә гүзәл вә зәвыклы нөсхәләр иде алар. Бу якларда фарфорның биниһая күп булуы гаҗәпләндерә, әмма, югыйсә, Чин иленнән килүче борынгы сәүдә кәрваннарының нәкъ биредән үткәнлекләре дә бик яхшы мәгълүм.

Лахути урамындагы коттеджларында кичергән иң бәхетле көннәр үтеп, инде өлкә прокурорлыгыннан төшерелеп, тикшерү бүлегендә әллә ни зур булмаган вазифа башкарганда, аңа «коллекционерлар» дип аталучыларның «эше» белән якыннан танышырга туры килде. Соң, әле кайчан гына, хатыны өч ел дәвамында җирле музейда сәнгать белгече булып эшләгәндә, «шәхси тупланма» дигән төшенчәне бу якларда бөтенләй белмиләр иде. Ә менә хәзер исә, сиксәненче еллар башында, яңгырдан соң калыккан гөмбәләр күк, шәхси тупланма хуҗалары пәйда булды. Әлеге тупланмалар арасында, әлбәттә, чын сәнгать әсәрләре дә очраштыргалый. Вәләкин бу хуҗаларның күбесен җыйган әйберләренең матди ягы, бәһасе кызыксындыра.

Тәңкәләр, портсигарлар, беләзекләр, галстук кыстыргычлары, булавкалар, брелоклар—ни-нәрсә генә тупламыйлар хәзер, һәм боларның һәммәсе дә алтыннан булырга тиеш. Дөрес, бер «белгеч»нең алтынга бөтенләй исе китмәгән, ул бары платинадан гына эшләнгән уналты данә шкатулка һәм тәмәке савыты җыйган. Көмеш әйберләр туплау буенча бер рекордчының хәзинәсеннән, үзе кулга алынгач, Мәскәү белгечләре Фаберженың әле моңарчы билгеле булмаган дүрт эшен табып алып, музейга тапшырганнар. Прокурорны «коллекционерлар»ның янә бер төре таң калдырды. Өлкәдә алтыннан калышмыйча «туплана» торган тагын бер әйбер бар. Ул—энҗе. Антиквариат җыючылардан аермалы буларак, болар үзләренә кирәкле нәрсә хакында бик күпне беләләр, бу җәһәттән алар хәтта сәнгать белгечләрен дә уздырып җибәрәләр. Эше шундый булгач, прокурорга да Якын Көнчыгыш илләреннән, Африкадан, Австралиядән һәм Филиппиннан кайтарылган энҗе бөртекләрен күрергә туры килде. Хәтта океан фермаларында җитештерелә торган яңа япон энҗеләрен дә тотып карады ул. Мөселманнар элек-электән үк энҗене алтыннан һәм хәтта бриллианттан да өстенрәк санаганнар. Ә прокурор өчен иң өстене—гаделлек.

***

Таң атты. Кояш чыкты. Кояшның алтын нурлары өй эчендәге электр яктылыгын кирәкмәскә әверелдерделәр. «Кара син аны, ничек тиз үтте бу төн!—дип уйлады элеккеге прокурор.—Күргәзмәне җыярга да вакыт». Альбомнарны урынына алып куйганда, янә берсен ачып карыйсы итте. Монысы Швейцариядә дөнья күргән иде. Соңгы күргәзмә... Ларисаның үлеменә ярты ел кала... Ул чагында хатыны Цюрихта гасыр башы керамикасын күрсәткән иде. Фирганә үзәнлегенең архив документларын карап утырганда ул, көтмәгәндә-уйламаганда, бик тә кызыклы мәгълүматларга тап булган. 1898 елда генерал Скобелев фәрманы белән урыслар төпләнеп яшәгән Горчаковода ике керамика мастерское ачыла. Биредә җирле осталар эшли. Уналты ел буе, ягъни беренче бөтендөнья сугышы башланганчыга кадәр бу остаханәләрдә эш бара. Ләгәннәр, чәйнекләр, пиалалардан тыш, монда бик кыйммәтле савыт-саба да җитештергәннәр. Аларны губернатор йортына, офицерлар җыенына һәм хәтта биредәге идарәче, бөек кенәз Михаил Алексеевичка да җибәргәннәр. Нәкъ менә шул заказга эшләнгән затлы керамика аеруча зур кызыксыну уята да иде инде. Лариса аларны эзләп табуга шактый вакытын вә көчен сарыф итте.

Әмма прокурор альбомнан ул табышларны түгел, ә бөтенләй икенче нәрсәне эзли иде. Альбомда сурәтләнгән ике экспонатны янә күздән кичерәсе итте ул. Элеккеге прокурорга заманында гаять зур күңелсезлекләр вә бәлаләр китергән иде алар.

Ул альбомның әнә шул битен ачты. Тәбәнәк өстәлне тулысы белән томалап, бик яхшы эшкәртелгән зур бүре тиресе ята. Гыйссар бүресенең «туны» өстенә исә чакматашлы борынгы мылтык куелган. Һай, кем белгән бит аны, бүре тиресе белән чакматашлы мылтыкның бәла алды билгеләре булуын—кем белгән?!

Яз башының ул якшәмбе иртәсен Әмирхан әле бүгенгедәй хәтерли. Бакчада шаулап сирень чәчәк атып утыра, анда-санда умырзаялар, ләләләр калкып маташа. Ул елны кыш бик суык килде, килде дә—китә белмәде, озын-озакка сузылды. Шуна күрә дә, язның тәүге чалымнары үтә матур, үтә тансык тоела иде. Җылына башлаган җир исе, һава исе, калкып чыккан чәчәк-үлән исе—һәммәсе дә исерткеч ләззәт китерәләр иде.

Ул көнне алар бу язда беренче тапкыр ачык верандада ашап-эчеп алырга, тирә-юньдәге яз хакимлеге белән хозурланырга җыенганнар иде. Лариса аш-су әзерли, ә ул өстәл-урындыкларны көйләштереп йөри. Кинәт кенә яшел капкаларында кыңгырау чыңлады. Әмирхан иртәнге кунакны каршыларга ашыкты.

Капка төбендә бик затлы киенгән бер кеше басып тора иде. Бераз гына читтәрәк өлкә номерлары сугылган өр-яңа эш «Волга»сы туктаган. Таныш түгел бу кеше аңа исеме-аты белән эндәшеп исәнләште. Ә инде өйгә чакыргач, каршы килде, үзенең бик тә ашыгуын аңлатты. Район прокуратурасында эшләүче коллегалары аның аша мөхтәрәм Әмирхан Даутовичка ике керамик савыт җибәргәннәр. Ә ул исә аларның гозерен-йомышын үтәргә рәхәтләнеп риза булган, чөнки Лариса ханымның сәнгать өлкәсендәге казанышлары хакында да ишеткәне бар икән. Төбәк сәнгатен үзебезнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә киң таныту мөһимлеген дә әйтергә онытмады кунак. Ул арада шоферы да килеп җитте һәм кәгазь төргәгеннән арындырып, бер савытны хуҗасына тапшырды. Тегесе исә аны прокурорга тоттырды. Районнан килгән, үзенең исемен дә әйтмәгән бу кешенең сөйләвен тыңлап торганда, Әмирхан: «чираттагы кытай фарфоры китергән ахрысы бу» дип уйлап куйган иде. Тик ул ялгышкан булып чыкты. Савыт чыннан да керамикадан һәм бик яхшы сакланган иде. Хәтта яңа диярлек.

Жентекләп, үткен күз белән караганда гына, бу савытның бик тә, бик тә борынгы икәнлеген ачыкларга мөмкин иде. Аны күрүгә, Лариса «аһ» итте, хәтта кунаклар белән исәнләшергә дә онытты ул. Әмма үзен шундук кулга алып, исәнләште, аларны өйгә чакырды.

Ул арада шофер икенче савытны да алып килде һәм Ларисага тоттырды.

Берничә минуттан чакырылмаган кунаклар, алар белән саубуллашып, китеп тә бардылар. Икесе дә берәр савыт кочкан ир белән хатын капка төбендә басып калдылар.

Бу көнне алар иртәнгесен генә түгел, төшке ашны да оныттылар. Савытларны әле өйгә алып кerделәр, аннары исә кире алып чыгып, кояш яктысында лупа белән һәр квадрат сантиметрын жентекләп өйрәнергә-тикшерергә керештеләр. Форма-кыяфәте, рәсем-бизәкләренә караганда, нәманган керамикасы иде бу. Лариса иренә болай дип аңлатты: биредә балчык форма һәм яндыру өчен генә, аз күләмдә кулланылган. Калган материал—минераль өстәмәләр белән, тау токымнарының билгеле бер кушылмасы. Вакытка бирешмичә сакланган жете төсләр һәм савытның бик нык булуы әнә шуларга бәйле. Ларисаның әйтүенчә, бу предметлар гасырлар дәвамында бик күп мәртәбәләр җиргә мәтәлеп төшеп, бәрелеп-сугылып йөргәннәр, әмма дә ватылу түгел, кителү түгел, хәтта тырналмаганнар да. Савытларның авырлыгы исә аның эчендәге чын көмеш белән кушылган калын эмаль катламына бәйле булып чыкты. Эмальгә билгесез компонентлар да өстәлгән. Әмма боларның серен борынгы осталар инде үзләре белән алып киткәннәр... Сүз дә юк, бу савытлар су салып йөртү өчен эшләнгән булган. Сәүдә кәрваннары белән биниһая озын юлларда йөрүчеләр һәр тамчы суның кадерен белгәннәр. Мондый керамика эшләүнең ысул-техникасы Ауропада, аеруча Алмания белән Һолландиядә инде күптәннән билгеле икән. Бу савытлар бик кыйммәт торганлыктан, гади халык алардан файдалана алмаган. Шушы ике савытны да, махсус заказ буенча, бик тә бай вә кодрәтле затка ясаган булырга тиешләр. Балчыкка дөя сөте, куй каны һәм аксымы да кушылуы бик мөмкин. Хәер, җирле керамиканы өйрәнүчеләр өчен боларның берсе дә сер түгел, билгеле нәрсәләр. Вәләкин ул матдәләрнең никадәрле микъдарда кушылуы һаман да тирән сер булып кала бирә. Озын-озак юлга исәпләнгән бу савытларның тышында каеш белән эләктерү өчен сизелер-сизелмәс кенә өч уентык сызылган. Тик бу каешларны каян табарга?!

Лариса ике ел буе төрле республикадагы коллегалары белән язышып, хәбәрләшеп торды. Һәм, ниһаять, көннәрдән бер көнне аңа Таулы Алтайдан ике каеш җибәрделәр. Һәрберсе метрдан чак кына озынрак бу борынгы каешларны савытларга буып беркеткәч тә тәмамланган вә бөтен күренеш хасил булды. Әйтерсең лә, каеш бил-баулар савытларга жан өреп, аларны тергезделәр. Затлы күксел-сары бүре тиресендә тезелешеп утыручы өлгергән өрек төсендәге бу савытлар аеруча матур вә табигый күренәләр иде. Савытларның нечкәребрәк килгән муеннары да, мөселманнар билгесе—ярым ай сурәтләнгән көмеш капкачлары да шушы матурлыкка бик тә күркәм нокта куялар иде.

Менә хәзер ул әлеге матурлыклар сурәтләнгән фотоларга карап-карап тора да, янә карап куя. Гәрчә, бу савытлар хакында ул хәзер хәтта газизе Лариса белергә өлгермәгәннәрне дә белә. Белә—әмма дә аларга карата ни шатлык, ни нәфрәт хисләрен инде кичерми хәзер. Юк, кичерми.

*Дәвамы киләсе санда*



Шамил
Маннапов

## АРГАМАГЫН ТЫЙМЫЙ ҖАЙДАГЫ...

***

**Янмасын дип, ярсу аргамагын**
**Тыйган кебек кайчак җайдагы,**
**Гомер узган саен ешрак эзлим**
**Йөрәгемне тыяр чаманы:**

**Өлкәнәйдең дими, тели һаман**
**Элеккечә янып йөрергә...**
**Йә, шаярма, җитте, тилекәем,**
**Калуың бар юкса күмергә.**

**Оныттыңмы әллә табибларның**
**Катлы-катлы биргән сабагын:**
**«Сиңа хәтта артык көенүнең дә,**
**Артык сөенүнең дә зарарын!..»**

**Шуңа тыям сине,**
**Тик, җанымда**
**Шигъриятем канат кагынса,**
**«Зарарлы»лар һәм «ярамый»ларның**
**Онытыла никтер барсы да.**

**Һәм яңадан ярсу аргамак мин,—**
**Йөрәк кагып атылам бәйгегә.**
**Җилне түгел, Әҗәлне дә узам,**
**Килгәнмен күк Җиргә мәңгегә...**

Шамил МАННАПОВ (1938) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Тамырлар», «Әти урманы», «Өндәге төшләр» һ. б. егермегә якын китап авторы. Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Хыял һәм чынбарлык

Төнге күккә карыйм,
Биеклектән
Сызылып-сызылып йолдыз атыла;
Метеорит
Хыялында йөрткән
Сөйгән Җиренә шулай ашкына...

Еракларда зәңгәрлеге белән
Сокландырган Җирне—якыннан
Күргәннән соң, Галәм алиһәсе
Ниләр уйлар аның хакында?

Сизмәсме ул, чынбарлыкны күргәч,
Алсу хыялының алдавын?
Ничек кичерер Җирнең куенында
Кайнар тәненә салкын сарганын?

Сизмәсме ул Җирнең тыштан гына
Салкын булып, эчтән янганын?
Метеориттан гына түгел, кешедән дә
Җирнең бик күп яра алганын
Күкнең алиһәсе аңлармы?

Кылган гамәлеңә, Метеорит,
Хәзер инде үкен-үкенмә,
Теләсәң дә,
Ычкыналмассың син
Җирнең көчле тарту көченнән.

Кавышкансыз икән, инде сезгә
Бу Галәмдә уртак юл кала:
Хыял хисен югалтмаган хәлдә,
Бергә очу,
Кыен булса да...

## Наис Гамбәрнең соңгы төше

*Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер...*
Зөлфәт

Ул кайтырга чыккан, имеш,
Күптән
Сагынып көтә аны Уразмәт.
Җәяү кайта, җанга шундый рәхәт,
Яланаяк атлый, юл әйбәт...
Җигүле ат аны куып җитте,
Карасана, Зөлфәт утырган:
«—Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә...»—дип,
Елмаеп кул болгый дустына.

—Зөлфәт! Атың туктат!
—Туктаталмыйм,—
Дилбегәсе аның язмышта...
Җәяүләп кайт,
Бу арбага әле.
Утырырга, Наис, ашыкма...

—Һе, дус, имеш... Утыртмый да үзе...
Әйтерсең лә урын тар анда...—
Зөлфәт рөхсәт итмәсә дә, Наис
Куып җитеп сикерә арбага.
Һәм шул вакыт күрә:
Алда—бушлык!
Оча алар икәү упкынга!
Очу шундый рәхәт икән ласа,
Рәхәтлектән йөрәк кысыла.
Очу рәхәт... Тик озакка бармас...—
Бу—өн түгел бугай, төш кенә...

Мәңгелекнең арбасында килеш
Очар алар, очар—Мөслимгә...

## Авыру сызмалар

*Ник тавышы моңлы, димсең,*
*Кулларымдагы сазның?—*
*Язмаган чакта—авырдым,*
*Авырган чакта—яздым....*

Сиздермичә уза икән гомер,
Азаялар дуслар, дошманнар...—
Сиздермичә урап ала икән
Дошман явы кебек сырхаулар.

Ләкин барыннан да кыены шул:
Җанда арта сагыш хисләрең,
Газиз кешең китеп,
Язмыш сине
Ялгызлыкка дучар иткәне.

Жанны нурлап торган сөю шәме
Сүнәр-сүнмәс тетри күңелдә.
Яшәүме бу, әллә җан саклаумы?—
Ниләр көтә калган гомердә?

Яшисе дә килми, үләсе дә,—
Билгесезлек никтер куркыта.
Бер киткәч бит кире кайтулар юк,—
Соңгы чиктә сине шул тота.

Фани бу дөньяда бар да уза,
Бирәүгә дә мәңге калу юк.
Сырхаулардан дарулар бар,
Ләкин
Яшьлегеңдә калган Мәхәббәттән
Һәм картлыктан гына дару юк...

## Вакытлыча гына...

Шифаханә.
Колач җитмәс нарат егетләре,
Зифа буйлы каен кызлары
Өстән карап мине сәламләде,
Каен кызы кулын болгады.

Һава әйбәт, туфрак ашламалы,
Таза булып шуңа үскәннәр...
Сугыш гарасаты, ризык җитмәү
Без үсәсе буйны кискәннәр.

Хәзер ризык җитә.
Ләкин менә
Сәламәтлек кенә чамалы.
Яңгырның да шифалырак була
Вакытында килеп яуганы...

Ә шулай да рәхмәт табибларга,—
Дәвалыйлар төрле сырхаудан,
Дөнья җәннәтендә яшик әле,
Вакытлыча гына булса да.

Вакытлыча гына бирелгән шул
Өч атналык кына юллама.
Хәер, үзебез дә вакытлыча
Килгәнбез ич фани дөньяга...

Без китәрбез.
Мәгәр булмаячак
Җир-җәннәтнең бушап торганы:
Килгәннәрне мәңге каршы алыр
Нарат егете, каен кызлары...

## Чикләнмәгән дөнья—җаннарга...

Үлем фәрештәсе—Газраилдән
Нигә куркынабыз икән без?—
Мәңгелектән Җиргә килгәнбез дә,
Янә шунда гына китәрбез...

Ходай биргән гомерләрен яшәп,
Китеп барган бөек ханнар да,
Китеп барган хәтта пәйгамбәрләр,
Без соң шәбрәкмени алардан?!

Гарештәге күпме җаннар әле
Чираттадыр Җиргә килергә:
Гомер чигенә җиткәч, без тиешле
Ул җаннарга урын бирергә.
Ходай иҗат иткән бу дөньяны
Алар да бит тиеш күрергә...

Балаларга, оныкларыбызга
Калдырырбыз барын җәлләми.
Ходай биргәненә разый булып,
Татысыннар дөнья ямьнәрен.

Тормыш сиратларын узганнан соң,
Мәңгелеккә китәр алар да...
Җирдә—урын чикле,
Ә Галәмдә
Чиксез дөнья—сансыз җаннарга....

## Яңгырлы көздә

Күкнең төбе тишелгәнме—
Коя да коя яңгыр,
Хет яңгырга сусап язган
Шигырьләреңне яндыр!

Кабул итми суны туфрак,
Күлдәвекләре тирән.
Әйтерсең Жир карый Күккә
Яшьле күзләре белән.

Үзе үстергән уңышны
Егып черетә яңгыр,
Үзенә булган хөрмәтне
Агызып китә яңгыр.

Кайда йөзгән бу болытлар
Коры җәйдә, кирәктә?
... Соңлап кабул була, ахры,
Без теләгән теләкләр.

Минем хисләр дә ярыма
Шулай соңлап җитәрме,
Зарыгып көткән назларым
Аны гарык итәрме?..

Күңелсез уйлар кузгатып,
Коя да коя яңгыр.
Хет назларга сусап язган
Шигырьләреңне яндыр.

## Әй, балалар...

Белмисезме: фани бу дөньяда
Кунак кына ласа һәммәбез?
Тыңлагызчы олыларның сүзен:
Сабыйлыкта без җәлләдек сезне,
Карыйлыкта безне җәллəгез.

Шәфкатегез, җан җылыгыз җитә,
Кирәк түгел безгә әлләни.
Бала-каза китермисез икән,
Шушы—
Иң мөһиме
Безне җәлләүнең...

Ата-ана өчен иң кыены—
Бала хәсрәтләре булмасын.
Форсат барда алып калса идегез
Шушы газиз кешеләр догасын.

Айдар
Хәлим

## ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

Тәрбия-ханымның бармак очлары белән майланган ишек инде кичәге кебек җырламый иде. Ул тавышсыз-тынсыз алгы якка чыкты. Иркен ага дивардагы фотосурәтләрне карап чыкты, тәрәзә кашагасы башларына эленгән чупләмле тастымалларны куллары белән тотып, капшап, иснәп карады. Аларда картинәсе Бибикамалның кул чалымнары бар иде. Бу Тәрбия-ханымның әнкәсеннән калган уң кул эшләре булырга тиеш. Бик борынгылардыр. Бүрәнә диварның тәрәзә араларына вак кына кадак белән тартылып кадакланган чигү эшләренә сокланды. «Менә болары Тәрбиянең үз кулы булыш кирәк».

Өстәл янына килде. Иркен-ага утын сүндереп, көч-хәл белән урынына барып ятты. Аның күзе пычкылдап томанланган, башы эшләми, тәне утлы коршау эчендә янып сыкрый иде. «Сырхап китмәсәм ярар». Менә сина дүрт сыйныф белем!—дип уйланды ул. Бу Кизләү мәктәбенең нибары «дүрт кенә сыйныфы»н бетергән егет барлык кешелеккә, барлык капитал дөньясына сабак бирә түгелме? Әгәр ун сыйныфны тәмамлаган булса, нındирәк акылга ия булган булыр иде икән? Язмасының исемен кара син: «Шәхси Зар». Зарлану да, кеше өстеннән Шикаять, Үтенеч кенә дә түгел. «Шәхси Зар»...

Баш миен ялт итеп яктыртып, аңа борчыган фикер урыныннан күтәрде. Янадан утын кабызды. Дулкынланудан калтыранган куллары өстәл өстеннән кәгазь берлән каләм эзләп тапты. Тынычлану ниятендә күзләрен йомды. Ниһаять, ак кәгазьнең уртасыннан яза башлады...

*Берләшкән Милләтләр*
*Оешмасының*
*Генераль Секретаренә*

*ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ДӨНЬЯ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕНӘ МЕМОРАНДУМЫ*

*Берләшкән Милләтләр Оешмасының барлык төрдәге коллык, сегрегация һәм дискриминацияләрне гаепләвен һәм аның колониаль территорияләргә һәм халыкларга бәйсезлек бирү турындагы 1960 елның 14 декабрендәге тарихи*

*Ахыры. Башы 9—11нче саннарда.*

*декларациясен, 1963 елның 20 ноябрендәге барлык расачыл кысымнарны бөтен дөнья буйлап кичектергесез гамәлдән чыгару турындагы тарихи декларациясен исәпкә алып,*

*Европа һәм Азия кыйтгаларының Рәсәй өлешендә кешелекне империализм һәм колониаль изелүнең соңгы хурлыклы эземтәләреннән тулаем һәм котылгысыз рәвештә азат итү, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукларын тормышка ашыру һәм колониаль милләтләргә Өченче мең ел башында мөстәкыйльлек тәкъдир итү юлында хәлиткеч омтылыш ясап,*

*«Рәсәй Федерациясе-Россия» дигән сәер ике катлы исем йөреткән дәүләттә гомер бакый килешеп, күрше яшәгән халыкларның киләчәк язмышы өчен борчылып һәм алар өчен тарихи җаваплылык тоеп, Татар Халкының...— Иркен-ага кем исеменнән язарга белмичә, уйланып торды.—... Милли Мәҗлесе күп миллионлы татар милләте исеменнән барча кешелеккә түбәндәгеләрне белдерергә тиеш тапты...*

Ул шабыр тиргә баткан иде. Документның иң борчыган баш өлеше булды да бугай. Бүгенгә житкәндер. Чак кузгалып, утын сүндерде һәм барып ятты.

Начар йоклады. Урам яктан баш очында тәне буе мотоциклет тырылдады. Теге Хромосом Сәйфетдинечнен өрәкитәле мәтәстикле түгелме? Авылның бер башыннан икенче башына чапкан бу жүләрне асып куясы килгән минутлары булды. Аннан гел саташты: ниндидер йөнтәс шүрәлеләр затлы мерседесларда яулыкларын канатлатып бәйләгән Сихәт-сылуларны ташый, имеш. Һәмма мерседесның номеры 175, һәммасында Сихәт-сылу утырган, имеш. Нигә 175? Менә бер мерседестан атлы шүрәле чыга. Баш Шүрәле үзе, имеш. Кинәт мерседеслар уенчыкка әйләнеп кечерәя һәм баш Шүрәле аларны Сихәт-сылулары белән кесәсенә тутыра башлый...

Иркен-ага куркып уянды.Тәрәзәдә көзге тан сарысы жәелеп килә иде.

Догасын укыды да, икенче ягына борылып ятты.

Һәм шуннан соң гына упкынга төшкәндәй тирән йокыга китте. Бераздан аны мөгрәгән мал, чылбыр чыны белән жир селкетеп үткән трактор тавышлары уятты...

## IV

Сихәт-сылу белән Шәйхенур иртән дә кайтмаган иделәр.

—Урамда салкынмы?

—Зарарлы түгел.

—Рокерлар сездә дә бар икән.Тәне буе мотоциклетта чаптылар.

—Әйе, исерешәләр дә, башларын кая чәнчелдерергә белмичә чабышалар шунда...

Борчылуы йөзенә чыккан Тәрбия белән сирәк кенә сүз алгалашып, куян канына охшаган куе кызыл чәй эчте дә, кесәсенә блокнот, каләм тыгып, жирле идарәгә китте. Ул авыл уртасындагы мәйданда, зур кибет белән янәшәдә икән. Иркен ага Ватан сугышында һәлак булучылар хөрмәтенә куелып, еллар үтүдән акшары купкан, кирпечләре таушалып вә кителеп тарала башлаган таштакта каршына килеп, исем-фамилияләр белән танышып чыкты. Йөздән артык авылдашы арасында Сәлахиләр фамилиясен йөреткән бер генә инсан да юк иде.

Үлән баскан иске сукмактан урамга чыккач, көтмәгәндә, теге Кырмыска Корбангали белән тагын очраштылар. Якыннан караганда, урта яшьләрдәге мөлаем генә бәндә икән үзе.

—Шәйхенур абзыйны әйтәм. Картаеп бара, һаман салыштыра. Аны мин дә эчә идем... Фермер хужалыгы оештыра башлагач, ташладым да

куйдым...—Ул күптәнге танышлардай. зарларын сөйләп китте.—Йөз гектар җирем, иске булса да ике тракторым, комбайным бар.. Кешеләрем, кулдашларым юк. Килмиләр. Искедән китәргә, яңага килергә теләмиләр. Авылны гөл итәсем килә. Юк, теләмиләр. Авылның яртысы ишек алдын себерми, йорт-җирен карамый, кунакка йөрешми, җиләк-җимеш, агач-фәлән утыртмый, хәтта сыер да асрамый. Бары тик дәүләтне... башканы гаепли дә аракы эчә. Нишләде бу халык, абзый, ә?

Иркен ага авызын ачып өлгермәде, караса—тырыш булганы өчен кырмыска кушаматы алган Корбангали китеп тә барган.

Сентябрь кояшының сүрән нурларында җылынып яткан тупса аша ул хакимият бинасына керде. Берничә хисапчы хатын утырган бүлмә аша аны эчкә үткәрделәр.

Ишектән үк карашы беренче булып Президентның ат башын кочаклап төшкән сурәтенә төште. Сурәт сабантуй мәйданы кебек иркен, буш өстәл артында утырган әфәндене нәкъ баш өстендә иде. Иркен-аганың сурәтне моңа кадәр кайдадыр күргәне булды кебек. Конгресстан сон—Питрәчтәме? Әллә Иман әфәндене аракы фирмасындамы?

Кырык яшьләр чамасындагы, тәбәш гәүдәле, җылы көнне дә башыннан аягына кадәр күннән киенгән, йөзенең уң ягында төймә кадәр миңе караеп торган рәис таныш булмаган кешене урыныннан торып каршылады. Руслан Закирович икән. Ул, кунакның Америкадан икәнлеген белгәч, тагын да җанлана төште. Әлбәттә, бик тә аптырады:

—Монда американецлар йөреп ята, ә без йоклап ятабыз!.. Ни хәлләрдә килеп җиттегез? Кемгә, күпмегә килдегез?

Иркен ага кыскача гына аңлатып бирде.

—Сез Мамадышка... Илгиз Галиулловичка сугылмадыгызмы?

—Юк... Без бик ашыктык.—дигән булды Иркен ага.—Вакытыбыз бик тә накыс иде.

—Сугылырга кирәк иде!.. Илгиз Галиуллович искиткеч кеше җанлы кеше!.. Сугылган булсагыз, ул миңа күрсәтмә дә төшергән булыр иде...

—Зыян юк... Без канәгатьбез. Халык ифрат та күркәм, кунакчыл. Кичә мәптектә укучылар белән дә очрашып өлгердек!..

—Һы. Дамир Хажиевич булдымы?

—Әйе.

—Һы.—Рәиснең бармаклары өстәл өстендә биештерде.—Кемнәрдә тукталдыгыз?

—Сихәт-сылу... Шәйхенур-кардәшләрдә...

—Сихәт? ТИҮдән? Һы...—Рәиснең йөзе карангыланып алды, бармаклары телефон тирәсендә биеште.—Һы...—Нәрсәдер сорарга итеп, туктап калды...—Һы... Инде дә, әлбәттә, миңа бит!... Хәбәрсез-нисез диген!..

Иркен аганың хәтеренә Сихәт-сылуның чишмә буенда «Хакимиятнең күзенә артык чалынырга ярамый...» дигән кисәтүе исенә төшкәч, дертләп куйды. Бирегә бу ханым белән кайтып дөрес эшләдеме? Бу аңа, аның улларына, абыйсына зыянга булмасмы? Тәҗрибәле психолог һәм дипломат Иркен-ага әле беренче тапкыр гына күргән рәис янына кирәкле сукмакны эзләде. Бу сукмак үзен балаларча эчкерсез, беркатлы, бернинди дәгъвәтсез кеше итеп күрсәтүдә иде. Мөһаҗир сүзләрен табып, рәисне район хакимиятенә кунгыратып мәшәкатьләнүнең һич тә кирәк түгеллегенә инандырды. Рәис моңа ышанды кебек. Бәлки, ышанган булып кыйлангандыр? Анысы Иркен агага мөһим дә түгел иде.

Рәис, ниһаять, һушына килгәндәй, урында җәелде, ярты сәгать чамасы җирле хакимияткә кергән авылларда колхозлашу, советлашу тарихын, үзе җитәкчелек иткән хозурда тормышның тынычлыкта, барлыкта-байлыкта

бернинди чөйсез-җөйсез, проблемасыз, рәиснең үз сүзләрен кулланып әйткәндә, «эксцессыз» дәвам итүе турында горурлык белән сөйләде. Проблеманы бар дисәк, ул халыкның мөнә ике елга якын инде эш хакы вә пенсия алмавында гына икән. Анысы да, ниһаять, иртәгә хәл ителәчәк. Шуна күрә иртәгәсе аның өчен бик тә кайнар булачак икән. Раславынча, авылда Сәлахиләр бөтенләй юк икән. Әмма рәис бер кызыклы фикер дә әйтте: унтугызынчы гасырдан егерменче гасырның илленче елларына кадәр ир балаларга фамилия итеп аталарының исемнәре бирелгән. Шуна күрә фамилияләр җинел генә үзгәрә килгән, имеш. Шуннан—рәиснең бу фикере дә кызыклы күренде—утызынчы еллар репрессияләре чорында авылдан шактый гына кешеләр Магнит-тау төзелешләренә куылган икән. Алар турында мәгълүматларны бары тик Федераль Иминлек хезмәте архивларыннан гына табып буладыр.

Рәис тынычсызлана башлагандай итте. Шулай да ул үзен кулга алды. «Акча җитми, колхоз эше бетми, әйдәгез, сәхрәгә чыгып, бераз чәйләп-мәйләп, сөйләшеп утырыйк»,—дип тәкъдим дә ясады. Әмма Иркен ага, рәхмәт әйтеп, тизрәк эшкә керешәсе килгәнен, сөйләшеп утыруны беразга сонга калдырырга теләвен әйтте. Шулай килештеләр дә. Тик шунысы, Иркен ага аның исемен-атын шундук хәтереннән җуйды. Ул аны шартлы рәвештә Күн Кеше дип кенә атады.

Күн Кеше белән сөйләшү Иркен-аганың күнелен күтәрмәсә дә, артык төшерә дә алмады: ул авылның башыннан башлап, йорттан йортка сорашып йөрергә кирәк, дигән фикереннән кире кайтмаска булды.

—Инде дә, әлбәттә, үтенечләрегез булса... нинди дә булса ярдәм кирәк булган булса, инде дә, әлбәттә, тартынып тормагыз, мөрәҗәгать итегез...

Тагын да рәхмәт белдереп, мөһаҗир авылның Үрге Очына таба юлга чыкты.

Шушы минуттан алып аны янә бер сөаль борчыды: Күн Кеше Биарысланнарны чечен фронтыннан нинәрсә хакына яшереп яткыра? Ана, хакимият рәисенә, егетне тотып тапшыру сукыр бер тиенгә дә тормыйдыр. Сихәт-сылу монын серен беләдер кү?

Шулай да ана рәхәт, дөресрәге, газаплы рәхәт иде.

Авыл урамында кеше сирәк очрады, очраганнары да күбесе карт-корылар иде. Балалы йортта сер тормый, дигәндәй, кичә мәктәптәге очрашудан сон авылга әмерикан кайтуы, аның хәтта мәктәп бүлмәсеннән космик телефон аша Америка белән сөйләшүе турында бөтен авыл белә дип әйтергә мөмкин иде. Әйткәндәй, очрашуда булган берничә укучы каршы булды ана. Барысы да: сабыйлары да, сабый акылына кергән картлары да, Иркен-аганын чит-ят яклардан кайткан инсан икәнлеген әллә каян күреп, абайлап алып дигәндәй, юл читенә үк чыгалар, бернинди сорау белән баш катырмыйча, тыйнак кына елмаеп исәнләшү белән чикләнәләр.

Бакча башларыннан, сирәк кенә ихата эчләреннән торна кебек муенын сузган кое баганалары, инде көзге куе һавада оеп утырган печән эскертләре, алар янында тышаулы, арканга бәйләнгән, йә булмаса тәмам иркендә сикеренгәләгән атлар күренгәли.

Ул урамнан Сихәт-сылу сынын эзләде. Ул ана кирәк иде. Юк, күренми иде шул ул. Әнә, күпер төбенә җитмәстән туктап калган трактор янында берничә яшь кеше кайнаша. Кайдадыр тагын бер трактор пытырдап куйды. Авылда эшче көч бар икән әле. Ходай Тәгалә рәхмәте булса, тормыш дигәнен өзелде дигән җирдән ялганып китә бит ул. Әле тан салкыны югалып бетмәгән сукмак буйлап ул ярларын полиэтилен капчыклар, шешәләр, эрзин көпчәкләр, ташландык каз оялары, тимер-томыр, бетон-таш арматурасы биләп алган Чак-суга барып чыкты, аннан сон, вак таллык

басып киткән кечкенә күпер аша үткәч, чокыр-чакырлы юл ишарәте күркәм генә юлга әйләнеп, агабызны авыл буйлап алып китте. Чак-су тирәли утырган өянкеләр дә нәкъ авыл өйләре кебек карт, борынгы, таушалган, кайберләренең кәүсәләре урталай ярылып, юан ботаклары кулса-кулса итеп сынып төшеп, канаты сынган фантастик кошларны хәтерләтә иде. Йорт-җирләр барысы да диярлек бүрәнәдән, күптән ирләр кулын күрмәгән ихата-бакчалардан гыйбарәт икән. Һәркайда тормышка битарафлык үзен сиздерә. Янбашлары кәнкәеп төшкән өянкеләр арасыннан полиэтилен капчык күтәргән карт күренде. Ул туп-туры Иркен-агага килде дә:

—Кара кашлы мелиоратор син түгелме? Синме минем өянкеләремне корыттың?—диде һәм, начар күргән күзләре белән чәнчелердәй булып карап торганнан соң, өстәде:—Түгелсең икән. Кара кашлы мелиораторны эзлим. Өянкесез калдырды...

Монын да тенкәсе котырган иде, күрәсең. Һәм монысы да, Кырмыска Корбангали кебек, соравына җавапны да көтмичә, кире китеп барды.

Иркен ага күккә карады. Күк йөзе жете зәңгәр һәм ул реактив очкычларның ак буразналары белән сөрелгән иде. Теге Хромосом Сәйфетдинеч дигәннәре шактый зиһенле өрәк, убыргали, күрәсең, көндезге пенсияне төнлә көтеп утырса да, урыс армиясенең аппетиты уянганга чиксез шат булса кирәк.

Һәр йорт жире бәрәнге бакчасы белән тоташып, урыны-урыны белән коймаланган, кайберләре бөтенләй дә коймаланмыйча, аргы калкулыкларга барып төртелә. Йортларга аркылы салынган азбарлар артында, тартып-сузып кына җиләк—җимеш бакчасы дип атала алган агачлар арасыннан агарып утырган мунча күренә. Әле печән өсте бетмәгән, урак исә яңа демократия шартларында башланып кына килгән бу аралыкта кешеләр бик сирәк күзгә ташлана һәм мондый сирәклек йорт хуҗалары кайдадыр яланда эш белән мәшгульләрдер дигән иллюзия тудыралар иде.

Иркен ага таң калды: Шәркый Төркестан Кизләве һәм тарихи ватандагы Кизләүнең матди культурасы бер вә бердәм иде. «Милләтебез, төрле материкларда көн итүенә карамастан, милли мәгыйшәт, гомумән алганда, нинди дә охшаш тоем, хәтта ки бер төрле калыпларда калыплана,—дигән нәтиҗә ясады ул.—Менә шушы тоем аны башка меңнәр вә миллионнар арасында кабатлангысыз көчкә әверелдерә. Менә бу, әле ул исемен-атын бөтенләй белмәгән абзыйның бүрәнә араларына салып калдырган мүкләре, Төркестан Кизләвендәге Галирахман абзыйның йорт бүрәнәләре арасына салып калдырылган кондырак-үләнгә никадәр охшаган бит!»

Ташландык базлар, ямнар, таштан салынып, инде «эһ!» дигән мал тавышы да чыгармаган телсез абзарлар яныннан үтеп, ул, ниһаять, авыл очында тәрәзә капкачлары белән зәңгәрләнеп утырган йорт янына килеп җитте. Вакыты санаулы икәнлеген хәтереннән чыгармыйча, һәр йортта озак тукталмас, кирәк-кирәксез истәлекләр сазлыгына батмас өчен, һәр йортка керү белән сүзне шундыйрак тәртиптә тотарга кирәк тапты: ул—фәлән-фәлән, фәлән-фәлән җирдән, максаты—фәлән-фәлән, фәлән-фәләннәр турында белештермисезме һәм—нокта!

Әмма ләкин тормышның үз кануннары бар иде. Ул сценарийны үзе төзеп, нокта урынына өтердән, өтер урынына күпноктадан башлый иде.

Бәләкәй капканы ачу белән аңа өрмичә-нитмичә бозау чаклы бурзай ташланды һәм ул Иркен аганы өзгәли башлый дигәндә генә сыйпалана-иркәләнә башлады. «Хунвейбиннар этенә охшаган,—дип уйлады Иркен-ага.—Тәклә-Макан катыргасында этләр белән талатуның нәкъ менә шундый ысулы бар иде. Сиңа томырып килә дә, амаламый, томырылып килә дә—амаламый».

Азбарның ачык сәндерәсе алдына тугарылган арба белән янәшәдән сәнәк

тотып сырты белән торган ир кеше кемгәдер эчкәрегә эндәште:

—Астан бирәсеңме, әллә өскә менәсеңме?

—Астан да, өстән дә ярый,—диде азбар эченнән хатын-кыз тавышы.—Мина барыбер.

—Ярар, мен, алай булгач. Мин астан мәтәшермен.

Кемдер өченче кеткелдәп көлде:

—Безнең тел, белеп кулланса**ң**, шулай бай инде ул, малай!..

Иркен ага боларны борчыргамы-юкмы дип торганда азбар авызындагы печән йөгенә йөгереп килгән ир аны күреп калды:

—Карагыз, Әбугалисина! Кил, абзый, кил!..—Ул аны тартып китергәндәй китерде, кул биреп күреште. Печән оны каш кылчыкларына кадәр кунган бу кеше аны һич көтмәгәндә өерелтеп коча, мәһабәт колачында камыр кебек изә башлады.—Карчык, төш, безгә Әбугалисина килгән. Американың үзеннән! Сөт өсте кебек ап-ак!.. Хатын, өстән төш, дим, өстәл яп, дим бит...

Ул арада булмый шундый ук печән оннарын кагына-кагына, башына төрткеле ак яулык, өстенә вак чәчкәле яшькелт күлмәк, ак йон оек өстеннән очлы калуша эләктереп алган хатынкай сәндерә өстеннән төште дә, күз кырые белән кыяр-кыймас кына исәнләшкәндәй итеп, йортның ишегенә чумды.

—Әнкәсе, баздан салкын катык, бүгенге каймак, аннан тагы... теге кызыл бөрлегән белән кушып эретелгән сары майны да куй!—дип кычкырды ир хатыны артыннан.—Ә син, Кәтүк күрше, баздагысын, төнлә туганын карарсың!..

Ул да булмый абзардан:

—Әлеү-әлеү! Беттем-беттем!—дигән тавыш ишетелде һәм авыз читеннән тәмәкесен тырпайтып, кәпәчен баш очына чөелдергән, коры-карангы йөзле, капкынга капкан ун аягы белән сикерәннәп, кәтүк сыман кечкенә буйлы адәмзат килеп чыкты.—Беттем-беттем!.. Ну, Хажигали, әйттем сиңа капкыннарыңны шунда куйма дип!.. Печ итәргә кергән жирдән янбалит ясадың!..

—Анда бит стенага каләм белән «Тыелган территория. Крыса!»—дип язып куелган, әмиткә! Укый беләсеңдер бит?.. Туктап тор!.. Үлмәссең!..—Хажигали ашыкмыйча, гүя аерым бер ләззәт белән ун аягын капкынның тәжесенә басып, аның дугаларын ике кулы белән аерды, ашыкмыйча гына Кәтүккә мөрәжәгать итте:

—Капкыныңны өстерәп, медпунктка хәзер үк юлга чыгасыңмы, әллә йөз грамм эчкәч барасыңмы?

—Сорап торасың, тизрәк чыгар инде!—дип сызланды Кәтүк.—Син миңа хәзер үк бер стакан шоковый порция бирергә тиешсең!.. Үзенә печән өешәм тагын. Үтерә яздың!..

—Үзең барып кергәч...

Хажигали аның аягын капкыннан чыгарды. Кәтүк чатан-ботан килеп йөреп азапланды.

—Ярый, бармак сөякләрен измәсә...Синнән банкет!..

—Күрше хакы—тәңре хакы!... Нәрсә безгә—өйдә газ, күнелдә наз, бакчабызда саз! Чыжт иттек, кабына—утын да кирәкми.

—Әйдәгез, керик!

Ике ир ике яктан Иркен-аганы күтәреп диярлек салкынча өйгә алып керделәр.

Өйдә кухнә ягында мәшәләнгән хатыннан башка беркем күренмәде.

Ирләр өстәл артына утырышып алды. Өстәлдә авыл ризыгының барысы да, хәтта тары әйрәсе дә бар иде.

Иркен-ага тирә-ягына күз ташлады. Диварлар буш, аларда хатын-кыз чиккән чигеш тә, башка йортларда мотлак була торган эленмәле фотосурәтләр дә күренмәде.

—Ишеттек, ишеттек, Американың үзенән үк кайткансыз...—диде Кәтүк авырткан аягы белән өстәл астында тыпырдап.—Америкада бездән башка ничегрәк яшәп ятасыз? Безләрне искә төшерәсезме? Һо-һо-һо!.. Йә, сал инде, Хаҗигали!..

Иркен ага сүзне кыска тоту өчен әйтеп куйды:

—Борәдәрләремне эзлимен. Чыгышымыз белән без шушы авылдан.—Туганнарымны, дип әйтәмен. Авылда Сәлахиләр нәселе турында ишеткәнегез булмадымы?

—Юк андый кеше бездә! Моның өчен башта күтәрергә кирәк. Башта күтәрик, аннан... бергәләп эзләрбез!—диде Кәтүк.—Хаҗигали, нәрсә карап каттың? Сәлахиләр нәселен мәсәл белән сыйламыйлар, һо-һо-һо! Менә син әйт әле, абзый, Америкада Уфадагы Салаватка куелган кебек һәйкәлләр бармы?

—Ашыктырма, әмиткә!..

Кәтүккә үз исеме белән эндәшүче дә, бу «әмиткә»нең нинәрсә икәнлеген төшендерүче дә юк иде.Баксаң, Хаҗигали һәр якынына дус итеп, «әмиткә» дип эндәшә, аның үзенең халыктагы атамасы да «Әмиткә» икән. Аракы күрү белән калтырана башлаган, авыр эштән хоккей шакасы сыман суккаланып беткән куллары белән шешәне ачып азапланды.

—Әмрикә иң күп һәйкәлләр иле. Ул эшләп арыганнан соң һәйкәл куя. Бигрәк тә ат өстендәге генералларга. Һәр зур шәһәрдә генералга һәйкәл. Әгәр ат ыргыган килеш торса—генерал, димәк ки, орышта һәлак булган. Әгәр уң аягы күтәрелгән икән—ярадан шәһид киткән, димәк. Әгәр ат дүрт аягында басып торса—димәк ки, генерал урын өстендә, өендә үлгән булып чыга, солтаннарым...

—Кара син аны, ә?! Дүрт аягында торса, үлә икән, ә?! Без кайчакта ике аякта да чак йөрибез...—дип тел шартлатты Кәтүк.—Син дөрес әйтәсең, без—солтаннардан. Мин, мәсәлән, үзем Солтанов. Сәлахиләрне белмим. Ишеткәнем дә юк...

—Бездә һәйкәл өчен сурәт ясарлык та ат калмады,—диде кырыс кына Хаҗигали.—Аның каравы хуҗасыз эт күбәйде. Кәнтәй этләргә һәйкәл куя башларга кирәк.

—И-и-их... Өзәсең үзәкне!.. Кәнтәй хатыннарга, диген!..

—Субсидия!..—дип кычкырып җибәрде Хаҗигали һәм, ниһаять, эчемлек салынган бәллүрләрне калтыранган куллары белән урнаштырып чыкты, аннан тагын хатынын—аның исеме Субсидия икән—күз чиртеп кенә чакырып, ана да бәллүр тоттырды. Һәм эчеп тә җибәрде. Иркен агадан башкалар да эчеп куйдылар.

—Ләкин, абзый кеше, Американың атлы һәйкәлләре барыбер дә башкортның Салаваты астындагы ат һәйкәленә җитмәс...—Эчендәге утлы ягулыктан ләззәт кичергән Кәтүк илһамланып сөйләп китте:—Ул шундый зур, авырлыгы, мин сезгә әйтим, җитмеш тонна чуен, ди. Үзем кереп тотып карадым, теге корсак астына таккан гере генә дә бер тонна булыр... Көн саен аны, ук-җәя тотып, башына төлке бүрек кигән унике башкорт саклап тора. Үзем күрдем, бәй, күрмичә!.. Бер тапкыр шулай, башларына аю тиресе кигән икенче бер кабилә башкортларын чукеч-кискечләр белән һәйкәлнең яртысын бүлеп алып китәргә азапланганда тотып алдылар, малай... Сакламыйча, кәк же? Югыйсә, аны бит әллә кайчан Агыйделгә тәгәрәтеп төшерерләр иде!..

Иркен-ага бәллүренең кузгатылмый торуын күреп, хуҗалар тәмам

аптырады. Очрашу хөрмәтенә? Американың үзеннән кайтып? Ата-бабалары шушы Кизләүдән чыккан була торып?!

—Субсидия, жырла, әмиткә! Жырлап эчерик!..

Үзе шундук жырлап та куйды:

Ай-ли, Жәмилә,
Жәй көннәре жәмле лә...

—Әй, синең авызыңа йөз грамм керсә, шул Жәмилә дә Жәмилә булыр инде, Хажигали,—диде хатыны.

Эш онытылган, сүз онытылган, йомыш онытылган иде. Хәмердән шундук йомшарып, авыз тирәләре чиләнеп алган Субсидия Иркен-ага янына ук килеп утырды һәм жырлап та жибәрде:

Алмалы гына куак, түгәрәк күл,
Анын тирә ягы ла кызыл гөл, ай,
Эчкенәең тулы хәсрәт булса, ай,
Ятларга сөйләмә, үзең бел...

Жыр матур, жырчының мәкаме камил, сүзләренең мәгънәсе тирән булса да, аның үзенә тап килсә дә, эчмәде Иркен-ага. Хужалар аңа бәйләнүдән туктап, үзләрен генә карар булдылар.

—Аны беркем дә эчәм дип эчми инде...—дип фәлсәфә куерта башлады Хажигали.—Менә мин дә эчә торган кеше түгел ул как такавай. Мин ике кешедән торам: беребез—Хажи, икенчебез—Гали. Миндә көне буе Хажи белән Гали көрәшә... Хажиым «Эчмә!»—ди. «Гали»ем «Эч!»—ди. Ахырда Гали Хажины жинә дә, мин Хажигалигә әйләнеп, сыгылам да төшәм...Эчелә шул, туганнар, эчелә. Әүвәлдә кешене уббажать итеп эчәсен...

—Әй-йе!—диде Кәтүк күзләрен түшәмнән үк әйләндереп.—Уб-бажение харап итә бездә кешене. Моны Мәнди анасы да белә!..

—Аннан мин кешедән киммени дип эчәсен...

—Әййе!—диде Кәтүк өстәл сугып.—Дөр-рес, Хаж-жигали абзый!..—Мин кешедән киммени дип эчәсең! Әйдә, эчик әле!..

—Аннан инде үземне-үзем уб-бажать итеп эчә башлыйм. Башлыйм да кәндисигә житәм. Менә ул уб-бажение кая илтә, туганнар. Чөнки күңелем саф...

—Әйе!—диде инде исерә барган Кәтүк.—Күңелеңнең сафлыгы башкаларга йога күрмәсен, Хажигали абзый! Минем комбатым майор Попов әйтә торган иде: «Эчәргә кирәк. Эчмичә яшәп булмый. Әмма кем белән, кайчан һәм күпме эчәргә икәнлеген белеп эчәргә кирәк». Вәт!.. Миннән үрнәк ал, Хажигали, сал, саранланма!.. Ә нигә эчәм мин? Ашарга житми, шуңа эчәм!.. Америкада эчәләрме?

—Эчәләр. Хәтта күп эчәләр...—диде Иркен ага тәмам кәефсезләнеп.

—Алар белән безнең эчү арасында нинди аерма бар?

—Анда ашап эчәләр—кырылмыйлар. Рәсәйдә ашамыйча эчәләр—кырылалар. Ашап эчкән халык аңын югалтмыйдыр күү. Рәсәйдә жинаятьләрнең сиксән проценты исерек килеш кылынса, Әмрикәдә ул ун процент кына тәшкил итәдер. Әмма Әмрикәдә бернинди кайгы-сагыш юк икән, дип уйлый күрмәгез тагы. Анда да үтереш-суеш житәрлектер. Әмрикә нисбәтеннән караганда, ачлар анда да бар. Моны аңлау өчен Нью-Йоркның үзәк урамы—Бродвейдан үтү дә житә. Ул утыз чакрымга сузыла. Анда утыз мең хәерче!..

—Алдашма, Америкада хәерчеләр юк!. Анда миллионерлар гына яши,—диде Кәтүк.—Үзем күрдем.

—Утыз мең автомобильле хәерче!—дип төзәтте Иркен ага.

—Утыз чакрымга .. утыз мең автомобильле хәерче! Шулай диген!.. Бер чакрымга бер хәерче, димәк. Бездә дә шул чама инде...

—Гомумән, Әмрикә мавыктыргыч ил...—Очрашуны шунда чикләп, чыгып китәргә җыенган Иркен-ага, унайсызланып, туктап калды.—Аның һәр штаты нинәрсәдер белән дан тота. Әйтик, Висконсин—сөт чүлмәге. Айдахо—бәрәңге бакчасы... Ә менә кытайлар бәрәңге ашамый...

—Кара, бу кытайлар бөтенләй дә дүрәк икән!..

Хуҗалар, бигрәк тә исереп беткән Кәтүк, айныгандай булдылар.

—Бәрәңгесез... ничек?! Сал, Хаҗигали абзый, моның өчен эчмичә булмый, әмиткә!

—Аларның бәрәңгесе—дингез суүсемлекләре...—диде Иркен-ага.

—Суүсемлеге мин ул...—Эчемлекне үзе теләгән кадәр эчеп исергән Кәтүк аягы авыртуын да онытып, Иркен-агага бәйләнә башлады.—Алып кит мине Америкага, ә? Анда минем кебек берәү дә юктыр... Алып китәсенме, юкмы?—Ул аның беләгенә асылынып сөйли башлады:—Миндә сезнең берегездә дә булмаган горурлык бар... Сезнең ул хакта уйланганыгыз да юктыр әле. Япуннардан кала атомнан нык кыйралган икенче халыкның кем икәнлеген беләсезме? Белмисез! Япуннардан кала атомнан ин нык кыйралган халык—татарлар!.. Ә мин шул халыкның улы... Хиросимадан соң икенче атом бомбасын маршал Жуков кайда шартлатты? Ырымбурның Тоцки лагерьләрендә, татар авыллары өстендә!

—Авылларны күчермәделәрме?

—Урыс авылларын күчерделәр. Татарлар калды.

—Ходай безне хатынлы, Жуков безне атомлы итте!...Ха-ха-ха!..

Хаҗигали буылып көлде.

—Итте шул!.. Нинди горурлык!.. Өченче атом кайда шартлады? Чиләбенең «Маяк» заводларында—шул ук татар авыллары өстендә шартлады... Ыслушшай-те, әнә шул вакыйгаларга егерме ел үткәч,мине , Кизләү малаен, шул «Маяк»ка илтеп тыктылар бит. Мин бит Чиләбе-70-тә хезмәт иттем...

—«Маяк»?—дип кычкырып җибәрде Иркен ага.—Бу бит миллионер Гани бай Хөсәенов җирләре!.. Андагы тауларны әле дә «Хөсәен таулары» дип йөртәләр...

—Ә сез каян беләсез?—диде Кәтүк аңа исрек балык балык кебек оеган күзләре белән укталып.—К-к-каян б-беләсез?

—Ырымбурда яшәгән тарихчыбыз Мәдинә Рәхимкулова китапларыннан. Гани бай ул тауларда комташ яндыру заводлары тоткан. Йомырка сарысында гына изеп, махсус кирпеч житештергән. Уфадагы «Галия» һәм Уралдагы башка мәдрәсә-мәчетләр барысы да шушы шартлатып та җимереп булмый торган кирпечтән төзелгәндер кү...

—Һы!.. Эчеп исергәч кенә елмаям мин хәзер!—Кәтүк ыржаеп күрсәтеп елмайды.—Матурмы мин? Шундый матур, хәтта өйләнә дә алмыйм... Әмма... япа-ялгызым яшәп, кызлар түгел, казлар үстерәм!... Ә бит мин, Иркен абзый, өйләнгән дә идем...Минем өчен дүртенче атом үз өемдә шартлады...—Ул башын ике учына салып ыңгыраштыда, сирәк чәчләрен җилкендереп артка ыргытты.—Командировкада идем... Кайтсам, минем чибәр хатыным—чит ир белән!.. Син, Хаҗигали абзый, барысын да беләсең!..

—Сөйләмә инде!—диде Хаҗигали.

—Сөйлим!.. Америкада да белсеннәр минем хатынны...Мин аны нишләттем, дисең? Судка бирдемме? Аердыммы? Юк, мин җир белән тигезләдем. Таста җылы суда аякларымны юдырдым һәм, бүтән хыянәт итмим дип ант иттердем дә, шул суны үзенә эчердем!.. Аннан, кулына акча тоттырдым да, куып чыгардым. Үн ел килеп, ялынып йөри. Кертмим!..

Шуннан бирле, кызлар түгел, казлар үстерәм мин...

Шуны гына көткәндәй, күрше ихатадан казлар гагылдады.

—Минекеләр!.. Монда, күршедә генә мин, казларым!... Кер, кунакка кер, абзый... Каз пешерербез...Хәрби хезмәттә радиациядән мин шундый шаукым алдым, сәбәпсез елмайсаң, тирем тартыла да, ниндидер нурлар-аллергоннар кеше тиресенең иң йомшак, иң нәфис урыннарын ерта да чыга... Әйтик, иренне... Шулай итеп, ирен ияккә кадәр ярыла да төшә, мин сиңа әйтим... Мондый радиацияны алучылардан мин бездә бердәнбер татар бит... Ничек горурланмыйсың!.. Алып кит мине Америкага, ә? Атом нурланышыннан исән чыккан татар дип, спиртка салып, музейда сакларлар иде... Ә сезгә...—Ул Хажигалиләргә баш какты.—минем пенсияне түләрләр... Алып кит, ә!..

Мулла, мулла, мутина,
Мулла абзыйның күзе төшкән
Сажидәнен ботына...

Ул үксегән аһәннәр чыгарды да, башы белән өстәлгә бөгелеп төште.

Болар барысы да коточкыч иде.

Көтелмәгәндә, гүя аның хакына гына оештырылган сәрхүшлек табыны өчен Иркен-ага бик уңайсызланды. Нишләргә соң? Ничек хәлдән чыгарга? Ул бит кеше авызына йозак сала алмый.

Хужаларга тәмле ризыклар-чәйләр өчен рәхмәтләр әйтеп ишеккә юнәлде.

Хажигали белән килен озата чыктылар.

—Нәрсә—«Маяк»?—диде Хажигали.—Бу армиядә алган чиренә колхозның химик ашламалар сараенда да өстәде. Шунда эшләде, шунда йоклап та йөреде...

Хатын белән ир абзарга, бая Иркен ага керү унаеннан бушатылып бетмәгән йоккә таба юнәлделәр.

Ни гажәп, Иркен-аганың артыш таягын, әллә сарысына кәрәз дип алданып, бал кортлары сырып алды. Карт аптырады. Каян алар—мондагы Кизләүнекеме, әллә үз кортлары—Шәркый Төркестан, Висконсин Кизләвеннән үк океан аша очып килгәннәрме? Күз алдына юл буйлап төрле төстәге умарталыклары белән Висконсин болыннары килеп басты. Анда һава бал кортлары белән мыжгып тора, еш кына корт автомобильнең радиаторын сырып ала да, моторны кыздырып, подшипникларны эретә. Андый чакта радиатор буйлап сары бал ага...

Ул моны яхшыга юрады. Берничә бал корты аның таягыннан төшмичә авылы буйлап сәяхәткә чыкты.

Иркен-ага Хажигали күршесе Кәтүкнең тыштан бик тә яхшы каралган йорты аша атлап, өченче ихатага үтте. Ишек алды биек бәпкә үләне белән түшәлгән иде. Шакыды. Жавап бирүче булмады.Сәлам биреп эчкә үтте. Сәкесенә арты белән утырып, мөнәжәт иткән әбекәй чынлап та колакка шулкадәр каты иде ки, ул хәтта керүен дә шәйләмәде. Башта Иркен-ага аның мөбәрәк тәсбихләрен өзмичә, шундук чыгып китәргә дип тә уйлады. Әмма аны матур мәкамле мөнәжәт һәм киштә тулы китаплар туктатты. Кем белә, бәлки эзләгәне шушында табыла башлар? Тышта кояш, өйдә Корьән-Китаплы киштә-сәке һәм сиксән яшьтән дә ким булмаган мөнәжәтле карчык иде.

Кечкенә, әмма идәннәренә асалы палас җәелгән, тәрәзә кашагаларында әле булса чүпләмле тастымаллар эленеп торган бу уймак йортта әдәпле, иманлы картлык хөкем сөрә иде. Сары камзулдагы карчык кулына дисбесен

тотып, алтын уймак кебек итеп тез бөкләп алган да, көйли дә көйли:

Газраил жаныңны алур,
Варислар малыңны алур,
Сиңгә саваплары калур,
Аллаһ, дигел, бәдәвам...

Карчык шаукымда иде. «Бәдәвам»ның азагы булмас, бүлдермим, дип уйлап чыгып китәргә чамалаган Иркен-аганы әбинен өлкән яшьтә булуы, аның нәселе хакында чынлап та нинәрсәдер белү мөмкинлеге туктатып калды.Әгәр карчыкка сиксән яшь чамасы булса, димәк ул 1917 елгы, утызынчы еллар башында аңа 13-15 яшь булган. Бу бит инде күп нәрсәләрне хәтердә калдыра торган ушлы чор.

Карчык кузгалгалаганда турыдан бәйләнгән яулыгы астыннан чәчүргеч очындагы көмеш тәңкәләре чынлап куя. Чулпы тавышын өркестан Кизләвеннән киткәненнән бирле ишеткәне юк иде. «Шушының өчен генә дә кайтасы болады».

Карун зикер әйтмәде,
Аны шуңа йир йотды.
Жәһәннәм төбенә китди,
Аллаһ, дигел, бәдәвам...

Колакка каты булса да, ушлы иде булса кирәк, артында ниндидер чит тын тоеп, борылды—һәм таныш түгел, әмма бик мәһабәт ир сыны күреп шомланып калды. Карчыкның йөгрек күзләре йөгереште. Турыдан бәйләнгән яулыгы астыннан майлап тараган чәчләренең алтын ызаны чак кына күренеп тора.

Әмма бу шомалану һич тә курку түгел иде. Иркен-аганың аны тынычландырырга тырышуына керфеген дә кымшатмыйча колак ярырлык итеп кычкырды:

—Кеше ишетсен дип каты кычкырып сөйләшәм!.. Кеше дөбердәсә, мин алардан да катырак дөбердим... Үзем ишеткәнче дөбердим... Ишетмиләр бит, чукраклар!..—Ул елмайгандай итеп мөһәжир ягына башын сузды.—Чыгып китми тор... Миңа кеше сирәк керә... Әйт, бәй, ни йомыш?..

Иркен-аганың язмышын, максатын сөйләп, карчыкны ялкытасы килмәде. Бары тик бер нәрсә сорады—ул да булса, сабый чагыннан алып, авылда Сәлаховлар дигән нәселне хәтерләмиме?

Карчыкның акылы чынлап та аек иде. Ул кан тамырлары зәңгәрләнеп торган кулларының сыртын берсен-икенчесе белән сыйпый-сыйпый озак кына уйланып торды да:

—Безгә мулла булып килгән кеше түгелсең микән дигән идем...—диде.—Тирә-якта бер мулласыз без генә калдык. Үзебезнекеләр тәмам исерешеп бетте. Женаза намазы укып, кабергә куярга кешебез дә калмады...

Иркен ага үтенечен янадан кабатлады. Карчык шактый өметле фикер дә әйтеп куйды кебек:

—Сәлаховлар... Сәлаховлар...Нигә, булмас димә, булгандыр. Калхузлашу башланган чорда авылдан жиде-сигез гаиләне сөрделәр бит. Мулла-мунтагай, кулак ясап. Түбән очтагы Рәжәп абзыйлар... шул Сәлаховлардан булмадылар микән? Хәзер авылда Сәлаховлар юк бугай шул... Син Түбән Очта...—Карчык уйланып туктап калды.—Түбән Оч Мөкәрәмәләргә кереп кара әле. Күп укый ул... Аңарда берәр нәрсә килеп чыкмасмы... Аннан, без бит йөз генә еллаган яшь авыл... Без бит борынгы Тау Иле авылыннан качып килгән халык...

Иркен-ага карчыкка чиксез рәхмәтле иде. Исемен Мөсаббихә икән. Нинди сирәк исемнәр. Үзләре генә дә бер энциклопедия диярсен... Ул кенәгәсенә карчыкнын һәм ул әйткән Мөкәрәмә апа-жаннын исемен теркәп куйды.

—Суга гына камыр изгәнием, пешереп алыйммы? Ашыйсынмы?—дип сөйләп китте күзлекләре танау очында гына эленеп торган карчык бар дөньяга ишетелерлек итеп кычкырып.—Син суга гына изелгән камыр коймагы ашаганын да юктыр әле, әйеме? Бик тәмле була ул, камыр үз көченә әчегәч!..Ярлы кеше кебек, аерым хәстәр сорамый...

—Юк, апа-жаным, рәхмәт!..

—Мин үзем керәшен кешесе белән белән гомер кичердем, дунгыз итен өемә кертмәдем...

Ул Мөсәббихә карчыкка сәдака бирде. Карчык күп бирәсен дип, кабул итми маташты. Ниһаять, фатыйхасын алганнан сон, бу рәхмәтле йорттан чыкты.

Алдагы ике хужалыкта тормыш каны типсә дә, жан әсәрәсе очрамады. Йорт-жирләрен ачык калдырып, алар каядыр киткән иде.

Чираттагы йорт ихатасына кергәндә азбардан артына ут капкандай бер ир килеп чыкты да аны күреп, кычкырды:

—Кермә, кермә, вакытым-чиратым юк! Чебеш чыгарам!..

Иркен-ага анлап та өлгермәде, йортнын урам ягындагы тәрәзәсе ике якка ачылды һәм аннан кавын кебек сап-сары баш күренде:

Минем инкубатор яхшы эшли,
Сикереп кенә төшә чебешләр!...

Һәм бу Баш тәрәзәләрен шапылдатып япты.

Шушы йорт белән алдагы йорт арасына китереп бушатылган сары комда уйнаган алты-жиде яшьлек кызчыкка тап булды ул. Авыл баласынын тормышка зурларча һәм иртә яраклаша белүен ярата Иркен-ага. Шушы ком кебек сары чәчле, авыз читләреннән әле генә эчкән катыгы да кибеп өлгермәгән сабыйдан ул уйнап кына сорашмакчы-сынамакчы булды.

—Сыерыгыз бармы?

Куллары белән комда казына-казына, комнан күзен дә күтәрмичә, ул иң житди сорауларга да анык жавап бирә башлады.

—Бал.

Теленен очы шәмәхә каләмне төкрепләп сурәт төшергәнгә күрә булса кирәк, шәмәхә-көрән төскә кергән иде.

—Бозауладымы?

—Бозаулады.

—Үгезме, танамы?

—Үгез дә, тана да.

—Икене китерде мени?

—Сыеллалыбыз икәү.

—Менә кандай! Сарыкларыгыз бәрәнләдеме сон?

—Бәләнләде. Салыклал да, кәжәлал дә.

Ул сабыйны кочаклап үпте һәм үзе дә сизмәстән кычкырып жибәрде:

—Сөбханалла! Әссәламәгәләйкүм, булачак милләт анасы!..Әле яшибездер кү!..

Ул бәлигъ һәм ата-анасы янында булмаган сабыйга һәдия итеп акча бирергә уңайсызланды. Ул өстендәге вельвет курткасына кадап куелган миниатюр Әмрикә туграсынын каптырмасын ычкындырды һәм аны кызчыкнын күлмәк якасына эләктереп куйды.

—Нәлсә бу?

—Бу тәти уенчык. Сиңа бүләк итәмендер.

—Ләхмәт.

Аның бу сабыйдан һич кенә дә аерыласы килмәсә дә, туган-тумачаның очын тизрәк табу туктаусыз алга, бары тик алга чакыра иде.

—Монда кемнәр яши?—дип сорады ул сабыйдан тәрәзә капкачлары һәм тимердән ясалган урам капкалар зәңгәр белән ак буяу аралаш буялган йортка күрсәтеп.

—Ачулы Залифлал.

—Нигә ачулы?

—Ул гел ачулы.Көлми.

—Синең исемең ничек?

—Зөбәлҗәт, диләл.

—Ә син кем кызы?

—Ачулы Залифныкы, диләл. Ул минем әтием булгание...

—Хәзер әтиең түгелмени?

—Хәзел әтием Хәләф. Без авылның теге башында яшибез.

«Күрәсең, әнисе икенче кешегә кияүгә чыккандыр,»—диеп уйлады Иркен-ага.

—Бу әтиеңә кермисеңмени?

—Чакылса, келәм.

—Монда уйнарга киләсеңмени?

—Әйе. Чакылмаса да, уйналга киләм...

«Вәт бу Ахырзаман баласы». Ачулы булса булыр инде дип, ул аклы-зәңгәр капканың тимер келәсен зыңгылдатмыйча гына үтте. Ишек алдында эт-мазар күренмәде. Ишек алды ялап алгандай себерелгән, бакчадан кызыл балан-миләшләрнең явы өскә ишелеп тора. Бирелә яхшы хужа, күрәсең. Алдарак, чөйләрендә ат камыты, дуга һәм башка дирбия эленеп торган келәт белән азбар арасында, бераз гына эчкәрәк кереп җәелгән чүпрәк паласка таратылган суган өемнәре арасында аңа арты белән утырган, төрле тырысларга төрле эрелектәге суганбашлар аеру белән мәшгуль ирне күреп, Иркен-ага туктап калды. Ир дә сак колакларына арттан савылган аяк тавышларын чамалап, башын аңа таба борды.

—Әссәламәгәләйкем, кардәшем.—Иркен-ага ике кулын сузды.

—Сәлам, сәлам.—Ачулы Зариф булырга тиешле кеше мосафирны кара карашларына чумдырып алды да ике бармаксыз уң кулын бирде.—Мә, бер ирләр кулы тот.—Авыр эштән булса кирәк, аның бармакларының тырнаклары ояларыннан купыраеп чыккан иде. Үзен бергә казлар көтеп үскән малай кебек иркен тотып сөйләшүе Иркен агага ошады.—Ишеттем, ишеттем, ниндидер Сәлахиләрне эзләп Америкадан ук кайткансың икән. Анысына маладчина, әлбәттә... Таба алмаячаксың син аларны монда.. Монда теге гасырдагыларны түгел, кичә генә гербицид агуыннан кырылган кордашларны табып булмый... Ярый, силсәүит алтмыш ел элек Ватан сугышында үлгәннәрнең исемлеген белми, монда үлгәннәренә ун ел үтмәгән—барыбер исемнәрен белмиләр!.. Кая ди анда кәк пәгибши пенсия түләү?!—Ул йортның ачык, зәңгәр чыбылдык белән капланган ишеге ягына карап кычкырды.—Зөлхәбирә, кешегә урындык чыгар, ишек алдына кеше кергәнен күрмәскә күзең чыккан мәллә?

«Билхаккый ачулы бу».

Өйдән урындык күтәргән яшь, матур гына хатын килеп чыкты, таныш булмаган ир затын күргәч, башыннан шуып төшкән яулыгын төзәткәләгәндәй, ярымачык күкрәген кулы белән каплагандай итте дә, чак

кына ишетелерлек итеп сәлам бирде һәм тавыш-тынсыз гына кире кереп китте.

—Утырып җибәрегез. Урыс әйтмешли, басып торган аяктан дөреслек качкан.

Иркен-ага Ачулы Зариф каршысынарак утырды.

Сары төстәге бәйләгән джемперы изүеннән дингезчеләр кия торган зәнгәр дулкынлы эчке күлмәге күренеп торган, шомырт кара күзле, берничә көн кырылмаган, башына кара кәләпүш чәпәп алган Зариф, Иркен-ага сизенүенчә, үзенә бер төрле, кылчыклы инсан иде.

—Йә, сөйләп җибәрегез, Америкада тормышлар ничек? Анда да бәрәнге ашыйлармы?

—Ашыйлар...—Иркен-ага әллә уйнап, әллә уйлап соралган бу сорауга ничек җавап бирергә белми бераз торды.—Әмрикә бәрәнгенең ватаныдыр кү. Христофор Колумб Европага бәрәнге, помидор, һәммә төр салат, кактус, фикус, тәмәкене Әмрикәдән алып кайтадыр кү...

—И-и-и, син белгәнне без киптереп элгән! Салат-малат, кактус-мактус, фикус-микус!.. Иң мөһимен оныттың. Христафур Калуп Америкадан тагын бер татлы тамыр—ул да булса сифилис алып кайта. Кеше ашаучы хатыннар белән йоклап... Безгә бу хакта клевер чәчкәндә лекция сөйләп киткән партком Икзим Фәрдүнәтович сөйләгән иде. Ничек ачуың килмәсен, малайкаем!..

Иркен-ага йөзен чытты.

—Гинекология дигәнне, үзебезчә әйтсәк, тишек чирләрен тикшерү була, шулай бит? Мин аны «жен-экология» дип атыйм...Син көлмә, хатын-кыз женле җан иясе. Хәзер тишек корты белән чирләүчеләр бездә дә очраштыргалый... Нифте бездән китте-бетте, алмашка чир килде, ничек ачуың килмәсен, малайкаем. Хәер, һәр җан иясенең үз корты була инде, шулай бит? Тормыш бар җирдә корт та бар. Менә суганны гына алыйк. Әчедән әче нәрсә. Аның да корты бар. Анауы миләшләрнең дә үз корты бар...—Ул чиләкләргә алмаш-тилмәш суганбашлар ыргытудан туктап торды.—Менә син әйт, бармы Америкада җир тетрәүләр? Бездә көн саен тетри. Нифте чыгарып, җир асты буш калды. Бушлыкка су җибәрәләр дә, җир гөрселди дә төшә!..

Урамнан майламаган тәгәрмәчләре белән шыгырдап печән йөге үтте. Йөк өстеннән берәү Ачулы Зарифка нәрсәдер әйтте.

—Бара алмыйм, малай,—дип җавап бирде ана Зариф.—Куна-гым килде!..

Бу адәмзатта нииндидер яшрен чикләвек төше бар иде кебек. Сөйләшүне бөтенләй икенче ызан—читкә сукалаудан башлаган Ачулы Зарифның нәрсә әйтергә теләгәнен белүе дә читен иде. Иркен-ага эчтән нииндидер ярсу белән ярсыган, ләкин аны тышка чыгармыйча, үзенә бөтенләй «кирәге булмаган» әңгәмә корып азапланган кардәшен житди гәпкә алып кереп тынычландырмакчы булды.

—Әмрикә табигате берлә Азиягә охшаса да, анда җир тетрәүләр, тайфуннар, су басулар бик сирәк күренеш...

—Оҗмах икән!.. Ничек ачуың килмәсен!..

Бакча артыннан үткән тау юлында Күн Кеше чагылып алды.

—Әйе, оҗмахтыр кү. Бу, минем уйлавымча, температураларның капма-каршы төрлелегеннән килә. Караңыз: төньяк Әләскедә гыйнвар уртасында температура минус алтмыш биш, ә шул ук Әмрикәнең Мексика берлә чигендә плюс утыз алты. Тирбәнеш 110 градус тәшкил итә.Төркестанның Тәклә-Макан чүллекләрендә дә шундый ук тирбәлеш...

Ачулы Зариф авызын ачып каткан иде.

—Әмрикә халкы мондый тирбәлешкә нихәл түзә?—Ул эре башлы суганнарны ачуы белән тырысына атты.—Шуны гына сөйлә!..

Юк, ахмак түгел бу Ачулы Зариф дигәннәре. Үзендә Хуҗа Насретдин белән солдат Швейкны кушкан бу инсанның миен ниндидер бер сәер витамин тукландыра түгелме?. Бу көтелмәгән сораудан мөһәҗир үзе дә аптырап калды. Гомерендә беренче тапкыр аны шушы кеше—туган җирендә вә туган авылында!—Әмрикә халкының шушы тирбәлешкә түземе хакында уйланырга мәҗбүр итте.

—Әмрикәннәрнең үзләренә дә шундый төрлелек хас...—дип башлап китте ул сүзен.—Анда төрлелек күзгә бәрелеп тора. Анда... бертөрлелеккә түгел—төрлелеккә, охшашлыкка түгел—аерымлыкка, унитарлыкка түгел—чуарлыкка күнеккәннәр. Охшашлык—Әмрикәнең дошманы!.. Юкка гынамы, аның егерме биш центлык акча тәңкәсендә «Бердәмлек төрлелектән яратыла»,—дип язылган...

—Безнең кебек инде! Без дә төрле бит...—дип кычкырып җибәрде мыек астыннан елмайган Ачулы Зариф.—Әнә, син дә кара түбәтәйдә, мин дә кара түбәтәйдә!.. Тик синекен Президент бүләк иткән, моны телевизордан күрсәттеләр. Синекеннән хушбуй исе килә, чөнки син—импортный татар! ... Ә минә минекен телевизордан күрсәтеп маташмыйлар—минем кәләпүш тозга, тиргә каткан, аңардан...—Ул түбәтәен салып иснәде.—Фу, милли ис аңкый!.. Ничек ачуың килмәсен!..

Иркен-ага рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аның күптән инде мондый ихласлык белән көлгәне юк иде. Аңа ияреп Ачулы Зариф та эре тешләрен күрсәтеп елмайды. Әңгәмәнең уртак зәме барлыкка килүенә куанган мосафир кулы җиткән җирдән суганбашлар чүпләштерә башлады.

—Авылда... милли хәрәкәт бармы соң?

—Милли хәрәкәт, имеш!—Зариф кулын гына селтәде.—Мин аларның безгә килеп җиткән гәзитләрен укыштырам... Шәһәрдә—милләте юк, хәрәкәте бар кебек... Авылда милләте бар, хәрәкәте юк... Чынбарлыкта исә, икесе дә—милләте дә, хәрәкәте дә юк. Хәрәкәтендә кан йөрми. Быел җәй Казаннан бер бик тә укымышлы бәндә кайткан иде. Милли хәрәкәт түгел, милли хәкыйрәт ул, ди... Иван Грозный белән бергә үлгән хәкыйрәт, ди... Хәкыйрәте нәстәдер инде... Татарча сөйләшү авылда минә шул сентябрь кереп, дачниклар киткәч кенә ишетелә башлый... Аңарчы бездә чегән табыры була.. Җәй житте исә, кайталар мин сина әйтим безнең авылдан чыккан дачниклар үзләре белән кемнәрне генә өстерәмәгәннәр... Дөньяның барча телләре гөрләп тора—грек та, албан да, ниәндиртәлис тә бар, җимерек танаулы әрмән-әзәриләрне инде әйтеп тә тормыйм. Араларында татар гына юк... Бәхетлеме алар?! Ничек ачуың килмәсен?!—Зариф Иркен-аганың колагына якын килеп, пышылдауга күчте:—Татарның башта җаны, аннан... мие кортлады бит. Шуңа алга баралмый ул татар, малайгынам. Милләт чибәр кызларын күпме акча тотып, иркәләп үстерә үстерүен, тик чәчбиләр шул чибәрлекне кая куярга, кемгә бирергә белми бәргәләнә... чөнки кычыта, җаны кортлы!...Ул сина милләт өчен утка кергән чечен кызы түгел. Ир-ат, татар ир-аты кая карый?! Без гаепле түгелме? Ничекләр ач-чуың килмәсен, ә?! Хатын-кызның барысы бер аның, мышнаулары гына төрле. Бу минем икенче хатын...—Ул ишек ягына баш какты.—Беренчесе өч бала китереп, чөгендер чыгарганда йөгенеп үлде... Ике балам Казанда—берсе укый, берсе эшли... Төпчеге мәктәптә бәрәнгесен чыгара... Мин шул чаклы бала яратам, малай!...Әгәр мин җир йөзеннән китеп барсам, туйганчы бала яратмыйча китеп барачакмын... Кабер ташыма фамилиямне язу да кирәкми. «Бирелә Бала Сөеп Туймас Зариф ята» дип язсалар, шул житә, малайгынам...—Зариф яшьләнгән күзләрен җиң очы белән сөртеп алды.—Киләсе кайтканда, алып кайт мина Америкадан күп бала таба торган берәр хатын, ә? Теге,

каралардан булса тагын да яхшы. Уч төпләре ак аларның. Мин аларны печән сәндерәсендә агартыр идем, биллаһи әйтәм!.. Авылга хәзер гитара чиртеп, шәрә килеш биегән негритослар гына житешми...

Иркен-ага тагын көлде.

—Мин алардан шундый космонавтлар... юк, жиһангирлар үстерер идем, биллаһи әйтәм!..

—Ә бу кәмперенә ни булган? Яшь, матур...

—Кара, матурлыгын күреп тә өлгергән, карт шәйтан. Күзен—ватерпас! ...—Аннан, якын килеп, тагын пышылдый башлады:—Яшь, матур, тик бала китерми... Тагын өйләнер идем, бала үстерерлек хатыннары да юк...

Сентябрьнең сүрән кояшының ялкынланып янган миләшләре вә баланнары астында, алтын өемнәрен хәтерләткән өемнәрдән суганбашлар чүпләп утырган Ачулы Зарифның күкрәгендә тыштан гына тупас, каты, хәтта имансыз күренеп, эчендә исә нинди зарлы, нинди нечкә гарьле, нинди шәрә йөрәк типкәнлеген әле килеп аңлады Иркен-ага. Ул үзе укыган, зыялы интеллигент, биолог, тормыш асылын нечкә, зәвыкълы теоремаларда ачарга, анысларга тырышса, Ачулы Зариф исә, «Шәхси Зар»ның «сигез сыйныфлы» авторы Ильяз Хәкимуллин кебек, тупас, әмма үзенчә тупас, үзенчә гадел формулалар белән эш итә иде. Ул Кизләүнең ялкынлы баланнары астында үзенең капма-каршы булган игезәген очратырмын дип һич тә уйламаган иде. Баксаң, Зариф кардәше дә шул ук үз жәфасында гаделлек эзләүче мосафир бит!.. Әгәр урамда ком өстендә уйнап утырган бала «р»ны «л»га әйләндерә-әйләндерә, күршедә генә «Ачулы Зариф» яшәгәнлеген очраклы гына әйтмәсә, ул аның белән күрешә дә, таныша да, гомере буе жәфаланып эзләгән сөальләренә жавапларны—әйдә, алар шушы авыл жирлегендә тупас калыпта булсалар да!—таба да алмаган булыр иде. Әй, язмыш, язмыш!..

—Ә сез нимәгә Ачулы Зариф? Сез бит бер дә ачулы түгел?

—Минме ачулы түгел?!—Зарифның кара күзләре күкләрне айкап төште.—Бирермен мин сиңа!...Шундый да ачулы мин. Мин ачулана башласам, моннан чыгып сызганыңны да сизмәссең, малайгынам. Ничек ачуың килмәсен? Әнә, Кукмарада «Акбарс» банкының өч еллыгын зурлап үткәреп маташалар. Безнең чәйгә дә акча юк...Ачулы мин!.. Ничек кенә ачулы!.. Бу тормышта минем ачуымны китермәгән берәр нәрсә калды микән? Бер ләззәтем бар—һәрнәрсәгә бәйләнәм мин. Хәтта иң нечкә нәрсә—мәхәббәткә дә бәйләнәм мин. Чөнки ачуым бар!.. Ул мәхәббәт булудан туктады... Их!..—Зариф тирә-якны сөзеп күздән кичерде.—Балаларны укытырга кирәк... Эшемне, тракторымны тартып алдылар. Житмешенче елларда, анысын-монысын аешмастан... бу агулы ашлама, фәлән-төгән дип кисәтүче юк, борынны чүпрәк белән дә каплап тормыйбыз, гербицидләр келәтендә күпме агулы ашлама төядек без? Хәер, химикатлар белән эшләү авылда әле булса зарарлы дип исәпләнми. Махсус азык та бирелми, аерым түләү дә түләнми... Без, өрлек кебек биш ир-егет—Әмин, Зөбәер, Әхтәм, Камил абзый һәм мин бик тә яман агуландык... Дүртебез ашказанындагы яман шештән үлеп китте. Мал булып мал түзәлми—сыерлар ике башлы бозау сала... Ә мин түзәм, бер мин генә калдым...Ничекләр ачуын килмәсен, ә? Бу хатыным ашлама завскладып иде, чөгендер агуыннан аналыксыз калган, минем исә, кукыруз ашламасыннан... ирлек орлыгым котыра... Үземә урын табалмыйм!.. Ничек моны аңларга, ә? Бездән аскарак йортларда Максимум белән Минимумга керерсең әле син. Ашламадан агуландык дип үзләреннән герой ясарлар. Ышанма! Безнең данга примазаться итәләр, малайкаем... Алар чучка вирусыннан агуланды!..

Бакча эченнән муенын сузган кое баганасына саескан килеп кунды да, шыкырдый башлады.

—Кунак чакыра,—диде яшьле күзләре белән елмайган Ачулы Зариф. Анарда ачуының кәтрәсе дә калмаган иде.—Килсеннәр. Азык житәрлек. Хәзер эчмим. Планны үтәдем. Саескан —иң акыллы кош. Юкка шыкырдамый ул. Янгырны да хәбәр итә ул мина. Күр дә тор, иртәгә авылга йә салым түләтергә, йә пинсә китерәчәкләр... Хәер, алар икесе бергә йөри инде!..—Ул урыныннан күтәрелде һәм чыбылдыклы ишек ягына кычкырды.—Хатын, чәенне янарт!..

—Кирәк имәс! Берүк хафаланмагыз!.—Минутын да исәпләгән Иркен ага аны көчләп диярлек өенә алып кергән Ачулы Зарифтан капкага таба тартылды.—Әле миңа авылны урап чыкмак кирәк!... Рәхмәт сезгә!..

—Бүген булмаса, иртәгә килерсен, шулай бит, малайгынам? Көчләмим!..—дип тынычландырды аны Зариф.—Дингез төбен үлчәп булса да, кеше күңелен үлчәп булмый...—Ул Иркен-ааны озатып, капка эргәсенә үк килде һәм әйтеп бетермәгән фикерләрен түгә-чәчә башлады:—Менә син дә Ачулы дип атадың бит әле... Ә нигә ачулы мин? Ачулы түгел—чәмле мин. Чәмле кешенең күп сөйләргә, көйсезләнергә чамасы юк. Шуңа күрә ул кәнкрит—түбә яба, мич чыгара, сәгать төзәтә, киез итек баса... Адәм баласына эш кирәк... Ә безнең авылда эш житми. Кайчандыр һөнәрмәннәр—атаклы көмешчеләр, итек басучылар, миччеләр, арба-чана ясаучылар, хәтта сәгать төзәтүчеләр авылы бүген—эшсез!..Менә шуннан башлана ачу, менә шуннан башлана усаллык.. Кеше жаныннан иркәлек кача. Пинсәгә ун ел бар, ә мин эшсез!... Ач кешенең ачуы яман дигәнне ишеткәнең бармы? Мин ач түгел, мин—эшсез!.. Сез бал кортын алыгыз. Ул нигә чага? Табигатьтә бал таба алмау ачуыннан чага ул кешеләрне, малларны. Ә кешеләр бер-берсен нигә чага? Кешелектә үзенә тиешле балны табалмаудан чага!.. Әгәр табигатьтә бал мул булса, кортның кешедә эше юк. Умарталыкка кереп хет шәрә-бака утыр—сиңа кагылмый, аның эше бар, малайгынам!.. Тик аракы, одеколон белән табигатьне сасытма, тавыш чыгарма, оркестр акыртма—ул сине күрми, аның эше бар!..

—Сез бал кортлары тотмайсыз?—дип сорады Иркен ага.

—Кая аңа вакыт!—дип кычкырып жибәрде Зариф.—Аңа биткә кияргә битлек, инвестици, чәчкәлек кирәк!.. Бездә аларның берсе дә юк. Естиствинни чәчкәлекләр бетте... Басуларга гербицид сибеп, ел саен ун центнерга иген ишәйтәбез!.. Мин жыр да чыгардым: «Ашламага яса ташлама—ялган уңыш шуннан башлана...» Гәзитәләрне укып барасындыр... Гектарыннан йөз центнерга життек!.. Кибеттә һаман ипи хакы күтәрелә. Ничек ачуың килмәсен!..

Алар хушлаштылар. Ачулы Зариф белән очрашу вакытында күп нәрсәләрне аңлаган Иркен-ага бернәрсәне аңламады: авылда, жирдә яшәп, ничек итеп эшсез булырга, ничек итеп эшсез утырган инсанның вакыты булмаска мөмкин икән?

Урамга чыккач жил кыштырдагандай итте. Жил дымлы, янгыр жиле иде. Кояшны үзенә кертеп яшергән көзге күк йөзе исә, берничә урында табырланып алган аксыл-кара болытларны исәпләмәгәндә, һич кенә дә янгырга тартмый, югыйсә. Сихәт-сылу күренмәсме дип авыл очы тарафына күз ташлады. Юк, күренмәде. Чираттагы ихатага үтте дә туктап калды. Кеше аягы сирәк баскан ишек алдында бәпкә үләне күпереп үскән. Бакса, йортның тәрәзәләре такта белән аркылы-торкылы кадакланган икән. Аны ташландык ишек алдында качышлы уйнаган балалар шундук танып алдылар:

—Исәнмесез, бабай! Туганнарыгызны таптыгызмы?

—Тагын сөйләгез әле Америка турында!..

—Күрше йортка кермәгез, анда кеше яшәми!

—Безгә керегез, безнекеләр өйдә!..

—Кемгә алып барыйк? Кая алып барыйк?

—Кизләү чишмәсенә алып барыгызлар!—диде көтмәгәндә генә мөһаҗир.

—Нинди чишмә диде?—Балалар үзара караштылар.—Бездә шундый чишмә бармени?

—Юк-юк, уенызда булыгызлар...

Ул сәгатенә карады. Намаз вакыты җиткән икән. Бер читкәрәк китеп, туфрак белән тәһарәт алды, якты болытлар катламы аша җир йөзен күренмичә генә сизелеп яктырткан кояшка карап, кыйбласын билгеләде, кесәсеннән чиста кулъяулыгын чыгарып, ямь-яшел үләнгә җәйде һәм өйлә намазының фарызын гына укып, дога кылды. Мондый гамәлне беренче тапкыр күргән балалар, аны уратып алган хәлдә нәрсә әйтергә дә белми тордылар. Аның белән бергә дөнья читенә дә сәяхәткә әзер балалар ияреп ихатадан чыктылар.Иркен ага аларны туктатып, аркаларыннан сөйде:

—Солтаннарым, сез уйнагыз. Кирәксәгез, сезләрне чакырырмын. Хуп, мәйлеме?

—Хуп! Мәйле!—дип сикерешә сабыйлар.

Урамның каршы ягындагы колхоз бетергән кирпеч йортларда яшәгән дүрт гаиләнең барысы да һәрнәрсәдән бихәбәр булып чыкты. Икешәр, берсендә хәтта өч бала күргән Иркен ага, аларның тормыштан бу кадәр дә хәбәрсез булуларына көенеп алса да, авылның киләчәге шушы балалар кулында булуына сөенеп тә куйды.

Ашыйсын китереп, ашказаны суырды. Бая Хаҗигалиләрдә ныклабырак үзәк ныгытмавына үкенгәндәй итте. Әмма тамак туклык итү өчен өйгә кайтып азапланмаска булды—күпме вакыт сарыф ителәчәк. Ул яңадан урамның бу ягына чыкты һәм ишек алды вак таш белән түшәлгән ихатага үтте. Колакны ярып һәм күренмичә генә чылбырларын өзәрдәй булып эт өрде. Иркен ага этле йортларга чиксез куана: эт—йорттагы мал сакчысы.

Эт тавышына өйдән үзеннән биш яшьләр чамасында өлкәнрәк апа-җан чыкты. Ул капкасын ачып, тыйнак кына исәнләште дә кунакны өйгә үткәрде.

—Хуш киләсез. Әйдәгез, үтегез...

Ул керешли алъяпкычын чиште, аны алгы якның элгеченә элде, электр чәйнүген тоташтырып, өстәл артына үтте.

—Тиллебизыр кабызыйммы?

—Кирәк имәс.

—Ырадиу?

—Кирәк имәс.

—Ярар, алайсә.

Өй эче якты, тәрәзәләр киң һәм чиста зәңгәр пыялалардан төшкән сыек зәңгәрдән зәңгәрләнеп тора. Диварлар пыялалы фотосурәтләр белән тулган.

—Утырыгыз... Менә шушында.—Апа-җан кулдан ясалган артсыз урындыкны аңа таба этәрде.—Үлгән улымның истәлеге. Кулы оста иде мәрхүмнең... Килеп әйбәт иттегез әле. Югыйсә, мин үзем сезне эзләп барырга идем әле...

Мөһаҗирнең эченә җылы кереп китте. Менә-менә табылачак туганнарының чыбык очы!..

—Сез туган-тумачаларыгызны эзләп, Америкадан ук кайткансыз икән. Ә мин гаделлек эзләп, Америкага барырга җыенган идем!—Апа-җан авыз чите белән генә серле елмайды.—Кичә оныгым очрашуда булган... Әле кайдадыр уйнап йөри. Төне буе сез сөйләгән нәрсәләр белән саташып

чыкты... Америкага китеп байыйм да, аннан саранга әйләнәм, ди.

Апа-җан күзлекләрен салып, тагын көлемсерәде.

—Сездә Америкада халык шулай саран мени?

—Сабый әмрикәннәрнең сакчыл булуын артык турыдан аңлагандыр кү...—дип тынычландырырга ашыкты аны Иркен-ага.—Гафу итегез, әмрикәннәр максади юлда ифрат та юмартлар. Сезнең атыныз кандай?

Тәүхидә икән.

—Мин үзем бу авылдан чыккан кеше түгел, тик сез эзләгән Сәлахиләрнең авылда барлыгын һич кенә дә хәтерләмим...

Апа-җанның өстәле—кай арада, моңа нинди чаралар белән ирешкәндер—күз ачып йомганчы азык белән тулды. Хәтта тукмачлы аш белән катыгы да бар иде.

—Һи-и-и, күпме сулар акты бит инде ул заманнардан... Хәзер Ватан сугышында үлгән кешеләрне хәтерләүчеләр дә бетте, кая ди инде ул теге заманнарныкын хәтерләү... Сезгә Түбән Очтагы «Тере Китап»ка барырга кирәк!

—Кем ул?

—Мөкәрәмә.Бу хакта әйтүче булмадымы? Аны «Тере Китап» дип йөртәләр...

Түбән Оч Мөкәрәмә турында аңа берничә кеше әйткән иде. Әллә йорттан йортка йөрүне ташларга да, Мөкәрәмәне табып сорашырга һәм шуның белән нәселенең чыбык очларын эзләүне туктатыргамы сон?—дигән фикер дә килеп куйды аңа. Юк, диде аңа икенче тавыш. Синең әле бихисап вакытың бар. Авылны мөмкин кадәр сөреп чыгарга кирәк. Кайчан булачак мондый мөмкинлек? Хәлеңнән тайганчы өйдән-өйгә йөре. Иртәгә иртәләп Түбән Очка төшәрсең. Төшәрсең дә, Мөкәрәмә апа-җанда булганнан соң, Үрге Очка күтәрелерсең. Бәлки Мөкәрәмә апа-җан чынлап та тарих чаршавын күтәрер? Аны һәр йортка кереп йөрү бурычыннан коткарыр? Йөре, өлгерә алганча, шулай бит? Житмәсә, Алик сине алырга бары тик иртәгәдән сон гына киләчәк. Аннан, туганнарыңны эзләү бу бит әле—туган авылың буйлап сәяхәттә йөрү дигән сүз. Мондый бәхет тагын кайчан тиячәк?

Карыны ачкан Иркен-ага Тәүхидәне тыңлый-тыңлый башта ләззәт белән берничә кашык катык капты, аннан Төркестандагы гадәт буенча тукмачлы ашка катык катып, бик тә яратып ашады.

Тышта баягы кебек өзгәләнеп эт өрде.

—Абзар эченә кертеп бәйләдем,—диде Тәүхидә.—Күрмичә өрсә, гаугасы ул кадәр йөрәккә төшми.

Көннәр буе берьялгызы булган Тәүхидә сөйләшер кеше табылганга куанып бетәлми, сүзне ничек башларга белмичә утырды. Менә ул кулларында күзлеген бөтерде-бөтерде дә, күзләренә элде. Тән тиресенең күз төпләренә җыелган җөй түгәрәкләре янадан борын тирәсенә төшеп тигезләнде.

—Мосафирга сүз сенә, ди торган иде минем әткәй. Фронттан кайтып үлде, мәрхүмкәй..Кем беләндер сөйләшәсем килгән иде бүген. Киленем эшсез калгач, Мамадыш базарында сату иткән булып маташа...Улым аның янына дип киткәние.. Аллага шөкер, кече улымның килененнән бик тә уңдым... Картым ун ел чамасы элек ашказаны шешеннән вафат булды. Һәйбәт яшәдек. Менә шунысы гына... Өлкәнебезнең килененнән уңмадык. Нирбыларны ашады тек ашады инде, кашыклап түгел—чиләкләп... Атасын да, улыбызны да шул килен генә тыкты гүргә... Киленнең әле булса мина «Әни» дип эндәшкәне юктыр...Бер авылда яшәп, оныкларымны безгә аяк та бастырмый...Нинди дәҗҗалдыр инде, ходаем...

—Сезгә Ходай Тәгалә сабырлык бирсен. Гафу итегез, сез... намаздамы?

—Юк шул...—Тәүхидә күзлеген салды, теге түгәрәкләр борын

тирәләреннән китеп күз төпләренә жыелды.—Юк шул... Башкага өлгерәбез, иманга килергә генә өлгермибез...

Хатын житди әйбер әйтергә уйлагандай күзлеген бөтерде-бөтерде дә, уеннан кире кайтып бугай, бөтерүеннән туктады һәм күзлеген киде.

—Минем шушы киленем турында Америкада берәр клеветон чыгарып булмасмы? Әйдәгез, чыгарыйк әле, ә? Татарда шундый имансыз килен барлыгын бар дөнья белсен!.

Йә, Ходай! Иркен-ага эченнән генә аһ итте: нәсел тамырын эзләгән мөһәжиренә язмыш кинәя белән татарның юньсез киленен күрсәтә иде!.. «Нәселдәшемне эзләп, мин милләтемнең барлык зарларына барып юлыгам түгелме?—дип уйлады ул.—Һич кенә дә көтмәгән идем!»

—Сыерымны сатып булса да... Әйт әле, шул клеветонны Америкада чыгару өчен бер сыер акчасы житәрме? И-их, сөйләр идем мин бар дөньяга гыйбрәт итеп... Сездә бит андыйлар юктыр? Татарда бар! Сездә юктыр. Андыйлар булса, Америкада эшләргә вакыт кала диме? Америка байый ала диме?

—Ә нигә Рәсәйдә чыгармыйсыз? Монда жинелрәктер!—диде Иркен-ага гажәпләнеп.

—Монда юк...—диде Тәүхидә уйга чумып.—Монда бит димәкрәти!.. Рәсәйдә аның хакында белүнең мәгънәсе юк. Андыйлар адым саен. Аның хакында менә Америкада белсеннәр иде ул! Аннан, безнең гәжитләр гәжитмени ул? Чүп савытлары!... Син жинел уйлыйсың, абзый кеше. Ул дәжжал монда һәркемнең авызын йомдыра... Гүләшши бит ул!.. Улым шуның аркасында эчкегә салынды... Шуның аркасында тегендә китеп тә барды...—Ул урыныннан торды һәм Иркен-аганы житәкләп диярлек диварга эленгән фотолар янына алып килде.—Монысы әти белән әни. Сугыш беткәч төшкәннәр. Менә монысы картым. Әрмедә чакта. Замкомвзвод булдым диярие. Менә монысы өлкән улым... Киленем мичена сазлык усагы ягып кыздырган да, торбасын иртә ябып, чыккан да киткән... Исерек тә түгел, төшермеш кенә булган!.. Сөрем исеннән исереп үлде... Кырык алты яшендә...—Тәүхидә елап алды.—Сөрем артур тамырларына кадәр үтеп кереп, тәнен зәп-зәңгәр иткәние... Үз балаларым белән судлашу була дип хөкемгә дә бирмәдем... Менә монысы аның улы, оныгым Артур. Алтын бала иде! Аһ, бу язмыш дигәнен, нигә шулай икән?—Ул Иркен-аганы икенче бер сурәт каршына алып килде. Аннан хәрби киемле егет елмаеп карап тора иде.—Чичнәгә алып киттеләр дә, эзсез югалды. «Баявиклар ягына чыккан»,—дип, ваянныйлар килеп тикшереп тә йөределәр. Теге яктан да, бу яктан да хәбәрсез...—Ул еламаска тырышып, тартышып куйды.—Әнә, бакчада сыгылып утырган ике миләшне күрәсезме? Улым һәм оныгым хөрмәтенә мин утырттым аларны...Тукта әле, исемеңне дә сорамадым. Синең исемең ничек?

—Иркен.

*Тәмам*



Җәүдәт
Дәрзаман

# ТОРМЫШ—СӘХНӘ

ПУБЛИЦИСТИК ПОЭМА

*Драматургия классигы*
*Галиәсгар Камалга*

*Ул сәхнәгә тумышыннан килде,*
*Балачактан белде иңен, буен.*
*Аның өчен сәхнә—тормыш иде,*
*Тормыш аңа булды бары уен.*

Бер актер авызыннан

**Тормыш—сәхнә. Анда гомер кичә**
**Бала-чага белән яше-карты.**
**Сәхнә—уен. Сәхнә—ялган туе,**
**Чын тормышта кайный... сәхнә арты!**

**Сәхнә арты... тоташ пыяладан**
**Корылгандыр, ахры, бар дивары:**
**Үтәлигә барсын күреп була,**
**Күңел биреп кара син нибары.**

**Тормыш—сәхнә. Бер әйләнеп килеп**
**Кабат баса торган куласа ул:**
**Басам дип тә, кайчак басмый кала,**
**Ходай кушып, бүрең уласа ул.**

**Үткәннәргә карап, бүгеннәргә баксаң,**
**Рухи ярлылыкка китә исләр.**
**Нигә менми заман сәхнәсенә**
**Яңа Зөлфәт, яңа Мөдәррисләр?!**

Җәүдәт ДӘРЗАМАН (1945) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Җир авазы», «Илләр гизә Илгизәр», «Чорлар кайтавазы», һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Чорлар кичеп аккан Иделкәйнең
«Илкәем!» дип даулар гавамы юк.
Күңелләрдә йөргән изге җырның
Азагы бар, әмма дәвамы юк.

Тарих төпкеленнән Тукай калка,
Күз салыйм дип, Печән базарына.
А!
Никадәр охшаш заман килгән,
Никадәрле азык язарына:

Һәр чат саен яшь тәтәйләр баскан,
Иңнәренә нәни сумка аскан.
Китсәң дә тик ялгыш тиеп кенә,
Сарылалар
«На работе!» диеп кенә.

Кире кайткан Дәүләт Думалары,
Киледә су төя депутатлар—
Һаман «урыс» диеп кайгырталар,
Урыс түгелләрне кем соң яклар?!

Элек әле татар татар иде,
Ук булмаса, хет сүз атар иде.
Думаларда дистә урын алып,
Каты төшләрне дә ватар иде.

Бишәр гасыр ээзрлекли икән
Бер җибәргән бер тарихи хатаң,
Моң да бирми сиңа, тын да бирми
Мәскәү кулы тоткан милли якаң.

Тормыш—сәхнә. Яшәү—комедия,
Тамашачы бары көлә генә.
(Тәкъдим булса, бүген Тукай үзе
Узмас иде Тукай бүләгенә...)

Тормыш—сәхнә.
Әнә Җәлил кайткан,
Дәлил кайткан кичеп гарасатлар.
Гарасатлар кичкән дәлилләрне—
Исхакыйлар, Туфан, Җәлилләрне
Кабат буяр, кабат җуяр өчен
Көнен көтеп тора кара затлар.

Тормыш—сәхнә, таптап, изеп уза
Җанга газиз, изге нәрсәңне дә:
Күңелеңдә синең җомгамыни?!—
Бөгә—
Әйләндерә чәршәмбегә!

Каннан исереп, Сталиннар китсә,
Штаниннар килә алмаш белән—
Татар илен кабат сыртка сала,
Канун дигән булып, янбаш белән.

Һәм ил ята.
Ята—
Кайтарылып,

Кабат сыртка баскан зур чабата.
Тарих шулай безнең борыннарны
Каната шул кабат кайта-кайта.

Тормыш—сәхнә.
Каф тау илләрендә
Гөнаһсызга кыела күпме җаннар:
Бөтенлеге өчен Россиянең
Кан коеша шул ук россияннар...

Бу афәтләр һаман килә тора
Буй сындырмас Бүре ыруына.
Башка кавем түзәр иде микән
Каршы якның болай кыруына?!

Ичкерия канлы сәхнә булса,
Садовое кольцо—сәхнә арты.
Бөтенлек дип, җимерү хисабына
Баеп калу—эшнең бөтен шарты.

Тормыш—сәхнә. Узган гөнаһларны
Кайта-кайта искә төшерә шул—
Кагылып булмый тарих битләренә,
Утлы юллар җанны пешерә шул.

Тормыш—сәхнә. Барын бутап бирә
Карасында, соры, аклыгында.
Манаралар кискән дәһриләрнең
Мулла итә улын картлыгында.

Гаҗәп халык! Алар—диндар, имеш,
Вәгазь укый сиңа, дингә дәшә.
Тик сүзләре җанны җылытмый шул,
Дәшкән офыклары—тоташ рәшә.

Тормыш—сәхнә. Килгән заманалар
Бер ишарә гүя үткәннәргә:
Ишеп-ишеп кайгы-хәсрәт бирә
Ихласыннан бәхет көткәннәргә.

Хәлилләрне Исмәгыйльләр атса,
Мин бай, диеп, кайчак элек заман,
Исмәгыйльне Исмәгыйльләр ата—
Безнең хәлләр, димәк, күпкә яман.

Элек бер бай ярлы кызын сөйсә,
Ярлы егет сөйсә бер бай кызын,
Тарихлары бәет булып киткән,
Бәетләре булган, ай-һай, озын.

Бу хәлләрдән хәзер бәет тумый,
Мәет кенә туа яшь анадан.
Үзебездән моңа зарланыйкмы,
Зарланыйкмы әллә заманадан?

Атлап булмый хәзер хәтта саплам,
Өйдә саклан, эштә, тышта саклан—

Искеләрен атып өлгермиләр,
Яңа байлар туа катлам-катлам.

«Мерседес»та узып китә берәү,
«Запарай»дан төшеп кичә генә.
Каян болай бик тиз байган, димсең?—
Минем исәп, синең исәбеңә!

Тормыш—сәхнә. Бөек түнтәрешләр
Узган юкса безсез, сезсез генә.
Әмма ләкин безнең өчен дә ул
Узмый калмаган шул эзсез генә.

Акчуриннар фабрикалар җуйган,
Рәмиевләр җуйган алтыннарын.
Асыл затлар, фани кичәр элек,
Тәүдә кичкән Себер салкыннарын.

Гасырларны кичкән кульязмалар
Төтен булып очкан морҗаларга.
Сука белән җир сукалау калган
Чабаталы мәэюс морзаларга.

Тормыш—сәхнә. Түнтәрелгәннәрнең
Коммун булып үсте балалары.
Үстеләр дә, кемнәр түнтәрсәләр,
Түнтәрделәр шуны аннан ары.

Түнтәрделәр җайлап, иплап кенә,
Дәлил арты дәлил сипләп кенә:
Ябырылып килгән ярлылыкны
Кабул итте халык җөпләп кенә.

Элек, имеш, тормыш начар булган,
Аның шәбе менә хәзер икән:
Яңа байлар ярлы-ябагайга
Җанын бирергә дә әзер икән.

Тик әлегә алар алтын ала
Читкә аккан нефть акчасына.
Күккә сонган буровойлар гына
Үсеп чыга ярлы бакчасына.

Яңа байлар анысы эшне җайлар,
Тик ярлылар ничек гомер юллар?!
Ничек яшәр, нинди нәрсә ашар,
Тере акча күрми айлар, еллар?

Тормыш—сәхнә. Әле кайчан гына
Герой иде Ильич, Виссарионычлар.
Инде милли каһарманнар булды
Батька Махно, Врангель, Юденичлар.

Тик бер нәрсә һаман үзгәрешсез,
Татар идек, калдык татар булып.
Тарих күзләреннән көпшә карый,
Йөрәкләргә ядрә атар булып...



Роза
Хәбибуллина

# ЗӘЙТҮН ИЛЕНДӘ

ПОВЕСТЬ

Кышкы ак тынлык. Тау башында егет белән кыз чаңгыда басып торалар.

—Төшәргә курыкмыйсыңмы?

Кыз икеләнде, куркам дияргә оялды.

—Минем эздән тайпылмыйча төшсәң, бернәрсә дә булмас. Әйдә, киттек!

Солдат чалбары, ак свитер белән ак башлык кигән озын буйлы, хәрбиләрчә төз гәүдәле егет алга ыргылды. Кыз, күкрәгендәге куркуны тыеп, чаңгы таякларын этеп җибәрде. Колакларында җил сызгырды, чаңгылар табанында буран күтәрелде! Җилдә йөзе алсуланган, башлыгы астыннан алтынсу-сары чәчләре сибелгән ымсындыргыч сылу кыз тау итәгенә төшеп җитте.

Егет күзен кысыбрак сокланып карап тора.

—Нурия, бер сюрприз күрәсең киләме?

—Нинди сюрприз?

—Баргач күрерсең! Әйдә, чаңгыларыңны сал!

Алар тауга күтәрелгәндә аяк астындагы кар шыгырдавына нindiдер сәер челтерәү кушылды. Нурия аны шунда ук таныды.

—Әлекәем, чишмә! Әйдә тизрәк!—Ул сукмак буенча йөгерде. Ташлар арасыннан агач улакка көмештәй су бәреп чыга. Нурия мамык бияләен салып, улак очында кулын юды да, учын тутырып чишмә суын авыз итте.

—Син дә эч, кил!

—Сыйласаң, эчәм!

Нурия кушучына су алып Насихка сузды. Егет гүя алсу чәчәктән иелеп су эчте дә, кечкенә учны үбеп алды. Салкын кулга тигән кайнар иреннәрнең ялкыны Нуриянең бөтен тамырларын яндырып, йөрәгенә барып кабынды.

күзләрендә зәңгәр чаткылар булып уйнады. Нуриягә текәлгән көләч күзләр дә шундый ук ялкын белән яна, аларда шундый наз, шундый ук сөю балкый... Бу күзләр алдашмый, Нурия ул карашларда ихлас сафлык, сабыйларча садәлек күрде.

—Нурия! Безнең авылда кызлар белән бер чәшкедән эчсәләр, «өч көнлек хатыным булдың!»—диләр. Мин чәшкедән түгел, синең кулдан эчтем! Димәк, син миңа өч көнлек кенә түгел, гомерлеккә булырга тиеш! Син ризамы шуңа?

Көткән иде Нурия мондый аңлашуны, ләкин менә шулай карлы тауда, ярым шаярып, ярым җитди әйтелер дип түгел. Шуңа күрә үзе дә шаяртуга шаярту белән җавап бирде:

—Әй, алдашма! Бездә кыз башына егет бүрек кигертсә генә шулай диләр. Ә бер чәшкедән эчсәләр «сердәш булабыз», диләр.

—Барыбер инде! Әйт, син ризамы?

—Синең йөргән кызың бар, диләр бит!

—Каян килеп?! Без әллә кайчан, мин армиягә киткәнче үк ташлаштык бит инде!

—Ай, белмим, белмим...

—Хет теләсә кемнән сора! Мин әйткәнне әйтерләр!

Нуриянең теле «риза» дип әйтәсе килеп кычыта, йөрәге бугазында тибә, дулкынланудан авызы кибә...

—Тукта әле, эчәсем килә...—Кыз иелеп тагын су эчте. Тешләрне камаштырырлык салкын су Нуриянең йөрәк ярсуын баскан кебек булды.

—Миңа дә эчерт!

—Зинһар диген!

—Зинһар!

Бу юлы Насих, су эчкәч, кызны кочаклап иреннәреннән суырып үпте.

—Синең иреннәрең чишмә суыише генә түгел!—Ул кызны кочагыннан чыгармады, тагын да ныграк кысып:

—Җавап бир! Чыгасыңмы миңа кияүгә?

—Ай! Ай! Чыгам! Чыгам!

—Әйткән сүзеннән кайтма! Менә Ташлы тау чишмәсе шаһит! Ул изге, шифалы чишмә, аның хәтере бар диләр! Аның суын эчкән кеше озак яши!

«Миңа да шушы чишмә суын эчеп яшәргә язсын иде!»—дип теләде кыз. Йомшак кар өстеннән эз салып кайтыр юлга чыкканда, кыз үзен чаңгы түгел, канатлар күтәргәндәй хис итте... Бу болытлы көн күзне чагылдырмый торган аклыгы, баш очында гына тоелган тыныч күге, Ташлытау чишмәсенең челтерәве белән мәңгелеккә Нуриянең исендә калды. Шифа чишмәсенең саф суын эчеп вәгъдәләр бирешү моңа кадәр җир йөзендә беркайчан да булмаган искиткеч вакыйга, Насих кебек егет дөньяда юк, аларның мәхәббәтләре кебек мәхәббәт тә, Нурия кебек бәхетле кеше дә юктыр дип уйлады...

***

Ташлытау, 2 февраль 1970 ел.

«Илгизә, исәнме, җан кисәгем!

Кайнар сәламнәремне кабул ит! Сиңа сөйлисе серләрем бихисап! Их, ник үзең монда түгел микән?!

Ташлытауга практикага җибәрәләр дип язган идем бит. Менә, дустым, практика үтеп ятам. Авыллары зур, мәктәпләрендә укучылар да, укытучылар да күп. Килгәч тә үз итеп каршыладылар. Син мине беләсең бит, кысылмаган җирем юк, шунадыр инде әллә ничаклы эш өйделәр!

«Өти балак» дигән спектакль куйдык. Баш рольне—Өти балакны уйнадым, аңа гашыйк егетне күптән түгел армиядән кайткан физкультура укытучысы башкарды. Әллә рольгә ныклап кереп киттек, әллә бер күрүдән гашыйк булдык—хәзер уйларымда гел шул егет кенә! Әле моңа кадәр бер егетнең дә болай ошаганы юк иде! Насих исемле. Ул миңа өйләнешик ди. Синең белән институтка китәм, заочныйдан очныйга күчәм,—ди. Мәктәптә хәзер безнең йөргәнне беләләр, җае чыккан саен миңа мактыйлар. Бигрәк тә завуч Сәкинә апа яратып мактый, ул бик тәрбияле гаиләдән, акыллы, кешелекле, эшчән, ди. Насих миннән ике яшькә генә өлкән булса да, үземне аның янында бала-чага кебек сизәм, чөнки ул гаҗәп житди...

Илгизә! Минем стипендиягә генә укып ятканны беләсең бит, Насихтан яшермәдем, әйттем. Бер дә аптырама, мин кичләрен эшләп укытырмын, электрик та, столяр-плотник эшен дә беләм, бер эштән дә курыкмыйм, ди. Кинәшер кешем юк, апа да, син дә читтә. Шулай да Насих ышанычлыга охшаган, күңелем сизә—ул минем язмышымдыр, мөгаен...»

***

Кемнең кем икәнен аңлый белү—акыллылык галәмәте. Насихның ышанычлы, таянырлык егет икәнен тоемлады Нурия. Билгеле, төрле чаклар булды. Нурия түземлеләрдән түгел, хискә бирелеп китеп, каршысында кем икәненә карамастан, уйлаганын йөзгә бәреп әйтүчән. Ләкин ачуын җыеп йөрми, эчкерсез булганга, Нуриягә бераү дә үпкәләми.

Институтны тәмамлагач, Ташлытауга кайтырга тәки насыйп булмады, аларны башка районга җибәрделәр. Унөч яшеннән әнисеннән ятим калган Нуриягә тормыш күтәргә бердәнбер ярдәмче булды Насих. Өч улын да әниләреннән ким карамады, малайлар бәләкәй чакта әтиләренең муеныннан төшмәде. Эшенә соңармыйча, мәктәптән өйгә, өйдән мәктәпкә чабып, өч баланы чиратлап яслегә, балалар бакчасына, мәктәпкә йөртеп, ун ел үткәнне сизмәделәр дә...

Бер кич, ниһаять, малайлар тынып йоклап киткәч, Нурия үзләренең караватына көчкә барып капланды. Артык арыган иде, йокыга китә алмыйча ятты. Күңелен ниндидер канәгатьсезлек борчый...

—Тормышмени бу! Бер карангыдан икенче карангыга кадәр чап! Тукталып үзең турында уйларга, үзенне карарга вакыт та, мөмкинлек тә юк! Насих, без авылда гомерлеккә калабызмени инде? Малайларны укытасы, кеше итәсе бар. Аларны бер-бер артлы шәһәргә укырга чыгарып җибәрү өчен ай-һай күпме кирәк булыр: юлына дисеңме, ашарына-эчәренә, киемсалымга, торырына дисеңме! Әллә шәһәргә күчик микән? Минем дә кешечә яшисем килә! Әнә, шәһәр хатыннары, яшьтәшләрем, кызлар кебек, мин монда кибеп-корып беттем, картайдым!

—Картаймадың! Син аларның барысыннан да матуррак! Гәүдәң кыз чагындагы кебек!—Насих хатынын кысып кочаклады.—Кем уйлар сине өч бала анасы дип! Дөрес әйтәсең, карчыгым, улларыбызның киләчәге турында кайгыртырга вакыт. Мин дә ул турыда күптән уйлап йөрим. Чаллыга күчәргә кирәк. Анда хәзер төрле уку йортлары күп.

Күченү авыр булмады. Безнен илдә гомер бакый укытучының хезмәт хакына көрәерлек түгел: зур машиналарга төярлек җиһазлары юк, төп байлыклары үзләре кебек житен чәчле, зәңгәр күзле шаян уллары гына иде.

Яшьлек дусты Илгизә югары урында эшләгән ире аша Нуриягә эшкә урнашырга булышты. Насих электрик булып урнашты. Биш җанга бер бүлмәле «малосемейка» дисән дә унайлыклары куандырды: кайнар суы агып

тора, рәхәтләнеп коен, керенне юсаң суны түгеп интегәсе, мичкә ягасы юк! «Түзгән—түл җыйган», күрше бүлмәдәге кыз кияүгә чыккач, квартиралары тагын да кинәйде.

Ахырзаман гасырының 90нчы еллары башланды.

Насих белән Нурия рәхәт тормыш корырга дип күчеп килгән шәһәрдә күпме генә яшәп өлгерделәр икән... ташлап киткән авыллары андагы тормышлары хәзер оҗмах булып исләренә төшә!

Болгавыр үзгәрешләр берәүне дә читләтеп узмады. Акны ак, караны кара дип яшәргә өйрәнгән укытучылар гаиләсе моны авыр кичерде. Яна гына Кама политехник институтын тәмамлап КамАЗда инженер булып эшли башлаган өлкән уллары Ринат кинәт эшсез калды.

—Әллә эшендә берәр нәрсә килеп чыктымы?—дип сорады Насих, улынын кәефе кырылганын күреп:

—Әйе. Сокращениега эләктем...

Насихнын йөрәге чуан кебек сулкылдап сызлый башлады. Сул кулы белән йөрәк турын каплап, авыртуын басарга теләде...

—Сокращениегә күп кеше эләктеме соң?

—Күп. Яшьләрне кыскарттылар. Пенсия яшенә житәрдәйләрне калдырдылар.

—Ярый, улым, артык борчылма, илдә чыпчык үлми дигән мәкаль бар, берәр жае чыгар әле, эшләргә теләгән кешегә эш табыла ул, син әле яшь, һич югында башка төрле яна һөнәр өйрәнә аласың.

Насих тыныч күренергә тырышса да аның урынына, Нурия кайткач өйдә буран, буран гынамы соң, давыл купты! Йөзе кызарган, күзләреннән зәһәр очкыннар чәчрәгән хатыннан хөкүмәткә, президентка, Чубайска ләгънәтләр яуды!

—Кабахәтләр! Халык байлыгын, бөтен ил байлыгын үзара бүлешеп үзләштерделәр дә дөньянын астын өскә китерделәр! Ил башына исерек президент, сатлык жаннар, бандитлар менеп утырды! КамАЗ тикле КамАЗны тараталар! Безне мыскыл итеп сигез сумлык ваучер тоттырдылар да, заводларны, шахталарны үз кешеләренә бушлай өләштеләр! Шул сволочларны рәшәткә артында күрер көннәр житәр микән! Адәм тәганәсе! Яртышар ел зарплата түләмиләр! Көн туды исә таң атса семьяга ни ашатыйм дип аптырыйсың!

Насих хатынын тынычландырмакчы булды:

—Ярар, әнисе, борчылма әле ул кадәр, мин тагын бер эш таптым—күрше йортка дворник булып урнашам. Без генәмени! Бүген мәктәптән бер укучыны «Ашыгыч ярдәм» машинасы алып китте! Бала анын югалткан. Врач: «Голодный обморок» дигән диагноз куйган! Халык ачлыктан интегә! Яшьләр артык жаннарга әйләнде, урамга куып чыгаралар! Үз тамагын үзе туйдыра алмаган егетләр ничек яшәргә тиеш? Алар ничек гаилә корсын, ничек бала үстерсен?! Әнә шул эшсез яшьләр йөри инде группировкаларда кеше талап, үтереп! Хәзер кич урамга чыгарга куркыныч бит!

Тиз генә тынычлана алмыйча, Нурия бик озак тузынды... Әни кешенен йөрәге үз баласы өчен генә түгел, барлык яшьләр өчен дә әрнеде...

***

Ринат беркая бармыйча өйдә утырды да, кичләрен чыгып йөри башлады. Аның бик сонга калып кайтулары борчуга салды.

—Кайда йөри микән бу малай?—дип аптырый Нурия.—Кемнәр белән? Жаны кимсетелгән бала нишләмәс?! Ходай сакласын!

Ринатнын соң кайтуларынын сере тиздән ачылды.

—Өйләнәм!—диде уллары бер көнне.

Әти-әни бер-берсенә карап сүзсез калды... Улларын өйләндерү турында уйласалар да, әле мона бу арада гына түгел, алдагы, киләчәктәге эш итеп карыйлар иде.

—Гаилә корып яшәве хәерле, өйләнсен!—диде Насих. Нурия ире белән килеште. Ике бүлмәле тар фатирларына алтынчы кеше булып килен төште.

***

Авырлыклар берәүләрне чыныктырды, җайлаштырды, икенчеләрне сындырды: күпләрнең йөрәге ярылды, баш миләренә кан сауды, яшьләр арасында, бигрәк тә егетләр арасында, үз-үзләренә кул салу күбәйде, ул замана чиренә әйләнде, бөтен бер ил халкының гомер чиге кыскарды, туасы балалар тумады... Ун елдан арткан бу мәхшәр табигать өчен бер мизгел генәдер, ләкин адәм балалары өчен озакка сузылган михнәткә әверелде ул...

—Нишлибез, Насих, безнең бит әле үзебезнең тормыш та бар! Бала-чага табаны астында яшәү яшәү мени!—диде Нурия, үзләренең йокы бүлмәләрен яшьләргә биреп, зал дигән якта уллары янында йоклый башлагач.—Илгизә янына барам әле, ире Чаллыда икенче кеше, кулында власть зур, бәлки ярдәм итәрләр.

Йөрде Нурия, иренмәде, читенсенмәде: авылдаш начальникның эшенә дә, өенә дә барды. Аның мәрхәмәтлелеге генә гаиләгә бәхет китерде:

—Наси-и-и их! Квартира бирәләр! Иртәгә ордер алырга барам! Ике бүлмәле!

Мондый шатлыклар кеше гомерендә күп булмый! Нурия белән Насихның куанычтан түбәләре күккә тиде!

Яна фатирга улларын күчерделәр дә, сөенә-сөенә үз бүлмәләрендә калдылар.

Ринат һаман эшсез йөрде. Хатыны акчасына яшәү аны кимсетә иде. Танышы Володя азык-төлек сата икән. Кинәшеп-сөйләшеп карагач, ниһаять ул Ринатны үз янына компаньон итеп алырга риза булды. Тизрәк шатлыкны әйтергә дип әтиләре янына килде Ринат.

—Мин бизнес белән шөгыльләнергә булдым,—диде ул ишектән керә-керешкә. Ул бик шат, йөзе алсуланган, күзләре янып, очкынланып тора.

—Нинди бизнес белән?—дип кызыксынасы итте Насих.

—Квартираны сатабыз да акчасына товар алып кайтабыз! Володя әйтә, мин шулай эшләдем ди, бер елдан квартиралык акчагыз да әйләнеп керә, бизнес та бара, машиналык та акча җыела ди.

Бу хәбәр өлкәннәрнең башларына китереп суккандай булды!

—Син нәрсә? Шушындый болгавыр заманда квартира саталар димени! Әниең көч-хәл белән алган фатирдан колак кагасыгыз киләмени?

—Ризык, азык-төлек белән сату итсәң, акча тиз әйләнеп кайта ди, Володя. Без аның белән Краснодарга дөгегә барабыз. Анда дөгенең килосы биш-алты сум гына икән. Ә бездә аны егерме сумга сатарга була.

—Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер! Юк, мин риза түгел!

—Нигә, Насих, күп кеше шулай эшли бит,—дип сүз кыстырды Нурия, иренең «юк»ына каршы.

Башкалар ничектер, белмим, эшлиләрдер, бәлки. Тик юкка чыкканнары, алданганнары да күп! Һавадагы торнага ышанып, кулындагы чыпчыкны ычкындырмыйлар! Бу турыда уйламагыз да!

—Әллә кредит аласызмы улым?—диде Нурия.

—Безгә андый зур кредит бирмиләр, аннан соң кредитның процентлары югары, вакытында түли алмасаң, бурычың арта.

Бернинди уртак тел дә табалмыйча таралыштылар. Ләкин Ринат барыбер

үзенекен итте: фатирын сатып, танышларына торырга керде.

Башта эшләре унышлы гына күренде: тотылган булса да машина алдылар. Ләкин... «Сукыр тычкан юлга чыкса, тез тинентен кар ява», диләр. Бер елдан фатир бәясе дүрт-биш тапкырга күтәрелде, Ринат ул чаклы акча жыя алмады. Володя да ышанычсыз компаньон булып чыкты: бар булган акчаларын алып берүзе Краснодарга китте дә, буш кул белән әйләнеп кайтты. Товары да, акчасы да юк. Анлатуының да атасы-анасы юк: башта таладылар диде, соныннан машина сазга авып дөге батты, диде. Ринат авызын ачып калды—үз өлешенә тигән акчаны кире кайтара алмады, судлашып та йөрмәде, чөнки кулында бернинди документы да юк иде.

—И-и-и-и-и, безнекеләргәме соң мондый эш белән шөгыльләнү! Нәселебездә юк бит сатучылар! Анын өчен тумыштан сәләт кирәк! Авызыннан кереп, тегеннән чыгардайлар гына байый! Юләр булдык! Үзебез гаепле! Мин инде! Шапылдатып планнарына киртә сугасы урынга, жебеп төштек! И Алла!—дип өзгәләнде Нурия. Борчылудан башы авыртып урынга егылды. Бу чир анальгин эчеп кенә туктый торган булмады.

Улынын акчасын кайтару өчен Нурия да йөреп карады, ләкин Володя дигән имансыз—яңа заманның кансыз кешесе—Нуриянен күзләренә туры карарга оялмады.

—Мин ничек түлим ди! Үзем дә Ринат хәлендә калдым.

—Оятсыз, син ничек Ринат хәлендә буласын ди! Кибетең тулы товар сыгылып тора! Минем улымның акчасына алынган әйберләр бит алар.

—Ладно, иди, иди, апа, если сможете доказать, возьмете!

Нурия ни әйтсен, акчаны биргәнгә бер документ та юк! Законнарны белмәгән килеш эшкә тотынасы түгел иде Ринатка! Наданлык бәласе инде...

***

—Нурия өйләренә ашыкты. Кайту белән берәр тәмле ризык пешереп өйдәгеләрне сөендерәсе килде. Ә инде үзләренен подъездында «Ашыгыч ярдәм» машинасын күреп алгач лифт чакырырга да онытып, баскычтан өскә томырылды. Тыны бетеп өйләренә килеп кергәндә диванда чалкан яткан Насих янында ак халатлы ике кешене күреп коты очты.

—Нәрсә булды?

—Сердечный приступ,—диде өлкәне. Яшьрәге Насихның йөрәген кардиограммага яздыра иде. Нурия чишенергә дә онытып катып калды. Төсе киткән, агарынган Насих гаепле кеше сыман хатынына карап елмайды, карашында хатынын борчыганга кыенсыну сизелә иде. Бу хәлсез елмаю Нуриянен йөрәген телгәләде, куркытты...

—Сезне хәзер үк алып китәбез, БСМПда кардиологлар ныклап тикшерерләр, дәваларлар,—диде врач.

Насихның йөзендә ризасызлык күреп, Нурия ана авыз ачарга ирек бирмәде:

—Берүк алып китегез, доктор! Ана күптән йөрәгендә порок бар диделәр, ныклап тикшеренгәне дә, дәваланганы да юк!

Борчылудан, каушаудан калтыр-колтыр килгән куллары белән Нурия иренең әйберләрен жыеп, сумкага тутырды, икенче пакетка ашарына салды.

—Син мине ерак командировкага әзерләгән кебек әллә ниләр тутырма, мин анда озак ятмам,—диде.

—Ярар, азыклы ат арымас, диләр, күршеләреңне дә сыйларсың.

Больницада аны берүзен аерым палатага, «интенсив терапия» дигән кечкенә бүлмәгә салдылар. Ул көнне Нурия ире янында кунды.

—Мин урынга егылган хаста түгел бит, карчык, урындыкта төн чыгып, ничек укытырга бармакчы буласың?

—Минем өчен борчылма! Мәктәпкә шалтыраттым, дәресләремне алыштыралар.

Төнлә Насих йоклагач, Нурия иренә карап баш очында бик озак уйланып утырды... Агарган, ябыккан йөзенә вак җыерчыклар сызылган...

Авылларындагы иң таза, иң матур егет иде. Өч ел армиядә хезмәт итеп кайтуы белән гомергә горурланды. Каян килеп чыкты бу авыру?! Кайчан? Нәрсәдән? Авырса аягөсте уздырды, больницага бармады.

Үкенечле, сагышлы уйлар Нуриянең йөрәген яндырды: «Иремне сакламаганмын. Балалар, балалар, дип, иремә әһәмият итмәгәнмен... Аны мәңгегә килгән тимердән дип уйлаганмын... Тормыш җиңел булмады. Акча җитмәгәч өчәр эштә эшләде, җаныкаем... Җәйге ялларында да ял итмәде, әле бер туганына, әле икенчесенә йорт төзеште... Үзе турында уйламады. Мин тиеш идем аның турында кайгыртырга! Сәламәтлеген тикшертәсе, дәвалыйсы, санаторийларга җибәрәсе калган!»

Дәвалаучы доктор барлык тикшеренүләрнең нәтиҗәсен аңлатты.

—Күңелегезгә авыр алмагыз, турысын әйтәм—дарулар белән генә булмый, операция кирәк. Әле соң түгел. Сез курыкмагыз, хәзер йөрәккә операцияләрне уңышлы ясыйлар. Республикада көчле, оста кардиохирурглар бар. Минем киңәшем шул: операциягә әзерләнегез, авырулар белән бик аралашмагыз, диета тотарга тырышыгыз, больницадан чыгарга ашыкмагыз.

Хәлнең болай кискен икәнен көтмәгән ир белән хатын сүзсез калдылар...

***

Операция беркемгә дә йөз процент шанс бирми... Батыр булып күренергә тырышса да, Нуриянең йөрәгенә ут капты... Хатынының агарынган йөзеннәнниләр кичергәнен аңлап, Насих исә Нуриянең үзен юатты:

—Әнисе, артык борчылма инде! Менә мин исән бит әле! Алдагысын Алла белә! Минем ише чирле-чорлы кешеләр яшәп ята, тап-таза ирләр егылып үлә. Яшәргә язган булса яшәрмен! Мин әле шушы матур, яшь хатынымны калдырып үләргә җыенмыйм! Кил әле яныма, бер үбим үзеңне!

Нурия иренә сыенып ятты. Насих аны кочаклап алды.

—Яшибез әле! Син булганда мин үлмим! Миңа синең белән яшәве рәхәт! Син мине карыйсың, ашатасың-эчертәсең, өс-башымны юасың, бала караган кебек минем турыда кайгыртасың! Син—минем бу дөньядагы бәхетем!

Казанда кардиохирург Насихның врачлар язган кәгазьләрен укып чыккач, нинди операция кирәген аңлатты. Аннан соң үкенечлерәк тавыш белән:

—Алданрак уйлыйсыгыз калган, моңа кадәр бу төр операцияләр бушлай ясала иде, хәзер түләүле шул.

Нурия түләүле икәнен белсә дә доктор әйткән сумманы ишеткәч, коты очты, андый акчаны каян табасың ди?! Больницага өмет белән кергән иде, үртәлеп чыкты: «Без хәзер беркемгә дә кирәк түгел икән! Егылып үлсәң дә ярдәм итүче юк! Менә сиңа мактаулы капитализм! Совет чорын хурлаган булалар! Ул заманда коммунизмда яшәгәнбез икән! Бушка дәваландык, бер тиен акча түкмичә укып югары белем алдык, ата-ананың күбесе эшли алмаганны совет хөкүмәте эшләде—һәр гаиләгә бушлай фатир бирде! Менә хәзер ни көтмәк кирәк!» Нәфрәтләнеп, Нурия бик озак тынычлана алмады: «Россиядә гомергә рәт булмаган, яшь чагым булса Насих белән

берәр юньле илгә китәр идем!» Иң газиз кешесе ярдәмсез калгач, дөньяның тигезсезлеге кимсетте, түбәнсетте... Алар бит үзләрен бар кеше белән дә тигез, горур санап яшәгәннәр иде, хәзерге хакимнәр аларны аяк астына салып таптый...

Кайдан акча табарга? Аларның беркайчан саклык запаслары булмады. Туксан сигезенче елгы дефолт вакытында: «Без хөкүмәтне алдадык—кассада янырдай акчабыз юк иде, хөкүмәт безне талый алмады»,—дип шаяртканнар иде. Менә хәзер сөекле хөкүмәт авыру кешене таларга җыена... Нурия әллә нинди планнар корып карады, тик берсе дә тормышка ашарлык түгел, тормышка ашса да тиз генә түгел иде. Насихны коткарыр өчен Нуриягә акча менә хәзер, бүген үк кирәк!

***

Дәрескә керергә кыңгырау шалтырады. Нурия журналын тотып коридор буйлап бара.

—Нурия! Нишләп ул чаклы бөкрәеп төштен? Ни булды?—Артыннан кечкенә буйлы, каратут йөзле, чем-кара күзле математика укытучысы Мәскүрә килә икән.

—И Мәскүрә, ирем авырый! Йөрәгенә операция ясатырга кирәк... Акчабыз юк ...

—Сер бирмә! Дус бар, дошман бар, дигәндәй, бетеренмә! Берәр җае чыгар әле!

Бу теләктәшлектән Нуриянең таштай каткан күңеле азга гына булса да йомшарды, Мәскүрәне кочаклап елыйсы килде. Биш бала үстереп, бәясе төшерелгән кибетләрдән генә киенеп йөрүче бу сабыр холыклы, тыйнак хатынның сүзләре бик кирәкле булып чыкты. Нурия һушына килде: «Чынлап та, нигә әле мин җебеп төштем! Ирем исән бит әле! Исән! Җан биргәнгә җүн бирә, диләр!» Ул башын күтәрде, тураеп елмайды.

—Рәхмәт, Мәскүрә!

***

Саклык банкында Нуриягә кредит бирделәр. Елга егерме тугыз процент түләү шартын ишеткәч, шаккатты: «Әстәгы, йөз сум урынына йөз егерме тугыз сум итеп түләсе була икән!» Әле бу акча да җитми... Аптырап-йөдәп апаларына киңәшкә йөгерде.

—Апа, әллә мәктәптән китеп, базарга сатуга чыгыйм микән? Мәктәптән алган зарплатаны җыеп булмый, тотылып бетә, яшәргә кирәк бит...

Апасы уйланып торды.

—Нәрсә сатарсың микән соң? Хатын-кыз киемнәре үтемлерәк инде дә... Ярар, товар алырга акча бирербез, эшләп кара.

Шулай итеп, кичәге укытучы бүген чүпрәк-чапрак сатарга чыгып басты. Ирен коткарыр өчен ул нинди эшкә дә риза, бернәрсәдән дә курыкмый...

***

—Менә, карчык, мине «списать» иттеләр, инвалид-пенсионер картны кабул итәсеңме?—дип ВТЭК комиссиясеннән бөтенләй икенче кеше булып кайтты Насих: борчылганы, кимсенгәне йөзенә чыккан... Ул бит типсә тимер өзәрлек егет иде юкса...

—Нурия, миңа бүген бер «чүлли» алып кайт инде! Соңгы тапкыр эчәм, янадан тамчы да капмыйм! Илле яшеннән инвалид булу кыен икән...

***

Базарда акча ишелеп төшмәсә дә көн дә әз-мәз керә тора. Нурия Насихны аерым диетага утыртты. Аның хәле яхшыргандай булды: йөзенә төс керде, кәефе аруланды. Бер кайтуында ире хәтта баянда уйнап утыра иде.

—Әнисе, бүген радиодан Салават яңа бер көй җырлады. Сүзләрен исемдә калдыра алмадым, көен отып алдым. «Синсез яшәп булмый» дигән җыр бугай. Менә тыңла әле!

Баянына иелә төшеп, яңа өйрәнгән көйне уйнап җибәрде. Нурия иренең музыканы сагынганын, тормыш яме күңеленә кайтканын күреп сөенде. Алар бик еш кичләрен шулай—яңа көйләр кабатлыйлар: Насих баянда уйный, Нурия җырлый иде, ул кичләр бәйрәм кебек шатлыклы була, малайлар да тынып тыңлый иде. Бүген дә, бүлмәдә шыңгырдап мажор көйләр яңгырагач, бәйрәмдер кебек тоелды...

***

—Насих, Казанга шылтыратып алтынчы больницаның кардиология бүлеге җитәкчесе белән сөйләштем, безне чиратка язып куйдылар, бер айдан килергә куштылар!—диде Нурия.

Башланган эш—беткән эш, дигәндәй, моңа кадәр булган тырышлыклары ниһаять максатка якынайткач ул канәгать иде. Ләкин Насих эндәшмәде, сүзгә кушылмады, йомылды... Кич йокларга яткач, хатынына сыенып, йомшак инсәсеннән үпте дә:

—И карчыгым! Мин сине шулкадәр яраттым!—диде. «Яраттым» диюе үткән заманда, сагышлы, моңсу ишетелде, хушлашкандай, бәхилләшкәндәй булды. Иренең сүзләре Нурияне сискәндерде: «Күңеле ни сизә микән?»

—Мин сине һаман шулай яратам! Терелсәсен әле Алла боерса!—дип ирен юатты. «Мине ташлап китмә, җаным, синнән башка яши алмыйм» дип әйтәсе килде, ләкин теле әйләнмәде, иренең яшәү өметен өзәрмен дип курыкты...

Казанга китәргә күп тә калмаган иде инде... Тирә-якны куркытып, ашыгыч ярдәм машинасы Насихны авыр хәлдә алып китте...

Бу вакытта Нурия эшенә килеп, базар ларегын ачып кергән иде. Төнге салкыннан әйберләр дым тарткан. Киштәдәге мохер кофталарны кабартып, каккалап, элгечләргә кигертте. Хәзер сатып алучыларны көтәсе генә калды. Сәгать тугыз тулса да көн карангы, күкшел болытлар куерган, әллә яңгыр, әллә кар яварга җыена. Нуриянең күңеле тынгысызлана: бүген иртән Насих кәефсез, зарланмаса да хәле юклыгы сизелә, ireннәре күгәреп тора, тынын еш-еш ала. Әллә кайтып китәсе инде, товары сатылмаса сатылмас, Насих янында булырмын, ул мине сагынып көтә! Пенсиягә чыккан карт түгел бит, кешеләр арасында булырга тиеш ир, дип Насихын кызганды.

Өйләренә кайтып җиткәч тә кече улын очратты.

—Әни! Мин синең янга барырга чыккан идем! Әтине «Скорый» алып китте. Әти янында Зиннәт абый, сиңа килергә кушты.

Нуриянең сизгер күңеле төзәтә алмаслык фаҗигане тойды: «Йә, Раббый Ходаем, исән генә була күрсен! Берүк исән булсын!»

Нурия палатага килеп кергәндә төсе качкан җизнәсе каршылады. Хатын ире яткан караватка карагач, егылып китә язды, җизнәсе тотып калды: Насихның өсте ак җәймә белән капланган иде... Нурия җизнәсен этеп, ире янына килде, җәймәне ачты... Насихның күзләре йомылган...

—Наси-и-и-х!!!—Үзәк өзгеч тавыш белән инрәп әле иренең тән җылысы да качмаган күкрәгенә капланды... Өметләнеп Насихының йөрәгe типкәнен көтте... Тик кадерле күкрәктән хәбәр килмәде... Нурия тынсыз калды да

идәнгә шуып төште. Коты очкан жизнәсе доктор янына чапты.

Нурияне күтәреп янәшәдәге урынга салдылар. Шәфкать туташы укол кадаганнан соң да ул әле тиз генә аңына килмәде.

—Курыкмагыз, тиздән аңына килер, мондый хәлләр була ул,—диде кыз.

Балдызы күзен ачкач, Зиннәт аны юатырга кереште:

—Сабыр булырга тырыш, Нурия! Нишләмәк кирәк соң! Тормыш шулай бит ул. Үлгән артыннан үлеп булмас... Әҗәл житкәч, барыбыз да шунда китәбез инде...

—Үзем үлсәм яхшырак булыр иде... Насихсыз бу тормыш нигә кирәк миңа?! Авырлык белән генә аңына килгән хатын зәгыйфь тавыш белән дәвам итте:—Жизнәй, син килгәндә ул исән идеме әле? Аңында идеме? Сөйләштегезме?

—Аңында иде. Сөйләшерлек хәле юк иде.

—Бер сүз дә әйтмәдеме?

—Нуриягә әйт, фатир аныкы, беркемгә дә бирмәсен!—диде.

—И бичаракаем, үлгәндә дә минем турыда кайгырткан!—Нурия илереп елый башлады.—Шул квартир мәсьәләсе үлемен тизләтте дә инде! Хараплар иттем! Саклый алмадым!—Нурия иренең янына килеп идәнгә тезләнде дә, башын күкрәгенә куеп кочаклап тын калды... Шушы газиз гәүдәне кочаклап, мәңгелек йокыга таласы килде...

Нуриянең тынсыз утыруы жизнәсен тагын да ныграк куркытты. Үзе белән үзе сөйләшкәндәй:

—Сабырлык кирәк инде... Карамадың түгел, карадың Насихны... Син тырышмасаң, әле бу яшькә житә алмаган булыр иде.

—Соңга калдык! Операциягә соңга калды-ы-ы-ык! Алданрак бара алсак, үлмәгән булыр иде!

Нурия иренең тынычланган, жыерчыклары язылган, елмаюга охшаган йөзен, чәчләрен сыйпап, газиз баласын иркәләгәндәй дәвам итте.

—И бәгырькәем... Хәзер йөрәгең авыртмас инде... И-и-и...—Ул нечкә генә итеп, скрипка кыллары чыңлагандай сузып-сузып елады. Бу елауда чарасызлык, үкенеч, мәңгегә аерылышу ачысы бәргәләнә иде.

***

И Насихым, бәгырькәем, барлык шатлыкларымны, дөньяның ямен үзең белән алып киттең... Синсез көннәрнең барысы да кояшсыз, кызыксыз... Мине көткәнсеңдер... Квартираны бер бүлмәлегә алыштырып, калган акчага операция ясатасы да бит! Нишләп башыма килмәгән? Ни берәрсе киңәш итмәгән? Исән калган булыр идең!

... Ничә еллар үтсә дә, ул әле һаман Насихын коткарырга мөмкин булган юлларны эзләп газапланачак, үкенәчәк... Үзе гел шул турыда гына уйлап яшәгәнгә, улларының әтиләре турында сүз кузгатмауларына хәтере кала, ә уллары исә әниләренең йөрәк ярасына кагылудан курка... Шушы ике ел эчендә алар өлкәнәеп, житдиләнеп киттеләр, уртанчылары Айрат читтән торып укырга күчте дә мәктәпкә урнашты, кечеләре автомеханик булып эшли башлады. Әтиләрен югалтканнан соң гаилә әниләре өчен жаваплылык тоеп яши башлады.

***

Нурия, гадәттәгечә, иртүк уянса да торасы килмичә ятты. Күңелендә бушлык, канәгатьсезлек, яшәвенең мәгънәсе юк: иртән тор да базарга кит, тор да кит! Бүген дә, иртәгә дә, берсекөнгә дә... Көннәр гел бер төрле. Мәктәптә ичмасам алай түгел, һәркөн ниндидер яңалык була торган

иде. Класска кереп, балаларның якты йөзләренә карасаң, бар дөньяңны онытасың, тормыш мәшәкатьләре, көнелсезлекләр бусага артында кала. Анда үзеңнең кирәкле кеше икәнеңне тоясың...

Ул кулларын баш өстенә куеп, бүлмәне күзәтте. Насих исән чакта өйләре якты, җылы, нурлы, көнелле иде. Иренең мәхәббәте яктырткан икән... Хәзер бүлмә төссез, шыксыз...

Кайчандыр изге йокы бүлмәсендә тагын улы белән килене... Нурия өендә үзен ят сизә, элеккечә кайтырга атлыгып тормый, чөнки аны шатланып, сагынып көтүче юк... «Оям туздың!» дигән уй йөрәген өтеп алды... Иренең васыяте исенә төште... Торып бер чәшке кофе эчте дә, җәһәт кенә кузгалып, апаларына китте.

—Әйдә, мактап йөрисең икән, сумса пешергән идем,—дип шатланып каршылады Фәридә.

—Сезне дә мактамасаң, кемне генә мактыйсың инде тагын!

Апасының тәмле ризык исе таралган якты өендә күңеле күтәрелде, монда рәхәт, аны монда яраталар, көтәләр... Әнисе үлгәннән соң Фәридә ана апа да, әни дә булып калды.

Тәмләп чәй эчкәннән соң, Нурия ник килгәнен әйтеп бирде:

—Мин базардан китәргә булдым! Туйдым, апа, бер көн торасым килми! Сату да бармый. Шул базар аркасында Насихның соңгы минутларында янында була алмадым...

—Базарны ташлап нишләмәкче буласың?

—Белмим... Әллә чит илгә китим микән? Телевизордан шул турыда рекламалар күрсәтәләр. Чаллыда агентстволары да бар диләр.

—Ай-һай, үскәнем, андый агентстволар ышанычлы микән? Алар турында әллә ниләр сөйлиләр, хатын-кызларны коллыкка саталар, ди!

—Һи, кызларныдыр ул! Минем ишеләрнең кемгә кирәге булсын?!

—Юкны сөйләмә, Алла сакласын, дип әйт!

—Бер таныш хатын Грециягә китәргә җыена. Анда аның кызы грекка кияүгә чыккан. Ияреп китсәм ышанычлы була инде. Бер-ике ел эшләсәң, фатир алырлык акча җыеп була, ди. Шуны күреп сөйләшәм әле. Ринатларга үз ояларын корырга булышсам, үлсәм дә үкенмәс идем!

—Әстәгъфирулла! Тәүбә диген! Фәрештәнең «Амин!» дигән чагына туры килүе бар! Ринат үзе эшләп тапса, кадерен ныграк белер! Бер квартир алып биргән идегез бит инде, нишләтте?!

—Хәзер аны искә төшерүнең файдасы юк... Минем болай да үкенүдән йөрәгем яна! Җаным урын таба алмый...

—Ярый, син ул хатын белән сөйләшеп кара алайса, тик миңа әйтмичә бернәрсә дә эшләмә! Ашыкма! Соңыннан үкенерлек булмасын!

***

Танышы Нуриягә барысын да җентекләп аңлатты:

—Мәскәүдәге турагентствога юлламага заказ бирәсең дә барып аласың. Виза өчен дә акчаны шунда түлисең.

—Ничә сум акча кирәк булыр икән?

—Җиде йөз илле доллар җитә. Бер-ике ай эшләсәң, бөтен расходларны каплап була, ди. Минем кызым гостиницада идән юып, кер үтүкләп аена биш йөз доллар ала.

—Башта путевка буенча ял итәсеме?

—Нинди ял ул! Килүгә эш эзлисең ди!

—Без эш таба алырбыз микән соң?

—Ну, хезмәтче итеп алырлар. Анда барганнарның күбесе картларга,

карчыкларга няня булып урнаша ди.

Фәридә сеңлесенең Грециягә китүен хупламаса да, каршы тормады, яна жирдә бәлки ире өчен әрнүләре таралыр, дип уйлады.

***

Нурия жыенып бетте. Киткәнче Насихы белән бәхилләшәсе генә калды. Иренең васыятен үтәп, аны туган авылына жирләгәннәр иде. Ташлытауга барып житкәнче Нурия үткәннәрне күз алдыннан кичерде. Бик яраткан иде Нурия мондагы бар нәрсәне: төзек матур авылны, Насихы белән кавыштырган Шифа чишмәсен, кызлары кебек яратып кабул иткән каенанасы белән каенатасын, бигрәк тә күз нуры Насихын... Их, ул вакытлар...

Әнә Шифа чишмәсе янындагы урман каралып тора. Насих чишмәнең хәтере бар дигән иде, безнең бәхетле көнебезне хәтерли микән? Әллә чишмәгә барып килимме? Юк... Ташлытау чишмәсе нинди булган, хәзер дә шулайдыр, мин генә элеккеге бәхетле кыз түгел, көләч йөзле зәңгәр күзле сөйгәнем дә хәзер юк инде...

Нуриянең бер ялгызын гына зиратка җибәрергә теләмәде, аңа килендәше Фәнисә дә иярде.

Зиратка кайчан килсәң дә бик ямансу... Салкын ноябрь аенда бигрәк тә. Монда бөтен нәрсә үлем турында уйлата: иске каберләрнең тутыккан рәшәткәләре, яңа каберләр өстендәге төсләре унган кәгазь чәчәкләр, кар астыннан сузылып торган меңъяфракның кипкән сабаклары... Тормыш бетте, дип кисәткән кебек... Кара кәүсәләрендә жил сызгырган агачлар да үлем йокысына талганнар, мәңге уянмаслар сыман...

Шулай да, ничек ямансу булмасын, мәңгелек йортларына килеп урнашкан кешеләргә карата олылау хисләре тоясың. Тормыш белән үлем киртәсен үткән бәндәләр изге жаннар кебек, алар монда авыр газапларны кичеп килгәннәр...

Насихның каберенә юка гына булып кар яткан. Ул кар Нуриянең йөрәгенә кунган кебек, жаны өши... Менә хәзер үзе дә үләр шикелле... Күкрәгенең кайсыдыр төше киселеп-киселеп китә... Ул Насихның кабер ташындагы рәсеменә карап елап жибәрде.

—Наси-и-и-их! Мин синсез адашам бугай! Әйт, нишлим, китимме чит илгә? Синсез тормышның ничекләр кыен икәнен белсән! Кичер мине! Кичер, ташлаплар китәм бит!

—Нуриякәем, артык елама, картлар еларга кушмыйлар бит! Гөнаһ диләр, яшең ирең каберенә төшсә, рәнжер,—диде килендәше.

—И, Фәнисә, еламый нишлим! Китәм бит! Насих кала!

—Кайтырсың, Алла бирса! Мәнгелеккә китмисен бит! Насихың рухына сәдака биреп торырсың! Күнеленә тынычлык инәр!

—Анда кемгә сәдака бирәсең ди! Греклар христиан динендә бит!

Нурия әллә суыктан, әллә борчылудан, калтырый башлады, күгәргән иреннәре дерелдәде.

—Мөселман кешесе булмаган жир юк! Булыр әле, очратырсың! Әйдә, Нуриякәем, кайтыйк, туңасың. Сиңа хәзер чирләргә ярамый.

Нурия кар өстенә тезләнеп иренең рәсемен сыйпады.—Хуш, бәгърем, рәнжемә! Күнелемнән бер минутка да чыкмыйсың! Кадерләренне белмәдем. Мин сине ничек яратуымны да аңлап бетермәгәнмен...

Ул тагын елый башлады...

***

Бигеш аэропортында тикшеренүләр үтеп, очкыч трапына менгәндә

Нурия килгән ягына каерылып карады—озатучылар бик еракта, бер кешене дә танырлык түгел иде. Туган илнең карангы күге, очкыч канатлары астыннан ноябрь салкыныннан туңган җир буйлап йөгерүче җәяүле бураны, сызгырып искән салкын җиле елаган кебек тоелды... Болай да икеләнеп кенә юлга чыккан хатынның йөрәге өшеп китте, траптан сикереп төшеп, үзе яшәгән Ак шәһәргә, уллары, апасы белән җизнәсе янына кайтасы килде, шул теләгеннән көчкә тыелды...

Кара болытлар аста калдылар, унбер чакрым биеклеккә менгәч, кояшлы җете зәңгәр күк ачылды, ләкин ул яктылык куандырмады, киресенчә, Җиранадан ерагаю тынгысыз күңеленә шом гына салды, йөрәге куркып типте. Ил-көнен ташлап кая китә бу хатын? Ни куа аны йортыннан? Нурия бу сорауга җавап бирә алмый инде... Тынгысыз җаны үзенә урын эзли торгач, өермә кебек бөтереп, чарасыз сагышлар канатында туган туфрагыннан кубарып, әллә кайларга алып китте...

*Нуриянең беренче хаты*

Кадерле Фәридә апа, Зиннәт җизни!

Сезгә кайнар сәламнәр белән сенлегез Нурия.

Грециягә килгәнгә биш көн үтеп китте. Мәскәүдән бары өч сәгать очтык. Самолеттан төшкәч тә башка дөньяга килгәнебезне тойдык: Мәскәүдә кар ява иде, монда коры җылы һава, тирә-якта искитмәле хуш ис—лимон, әфлисун, чәчәк исе таралган. Аэропорт янында клумбаларда кызыл чәчәкләр ут кебек янып тора, тирә-якта пальмалар, кипарислар... Гаҗәп инде! Икенче көнне графия дигән җиргә бардык, ул аерым кешеләр оештырган «биржа труда» сымак урын, законлы оешма түгел. Монда безне ачык йөз белән каршыладылар, чөнки Рәзифәнең кызы безнең киләсене хәбәр итеп куйган. Лена исемле хатын саф рус телендә сөйләшә, ул үзе дә ике ел элек кенә Пятигорскидан монда күчеп килгән гречанка.

—Бәхетегез бар икән, сезгә эш урыны таптык,—диде. Ул мина ике урын тәкъдим итте.—Кайда эшләргә телисез: Крит утравындамы, Афинадамы?

—Кайда соң ул утрау?

—Ерак инде, Әдрән диңгезендә, Төркия янында диярлек.

—Юк, анда китәргә теләмим, Афинада калам. Монда нинди эш соң?—Мин дулкынланып, язмышым кемнәр кулында микән дип көттем.

—Йөз дә биш яшьлек әбине караучы кирәк.

—Йөз дә биш?!

—Сез борчылмагыз, әби әле таякка таянып үз йомышларына йөри. Аның алты баласы читтә яши. Төпчек кызы Афинада.

Лена мине булачак хуҗаларыма алып барды. Әби Деметра исемле икән. Әбинең кызы Лена белән нәрсәләр турындадыр сөйләштеләр. Аннан соң Лена мина вазифаларымны аңлатты:

—Сез бу йорттагы барлык эшләрне дә башкарырга тиеш буласыз. Өй җыештырырга, кер юарга дигәндә автомат кер юу машиналары бар, ашарга пешерергә, кибеткә, базарга йөрергә, әбине карарга. Алар сезгә дүрт йөз илле евро түләячәкләр. Бу яхшы бәя, гадәттә тел белмәгәннәргә өч йөз илле евро түлиләр. Хуҗалар хисабына тукланасыз. Көнгә ике тапкыр итле азык, бер тапкыр балык пешерерсез, калганын тагын үзләре аңлатырлар.

—Ничек? Алар әйткәнне мин ничек аңлыйм?

—Әкренләп өйрәнерсез әле. Ике-өч айдан ярыйсы гына аңлаша башларсыз. Әйтергә онытып торам икән, сезгә айга өч ял бирәләр, яхшы кешеләргә туры килдегез, кайберәүләр айга бер генә ял бирә.

Лена хушлашып чыгып китте, мин телсез Темәй кебек карап калдым. Әбинең кызы галәмәт юан хатын, зур симез борынлы, калкыбрак торган зур

күзле. Ул миңа сынап карады да, ымлап үзе артыннан чакырды. Без кечкенә бүлмәгә кердек. Түрдәге караватта мендәрләргә сөялеп кечкенә генә, юка гына карчык ята иде. Мин аның янына килеп үзебезчә эндәштем:

—Исәнме, әбекәй! Ничекләр шушы яшькә життен?! Тормышың рәхәт булгандыр инде, җимешләр генә ашап яшәгәнгәдер.

«Монда яшәсә, минем Насихым да озын гомерле булыр иде, бәлки!»—дип уйладым да чак елап җибәрмәдем.

Әби ягымлы гына нәрсәдер әйтте. Мин аның көрән тамырлары кабарып торган кулын сыйпадым. Хикмәти Хода, гадәттә картларның кулы салкын була, Деметра әбинең кулы кайнар иде! Уйласаң һушың китәр: үз гомерендә бу куллар ниләр генә эшләмәгәндер! Алты баласын юындырган, киендергән, ашарларына пешергән, гаиләсен көйләгән!

Хуҗаларымның йорты дүрт катлы. Беренчесен кибеткә арендага биргәннәр, икенче катта әби белән без яшибез, калганнары буш. Кайчандыр бу йорт шаулап-гөрләп торган, этаждан-этажга балалар чабып йөргән, бәйрәмнәр, туйлар үткәндер, хәзер монда тормыш сүнәргә бара.... Йөз дә биш яшьлек әби генә калган... Мескен... Мебельләре үзләре белән бергә картайган...

Мин үземне Робинзон Крузо кебек кешесез утраудагыча тоям, бер авыз сүз сөйләшми йөрү, ялгызлык мона кадәр кичермәгән газап булып чыкты. Өстәл янында сезнең белән чөкердәшеп чәй эчүләр зур бәхет булган икән... Гомеремнең кире кайтмас көннәре сагыну газапларында үтәр микәнни... Килгәнемә үкенәм...

Ярый, хушыгыз! Туганнарның барысына да миннән сәлам! Сезне сагынып, сенлегез Нурия.

8 ноябрь, 2002 ел.
Афина.

***

Грециягә җыенганда көндәлек яза башларга исәбе бар иде. Шулай ук Борынгы илнең тарихы, хәзергесе, гореф-гадәтләре, этнографиясе дә аны кызыксындыра иде. Чаллыдан алып килгән калын дәфтәре уйлаганнан да арурак кирәк булып чыкты. Ялгызлыктан туган хисләрен, күргәннәрен шул дәфтәргә язып, җанына бераз җиңеллек тапты, дәфтәре әңгәмәдәшенә әйләнде.

*Нуриянең көндәлегеннән*

10 ноябрь 2002 ел.

Бүген беренче тапкыр базарга бардым. Бөтенесе бакырыша. Сугышалар бугай дип якынрак барган идем, алар: «Эна евро! Мисо евро! Эла! Эла! Глико!» дип, берсеннән-берсе ныграк кычкыралар! «Эла!» дигәннәре «Монда кил!» дигән сүз икән. Үзләренчә товарларын шулай тәкъдим итүләре икән. Русча-грекча сүзлек алган идем, өйрәнә башладым.

Без шәһәрнең борынгы өлешендә яшибез, урамнары тар, җимерек йортлар очрый. Чаллының киң, иркен проспектларына күнеккәч, мондагы бөтен җир күнелсез тоела. Боларда көн белән төннең дә аерым төсмере бар. Кояш та бер сәгатькә соңрак байый.

25 ноябрь 2002 ел.

Унбиш көн үткән дә киткән. Ял көнемдә графияга бардым, җыелдык, барыбыз да элеккеге СССРдан: Россиядән, Украинадан, Белоруссиядән. И сагынылган да соң! Туганнарымны күргән кебек булдым! Рәхәтләнеп кафеда сөйләшеп утырдык. Танышкан хатыннарның күбесе югары белемле... Бер

яктан караганда, тирәнрәк уйласаң, хурлыгы ни тора... Үз илендә кешечә яшәрлек кадерең булмасын инде!... Хатыннарның барысы да балаларын укыту өчен яки фатир сатып алыр өчен акча эшләргә гаиләләрен ташлап килгәннәр, миннән яшьрәкләре дә, минем кебекләре дә бар. Туган Илне сагынучылар бер мин генә түгел. Очрашкач бераз елаштык та, көлештек тә... Хуҗаларның бераз гайбәтен дә саттык. Тел белмәү аркасында әллә нинди мәзәкләр дә килеп чыга икән.

—Мин яңа эшли башлаган көннәрдә,—дип сөйләде Белоруссиядән килгән Вера,—тәрбиямдәге бабайның улы берничә тапкыр «Борис» дип ычкындырды. Мин бабай Борис исемле икән дип уйладым да, аңа гел Борис дип эндәштем. Мин эндәшкән саен бабайның йөзе караңгылана, шикләнеп карый. Шуннан бер көнне бабай улына нәрсәдер әләкләшә: бу хатынны куып җибәр, оятсыз нәрсә бугай ул, ди. Ни булганын көчкә аңладым: грекча «борис» «можешь» дигән сүз икән. Боро—могу, борис можешь дигән сүз, бичара бабай мин аны «можешь, можешь» дип кыстый дип уйлаган! Бабаема туксан ике яшь...

Без рәхәтләнеп көлдек! Графия илебезнең бер кыйпылчыгы кебек тоелды! Анда очрашканнан соң тынычланып кайттым, көч алдым. Без хәзер ялгыз түгел! Чит илдә ялгызлыктан интеккән җаннар берләштек, дуслаштык! Бу дуслык бердәнбер таяныч!

*Деметра әби турында*

Деметра әбигә карыйм да, бу кадәр озак яшәү кирәк микән, дип уйлыйм. Билгеле, һәркемнең бу дөньяда озак яшисе килә. Менә минем әбигә йөз дә биш яшь. Бер уйласаң, күп тә кебек, ләкин бу бер усак агачы гомере генә бит! Гомернең күңелле, яшь чаклары озагракка сузылсын иде дә аның!

Әбинең яше йөздән артса да үз акылында, бик мәрхәмәтле. Заманында алдынгы фикерле кеше булган. 500 евро пенсия ала. Таякка таянып булса да йөри. Ләкин ул яшәп туйган, яшәвеннән авырыксына. Кеше кулына калып яту рәхәт түгелдер инде... Бервакыт әби ачынып:

—Минем дус хатыннарымнан бер Мерсина гына калды, ул да хәзер авыр хәлдә, мине танымый! Нәрсәгә дип яшим соң һаман? Мерсина да китсә, мин дә икенче көнне үк фэвго! Китәм! Китәм дигәч китәм! Менә күрерсез! Яшә әле дип үгетләмәгез!—диде.

Мескенне җәллим... Ярый әле балалары исән. Алар да олы яшьтә инде. Миңа әбине карау бер дә авыр түгел. Ходай Тәгалә аңа гомерне шулай насыйп иткән икән, яши бирсен! Аны караган өчен Аллаһтан миңа да савап булсын иде! Шулай дип телим. Монда гаилә саен шундый озын гомерлеләр, тормыш шартлары яхшы булгангадыр инде... Климатлары әйбәт—суптропик, ел дәвамында яшелчә, җиләк-җимеш, җылы. Бар булган азыкны зәйтүн мае белән генә ашыйлар. Монда кыш булмый. Безнең өйдә бернинди мич тә, җылыту батареялары да юк, әби бүлмәсендә генә электр җылыткычы куелган. Яшәү бездәгедән күпкә мәшәкатьсезрәк. Менә шундый хәлләр. Берүк әбием исән булсын! Бу йорт—минем яшәү чыганагы бит! Базар да майлы ботка түгел иде! Бүрене аягы туйдыра дигән сыман, сатучыны да аягы туйдыра, товарны юнәтергә, алып кайтырга, сатарга, көне буе аяк өсте торырга кирәк!

*Нуриянең икенче хаты*

Исәнмесез кадерле апа һәм җизни!

Бу хатны Деметра әби йоклаганда язам. Туганнарның кадерен читкә киткәч кенә ныграк тоясың икән!

Балаларымның, сезнең исән-имин яшәвегезгә күңелем куана, ләкин вакыт-вакыт йөрәк яраларым түзә алмаслык булып кузгала. Насихымны юксынам... Бүген төшемә керде. Ул гел элеккечә яшь килеш икән, дим. Кочаклаштык, кочагында аның тән җылысын тойдым, мена гел өндәге кебек! Аермачык! Бик озак еладым...

Бүген кибеткә чыккан идем, әллә нинди демонстрация күреп шаккаттым: урамнан колонналарга тезелеп, ирләр, хатын-кызлар, балалар кулларына шәмнәр тотып баралар. Сөйләшү, кычкыру юк, тып-тыныч, аяк тавышлары гына ишетелә. Чиркәүгә баралар икән! Бүген Рождество башланган. Монда халык бик дини, әллә шуңа күрә Греция җинаятьчелек буенча иң соңгы урында, ди. Олыларны бик хөрмәтлиләр, каршы әйтү юк. Монда аракы эчмиләр. Әбинең кызларына кунакка барган идек, бик сыйладылар. Кунаклар бик аз гына вино эчте. Винолы үз шешәләрен күтәреп кибеттән барып алалар. Исеме, сорты, елы язылган әкәмәт зур мичкәләрдән кранын ачып агызып бирәләр. Болар да безнең кебек мәҗлестә җырладылар, биеделәр. Җырлары мөселман көйләре кебек моңлы. Биюләре дә дәртле, түгәрәккә басалар да җитәкләшеп тыпырдыйлар. Биюләре хоро дип атала.

Менә шулай яшим. Грекның бер әйтеме бар: «Бикес сто хоро-хоревэ», ягъни—биючеләр арасына кергәнсең икән бие, бии алмый торсаң таптап китәрләр... Тормышка җайлашырга мәҗбүрсең, дигәндәй...

Мондагы кыш бездәге сентябрь ае кебегрәк. Бүген бигрәк тә җылытты әле, җәй кебек. Бер уйласаң гаҗәп инде: хәзер безнең илдә кар ява бит! Буран. Яңа елга пыр тузып әзерләнәсездер, чыршылар куясыздыр. Ә бирегә мимоза чәчәккә бөреләнә... Мин бер сәгатькә генә булса да шул үзебезнең урамнардан кар шыгырдатып йөрер өчен әллә ниләр бирер идем... Сезне якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм. Сәламәтлек, байлык һәм тигезлек телим! Сезне сагынып, сеңлегез Нурия.

25 декабрь, 2002 ел,
Афина шәһәре.

***

Йокларга җыенып йөргәндә телефон шылтырады. Междугородка икәнен ишетеп, Фәридә ашыгып трубканы алды.

—Алло!

—Алло, апа, исәнме!

—Әлекәем, Нурия! Исәнме, үскәнем!

Апасының ягымлы тавышын, газиз туган телен ишеткәч, Нурия теге якта елап җибәрде. Ул бик озак җавап бирә алмады, телефон трубкасында аның мышкылдавы аермачык ишетелеп торды.

—Нурия, җаныкаем, ник елыйсың? Чирләмисеңме? Әллә эшең бик авырмы?—Сеңлесенең елаганын ишеткәч, Фәридә ни кылырга белмәде, аны кызганып үзәге өзелде.—Алло, Нурия ник дәшмисең?

—Чирләмим,—диде Нурия елый-елый.—Эш тә авыр түгел. Апа, мин монда тора алмам ахры, сагынам.—Насих гел төшемә керә, көндез исемнән чыкмый.

—И бәгырькәем, түзәргә тырыш инде! Иләшерсең әле! Расходланып, акчаңны туздырып, кире кайтырга ашыкма. Әллә хуҗаларың начармы?

—Ю-у-у-к! Әби бик әйбәт!

—Соң шулай булгач!

—Сагынуга түзә алмыйм!

—Чит җирдә сагындыра инде ул. Түз инде, сеңлем.

—И әйтергә җайлы! Син ялгызлыкны беләсеңмени?! Берүзең читтә торып

караганың бармыни! Мин монда давыл китереп ташлаган йомычка кебек. Сез... сез анда бергә...—Ул тагын елый башлады.—Бергәлекнең кадерен белегез!

—И, үскәнем, елама инде, син елагач, миңа авыр. Гафу ит мин юләрне, сине җибәрәсе калмаган! Болай буласын белгән булсаммы?!

Апасын артык борчыганын аңлап, Нурия тынычрак сөйләшергә тырышты.—Ярый, апа, борчылма! Тавышымны ишеткәч кенә әллә ничек, йомшап киттем... Торып карыйм әле. Бәлки күнегермен. Түзә алмасам, кайтырмын да китәрмен, мине көчләп тоткан кеше юк.

***

Апасы белән сөйләшкәннән соң Нуриянең сагынулары-сагышлары басылмады, киресенчә, көчәйде генә. Хәзер бу бәйләнчек уйлар чиргә әверелде: Нуриянең тамагыннан үтми башлады, тәмле ризыклар пешереп ашарга утырса, күңеле болгана. Моның өстенә ин хәтәре—йокысызлык җәфалый башлады. Авырткан җире булмаса да авыруга сабышты. Уйга чумып, эшлисе эшләрен онытып, бер ноктага текәлеп, үзен чолгаган чынбарлыктан әллә кайларга китә... Көндезге газаплардан, авыр эшләрдән, барлык мәшәкатьләрдән адәм баласы онытылып торсын өчен Ходай төнге йокыны биргән. Нурия хәзер аннан да мәхрүм... Санап та ятып карый, аз-маз белгән догаларын да укый, берсе дә ярдәм итми, борчыла, борсалана, торып балконга чыгып утырып карый... Әнә күк чите саргылт-яшел булып яктыра башлады, аннан соң алсуланып таң атты. Әбинең өе янында үскән лимон агачыннан иртәнге һава хуш ис бөркеде... Лимон исе тәмле... Ләкин Нурия яраткан исләр башка: ул колмак исен, бакчаларда койма буйларында, басу читләрендә үскән киндер орлыгы исен, шомырт, балан чәчәкләре исен ярата...

Соңгы тапкыр базарга чыккач, бер малайның кешеләрне үлчәп торганын күрде дә, үлчәүгә менеп басты, үлчәүгә карап коты очты: дүрт килога кимегән! Элек тә бер мыскал да мае юк иде, хәзер тире белен сөяккә генә калган икән!

Графияда очрашкач, дуслары андагы үзгәрешләрне күреп аптырадылар:
—Нурия, ты что, заболела что ли?
—Авырмыйм, йоклый алмый башладым.

Хатыннар аның өчен борчылып, төрле киңәшләр бирсәләр дә Нуриянең бу халәте аларның күбесенә таныш иде...

Рухың сынса, җаныңны да, тәнеңне дә чир җимерә. Бер кичне Нуриянең температурасы утыз тугызга күтәрелде, колаклары чәнчешеп, муенындагы бизләре шешеп чыкты. Тышкы яктан каты бизләрне капшады да, үлемем шушы икән, дип коты очты. И Ходаем, чит туфракларда ятып калыр микәнни? Соңгы сәяхәте Насихы янына булыр, аның янәшәсенә дип уйлый иде бит, юкса...

Куркудан йөрәге өшеп, җаны чыгардай булды, яшәүгә өмете ярма бөртеге кадәр дә калмады, күңеленнән балалары, туганнары белән, газиз туган иле белән бәхилләште...

***

Бу юлы сөйләшкәндә сеңлесе еламады, ләкин тавышы күңелсез, салкын иде:

—Фәридә апа, мин авырыйм, ашый да алмыйм, йоклый да алмыйм, сөяк белән тирегә генә калдым. Муенымдагы бизләр шеште, рактыр ахрысы. Үләрмен инде мин... Сезне яңадан күрә алмам...

Сеңлесенең сүзләре һушын алды, куркудан калтыраган кулларыннан

телефон трубкасы төшеп китә язды.

—Тукта әле, Нурия, ни сөйлисең?! Нишләп үләсең ди! Чирләгән саен үләләр димени! Авыру килә дә китә бит ул! Ангина белән күп кеше авырый, аннан үлмиләр бит!

—Ангина түгел шул, бизләр тыштан кабарып чыкты.

—Докторларга күрен!

—Ничек докторларга күренимм, минем документларым юк бит! Кулга алып төрмәгә тыгып куярлар!

—Нурия! Мин Сажидә белән сөйләшим, киңәшим әле! Иртәгә шалтыратырбыз, син аңа барысын да сөйләрсең. Ул тәҗрибәле терапевт, нәрсә эшләргә кирәген үзе аңлатыр.

Нуриянең тудыкасы ул Сажидә, бөтен туганнары да берәр нәрсә булса аңа баралар. Нуриянең муенына жылыткыч куйганын белгәч Сажидә аны әрләп алды.

—Янадан жылытма, ярамый. Кайгырма, үлмисең! Ләкин ныклап дәваланырга кирәк, көнгә дүрт тапкыр антибиотик ясат. Авыруын отит, лимфоденит булырга охшый. Витаминнар эч, нервларыңны да дәвала, антидепрессантлар эч. Вакытың булганда көн саен һавага йөрергә чык.

Сажидә туганының авыруга сабышу сәбәбе бигрәк тә нервларның какшавы, сагынудан икәнен белә.

—Нурия безнең игътибарга мохтаж, аңа жан жылысы житми, ешрак сөйләшеп торыйк, хатлар языйк, кучтәнәчләр, бүләкләр жибәрсәк тагын да әйбәт,—диде Сажидә.

Үлмисең дигән сүз ишеткәч Нуриянең күнеле күтәрелде, үлем чигенде. Туганнары аның өчен борчылып посылка белән чәкчәк салды, татар жырлары язылган кассеталар жибәрде. Телефоннан сөйләшү белән генә канәгатьләнмичә, озын-озын хатлар яздылар. Нуриянең авыруы Ходай сынавы гына булды бугай.

Шул вакыйгалардан соң күнеле утырып, тынычланып калды. Хәзер биредәге кешеләр дә, шәһәр дә, табигать тә рәхимле дөнья булып күренә! Юк, ул давыл китереп ташлаган йомычка түгел... Чит илгә чыгып китәр өчен кыюлык та, батырлык та кирәк! Һәр кеше дә моны эшли алмый! Ул илендә дә төшеп калганнардан түгел! Анда аны сагыналар, яраталар, көтәләр!

*Нуриянең көндәлегеннән*

8 Март 2003 ел.

Бу илдә 8 март көне бәйрәм ителми бугай, бернинди хәзерләнүләр дә күренми. Улларымнан, апалардан, туганнарымнан открыткалар килгәч сөенүләрем!.. Монда инде яз түгел, кайнар жәй. Безнең илдә шаулап бәйрәм итәләрдер. Бүләкләр, чәчәкләр, мәжлесләр! И күнелле дә була торган иде! Насих миңа чәчәк бүләк итми калмый иде!

Авырудан терелә башлагач, тынычландым, шуны аңладым: югалтулардан да файда алып яши белергә кирәк икән! Түзә алмаслык сагыш, ялгызлык, авырлыклар мине ныгытты бугай. Башта Афинада гел тискәре яклар гына күреп яшәдем. Карнеги китабында: «Два человека смотрели сквозь тюремную решетку: один видел грязь, другой видел звезды», дигән. Минем дә хәзер фикерем үзгәрде: кешеләргә дә, гореф-гадәтләргә дә башкача карый башладым.

Грециягә килгәнемә бер ел тулып үтте. Күз тимәсен, тормышымда уңышлар чыгып тора: Ринат улым хатыны белән әйбәт эшкә урнашып, байтак акча жыйганнар. Теге уңышсызлыктан соң тиешле нәтижә ясаганнардыр, күрәсең. Әни, безнең акчага син жибәргәнең дә кушып, квартирага житәрлек кредит алмакчы идек, бирмиләр, берәрсе аша кредит оештырып булмас иде микән,—дип язган. Тормыш безне гел сынап кына

тора. Квартиралар тагын кыйммәтләнде. Бер ел элек мин җибәргән акчага квартира алып булыр иде, быел инде яртысына да җитми. Тагын Илгизәгә йомыш төште. Илгизәдән дә игелекле кеше юктыр бу дөньяда! Ул үз исеменә кредит алып, Ринатка биргән. Аның изгелегенә бәя биреп бетерә торган түгел! Ринат шуны аңласын иде... Шулай итеп, хыялым тормышка ашты—өр-яна йорттан Ринат ике бүлмәле фатир алган: Аллага шөкер! Эх, Насихымны да шатландырасы иде! Кире кайтарыплар булмый шул... Алла боерса, ай саен дүртәр йөз евро салып барсам, ике елдан Илгизәгә бурычны түләп бетерәм! Тагын ике ел... Элладада яшәргә язар микән?

12 декабрь 2003 ел.

Тормышымда бераз үзгәреш бар. Алты йөз евро түлибез дигәч, икенче кешеләргә күчтем. Деметра әби белән хушлашу кыен булды: ул миңа бик күнеккән иде, мин дә яраткан идем, әбинең мине җибәрәсе килмәде... Нихәл итмәк кирәк, миңа тизрәк бурычны түләп бетерәсе бар.

Монда ике кеше карыйм: әби белән бабай. Бабайга туксан алты яшь, әбигә 93 яшь. Икесе дә авырлык белән генә йөриләр. Бабай култык таягында, гәүдәсе баһадирларча: бөкрәймәгән дә, кечерәймәгән дә. Һәр атна минем белән базарга чыга, барып житкәч, утырып ял итә. Бабай базардан тозлы балык, тозлы Элес—олива алдыра. Әби белән бабайның бүлмәләре зур гына. Әбинең караваты түрдәрәк, бабай караваты яныннан үтеп китәсе, һәр көнне әби юынып чыкканда бабай аны сөеп, артыннан: «Агапи му! Кардия му! Лулу де му! Бэрестери му!» ди. «Любовь моя! Сердце мое! Цветочек мой! Голубка моя!» ди. Минем исем китә! Аларның өйләнешкәннәренә дә житмеш елдан артыктыр инде! Нинди матур гомер кичергәннәр! Әби бик канәгать, бабайны ярата! Кайвакыт бабай йокымсырап, әби үткәнне күрми калса, әби тамак кырып бабайны уята, бабай үрелеп әбине сыйпап кала! Бик еш икесе ике караватта сөйләшеп яталар. Кайвакыт әби бабай янына килеп утыра. Шулай итеп бер-берсенә яшәргә көч биреп торалар, аларга тормышта күнелсез түгел! Менә ни өчен изге теләк итеп кешеләргә тигез тормыш телиләр икән! Мин аларга карап сокланам да: «И Аллакаем, ник минем иремә дә янымда картаерга насыйп итмәдең! Мин дә Насихымны шулай карар идем, сөяр идем!» дим...

Бабайның тавышы бик моңлы, вакыт-вакыт балконга чыгып утырып, матур итеп җырлый. Бабай Дракулис исемле, әби Канелла.

8 январь 2004 ел.

Тагын бер Яңа ел җитте. Монда яңа елны бездәгечә төнге уникедә табын корып каршыламыйлар. Бар халык урамда: ракеталар шартлый, салют ясыйлар. Беренче январьда туганнарын чакыралар. Тышта күркә яки яшь бәрәнне бөтен килеш кыздыралар. Бер-берсен: «Хроня полло!—долгой жизни! «Кали хроня!—хорошего года!» дип котлыйлар. Урамда җылы җәй кебек: кояшта мандариннар пешеп утыра, һавада мандарин, лимон исе аңкый!

Яңа елга үземә теләк теләдем: февральдән легализация башлана икән дип сөйлиләр, шул хак булсын иде! Безнең монда яшәү законлашсын иде! «Вид на жительство» бирсәләр, илгә кайтып килергә дә булыр иде! Алай дим дә... Белмим, кайтсам, яңадан илемне ташлап китә алмам...

***

Күркә итен үләннәр һәм брынза белән көмеш кәгазьгә төреп, газ мичендә пешереп алгач, әби белән бабайны ашатты да, Нурия аптекага җыенды.

—Даруларыгыз бетеп килә, мин тиз генә аптекага барып кайтам, борчылмагыз,—дип картларны кисәтте, әйберләрен сумкасына салып

китәргә жыенды. Кухнягә кереп плитәне карап, тикшереп чыкты. Нуриянең шәһәргә бик ерак йөргәне юк, чөнки кибетләр дә, базар да янда гына, ә менә аптека ерак.

Автобуста бер генә буш урын бар иде, Нурия шунда барып утырды. Күршесе ана урын кинәйсен өчен, кырыйгарак күчте.

—Рәхмәт,—диде Нурия. Янындагы кешегә илтифат итмәсә дә, тегенең кызыксынып күзәтүен тоеп утырды. Калын, тыгыз гәүдәле, киң җилкәле ирнең тезләрендәге шоколад төсендәге зур кулларында ничаклы юсаң да бетми торган тимер карасы, төзәлгән җәрәхәтләрнең эзләре сизелә. Нуриянең карашын сизеп, ир янәшәсендә сумка бавын кысып тоткан Нуриянең ап-ак кулына сак кына кагылып:

—Мармара!—диде. Мармара грекча мрамор дигәнне аңлата. Аксыл чәчле, зәңгәр күзле, ак йөзле сөйкемле хатынга битараф кала алмаган ир Нуриянe җәлеп итәргә сәбәп эзли иде. Нурия ана борылып карады. Күршесенең күзләре белән очрашкач, уңайсызланды: ул күзләрдән кайнар сәмум җиле искәндәй булды. Грециягә килгәч, хатыннар сөйләгәннәр иде, монлагы ирләр артык дәртле, утыздан үткәч тәмам шашалар, хатыннары өстеннән сөяркә тоталар, дип. Нуриянең иң сөймәгәне хатыннары өстеннән йөрүче ирләр. Насихның көнләшерлек сәбәбе булмаса да Нурия берничә тапкыр ирен утлы табага бастырган иде.

Ир Нуриянең кем икәнен чамалап алды бугай.

—Сез монда бизнес беләнме?—дип сорады.

—Юк,—диде хатын коры гына. Кемнеңдер аны энә күзеннән үткәреп утыруы ошамады, теге караш астында үзен уңайсыз сизде. Ак бриджи сыланып торган тезләрен кушып куйды, чәчләрен рәтләгәндәй итте. Күршесе бу хәрәкәтләрне елмаеп күзәтте. Тукталышта беркемне дә автобустан төшермичә, полицейскилар күренде.

«Беттем!» дип уйлады Нурия документлар тикшерә башлагач. Грециядә миллионлаган рөхсәтсез, документларсыз яшәүчеләрне шушылай автобусларда, электричкаларда аулаганнарын Нурия белә. Берәүләрне үз илләренә депортацияләләр, икенчеләрне төрмәгә утыртып куялар. Бәхетем юк икән, дип өзгәләнде хатын. Әллә нишләп урыныннан калкынып куйды, янындагы кешегә борылып карады. Нуриянең күзләрендә коточкыч курку, чарасызлык чагыла иде. Күршесе аның борсалануыннан эшнең нәрсәдә икәненә төшенде. Ул Нуриягә якынрак килеп утырды. Полицейскилар алар янында туктады.

—Сезнең документларыгыз!

Нурия сумкасында актарынган булды, эзләгән атлы итте. Күршесе:

—Без хәзер төшәбез, менә минем документларым,—дип документларын күрсәтте.

Ләкин аның сүзенә игътибар итмичә, Нуриянең документларын көттеләр.

—Документларым өйдә калган,—диде хатын.

Аны полиция бүлекчәсенә алып киттеләр. Борчылудан ул кая барганын да хәтерләмәде. Сорау алганнан соң, шул ук бинадагы бер бүлмәгә кертеп яптылар. «Мал кебек!»—дип уйлады бичара хатын. Басуга кергән малны «пуләвәй» дигән кеше колхоз утарына алып кайтып яба да, хуҗасы акча яки берәр ярты биреп алып киткәнче хайван шунда ябылуда ята.

Нуриянe бу бәладән йолып алыр кеше юк...

Бүлмәдә аннан башка тагын берәү бар иде. Елап шешенеп беткән яшь кенә кыз әледән-әле юеш борынын тартып утыра. Үзе кебек үк бәлагә тарыган кызны күргәч, кызганудан, буталган фикерләре әкренләп җайга килә башлады, шушы мәлдә юатыр кешесе булмаган кыз баланың кайгысы

үз хәсрәтен арткарак этәрде.

—Сине дә бүген тоттылармы?—дип сорашты ул кыздан русчалатып.

—Әйе.

—Кайда эләктерделәр?

—Тавернага керделәр дә, алып тә киттеләр.

—Анда нинди эштә идең?

—Официантка.

—Кайдан килдең?

—Белоруссиядән.

—Исемең ничек?

—Зося.

—Мин Россиядән. Исемем Нурия. Зося, ничә яшь сиңа?

—Егерме.

—Балакаем, ничекләр йөрәге житеп чыгарып җибәрде соң сине әниең.

—Җибәрергә теләмәде ул, мин үзем киттем. Эшсез дә, акчасыз да ничек яшәмәк кирәк? Ничә ел квартирага чират торабыз, бер бүлмәдә биш кеше...

Йорт алырлык акча эшләп кайтмакчы идем.

—Хуҗаң яхшы түлиме соң?

—Күп түли иде, айга мең евро. Хәзер булмый инде, ни квартир, ни эш... Мине бит икенче тапкыр эләктерделәр, хәзер өч елга төрмә тиеш, диләр...

Кыз тагын елый башлады. Кызның хәле Нуриянекеннән мөшкелрәк икән...

—Борчылма, балам, бәлки утыртмаслар әле...

Кызны юатса да үзенең күңелен кара кайгы басты. Чит илгә килеп төрмәгә утырырмын дип кем уйлаган! Күрәселәрем бар икән! Илгизәгә дә бурыч түләнеп бетмәгән... И Аллам! Нинди гөнаһларым өчен җәзалыйсың? Кемнәрне рәнжеткән идем микән? Ринат квартира алгач, и шатланган идем! Сөенергә ярамый миңа! Артык сөенмә, диде бугай Ходай! Дөньяны онытып шатлану гөнаһтыр.

Иртән иртүк кулга алынган Нуриягә көн коточкыч озын тоелды. Бер минут та эшсез торырга өйрәнмәгән хатын, үзенә урын таба алмыйча рәшәткәле тәрәзәдән тышкы дөньяны күзәтте. Тимер рәшәткәнең салкыны кулына тигәч, башы кайнарланып, күз алды караңгыланды: төрмә турындагы Карнеги сүзләрен көндәлегенә язуы исенә төште... Әстәгы! Каян хәтеремә килеп яздым микән бу турыда? Юраган юш килә, диләр, хак икән! Менә, тели белсәң теләк, тели белмәсәң—имгәк, үз башыма юраганмын, үз башыма теләгәнмен, Ходаем! Рәшәткә аша дөньяны күзәтүдән дә җан әрнеткеч нәрсә юктыр! Үлем белән бер! Үлемнән чак кына кайтыш...

Афинаның кай ягына карасаң да таулар тезмәсе күренә. Әнә, кояш чыгышында, түбәләре бозлар белән капланган зәңгәр таулар артында, аның газиз иле... Нуриянең йөрәге чәнчеп куйды. Эх! Очарга иде хәзер шул якларга! Акчасы да кирәкми! Бернәрсә дә кирәк түгел! Үз ожмахлары үзләренә булсын!

Урамнан кәрҗин тоткан юан гына хатын үтеп барганны күреп, Нурия елап җибәрде, теге хатыннан үлеп көнләште! Ул хатын кая теләсә шунда бара ала! Ул хәзер өенә кайтып керер, гаиләсенә ашарга әзерләр, өстәл янына җыелып утырып ашарлар, гамьнәре юк... Минем дә шулай бәхетле чакларым бар иде бит! Ирек дигән төшенчәне шушы яшенә җитеп аңламаган икән...

Ниһаять кайнар кояш таулар артына тәгәрәде. Шалтырап йозак ачылды. Ишектән тоткыннарга эндәштеләр:

—Ашарга алыгыз!

Кичке ашка зәйтүн мае салынган кукуруз боткасы белән яшелчә салаты һәм су бирделәр.

—Менә, балам, төрмә азыгы ашарга да насыйп итте,—диде Нурия.

—Мин теге юлы унбиш көн утырып чыктым, монда начар ашатмыйлар,—диде Зося.

Нурия төн буена күз дә йоммады, үткән гомерен уйлап чыкты, яктыра башлагач кына черем итеп алды. Кеше гомере озынмыни! Укыды, кияүгә чыкты, укытты, балалар үстерде, тормыштагы кыенлыкларга түзде, хәзер чыдасам, алга таба гел әйбәт булыр дип өметләнде. Унөч яшьтән әнисез, кырык сигез яшьтән ирсез калды... Ялгыз канат, нәрсәгә тотынса да берүзе... Менә язмыш аны тагын аяныч хәлгә куйды! Төрмәдә утыру гына житмәгән иде!

Камеренең каты ятагында гәүдәсе авыртты, әзгә генә йокыга талгач та әллә ниләр күреп саташты.

Иртән аларга үз-үзләрен рәткә кертергә мөмкинлек бирделәр. Нуриянең кирәк-яраклары үзе белән иде. Монда килгәч тә кисәтеп куйдылар: кая барсагыз да, якынга гына чыксагыз да, ин беренче кирәк әйберләрне үзегез белән йөртегез, чөнки теләсә кайсы вакытта кулга алулары мөмкин. Теш щеткасы белән паста, массажка, сабын, крем, барлык туганнарның адреслары һәм телефон номерлары, дарулар һәм акча гел яныгызда булсын. Иртәнге ботка әсирләрнең тамагыннан үтмәде. Йозакны тагын бордылар. Юньле хәбәргә өметләнмәсә дә Зося белән Нурия ишеккә текәлде: аларны нәрсә көтә микән?

—Сабирова, сезне чакыралар!

«Сорау алыргамы, икенче төрмәгә күчерәләр микән»,—дип уйлады Нурия. Аңа жыенасы юк—булган әйберләре кулында.

—Зося, хуш, балакаем, китәм мин!

Кыз аңа килеп сарылды, күкрәгенә капланып елап жибәрде. Нурия янында аңа тыныч, ул бердәнбер якын кешесенә әйләнгән иде, хәзер аннан аерылу кызга бик авыр...

—Зося, матурым, артык бетеренмә! Бу сынауларны Ходай бирә дә, ала да! Ни килсә дә хәерлегә булсын! Кайгы артыннан һичшиксез шатлык килер! Менә көт тә тор!

Адвокат сора, жәлләмә акчанны, яхшы адвокат ничек тә моннан тартып чыгарыр! Мин башка котылу юлын белмим. Үзем дә шулай итәрмен дип торам.

Зося камерада елап калгач, Нуриянең үз баласы калган кебек үзәге өзелде...

Бүлмәдә кичәге тикшерүче янында автобуста бергә утырган кешене күреп бик сәерсенде. Тикшерүче аңа мәгънәле генә карап:

—Танышыгыз сезнең өчен ышандырды, бергәләп документларыгызны рәсмиләштерегез,—диде.

Нурия бернәрсә дә аңламыйча карап катты.

—Сезгә китәргә мөмкин.

Нурия котылуына ышанмады.

—Әйдәгез!—диде кичәге юлдашы.

Хатын ашыгып аның артыннан иярде. Урамга чыккач, ир гел елмаеп кына тора:

—Хроня полло! Хәерле гомер! Котылуыгыз белән!—диде.—Таныш булыйк, мин Янис!—дип зур кулын сузды.

—Нурия.

Дулкынланудан, борчылулардан аның тез буыннары калтырый иде.

—Сез ничек мине коткара алдыгыз?

—Кичә һәлакәткә дучар булган бала кебек кызганыч идегез. Мин бит килермен, дигән идем.

—Ә мин аңлап бетермәдем, шуңа көтмәдем дә!

—Әйдәгез, китик моннан!—Ул кесәсеннән ачкычларын алып машинасының ишекләрен ачты.—Утырыгыз. Кая барабыз?

Нурия адресларын аңлатты. Аларның йорты турында туктадылар. Нурия белә: аны каталажкадан чыгарыр өчен бу кеше акча биргәндер. Ул рәхмәтләр әйтеп, сумкасыннан бар булган акчасын алды да Янискә сузды, ләкин ир акчаларны алмады.

—Кирәкми. Сез бу йортта нинди эш эшлисез?

—Әби белән бабайны карыйм.

—Сезгә ял бирәләрме?

—Әйе, айга өч ял бирәләр.

—Анысы яхшы икән.—Ул Нурияне тагын автобустагы кебек кайнар карашы белән коендырды:

—Сезгә хәзер тынычланырга, ял итәргә кирәк! Ярый, очрашырбыз әле! Ясас, Я! Сто кало! Сау булыгыз! Барысы да әйбәт булсын!»—дип машинасына утырып китеп барды.

Кызыл машина күздән югалгач та Нурия баскан урыныннан кузгала алмый торды. Ул һаман котылуына ышанып бетә алмый! Ул азат! Ул иректә! Ләкин уйламаганда, көтмәгәндә аның тормышына чит бер кеше килеп керде... Моның төбендә Нурияне кызгану хисе генә түгел, тагын нидер барлыкны аңлаганга күңелен шик тынгысызлый, борчый башлады...

Шимбә җиткәч, аларның урамына сатучылар палаткалар корып, киштәләргә кызыл пластмасса табакларда зәйтүн, җиләк-җимешләр, азык-төлек тезеп куялар. Нурия атнага җитәрлек ашамлык алып кайтырга чыкканда каршысына Янис килеп басты.

—Калимэра! Хәерле көн! Исәнмесез! Хәлегез ничек?—дип исәнләште, рөхсәт сорап, аның кулындагы авыр пакетларны алды.

—Ничек, хуҗалар иртәгә ял бирәме?

—Әйе, иртәгә ял итәм,—диде Нурия.

—Нәрсә эшләргә җыенасыз?

—Бернинди планнарым да юк әле.

—Алай булгач, мин сезне диңгез буена чакырам!

Нурия эндәшмәде. Бу кешенең үтенечен берничек тә кире кагарлык түгел... Ләкин Янисның чакыруын кабул итсә, Насихына хыянәт итү булыр дип Нуриянең коты очты.

Хатынның икеләнүен күреп алды.

—Нәрсәдән шикләнәсез? Миңа ышанмыйсызмы? Мин сезне аулакка чакырмыйм, кешеләр ял итә торган урынга барабыз.

Нуриягә уңайсыз булса да ризалашты. Чыннан да, кешеләр арасында су коенып, ял итеп кайтса ни була? Нәрсәсе белән исенә төшерер бу Афродита илен? Килгәненә күпме вакыт үтте, аның әле диңгезне барып күргәне юк!

Якшәмбе көнне Янис аны иртән иртүк килеп алды. Өй турысында машина сигналын ишеткәч, йөрәген тагын курку биләде. Каушый-каушый сумкасына зур сөлге белән бизәнү әйберләрен салып урамга чыкты. Янис аны чәчәк бәйләме тотып көтә иде инде.

Кайнар комнан яр буенда рәшә уйный. Күк тә, диңгез дә зәп-зәңгәр! Очсыз-кырыйсыз киңлектә дулкыннарны ярып ак җилкәнле

яхталар йөзә... Диңгез суы шундый чиста, якты: тирәндә, су төбендә матур ташлар аермачык күренә!» Менә нинди икән син, диңгез! Ниһаять, мина да сине күрергә насыйп булды! Ничек хыялланган идек Кара диңгез ярларында кайнар комда икәүләп йөрергә! Йомшак дулкыннарда йөзеп, тозлы суын авыз итәргә! Булмады шул... Булмады... Башта балалар кечкенә дидек, алар үскәч, ташлап китәргә курыктык! Акчасы да житмәде... Жанны эретерлек матур Эгей диңгезенә карап Нурия ямансулады... Ул инде алга-артка карамыйча, дөньясын онытып ләззәтләнер чактан узган...

Диңгез суы искитмәле жылы икән! Янис көчле беләкләре белән канатланып еракка, буекларга таба йөзеп китте. Коенып чыккач, бер зур зонт астына утырдылар. Янисның куе кара йон каплаган күкрәгендә алтын чылбырдагы тәрене күргәч, Нурия әллә нишләде... Бөтенләй ят, чит кеше белән нишләп йөри ул? Комда бу кеше янәшәсендә ятарга тәне ытыргый, аның карашыннан котыласы килә... Күктән Насихның жаны рәнжеп карап торган сыман тоела. Аның Насихы бөтенләй башка... Чиста ак тәнле иде...

...Беренче мәртәбә кияү мунчасына кергәч, Насих оялып ләүкәгә утырган жиреннән төшмәде... Нурия кыюрак булып чыкты.

—Кая аркаңны ышкыйм,—диде.

Ак күбекле мунчала белән иренең кин таза жилкәсен, төз гәүдәсен юганда эченнән генә «Тфү-тфү, күз тимәсен!»,—дип теләде. Сул калак сөяге астында матур көрән миңен күргәч:

—Синең шәхси тамгаң бар икән!—дип шаяртты.

Насих яшь хатынын мактап:

—Кулларың кечкенә булса да бик көчле икәнсең, арканы шәп массажладың,—диде.

Нурия тиз генә коенып чыкты да, мунча алдына басып Насихның киенүен көтеп торды. Шул арада юеш чәче бозланып катарга да өлгерде... Тәрәзә төбендә мунча ягучыга кияү бүләге—яулык белән исле сабын калдырганнар иде...

—Беренче көнне сезгә кояшта озак булырга ярамый,—диде Янис Нуриянең кадерле истәлекләрен бүлдереп,—берәр тавернага кереп ашап чыксак сез каршы түгелме?

Каршылыклы хисләр кичерсә дә, ул бүгенге көннән канәгать иде: гомер буе күрергә хыялланган диңгезне күрде бит. Диңгез буенда сүзгә-сүз ялганып, Янисның үз мастерскоенда автомеханик булып эшләвен, бер ел элек хатыны үлгәнен белде. Үзе турында да сөйләргә мәжбүр булды, чөнки турыдан-туры куелган сорауга жавап бирмичә мөмкин түгел.

Икенче ялда Янис тагын килде. Бик тә кадерле кешесен күргәндәй, эре ак тешләрен күрсәтеп, киң итеп елмайды. Исәнләшкәннән соң:

—Нурия, бүген мин сезнең гидыгыз булам, сезгә Акропольне күрсәтермен,—диде.

—Ой, гафу итегез, мин бүген графияга барам, дусларым белән сүз куешкан идек!

Янисның кәефе кителгәне йөзенә үк чыкты, ул бүгенге көнгә зур өмет баглаган иде, ләкин итагать саклап, Нурияне яңадан кыстамады.

—Ярый алай булгач, мин сезне анда илтеп куям, ләкин киләсе ялда Акропольгә барырга сүз бирегез!

Нуриянең графиядагы хатыннарга Янисны күрсәтәсе килмәде, ничек баш тартырга белми аптырады.

—Ярый, киләсе атнада Акропольгә барырбыз, ләкин бүген мәшәкатьләнеп йөрмәгез, мин үзем генә барам!

—Әйдәгез, илтеп куям, мин беркая да ашыкмыйм.

Графияда хатыннар чекрәеп аларны күзәттеләр, Янис киткәч тә, шаулашып алдылар:

—Нурия кемне эләктергән!

—Шәп егет күренә!

—Карагыз әле моны! Безгә әйтү-нитү юк, рөхсәт сорау юк!—дип шаярттылар.

—Әй, ташлагыз әле, булмаганны!.. Беркемне дә эләктермәдем! Кирәк тә түгел!

—Алай димә! Коега төкермә, суын эчәсең булыр!

—Сез нәрсә беләсез соң?! Мине бит автобуста полиция арестовать итте, төрмәгә яптылар!

—Боже мой! Когда?

—Үткән атна башында.

—Ничек котылдың?

—Әнә шул кеше коткарды.

—Ничек?

—Белмим. Участокка килеп нәрсәдер әйткән.

—Элек таныш иденмени?

—Каян таныш булыйм ди! Шунда, автобуста бергә утырган идек, берике сүз генә сөйләштек!

—И Аллам! Бәхетеңә күрә очраган! Менә, Алла юк, дип әйтеп кара! Бар ул, Алла бар! Юньле кешеләр дә бар бу дөньяда!

—Кызлар, тиккә генә түгел инде! Аның Нуриягә күзе төшкән!

—Хатыны бар микән?

Хезмәтче булып ялланган хатыннарның күбесе диярлек ирсезләр, байтагының күңел почмагында яшерен теләк—юньлерәк кешегә кияүгә чыгып, тормышларын көйләү уе.

Нурия соңгы сорауны җавапсыз калдырды, сүзне икенчегә борды:

—Мин утырган бүлекчәдә Белоруссиядан килгән Зося исемле егерме яшьлек кыз калды. Берәрегез аны беләме?

Хатыннар белмиләр иде.

—Эшкә безнең графия аша урнашмагандыр.

—Ул баланы бик кызганам. Аны икенче тапкыр тотканнар инде, өч елга утыртып куюлары бар.

—Без ни эшли алабыз соң?! Ул участокка барсак, хәзер үзебезне кулга алырлар, Аллам сакласын!

Күңел ачарга дип җыелышкан дусларның йөзләре моңсуланды—аларны да Зося язмышы көтүе ихтимал...

***

*Нуриянең көндәлегеннән*

28 май 2004 ел.

Китәргә җыенганда Греция турында берничә китап алган идем. Һаман укырга вакыт тапмадым. Янис Акропольгә алып барам дигәч, укый башладым һәм гаять кызык нәрсәләр белдем. Афина шәһәренә биш мең елдан артык икән. Ул Европаның иң борынгы шәһәрләреннән берсе. Афина шәһәренең яклаучысы Зевсның кызы Афина—җирдәге түгел, күкләрдәге гыйффәтле гүзәл кызның күзләре зәңгәр булган икән! Шуна исем китте! Мин грекларның барысы да кара чәчле, кара күзле дип уйлый идем. Чынлап та аларның күбесе шундый, билгеле. Афинаны хәзер дә бик ихтирам итәләр, горурланалар. Мифлар сөйләгәнчә, аны илгә байлык

китергән өчен (ул грекларга зәйтүн агачын бүләк иткән) һәм зирәк акыллы булган өчен шәһәргә баш итеп куйганнар. Бу мифларда хаклык барлыгына ышанасың, чөнки мондагы халык бар азыкны зәйтүн маендә пешерә, кыздыра, базарларда иң күп сатылган әйбер олива, аны маслины да диләр, шул килеш тә ашыйлар, тозлап-маринадлап та ашыйлар, ашка да салалар, җимешләреннән май сыгалар. Зәйтүн мае бар майлардан да файдалырак. Ул илнең төп байлыгы бугай, аны күпләп чит илләргә чыгаралар ди. Зәйтүн плантацияләрен күрдем: агачлары биек түгел, яфраклары нәкъ безнең талларныкы кебек, нечкә, озынча, төсләре дә шундый көмешсыман, зәңгәрсу-яшькелт.

3 июнь 2004 ел

Акрополь шәһәрдән йөз метр биеклектә, биек кыяда икән. Монда иң атаклы бина Парфенон—Афина Палладага багышланган храм. Мең еллар элек анда Афинаның тугыз метр биеклектәге бронза һәйкәле һәм башка антик каһарманнарга багышланган скульптуралар булган. Хәзер анда бернинди сыннар да юк. Күп меңләгән еллар, сугышлар, илбасарлар аркасында искиткеч гүзәл һәйкәлләр юкка чыккан, исән калганнарының күбесе Лондон, Париж, Рим, Ватикан музейларында ди. Хәзер Греция хөкүмәте тарихи байлыкларны ватанга кайтарту турында эш алып бара ди.

Парфенонның мәһабәт колонналарын күргәч, чыннан да монда Аллалар, антик геройлар яшәгәненә ышана башлыйсың. Моннан күп мең еллар элек яшәгән халыкның шундый югары культурага ия булуы, кешенең бөеклеге турында уйланасың, горурланасың... Акрополь янында Дионис театрының хәрабәләре сакланган: биш мең кеше сыешлы залның утыргычлары хәзер дә исән! Һушың китәр! Эралар, гасырлар үткән, күпме буын кешеләр алышынган, ә таш утыргычлар шул килеш... Бер уйласаң, мондый матурлыкны иҗат итүче кеше бөектер! Ә мәрхәмәтсез вакыт өчен ул тузан бөртеге кадәр генә... Бу бик монсу хәл, чөнки үзеннең дә тузан бөртегенә әйләнәчәгең турында уйландыра... Көн коточкыч кызу, тауга менү хәлне алды, ләкин һич үкенерлек түгел: бөтен кешелек дөньясына билгеле тарихи урыннарны күрдем.

***

Акропольне карап, йөреп чыкканнан соң бер кафега кереп ял иттеләр. Шунда утырганда Янис үзенең ниятен ачыктан-ачык әйтте:

—Сез дә тол, мин дә ялгыз, безгә кушылып яшәргә бернәрсә дә комачауламый. Сез миңа бер күрүдә ошадыгыз.

Дингез буенда ук Нурия бу кеше белән яңадан аралашмас өчен турысын әйтергә уйлаган иде. Бу килүендә очрашкач әйтәсе сүзләрен хәзерләп килде.

—Мин сезнең ярдәмегезне беркайчан да онытмам, гомергә рәхмәтле булырмын, ләкин тәкъдимегезне кабул итә алмыйм.

—Ни өчен? Ни сәбәпле? Мине ошатмыйсызмы?

—Сәбәпләр бар инде...

—Документларсыз һәрчак куркып яшәгәнче, миңа кияүгә чыгыгыз! Минем тормышым житешле, бернәрсәгә дә мохтаҗлык юк.

—Минем планнарым монда килеп иргә чыгу түгел бит, улыма квартиралык акча эшләү. Теге көнне автобуста мине кулга алмаган булсалар, без сезнең белән очрашмаган да булыр идек. Мине илемдә балаларым, туганнарым көтә. Анда ата-анамның, иремнең кабере... Аларның берсен дә ташлый

алмыйм. Гафу итегез, минем өчен түләгән акчагызны зинһар алыгыз! Нурия сумкасыннан акча алып сузды.—Минем сезгә бурычлы булып каласым килми, гомерем буе борчып торыр.

Янис Нуриянең кире кагуын көтмәгән, риза булыр дип уйлаган иде. Анынча, ике ялгызакка бернинди каршылык та юк, Нуриянең дәлилләре аны ышандырмады, андый әхлакый кыйммәтләр кешенен үз бәхете бәясенә тормый, чөнки гомер кире кайтарып ала торган нәрсә түгел.

Янис кебек үз сыендагы иргә кияүгә чыгарга теләүчеләр булыр иде. Хиссезрәк, талымсызрак булсаң гына илле яшендә бөтенләй чит диндәге ят кешегә иргә чыгарга мөмкиндер, ләкин үз гомерендә чын бәхетнең, мәхәббәтнең нәрсә икәнен белгән Нурия түгел... Нурия үз тормышының бәясе менә шул әхлакый кыйммәтләрдән торганын бу кешегә анлатырга тырышмады да. Хәзер туган илләрен ташлап чит илләргә китү гадәти күренеш, тик менә чит җирләрдә кемнең җаны ничек изалана, аны беркем дә белми...

И сөеклем, нишләп соң син бу дөньяга азга гына килдең? Югыйсә Ташлытау чишмәсенең шифалы суын эчеп үскәнсен, ник ул сина да озын гомер бирмәгән? Ашыгып яшәдеңме? Үз өлешенә тигән юлны шул арада үттеңме? Илле ел эчендә туарга да, үсәргә, укырга, өйләнергә, өч ул үстерергә, йортлар салырга, күп жырлар жырларга, сөяргә һәм сөелергә, бу дөньяда күрәсе газапларыңны күреп бетерергә өлгердеңме? Күп эшләдең, нык тырыштың, күп интектең, аргансыңдыр, дип Ходай үз янына алдымы? Мин синең белән яшәп туя алмадым, янадан йөз ел яшәр идем! Гомеребезнең уртасында ташлап киттең! Бәлки теге дөньяда очрашу насыйп булыр? Булмас шул... Бу дөньядагы газапларың өчен ярлыкап, Аллаһ сине җәннәткә урнаштырыр... Ә мин... Минем гөнаһларым күптер инде... Мәңгелеккә аерылдык микән? Бу арада төшләремә дә керми башладың! Теге кеше белән аралашканга үпкәләдеңме? Гафу ит, кадерлем, тик бер минутка да күңелемнән генә дә сина хыянәт итмәдем! Синнән башка бүтән кеше юк мина!

Нурия үз гомерендәге авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрен, өч бала үстергән чорда кеше балаларын укытып, аларга бөтен көчен, йөрәк жылысын биреп эшләвен, кылган гамәлләрен бизмәнгә салмый, зарланмый, үзен жәлләми...

***

Балконга кернәр элергә чыккач, почта тартмасында ниндидер кәгазь күрде. Акча түләргә квитанцияләр микән, дип уйлады. Хат икән! Уртанчы улы Айраттан хат икән! Конверт тышында «Foto!» дигән сүзне укып сөенде! Килене бәбәйләргә тиеш иде, баланың карточкасын салганнардыр! Хәзер замана икенче бит, кем туасын да беләләр—малай! Алар Насих белән бәбәй көткәндә гел чамалый алмадылар. Беренчесе малай булгач, икенчесендә кыз көттеләр! Анысы да малай булды. Өченчесен бөтенләй көтмәделәр, бала имезгәнгә, авырга узганын сизми калды, тазарам дип уйлады. Уртанчы улына бер яшь тулганда өченчесе туды! Биш елга өч ул!

Нурия конвертны ачып бер фотоны алды һәм... имәнеп китте: рәсемдәге сабыйның йөзеннән мөлдерәп... Насихның күзләре карап тора! Сары чәчле, зәнгәр күзле бала бабасына искиткеч охшаган иде!

—Улым! Улыкаем!—Нурия Насихына охшаган нәни йөзне үбеп, тынсыз торды... Елады... Көлде... Суга сусаган кеше кебек, шул баланы кочагына алып сабый исен исни-исни рәхәтләнеп сөясе, иркәлисе, үчтекиләсе

килде!

«Әни! Сине оныгың белән котлыйбыз! Малаебыз таза, сәламәт булып туды, авырлыгы өч кило җиде йөз грамм, буе илле җиде сантиметр, Алмаз дип исем куштык»,—дип язган улы.

Яна гына ирен сагынып юксынган хатын бу хат белән фотоларның очраклы гына тап килүенә ышанмады, күнеленең сиземләвен, кан тартуын, җан тартуын тойды. Нурия улы белән килененең кечкенәләрен тотып, бәхетле елмаеп төшкән фотоларын карады да кире оныгыныкын алды, төбәлеп нарасыеның йөзенә багып бик озак утырды. Караган саен карыйсы килде, гаҗәпләнде: ничек шулкадәр дә охшаган бу малай бабасына?! Үскәч тә шулай булыр микән? Эх, бәләкәчем, кайчан кулларыма алып сөярмен микән сине! Мин кайтканчы үсеп бетәрсен шул инде! И Аллам! Ни сөйлим! Үс, улым, үс! Мин кайтканчы үсеп тор! Тик бабаңның язмышын кабатлама, бәгырькәем! Бабаң, билгеле, бәхетсез түгел, бәхетле иде, тик гомере генә кыска булды... Сиңа Ходай хәерле озын гомер бирсен!

Оныгының киң маңгайлы садә йөзе, бәбкә мамыгыдай йомшак чәчләре, кечкенә алсу йодрыклары, тыпырчынып өскә күтәргән нәни тәпиләре күнеленең түрендә урын алды, ул сабый әбисенең шатлыгына, юанычына әверелде: үзенең җанын ярып чыккан баласымыни—Нурия әйтеп аңлата алмаслык наз һәм җаваплылык сизде. Сабый анын мәхәббәтенә, ярдәменә мохтаҗдыр кебек тоелды.

Бүгенге хәбәр Нуриянең тормышында бер могҗиза булды: күкрәгендә төерләнеп калган югалту хисе Насих күзләре белән карап торган оныгын—багалмасын күргәч, эреп юкка чыкты, күнеленә тынычлык инде, монарчы күрмәгән яңа бәхет аны гөнаһлы җирдән күкләргә күтәрде, бу хис шундый көчле иде ки, Нурия үзенең яшәргәнен тойды, канатлы җаны дәртләнеп газиз балалары, оныгы, якыннары өчен һәр мизгелдә батырлыкка, ярдәмгә, яратуга әзер иде!

Көтелмәгән бәхет сагынуларын тагын да көчәйтте... Шушы минутта кадерлеләре янында булырга, йөгерергә, очарга теләде! Сөенеч балкыган күзләре боз түбәле зәңгәр таулар артына, кояш чыгышына төбәлде: анда гына, туган илдә генә анын оҗмахы...

*2006 ел*



Шаһинур
Мостафин

## «ҖАНҖИЛӘК»ЛЕ ГОМЕРЕМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

*(Сөеклем Дамирәнең үлеменнән соң язган шигырьләрдән)*

### Ник алдыйм соң күңелне?!

**Барысы да онытылды кебек...**
**Пар йолдызга охшаш күзләр дә**
**Элеккечә чакырып янмас инде,**
**Нурын сипмәс инде тирәмдә...**

**Барысы да онытылды кебек...**
**Аккош канатына тиң куллар**
**Иркәләмәс инде бөдрәләрдән—**
**Чәчем белән бары җил уйнар...**

**Барысы да онытылды кебек...**
**Челтер-челтер чишмә агышын**
**Хәтерләткән тавышыңны Синең**
**Ишетмичә китеп барышым...**

**Барысы да онытылды кебек...**
**Аһ, алдыйм ич бары күңелне:**
**Чишмәләрдән тавышыңны эзлим,**
**Йолдызлардан эзлим күзеңне—**
**Табигатьтән эзлим үзеңне!**
**...Ник алдыйм соң, алдыйм күңелне?!**

Шаһинур МОСТАФИН (1948)—*язучы-публицист, шагыйрь; «Васыять», «Хәтер яктысы», «Яңа меңьеллыкка очыш» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Изге көн

Җомга көн бүген—изге көн,
Җаннарның хисле чагы!
Азан моңы иңә күктән,
Туганнар—янда... «Тагы
Нәрсә кирәк икән?»—дисәк,
Мәрхүмкәй җаннар җитми.
Бага алар бакыйлыктан—
Хәтерләрдән һич китми
Якты йөзләре, сүзләре,
Кылган шәп гамәлләре—
Илаһи нурга күмәләр
Җирдәге адәмнәрне!
«Пакъланcын, сафланcын,—диләр,
Тутыкмасын күңелләр—
Иман белән яшәгәндә
Матур үтә гомерләр!»
Сезнең хәер-дога истә—
Ниләр генә кылсак та...
Сезне уйлап янабыз гел
Без гомерлек Учакта!
Шул Учак җылыта җанны,
Ихластыр хисләребез.
Нурлырак була иртәләр,
Ямьлерәк кичләребез!
... Җомга көн бүген—изге көн,
Җаннар җаннарга дәшә:
«Җирдә гел яхшылык кылып,
Иманлы булып яшә!»

## Һаман «рухи тышауда» мин...

Сак белән Сок шикелле без:
Мин—аякта,
Син—кабердә...
Бакыйлыкта ничек хәлләр?
Януда мин һәм... кадердә:
Аллаһыма мең шөкер, дим—
Әле, ярый, балалар бар!—
Яраланган бу җанымны
Авыр чакта дәвалардар...

Аллаһыма ышангандай,
Аларга мин ышанамын...
... «Җанҗиләгем» оныта алмыйм!—
Һаман «рухи тышауда» мин...

## Безнең Сөю мәңгелеккә оча!

Батырлыкның Туган көне бар!—
Үлгән көне генә аның юк...
Матурлык та шулай!..
Ихлас Сөюем дә Матурлыкка
Сокланудан туды кабынып!

**Оча безнең Сөю—кайнар хисләребез!—**
**Чорлар аша, гасырлар аша...**
**Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрәдәй без!**
**(Шулай димен, әгәр яраса!)**

**Гомер буе озата барды Сөю!—**
**Күзләребез күздән китмәде,**
**Көн дә, төн дә гел серләшә идек—**
**Сүзләребез һич тә бетмәде!**

**Кавыштык без кышкы салкында—**
**Түзми йөрәктәге ялкынга!**
**Салкын карны эретер хисләр бар,**
**Мәхәббәтле, назлы кичләр бар!**

**Яктыртадыр төннең карасын**
**Пар Йөрәкнең Уты!!—аңларсыз...**
**Безнең Сөю Мәңгелеккә оча!—**
**Шуннан безне эзләп табарсыз...**

**... Батырлыкның Туган көне бар!—**
**Үлгән көне генә аның юк...**
**Мәхәббәт тә шулай!**
**Сөя белү—үзе Батырлык**
**Һәм Матурлык!—**
**Яшик табынып...**

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# ЫШАНАМ

Ләйсән Фәтхетдинованың зур шагыйрь булырга мөмкинлекләре бар. Ходай аңа табигый сәләтне мул итеп биргән. Дөньяны шагыйрь-рәссамнарча күреп, танып белергә, һәм шул чынбарлыкны күңеле аша үткәреп, Үз Дөньясын булдырырга сәләтле кыз бала ул. Нечкә тоемы, образлы күзаллавы, тел байлыгы булмаса, билгеле, моңа ирешү мөмкин түгел.

Ләйсән әле яшь: ул 2008 елны урта мәктәпне тәмамлап, Казанга килде, журналистлыкка укырга керде. Дәресрәге, яшь каләм ияләренең республика күләм төрле әдәби ярышларда җиңүләр, шул исәптән Гран-прилар яулап, Казан университетына имтиханнарсыз гына үтә алды. Димәк, максатчанлык, тырышлык җитәрлек бу кызда!



Ләйсән Фәтхетдинованың язганнары (иҗаты дип тә әйтү ярыйдыр) белән байтактан танышмын. Аның шигырьләрен матбугатта инде биш-алты ел буе күзәтеп киләбез. Алар башта Балык Бистәсендә чыга торган «Авыл офыклары» газетасында басылды. Төрле конкурсларда призлы урыннар алды. Хәзер инде Ләйсәннең тезмә һәм чәчмә язмалары чыкмаган басмалар Республикада юктыр да. Халкыбызның төп әдәби журналы булган «Казан утлары»нда да аның шигырь цикллары берничә мәртәбә дөнья күрде.

Үз гомеремдә байтак кешеләрнең иҗатлары турында матбугатта сүз әйтергә туры килде миңа: төрле кәеф, төрле теләк белән язылды алар; кирәк өчен дип, азапланыбрак язган чаклар да булмады түгел. Ә бу кечкенә генә кереш сүзне язу миңа рәхәт! Теләп, өмет-ышаныч белән язам. Талантлы яшь кеше турында фикер әйтү бит бу. Өстәвенә, Ләйсән минем якташым да бит әле. Хәтта мәктәптәшем дә.

Соңгы елларда, шөкер, әдәбиятыбызга күзгә күренерлек яшь көчләр килә. Берара буыннар өзеклеге килеп чыгу куркынычы да бар иде. Бүгенге унсигез-егерме яшьлек каләм ияләре—90 нчы еллардагы милли күтәрелеш шытымнары алар. Ләйсән дә шулар рәтеннән. Бу яшьтә, гадәттә, мәхәббәт-сөю, ашкыну-сагыну, кавышу-аерылышу, ягъни, күбрәк шәхси интим тойгылар турында язалар. Моны гаепләп тә булмый. Табигый хәл, һәммәбезнең диярлек башыннан кичкән хәлләр. Шуңа күрә дә андый шәхси хисләрнең бүтәннәр өчен кызыклыгы да чамалы. Ләйсән бу яктан аерылып тора. Шәхси кичерешләр белән бергә, аның ил-халык язмышы турында уйланулары да җитәрлек. Ил агасындагы кебек фәлсәфи фикерләре бар аның кайбер шигырьләрендә. Тарихи хәтерне җуймаган кыз бала ул дияр идем мин аны. Каян килә бу сыйфат? Әлбәттә, туган туфрактан, шул җирнең рухыннан. Ләйсән—Котлы-Бөкәш кызы. Борынгы Чаллы (КамАЗлы Чаллы түгел) якларыннан ул. Бу төбәктә Чаллы исемен йөрткән биш-алты борынгы авыл әле дә бар. Казан ханлыгы егылгач та, байтак дистә еллар буе, кирмән-ныгытмалар корып, баскыннарга каршы көрәшкән әле безнең бабаларыбыз. Тарихи хәтер, мөгаен, шул геннардандыр...

*Азатлык—бәхетең,*
*Хәтерең—тәхетең,*
*Җитезлек—өметең...*
*Шунда син—бербөтен!*

—дип яза Ләйсән үзенең бер шигырендә.

Ләйсән төрле жанрларда каләмен чарлый. Шигырьләрдән тыш, кыска хикәя-кыйссалар иҗат итә, аналитик характердагы публицистик мәкалә-язмаларда да үзен

сыный. Колачны киңрәк алгач, «иҗат кишәрлеген» чабып чыгарга көче житәрме? Нәтиҗәсе ничегрәк булыр, дияр кемдер. Унсигез яшьлектәгеләргә нәтиҗәләр турында сорау бирү кыен. Ышанырга кала. Ә моның өчен нигез бар. Мин үзем Ләйсәннең иҗади киләчәгенә ышанам.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре*

Ләйсән
Фәтхетдинова

# КАНАТ ЧЫГАРГАН ЙӨРӘК

***

**Йөрәк тибешемне тоймыйм бүген.**
**Күкрәк читлегенә бәреп,**
**Күңел дәшми.**
**Ә табигать бәргәләнә бирә:**
**Һава болытларын ярып,**
**Яшен яшьни.**

**Еласам да чыкмый күз яшьләре.**
**Фикерләрне ерткан акыл,**
**Никтер, тынган.**
**Әллә айлар буе хыялланган,**
**Күктә очып йөргән өмет**
**Җирдә сынган?**

**Хис бураны тезен кочаклаган...**
**Дөнья туктап калган әллә**
**Шушы мәлдә?**
**Курчакка әйләнү шулмы, Ходам?!**
**Сын-кешегә әверелү**
**Шушы мәллә?..**

**Җанда нидер чиртеп куйды кинәт,**
**Яшь сытылып чыкты күздән...**
**Ахры, исән!**
**Өч сорауга илле җавап эзлим.**
**Аптырама, дустым, тик торганда:**
**Нихәл, дисәм...**

***

**Башкаларның үче булыр инде,**
**Син үз-үзеңә үчле, татарым!**
**Чит милләтләр сине саткан чакта**
**Үз балаң да чыгып сатармы?..**

Горурлыгың, үҗәтлегең кайда,
Тарихларга кергән ныклыгың?!
Яусыз гына килеп үз түрәләр
Әллә синең җанны сыттымы?

Кардәшеңнән гаеп эзлисең син,
Үз-үзеңне сүгеп яшисең.
Ә дустыңны читләр рәнҗеткәндә,
Ни өчендер әле дәшмисең...

Ходай гына белә булыр инде
Күпме яшәп, ниләр күрәсен...
Башкаларның уе булыр да бит,
Ә син бүген, татар, үз-үзеңне...
Үз-үзеңне бүген күмәсең!

## Тарих

Җир. Туфрак. Сөяк. Чүлмәк.
Ир. Адым. Сөңге. Күлмәк.

Чүл. Болын. Урман. Басу.
Күл. Елга. Диңгез. Ташу.

Таң. Кояш. Болыт. Һава.
Чаң. Үлем. Кайгы. Дәва.

Җир. Сугыш. Халык. Җиңү.
Чир. Талаш. Туу. Шиңү.

Көн. Атна. Гасыр. Вакыт.
Өн. Тарих. Китап. Факт...

***

Икеләнә күңел, икеләнә.
Җиде чатның җиде юлы үзенә дәшә.
Үлем белән яшәү арасында калсаң...
Яшә!

Үпкәләрем ертылмаса, сулый алсам
Бу төтенне, агуланган бу һаваны,
Яшәп калыйм, кыя үренә кызыгып...
Хәерлегә генә булсын бу дәвамым.

Сайлау мөмкинлеге булу—бәхет микән?
Бер юл булса, шуннан гына атлап китәм.
Ә каршыда сигез юлның сигез үре.
Бүлгәләнде эчке "мин" дә, ә күңелдә
Сигез төрле улый бирә сигез бүре.

Кыйпылчыклар чәчелгәндә тирә-якка,
Тик шайтаннар торыр микән инде сакта?
Ике юлның берсен дөрес сайлар өчен
Җитәр микән сытылган ихтыяр көчем?

Икеләнә күңел, икеләнә!
Бер яшь ага, бер ут чәчри ике күздән.
Кан акса да сорау тишкән яралардан,
Түзәм...

## Күккә тиде түбәм

Күккә тигән түбәм бүген,
Канат чыгарган йөрәк...
Акыл теше сызлавына
Усал сүзләрне төбәп,
Утырыйк та бер йолдызга
Очыйкмы әллә тиздән?
Аерып булмас, дисеңме,
Авыр гәүдәне җирдән?

Күккә тигән түбәм бүген,
Җан сикерә биеккә.
Кан тамыры шартлагандыр:
Булмый күзгә тиеп тә...
Күрсә күрер күңел күзе,
Аптырама, утыр, кил!
Мин гамәлдә, мин—галәмгә...
Колакта сызгыра җил...

Күккә тигән түбәм бүген,
Аяктан тарта язмыш.
Күңелеңне дә тыймагач,
Ничек кылмассың ялгыш?
Сыймаса җан тән эченә,
Хыялыңда бар канат:
Кайтмаса тик көн җиленнән
Сынып, кайрылып, канап...

Күккә тигән түбәм бүген,
Кәеф тә бик шәп иде.
Кемгә генә ярамадым,
Кем елмаюга тиде?
Акыл теше сызлавына
Түзәм инде, тырышам.
Фәлсәфә сатасың, диеп,
Күңел генә карыша...

## Идел йортым—Туган җир

Идел-Җаек киңлегендә
Ярсып чапкан тулпар ат ул.
Күк белән Җирне иңләгән
Алтын сүзле хәтер-хат ул.

Гасырларда дастан булып
Мәңге яшәр Туган ягым.
Йөрәгемне бирер идем
Халкым өчен, дигән чагым...

***

Җил очырды акылымны...
Күңелдә таш, җанда боз.
Әйдә, бетсен, калмасын ут,
Син дә кәефемне боз!

Көн үтерде хыялымны,
Ә җәзасы—газапсыз.
Син биргән сораулар гына
Йә тозсыз, йә җавапсыз.

Төн кылычын кадаганда
Йокы яткан бишеккә,
Җан сыкраган авазларны
Йөрәк кенә ишетте.

...Матур итеп ясап куйган
Чәчләргә җил төкерде.
Каһәр хәтер! Менә дигән
Кәефемне үтерде!

## Юк

Сау кешенең чире юк,
Камиллекнең чиге юк.
Теләгәнне әйтеп булмый,
Ә авызның биге юк.

Тол хатынның ире юк,
Мөһаҗирнең җире юк.
Үз кырын үзе урмагач,
Байның хезмәт тире юк.

Урманнарда бүре юк,
Авылларның үре юк.
Өстәлләр түгәрәк хәзер,
Урыны бар, түре юк.

***

Тулыр–тулмас бер гасырны
Мәңгелек, дип уйлыйбыз да
Яшибез бер типтереп!
Бәхет кенә, кайвакытта,
(Сатылмый да, каһәр суккан!)
Тилмерткәли көттереп.

Чиге булмас күк тоелган
Гомернең җиткәч ахыры,
Яшисе килә кабат...
Ә син, дустым, һәр көнеңне,
Үз төсләре, үз хисләре,
Үз моңы белән ярат!

Мәңгелеккә китәр өчен,
Мәңгелектә күк яшибез
Бер гасыр—тулыр–тулмас.
Син изгелек кылам диган
Иртәгәң генә, дускаем,
(Үзең әле белмисең дә!)
Яңа таң булып тумас.

## Илем барда үзем бар

Җир астында серләре бар,
Байлыгы бар илемнең.
...Имән кебек нык тамырлы
Чәчкә булып күрендең...

Күк эчендә җаннары бар
Изге Туган ягымның.
...Әй, күңелем, нигә шулай
Югарыга кагындың?

Тарихта бөекләре бар
Батыр газиз халкымның.
...Син—үзәге, иң кайнары
Дөрләп янган ялкынның!..

Үткәне бар, бүгене бар
Киләчәкле илемнең.
...Галәм аша баккан идем,
Йолдыз булып күрендең...

Лира
Ибраһим-Вәлиди

## ЯҢГЫР КЫЗЫ

ХИКӘЯ

Челлә җиленең кайнар сулышы аның иреннәрен көйдереп алды. Борынына яңа чабып ташлаган печәннең хуш исе кереп тулды. Кайдадыр якында гына чикерткә чекердәде. Куллары белән сыпырганда татлы җиләк исе сеңгән чәчләре арасында әллә шепшә, әллә бал корты безелдәде.

«Яңгырда тудың син, кызым», ди ана әнисе.

Әйе, ул чынлап та, Янгыр кызы!

Әллә нинди гаҗәеп матур яңгыр иде. Үзе көчле, гайрәтле, үзе жылы, кояшлы. Кояшның шатлыклы йөзеннән таммады микән әле ул тамчылар?

Әйтерсең, ул бер генә кискен хәрәкәт ясап борылды да, кинәт, әллә кайсы караңгылыктан яктыга табан зур күзләрен ачып җибәрде... һәм Дөньяга күз салды. Дөнья да аның күз карашлары сымак киң, зур һәм якты иде.

Ул көннән тагын нәрсәләр хәтерли соң? Карашына калкып чыккан олы тәрәз өлгеләрен хәтерли. Битараф йөзле пыяла буйлап тәгәрәшкән янгыр тамчыларын хәтерли. Якты кояш нурларында җемелдәшкән юеш яфракларга, шундый ук тамчыларның бәрелеп меңләгән кыйпылчыкларга бүленеп, шул пыялаларга чәчрәп таралганын хәтерли.

Яшәеш аны Яңгырлы капкасына кабул итте.

Зурлап капка ачып торырга да кирәк түгел иде югыйсә. Шуышып чыгар өчен капка асты да артык иркен иде. Кулларында нәни генә ике пакь төенчек. Берсендә—пәрәнҗәсенә капланып тыйнак кына Иманы елый, ә икенчесендә—чиксез наз, ләззәтләр вәгъдә иткән ике күзен мөлдерәтеп Нәфсесе елмая...

...Ул чалкан яткан җиреннән йөзтүбән борылды да, куе сусыл үләннәр арасына кереп яшеренгән каен җиләген өзеп челлә җиленә елмайган коры иреннәренә терәде. Аннары торып таралган чәчен төйнәп җыйды. Тулы күкрәкләрен назлы кояшка ачып җибәргән күлмәгенең сәдәфләрен барлап төймәләде. Ромашка, мәтрүшкә, тагын башка чәчәкләрнең тажлары һәм шулар арасында адашып кайнашкан бар бөҗәкләре, кырмыскалары белән тере келәмне хәтерләткән итәкләрен бер-ике генә сыпырды да аякларына күтәрелде.

Аннары, куе кызыл җиләкләр белән мөлдрәмә тулган чиләген әллә нинди бер рәхәтлек, кәеф белән кулына алды да шарлама шаулавы янгырап торган бөдрә таллык буйлап, җиләк вакытына гына янарып, түшәлгән үләненен башлары гына кыркылган йомшак, нәфис кенә сукмактан авылга табан юл тотты.

Печән вакытына, һәрвакыттагыча, шәһәрдән бар булдырган-булдырмаганы кайтып җыела. Көтү кузгалу белән авыл эче кыска бер вакыт кына гөҗләп ала да, энгер-менгергә кадәр тынып кала.

Бу юлы да нәкъ шулай. Житмәсә, бүген шимбә көн, урман-басуларда халык тагын да күбрәктер, чалгы чыжлавы, анда-санда шаярышкан, рәхәтләнеп көлешкән тавышлардан урман кайнап торадыр.

Ә Нәфисәнен инде китәр вакыты җитте. Юлына иркенләп әзерлән дип абыйсы белән әтисе урманга да икесе генә киттеләр. Шуна күрә, вакыт табып, тизгә генә тау итәгенә җиләккә дә менеп төште.

Кичкелеккә яшь тавык суеп, аш әзерләп, үзләре өчен генә кечкенә кунак табыны җыйдылар, чатнатып мунча яктылар. Һәрвакыттагыча. Тик бу юлы әзер кунак табынына көтмәгәндә чын кунагы да килеп керде—кайчандыр шушы авылда математика укытып киткән Илсур абый.

Нәфисәгә абый кеше инде ул. Ничә яшькә олырак икәнен төгәл генә әйтә алмаса да, араларында бер ун гына ел барлыгы билгеле иде. Сирәк-мирәк кенә шулай авылга сугылганда Нәфисәләргә керми киткәне юк анын. Заманында әтисе белән бергә эшләгәннәр алар. Гел кереп йөрүе шул форсаттан икәненә беркемдә дә шик юк иде.

Алай да, мәктәпне бетергәннән бирле Нәфисә белән беренче очрашулары иде. Сонгы бер-ике елны укытып та маташты әле ул аларны. Карап торуга матур гына, буйчан, төз, матур гәүдәле егет сыйныф алдына кереп басуга әллә нишләп кызыл чөгендер шикелле кызара да куя иде.

Шул хәтирәләре исенә төшеп Нәфисә, иренеп кенә, кыр җиле үпкән иреннәрен чит-читләреннән элеп кенә елмаеп куйды да, бераз кызыксынулы көлемсәр карашлары белән кунакны күздән кичерә башлады.

Кунак ир дә үз чиратында, үзе Лотфулла абзый белән нәрсәләр сөйләшкән булып кыланса да, анда-санда Нәфисәгә дә күз төшергәләде. Тик, кызга борылып караган саен, иң кирәкмәгән чакта гына чөйгә элэгеп тартылган бау шикелле, карашларын Нәфисәнен күзләреннән тиз генә йолкып ала алмый изаланды. Берничә кат шул кыен хәлгә калганнан сон, өстәл артына кереп утырганчыга тиклем, кызга башкача борылып карарга базнат итмәде.

Ирнең үзеннән нигәдер карашларын яшерүе, әллә нидән каушап, югалып калуы Нәфисәне иләсләндереп, дәртләндереп җибәрде. Әйтерсен, аны кинәт кенә шушы вакыт кинлегеннән икенчесенә кысрыклап чыгардылар да, бу яна әйләнештә үзен бөтенләй башка кеше, дөресрәге, бөтенләй башка кыйммәтләргә ия хатын-кыз итеп хис итәргә форсат бирделәр: монда аны һичшиксез яраталар, телиләр кебек иде. Аны әллә нинди биеклекләргә күтәрелә ала торган таганга утырттылар да югарыга, һаман югарыга, ул әле бервакытта да татып карамаган биеклеккә чөяргә, ымсындырырга тотындылар.

Шушы күнел күтәренкелегеннән анын тәне буйлап кайнарлык йөгерде, үпкәләре кысылудан сулышлары калтыранып, башлары әйләнеп китте. Агарынып киткән бармаклары белән ул тиз генә күлмәгенен өске сәдәфен ычкындырып җибәрде, билендәге путасын кысыбрак бәйләде, җыелып куйган чәчләрен аннан-моннан тарткәләде дә, үзен-үзе кулга алырга тырышып ишек янагына терәлеп тынып калды.

Өстәл артында әле бер-берсенә сүзсез карашлар гына ташлап утырсалар да, алар үзләрен тулысынча чолгап алган бу яна кичерешләрдән арына алмадылар. Нәфисәнең әтисе, әнисе белән корылган әңгәмәдә катнашса да, бу сөйләшүнен нәрсә турында барганын да, нигә кирәклеген дә ныклап

аңламады сымак. Киресенчә, бу хәл аларга бары комачаулый, бер-берсенең күзләрнә яшерен генә ташланган карашлары белән күңел төпләрендәге әллә нинди нечкә кылларына кагылып иркәләнү ләззәтеннән мәхрүм итә иде.

Аларның бу халәтен Лотфулла абзый белән Мөҗәһирә апа да күреп, тоеп торып, инде ничәнче ел ялгызак яшәгән кызлары өчен эчтән генә куансалар да, нәрсә кылырга, үзләрен ничек тотарга икәнен белми кыенсынып аптыраганнар иде.

—Кызым, син дә сыйланыбрак утыр әле,—дигән булды Мөҗәһирә апа, кызын бу чолганыштан аеру нисбәтеннән,—иртәгә бит синен дә юлга кузгаласың бар.

Нәфисәне бу сүз сискәндереп җибәрде. Чынлап та, иртәгә тагын яңа көн туачагын, ә иртәгәсен инде хәлләр бөтенләй башкача булачагын күңеленнән кичереп, алдында торган шәрабле бокалын кулына алды да урыныннан торып басты:

—Әйе, әле тагын кайчан шулай очрашырга туры килер. Илсур абый, әйдәгез әле, очрашу хөрмәтенә берне йотып куйыйк. Әти, әни, әйдәгез, сез дә.

Өстәл өстенә исем өчен куелган, кунакчыллык билгесе итеп кенә бокалларга коелган шәрабкә дә бу тамашада роль табылды—шушы чолганышны сүтү, кыенсынып утырган дүртесен дә, ниһаят, бу хәлдән коткару, һәркайсын үз урынына кайтару, җөпләү бурычы.

Нәфисә бокалын тотып, кунак итепме, башта Илсурга, аннары әтисенә, аннары әнисенә таба үрелде. Киеренкелекне арттырмас өчен бокаллар да тыйнак кына зеңләде, шәраб йотымы да ымсындырып кына иреннәргә бәрелеп алды да, пыялада матур кызгылт эз калдырып бокал төбенә шуып төшеп чарасыз тынып калды.

Инде барсына да бераз җиңелрәк булып китте. Иркен сулап һәммәсе дә бокалларын ашъяулык өстенә куеп, кайсы җимешкә, кайсы конфетка үрелде. Чәшке-чынаяклар, бал калаклары телгә килеп, өстәл артындагылар фәкать шушы савыт-саба тавышларын тыңлар өчен генә өстәл янына җыелган сыман, берсе дә ләм-мим сүз катырга базмый, тавыш-тынсыз гына капкалап утыра башладылар.

—Ярый,—диде, ниһаять, Илсур.—Мин кузгалырмын инде, юлдагының юлда булуы хәерле диләр. Рәхмәт сезгә, Лотфулла абзый, Мөҗәһирә апа, сыегыз, якты йөзегез, җылы сүзегез өчен. Нәфисә, сина да, рәхмәт... Сине күптән күрәсе килгән иде инде.

Тагын нидер әйтәсе килеп ир туктап калды. Ун ел бит! Ун ел буе очратырга теләп кирәк-кирәкмәсә дә шушы авылга йөрде. Бәлки онытып та булыр әле дип, вакытны эзәрлекләми сабыр итте. Бигрәк яшь бит, үз тиңен табып бәхетле булсын диде. Нишләптер, Нәфисә дә, бәхетле булырга ашыкмады. Уңмаган иреннән аерылды да үзе генә тик яши бирде.

Илсур сүзне кайсы очыннан башларга белмәде. Мөҗәһирә апа белән Лотфулла абзыйның да шикләрен фаш итеп барсын да сөйләп бирәсе килде. Юк, дөресрәге, кыска гына итеп бер сүз белән генә, шушы тост вакытына гына сыярлык итеп әйтеп бирәсе. Аерылганлыгын да, ташбәгырь дип үйламасыннар өчен, балаларына һәрвакыт ярдәм итеп торганын да, хатынына фатирын калдырып китсә дә, үзе дә урамда түгеллеген. Яхшы эштә эшләвен белдерәсе килде. Ә иң мөһиме Нәфисәне, бары тик Нәфисәне генә үзенә тормыш юлдашы итәсе килүен, бар кыйммәтләреннән дә өстен куеп яратуын сөйлисе килде. Әле тагын Нәфисәне инде, мәктәпкә кергәнче үк күргәне булганлыгын, аның аксыл кашлары арасыннан монсуланып торган зәңгәр күзләрен күреп, и, минем булачак хатынымның да күзләре шушындый төстә булса иде дип теләгәнен. Авылга укытырга да үз теләге белән, ул кыз хәзер нинди булды микән дип, юри генә кызыксынып килгәнен әйтеп бирәсе

килде. Уйлары белән бер ярдан икенчесенә бәргәләнде-бәргәләнде дә, әллә кайсысына эләгеп чорналып, һуштан язып туктап калды Илсур. Шуңа, әйтелергә теләп, ирнен эчке кайнарлыгыннан тулышкан хисләре, акылы ничек кенә тыеп калырга теләсә дә, гади сүзләргә генә дә риза булмый, аның иреннәреннән түгел, ә күзләреннән, яшьләре булып бәреп чыкты.

Шул каһәр, сабырсыз күз яшьләре, хәлнен барысы уйлаганча вакытлыча гына түгел, ә күпкә мөһимрәк, тирәнрәк икәненә ишарә ясап, өстәл артындагыларны тагын пошаманга салды. Ирнен кытыршы чигәләреннән никадәр мул итеп аксалар да, өстәл артындагыларның берсендә дә ул яшьләрне күрәсе килү теләге тумады, кызыксыну уятмады. Киресенчә, һәммәсе дә бу хәлне күрмәмешкә салышып, дәррәү башларын аска иделәр...

Әлбәттә, башка вакытта булса, табынның бу өлешендә гади авыл халкына хас куна калу мәсьәләсендә кыстаулар башланыр иде. Әмма бу юлы, бик теләсәләр дә, Лотфулла абзыйның да, бигрәк тә Мөҗәһирә апаның авызыннан андый сүзләр ишетелмәде. Хәер, Илсур аны үзе дә көтмәде.

—Тәки китергә булдың инде,—дия-дия, хуҗалар аны капка төбендәге машинасына тиклем озата чыктылар. Җилкәсеннән кагып сөя-сөя, теләкләрен тели-тели, ир машинасына утырып китеп, олы юлга борылып күздән югалгынчы карап калдылар.

Нәфисә чыкмады. Әтисе белән әнисе әйләнеп кергәнчегә тиклем ияген учларына терәп елмаеп тик утыра бирде. Китеп барган ир, күз яшьләренә манчып, шулай онытылып елмаеп утырырлык итеп кызның күңеленә әллә ни тамызып киткән иде. Әллә өмет тамчысы, әллә гади генә куаныч. Ничек кенә булмасын, ул шушы хәлгә чын күңеленнән куанды.

«Нишләп мин моны алданрак шәйләмәдем икән соң?» дип уйлады ул. «Нишләп элегрәк күрмәдем икән соң мин аны, ике ел акбур тотып каршымда басып торган ләбаса. Ә ул тагын да матурайган. Чем-кара чәчләрен көмеш кыллар араласа да һаман егетләрчә матур, төз,»—дип уйлады ул.

—Кызым, ятыйк инде. Иртә таңнан юлга да кузгаласың бар.

Әйе, иртә таңнан ул юлга кузгалыр. Илсур узган юлдан, иртән, машинасы белән яктыртып ул узар. Икесе бер тарафка юл алалар бит.

—Бу Илсурны әйтәм, бер яшь кенә укытучыга өйләнеп чыгып киткән иде, һаман яшиләр микән? Алып килгәне дә юк, сөйләнгәне дә...

Йокы бүлмәсенә керешли карчыгына ташлаган кебек кыланса да, Лотфулла абыйның бу сүзе Нәфисә өчен иде, әлбәттә.

Ишетте аны кызы. Тик, эндәшмәде генә. Әтисе дә башка сүз катмады.

Барысы ды сабыр гына яңа туасы көнне көттеләр, яңа көн барын да үзенчә уңай хәл итәчәгенә өмет иттеләр.

Нәфисәнең бит хыялларга бирелеп хисләнеп утыруы да бүгенге рәхәтлекне, бәхетне тулысынча бүген татып каласы, ул кичерешләрне мөмкин кадәр озаккарак сузасы, иң татлыларын мендәренә тиклем алып киләсе килүдән генә сымак иде. Иртәгә тагын әллә кайдан болыт күтәрелер дә, яңгыр тамчылары мәрхәмәтсез рәвештә барын юып төшерер. Кояш нурында ялтыраган юеш яфракларга бәрелеп аның хисләре меңләгән кисәкчекләргә бүленеп чәлпәрәмә килеп, яшәешнең битараф пыялаларына чәчрәп агып төшәр.

Ничәнче кат инде шулай!
Яңгыр кызы шул ул!
Шуңа һаман ялгыз ул.

Икенче көнне, таң туар-тумас Нәфисә юлга кузгалды. Төн буе керфек тә какмады. Әмма ләкин ул үзендә бер авырлык та тоймады. Йөгерә-йөгерә әйберләрен җыйды, әнисе кысташа-кысташа тутырган күчтәначләре белән

аларны машинасына урнаштырды. Картлар авыр эш көне алдыннан тагын бераз ял итеп алсыннар дип, эшне озын-озакка сузмыйча гына йорттан кузгалып чыгып та китте.

Магистрльгә борылганчы авыл юлы тып-тын булып, бер машина әсәре дә күренмәде. Олы юлдан узган машиналарның утлары гына еракгагы җәйге рәшә кебек ялт-йолт килеп югалды да янды, янды да югалды.

Магистраль юлга борылуга, машинасы артыннан әллә кайдан пәйда булган ят бер машина бастырып килә башлауын күреп Нәфисәне курку алды. Әллә берәрсе шаярта микән дип, көзгесенә күпме генә текәлсә дә, фара яктысында берни күрмәде. Бу тирәдә кесә телефоннары да бик тотмый. «Бер үлемгә—бер сәбәп» ди торган иде әбисе. Нәфисә анын хаклыгын, менә хәзер, үз тәҗрибәсендә исбатлар ахрысы.

Кыз машинасының тизлеген күпме генә арттырса да, арттагы машина бер адымга да артыннан калмады. Шунысы тагын сәер, куәте Нәфисәнен машинасыннан күпкә артык булса да аны читкә дә кысрыкламады, алдына чыгып юлын да басмады. Артыннан тик килә бирде.

Авылдан да хәйран ерагайдылар. Нәфисә инде бөтен белгән догаларын укып бетерде, Хак Тәгаләдән бар гөнаһлары өчен гафу да үтенде. Ул да булмады, теге машина үкереп узып китте дә утлары белән уйнап ана туктарга ишарәләп, үзе тукталыш павильоны янына барып туктады. Нәфисә анымоны уйларга өлгергәнче машинадан кемдер сикереп төште дә, кулларын болгый-болгый юлга, аның каршысына чыга башлады.

Кыз, әллә танып гаҗәпләнүеннән, әллә каушаудан чак кына аны бәрдермәде. Чыжлап узып китеп берникадәр барды да, тизлеген акрынайтып юл читенә чыгып туктады.

Бер мизгелгә бар да тынып калды. Нәфисә юлбасарын таныса да ачуланып та, шатланып та аның каршына ташланмады. Бары, машина утыргычына башын салып күзләрен йомды. Ир дә әле һаман юл уртасына баскан килеш, алга табан ни кылырга белми аптырап тора иде. Аннары, Нәфисәнең машинасыннан чыгарга ашыкмаганын аңлап, акрын гына үзе ана таба атлады...

...Аларның бер тапкыр да мондый тирән тетрәнү кичергәннәре булмады. Шул бер мизгелдә, ничәмә еллар бер-берсен теләп эзләгән иреннәр, сулышка-сулыш, йөрәккә-йөрәк тибеше кушылды да, шушы мөһим нәрсәләр генә гамәлдә калып, калган бар дөнья җуелып юкка чыкты. Әйтерсен алар—ике жан, ике тән бер булып зәңгәр күккә атылдылар да, шунда эреп әллә болыт булып актылар, әллә йолдыз булып җемелдәделәр, әллә кояш нуры булып галәмне инләделәр. Тынычлыгын югалткан кулларының татлы кайнарлыгында янып, бу дөньялыкта әллә бар, әллә юк булдылар. Җанга—жан, тәнгә—тән куанды...

Кайдадыр, беркем төртеп күрсәтә алмаган сызык артында—фани дөнья. Ул фанилык катында, иреннән шул ук хисләрне өмет иткән Илсурның ташлаган хатыны, иң гадел кеше итеп яратучы ике улы, аны гаиләчел кеше итеп белүче шаһитләр, Нәфисәне акыллы, сабыр кыз, дип горурланучы Лотфулла абзый белән Мөҗәһирә апа, балаларына һәрвакыт үрнәк итеп куйган башка туган-тумачалары, тагын әллә кемнәре торып калган.

Ул торып калганнарда бу икәүнең һич эше юк иде.

Тик, әнә шул калганнардан кача алмаган кебек, хәзер инде алар бик теләсәләр дә бу кичерешләрне оныта да, шушы мизгел тарихын башкача яза да, бер-берсеннән миллион чакрымнарга ерагайсалар да шушы бәйләнеш ноктасыннан бер генә кәлимәгә ерагая алмаслар. Ул гел янәшәдә яшәр, башкача бер тапкыр да кабатланмас өчен, бу икәү, һәрвакыт, шушы көрчеккә әйләнеп кайту теләге белән янсыннар өчен, кайта алмый тилмерсеннәр өчен..!



Нурулла Гариф

# ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯТЛӘР

## Нәселеңә корт керсә...

Якташым Нәҗибулла абый төбәгебезнең алтын куллы кешесе иде. Гомер буе кешеләргә йорт салышты, тәрәзә рамнары, ишекләр ясашты. Ул чорда балта тотучылар күп булса да, аның кебек төгәлрәк эш коралы тотучылар сирәк иде.

Нәҗип абый үз йортын гомеренең икенче яртысына чыккач кына яңартырга алынды. Бар күңелен биреп, үз гомеренә генә түгел, уллары-оныкларыныкына да җитәрлек итеп төзергә тырышты. Әмма яңа йортка күчеп күпме генә гомер узгандыр, йорт бүрәнәсеннән агач оны коела башлады. Бер бүрәнәгә агач корты оя салган булган икән. Ике-өч ел эчендә агач корты башка бүрәнәләргә дә күчеп, бар йортка таралды. Йорт хуҗалары исә йортны коткарып калу өчен ни генә эшләмәделәр: агулап та, буяп та, майлап та карадылар, тик файдасы гына булмады.

Нәҗип абый гомер көзенең соңгы өлешенә кергәндә, йортны кабат сүтеп, өр-яңадан салырга мәҗбүр булды. Тырышты, тырмашты һәм кабат йорт җиткерде. Дөрес, бу мәшәкатьләр хуҗаның үзен фани дөньядан вакытсызрак алып китте. Шуңа да карамастан, бу йортта бүген аның уллары-оныклары матур гомер кичереп, нәселен дәвам итә.

Ә менә алар каршындагы гасырлар кичәрлек таш йорт күпме гомер инде буш тора. Аның хуҗасының улы, киленне чит кавемнән алып, үзе дә шул якка авышты.

Йорт-җирне кабат торгызып, байлык-малны да табып, җыеп була ул. Ә менә нәселеңә корт керсә...

## Төштән соң киләчәк акыл

Күршеләрдә чираттагы бәйрәм. Рухи күтәренкелек иртәдән үк сизелә. Күршем минем җир җимертеп эшләп йөрүемә гаҗәпсенә. Шул сәбәпле, уенын-чынын бергә кушып, ризасызлык та күрсәтә.

—Кара әле, нигә сез безне хөрмәт итмисез? Без сезнең бар бәйрәмнәрегездә дә ашап-эчеп, күңел ачып, ял итмичә калмыйбыз. Ә сез безнекен бар дип тә белмисез. Нигә шундый сез?!

—Син миңа үпкәли алмыйсың, күрше,—дим, башымны күтәрмичә генә.—Үзең беләсең бит, сезнең бәйрәмдә генә түгел, үземнекендә дә эчмим мин. Гомумән, аракы эчү сезнең өчен дә, безнең өчен зур гөнаһ ул.

Хатыны сөйләшүебезне тыңлап тора икән. Ул да сүзгә кушылып, минем тарафка баса.

—Хәзерге акылым булса, мин дә эчмәүче татарга чыгар идем,—ди.

Ире кызганнан кыза:

—Әнә, кызыңны бир, алар шундый яхшы булса. Яулык ябып, өеңдә иренә генә карап ятар,—ди.

—Нигә, начармыни, урамда ыштансыз йөргәнче яулык ябып йөрер, ни ояты бар аның...,—диде дә китте, китте хатын татарча яшәүнең яхшы якларын санап... Татар тормышының үзем белмәгән уңайлыклары турында да ишеттем хәтта. Халкым өчен тагын да горурланып куйдым.

Янәшәдә басып торган кызлары актан-карадан берни дәшмичә тыңлап торды да, акрын гына өйләренә кереп китте.

Мин дә, күршеләрнең гаугалы сүзләреннән качып, читкәрәк тайпылдым. Әмма күпме генә эш белән онытылырга теләсәм дә, башта туган уйлардан качып булмады. Кызык бу тормыш. Татар яшьләре күршеләребезнең күңел ачуга корылган тормышына кызыкса, шул тормышта яшәп, гомер уртасына җиткән марҗаларга татарның аек, тыныч яшәеше тансык икән бит.

Күрмәгәннең күрәсе, күргәненең качасы килүе шулдыр инде...

## Юллар чатында

Кремль урамы буйлап, прокуратура бинасын узып барам. Шул чак бер әби култыклап алды да:

—Улым, син татар баласымы?—ди.—Әйе, минәйтәм.

—И-и-и, балам, зинһар, юл аша гына чыгарып куй әле. Ярты сәгать басып торам инде, ник бер машина туктасын,—диде әбекәй.

Каршыда урам аша җәяүлеләр чыгар өчен эшләнгән тамгалы «кичү». «Әби, гомер буе басып торсаң да туктамаячак алар. Ә менә монда аяк басуга, бар машиналар да туктарга тиеш. Бу урында синең хокукларың беренчел»,—дип, тиз генә әбигә юл кагыйдәсен аңлатам да, юлга чыгам. Машиналар агымы шундук әкренәя. Әби дә гаҗәпләнүеннән берара сүзсез кала. Аннан:

—Нинди хокук белү, улым, гомер буе башыбызны түбән иеп йөрдек шул без,—дип, миңа үткәннәрен сөйли башлый. Әмма аны тыңларга вакытым юк. Юлны чыгам да, ашыгып китеп барам. Артымнан әбинең хәер-догасы гына ишетелеп кала.

Әби яныннан кәефем күтәрелеп китсә дә, бераздан күңелне авыр гамь били алды.

Безнең бабаларыбыз дүрт гасыр буена үз хокукларын даулап утка да, суга да кергән. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң бар халыкларга да бер төрле хокуклар бирелә. Ә без, шул хокукларыбызны белмичә, ярты гасыр инде дөнья чатында басып торабыз...

## Акылга сыймаслык бәйрәм

«И, улым, яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган кешенең үлеме дә бәйрәм икән ул»—дип еш кабатлый торган иде әнием. Аның бу гыйбарәсе белән озак еллар буе ризалашмадым.

Һәр көтелмәгән җан өшеткеч вакыйга аяз көнне яшен суккандай була икән. Күрше йортта олы фаҗига. Әнисен, хатыны белән ике кечкенә баласын калдырып бакый дөньяга бер яшь кеше китеп барды. Һәрвакыттагыча кинәт кенә, күңел һичкайчан ышанмаслык итеп. Мондый чакта тирә-якта аның белән аралашып яшәүчеләр тетрәнеп, дөнья куудан бераз туктап, аз гына уйланып ала.

Шул ук йортта, күршеләрендә генә, бер карт өч елдан артык инде үлә алмыйча азаплана. Үзе генә түгел, якын туганнарын да алҗытып бетерде инде. Ераклыгын җәһәннәм белән генә чагыштырырлык Себер ягыннан инде, менә үлә дип, өч тапкыр олы кызын да чакырып кайтардылар. Юк шул, үлем олысы-кечесе белән санлашмый да, чиратка да салмый. Карт кече йомышын да үзе үти алмыйча, азапланып, ыңгырашып ятуын дәвам итә.

Менә шуларны күргәч, уйланасың. Үлем дөрестән дә кемгәдер—фаҗига,

кемгәдер бәйрәм икән шул. Балалары тәрбиясендә яшәп, вакыты җиткәч вафат булган әти-әниеңне җирләү дә һәркемгә дә тәтеми торган бәхет икән ләбаса.

Кемнәрдер ризалашмаячак бу фикергә, яшьтән үк әти-әниләреңне, яшьтәш-якыннарыңны югалта-югалта гына киләсең икән.

## Акылың алдан йөрмәсә

Әхмәт бабайларның йорты авылның иң түбән өлешенә урнашкан иде. Бабалары йортларын ни йөрәк белән курыкмыйча суга шулай якын салганнардыр. Дөрес, йорт тирәсе гел коры торыр иде. Йорт белән янәшә колач җитмәслек дүрт тал агачы үсте. Авыл балалары да гел бу тирәдә җыелып уйнады. Шунысы истә калган, күпме генә тырышсак та без ясаган җәяләрдән аткан укларның берсе дә агачларның башына менеп җитә алмады.

Күпмедер вакыт узгач, бу йортны сатып, балалары әтиләрен шәһәргә алып киттеләр. Әхмәт бабай йортны алучы яшьләргә: «Йортны гына сатам, агачлар менеке түгел, аларына кагылмагыз»,—дигән булган. Ә хәзерге яшьләр олы кеше сүзен тыңлыймы соң? Ике-өч ел да узмады, бер-бер артлы агачларны кисеп яктылар. Имеш, йорт тирәсенә кояш төшми, җир кипми икән...

Күп тә узмады, бу урынны вак таллык басып, йорт тирәсе сазлыкка әверелде. Бала-чага да уйный торган урынын алыштырды. Әмма бу үзгәрешләрнең шаукымы Әхмәт бабай йортында яшәүчеләргә күбрәк тиде. Ябыштырган обойлары купты, мичләре чатнады, соңрак алгы өйләре дә бер якка авышты.

Бер зур тал агачының тамырлары тәүлегенә сиксән чиләккә якын су суыртып, яфракларына аны парга әйләндерергә сәләтле икән. Шул агачлар йорт тирәсен коры тоткан булган. Ә кояш көн саен елмаймый ул.

Картларның: «Акылың алдан йөрмәсә, астыңа су керер» дигәннәренең бер очрагы шушыдыр инде...

## Шулай да була...

(Бер хезмәттәшем сөйләгән вакыйга)

Бер көнне элекке укучымның әтисе килгән. Улы ике-өч еллар элек, миндә укып, мәктәпне тәмамлаган иде. «Малайга характеристика кирәк, язып кына бир әле»,—ди бу. Ризалаштым инде. Язмыйча барыбер котылып булмаячак. Чөнки аның моңынчы да, малайны әллә кайларга укырга кертәсе идем дип, яхшы сыйфатнамәләр сорап теңкәмә тигәне бар иде инде.

Әйбәт кенә итеп яздым да, кызым аша биреп җибәрдем.

Ярты сәгать тә узмагандыр, сулышы кабып килеп җиткән бу. «Кара әле, ачуланма инде, әйтергә оныткан мын, малайга повестка килгән, бу юлы характеристика военкоматка кирәк иде, начар итеп яз, армиягә алмаслык булсын»,—ди бит бу.

Кабат эшкә тотындым инде. Бу юлы авыр да булмады. Улы мәктәптә ничек укыган, үзен ничек тоткан, барын да нәкъ булганча тасвирладым. Хәер, аның үз-үзен тотышы әти-әнисенекеннән әллә ни аерылып та тормый иде.

Сыйфатнамәнең файдасы тигәндерме, башкасымы, егетне армиягә алмадылар. Әтисе әле дә күргән саен рәхмәт укый. Ә мин шушы хәлдән соң үземне бәя бирергә дә белми йөрим.

## Җирдәге тәмуг

Үзгәреш чорлары башларында бер хезмәттәшебез гарәп илләре буенча сәяхәткә китте. Дөньяга караш үзгәргән заман. Кызыксынуыбыз көчле иде, аның кайтуын дүрт күз белән көттек. Чит илләрне ничек мактар да, уңайлык-матурлыкларын нинди төсләргә салып тасвирлар икән?

Әмма хезмәттәшебез сүзен чит илләрне мактаудан бигрәк үзебезне сүгүдән башлады. Кешеләр анда ком-таш арасында да кешечә, бай яшәп, ил-көннәре өчен горурланалар икән. Ә без монда, Ходайның җәннәт бакчасына тиң җирдә дә, дәүләтсез, кадер-хөрмәтсез бер кавем булып беткәнбез!

Яшәгән җиреӊ, туган телеӊ, халкыңның кадерен белмәсәң, оҗмахтай җирләрдә дә тормыш тәмугка охшап кала икән шул.

## Кем иде дә кем булды

Авыл кызлары озатырга якын да китермәгәнлектән, яшьлеген кимсенеп уздырды Ирек. Хәер, кызларга гына түгел, авыл егетләренә дә, «печник Хаҗи малае» гына иде ул. Аның әтисе гомер буе якын-тирә авылларда мич чыгарып көн күрде. Үзенең дә кечкенәдән әтисенә булышып йөреп, тормыштан алган бердәнбер һөнәре ташчы иде.

Тугыз сыйныф тәмамлап, шәһәргә киткәч тә укып тормады, төзүче булып эшкә керде. Осталыгын күреп, төзелеш җитәкчесе үз йортын таштан салуны да аңа ышанып тапшыра. Йортның бизәлешенә сокланып, соңрак башкалары килә. Шуннан китә, минсиңайтим!

Бүгенге көндә Ирек ташчылар бригадасына җитәкчелек итә. Шәһәрдәге бөтен байларның төзелеш эшләре аның кулы аша уза. Шул сәбәпле, эшләп тапкан байлыгы да хәттин ашкан. Үзе өчен генә дә тырышмый ул. Күтәрәмгә калган авылның хәҗәтләрен дә кайгыртып, авылдашларына да булышып тора. Әтисе Хаҗиулла абый да улы төзеп биргән иркен таш йортта бер кайгысыз гомер кичерә...

Хәер, үкенүчеләре дә бар. Яшьлектә Иреккне кире борган авыл кызларының күбесе, аерылып кайтып, ялгыз тормышта авырлык белән көн күрә. Их, дөньяның кая борыласын алдан белгән булсалар икән!..

## Бала бәласе

Югары яктагы күршеләребез Һадиулла абый белән Фәгыйлә апай начар яшәмәделәр үзе. Икесе дә фермада эшләгәнлектән, җаен чыгарып, шәхси хуҗалыкларында да мал-туарны күп асрадылар. Хезмәтләренә күрә хөрмәтен дә күрделәр. Яхшы ашадылар, әйбәт киенделәр. Мөмкинчелек туган саен парлап ял йортларына чаптылар. Үзләрен, сарай-куралтыдагы малларын караганлыктан, гел эш белән мәшгуль булып, балаларына гына тәрбия-игътибар җитмәде. Аулакта калган шул балаларының шуклыгыннан гел зыян күреп яшәдек.

—Нигә бу балаларга азрак игътибар бирмисез?—дип тә әйткәләдек. Тыңламадылар. Барын да тормыш авырлыгы белән вакыт җитмәүгә сылтап калдыра бирделәр.

—Безне бик карамадылар әле, кешедән ким яшәмибез. Аларны да тормыш үзе өйрәтер,—диделәр.

Ел арты ел үтә торды. Тормыш өйрәтте. Көч-хәл бетеп, мал асраулары да авырлашты. Хәзер күршеләребезнең үзләренә балаларының игътибар-ярдәме җитми.

Баладан бәлә ясамаска иде дә бит, әмма Һадиулла абый белән Фәгыйлә апай язмышыннан гыйбрәт алмыйча яшәүчеләр бүген дә күп әле.

## Уйлансаң, уйландыра

Археологик казу эшләре вакытында тикшерелгән борынгы зират урынына, эшләребезне тәмамлагач, ташбилге куеп китәргә уйладык. Шуңа бәйле техника кирәк булганлыктан, икенче көнне якындагы авылның колхоз рәисе янына кердем. Керү сәбәбен ирештерүгә үк, идарәдәгеләрнең берсе:

—Ул зиратларны тикшереп ни хаҗәт табасыздыр? Үлгән-беткән бит инде,—дип, ризасызлык белдерде.

—Абый, бу бит безнең тарих, зираты да үз әби-бабаларыбызныкы. Ташландык, билгесез хәлдә ятулары яхшы түгел бит. Кеше дә күреп азрак уйланыр иде,—дип нотык тотарга туры килде.

Ләкин ризасызлык белдерүченең иптәшләре алдында үзен җиңелүче итеп калдырасы килмәде:

—Үлгәч, кайда ятсаң да бер инде ул,—дип, сүзне шаяруга борырга маташты.

—Сезгә, бәлкем, барыбердер, ә башкаларыгызга ничек икән? Кайсыгызның үлгәч тә кадерсез ятасы килә?,—дип, башка түрәләрнең күзләренә карап чыктым.— Аннан, кем белә бит, әгәр дөньясы сез әйткәнчә «үлгән—беткән генә булмаса», ни эшләрсез? Минем бабаларының зиратын сукалап баеган бер колхозны да күргәнем юк әле...

Кабинетта тынлык урнашты. Әле генә «болт, гайка, «подшибникларны» каян

табу турында баш ватып утыручыларның уе башка якка борылды. Соңыннан: «Трактор иртәгә булыр»,—диделәр.

Сүзләрендә тордылар.

## Замана туе

Авылның күрше йортында туй бара. Хәер, заманына күрә исеме генә туй аның. Түшәк инде тапталган, ак ипигә бал ягып ашалса да, яшьләрнең бергә булу тәме инде күптән татылган. Бар да ясалма хәзер. Табигыйлык юк, синтетик фән чоры. Булганын да бетереп, татар гаиләсендә татарча сөйләми торган угыл яисә кыз үсә. Алары да шул бер-икедән артмый. Килен яисә кияү башка кавемнән булгач, гореф-гадәтләр дә башкача. Диннәр каршылыгына да игътибар юк.

Бу очракта да, күрше татар әбиләрен гайбәт сөйләүдән мәхрүм итеп, ясалма никах уздырдылар. Килен ягындагы марҗа әбиеңнәрнең күңелен күреп, тегесенә дә барылыр. Әнә гороскоплар да аларның яхшы тормыш корып, бал белән майда гына йөзәчәкләрен искәртә икән.

Кеше тиз үзгәрә шул. Егетнең әнисе әле 90нчы еллар башында гына, яратмаган күршеләренең гайбәтен бар авылга сатып, исән булсам марҗаны тупсамнан да атлатмаячакмын дип сүз ирештергән булган. Хәзер сүзен җыеп бетерә алмый, соң инде. Кем уйлаган бит аны. Үзенең дә, күршесе кебек «дивани» (дәүәни)—оныгы авызыннан чыгачак бердәнбер татар сүзе—булып кына каласын.

## Коммунизм шаукымы

Коммунизмга баруның иң зур тизлеккә ирешкән чагы. Урып-җыюлар беткәч, көзге көннәрнең берсендә халыкны клубка җыйдылар. Коммунизм кояшы бүген булмаса иртәгә чыгасына өмет биргән докладтан соң алдынгы колхозчыларны бүләкләү башланды. Урыннар саны киредән барып, һәр елдагыча өченче урынны көтүче Заһир абыйга бирделәр. Бүләк бәһасе 50 сум. Икенче урын сыер савучыга бирелергә тиеш иде. Бу юлы да аны 100 сум дәрәҗәсендә Хәния апа алды. Ниһаять, беренче урын. Җиңүчесе Касыймхан абый. Ярты авыл туганнары булгангамы, кул чабудан клуб шартлый язды. Аңа җете кызыл Кучмә байрак тоттырдылар. Районнан килгән «олы кеше» кулын кысып үзе тапшырды. Шул арада ук, халыкның таралышмавын үтенеп, концерт буласын игълан иттеләр. Касыймхан абый берни аңламый, тагын нидер өмет итеп, колхоз рәисенә текәлеп карап тора. Әмма ләкин бирергә җыенучы юк. Менә шуннан соң башланды да инде. «Бу чүпрәк минем балаларга ыштанлыкка да җитми»,—дип, абзый байрагын клуб идәненә тотып бәрде. Аннан соң: «Кирәкми миңа беренче урын, икенчесенә дә риза мин»—дип, колхоз рәисенә килеп ябышты. Араларына теге «олы абый» керде. Шуннан китте...

Хәер, соңыннан ни булганын без, бала-чага, күрмәдек инде. Безне бер селтәүдә клуб эченнән куып чыгардылар. Белә дә алмадык. Ул заманнарда олы кешеләрнең өйдә, балалар алдында кеше гайбәтен сөйләү гадәте юк иде.

Бүгенге көндә бу сәер беренчелек гадәте татарның рухи бәйрәме булган Сабан туйларына үтеп керде. Хәзер батырга—сарык, икенче урынга—машина, өченчесенә суыткыч бирәләр. Әмма бер батырның да сөлгесен ташлап икенче урынны даулаганын күргән юк әле. Беренче очрактагы кебек, монысы да өметле фал—татарның аш та, баш та бирергә теләмәве.

# МИЛЛӘТ КАҺАРМАНЫ

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Һәр халыкның да үз каһарманнары бар. Ул каһарманнарның төп сыйфатларыннан зурысы, бурычларыннан берсе—Ходай тәгалә биргән акылын һәм физик куәтен милләтенә багышлау, шул юлда фидакарьләрчә хезмәт итү. Татар халкы, шөкер, андый шәхесләргә бай. Әдәбият-сәнгатьтебездә дә, фән өлкәсендә дә... Нәкый ага Исәнбәт—әнә шундый каһарман. Үзенчәлекле шәхес: милли сәхнәбездә үз мәктәбен булдырган драматург, тел гыйлеменә һәм фольклор белеменә бәяләп бетергесез өлеш керткән олы галим—кабатланмас талант иясе!

Мулла Сиражетдин улы Нәкый Закиров (Нәкый Исәнбәт) XIX гасырның соңгы көннәрендә (1899 елның иске стиль белән 29 декабрендә) хәзерге Башкортстанның Салават районы, Малаяз авылында дөньяга килә. Авылларында башлангыч белемне ала, аннары Уфадагы «Хөсәения», соңыннан Казандагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый. Соңыннан танылган шәхесләребез булып житешкән Фәтхи Бурнаш, Бакый Урманчеларның шәрекътәше булган Нәкый дә алар кебек үк бик яшьли әдәбиятка һәм сәнгатькә тартыла, шигырьләр яза башлый. Менә аның бер шигыреннән өзек:

*Байлар сата, байлар ашый,*
*Бу малларны эшче ясый,*
*Алып кайта аксый-аксый,—*
*Шул кайната каннарымны!*
*Тагын торып эшкә китә,*
*Бер ашарлык акча тота,*
*Акча тагын байга китә—*
*Шул кайната каннарымны!*

Артык гажәпләнмәскә дә мөмкин булыр иде, әгәр дә... әгәр дә үткен иҗтимагый эчтәлекле бу юлларны унике яшьлек малай язмаган булса! 1912 елның апрелендә язылган бу юллар.

Нәкый Исәнбәт үзе, аның иҗат биографиясе—эш һәм хезмәт турындагы шигырьләре тугрылык саклауның матур мисалы һәм үрнәге. Бүгенге укучыны аның бай һәм тармаклы-тармаклы иҗат мирасы, куелган көчнен, түгелгән хезмәтнен күплеге белән гажәпкә калдыра. Шул ук 12 яшьлек Нәкый:

*Гасыр үтәр чатанлаган тавык кебек,*
*Гомер үтәр су астында балык кебек,*
*Ун ел үтәр аучылардан качкан коштай,*
*Бер ел үтәр җәя белән аткан уктай...*
*Тәүлекне әйтә алмам нишләсәм дә,*
*Аз булыр, яшен яки җил дисәм дә,—*

дип тә язган булган. Менә шул яшендәй-җилдәй үтә торган тәүлек эченә әдип тау-тау хезмәтләр һәм әсәрләр язу өчен озын иҗат сәгатьләре сыйдыра алган.

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов әйтүенчә, «70 яшең тулган көненне ничек уздырдың, Нәкый ага?» дип сораганга ул: «Мин бүген көнемне бәхетле иттем, 16 сәгать эшләдем»,—дип җавап биргән. Менә шундый хезмәт нәтиҗәсендә ул зур иҗади мирас калдырды, үзе дә 20 гасырда татарны татар иткән, дәрәҗәле иткән шәхесләрнең берсе булып танылды.

Бу мирасның тармаклары гына да әллә ничә төрле: драматург, шагыйрь, балалар язучысы, либреттист, әдәбият тарихчысы, тәрҗемәче. Болардан тыш ул—тел белгече, фольклорчы галим, тарихчы, публицист та...

Шагыйрь буларак, иҗат дәверендә Н. Исәнбәтнең ике дистә поэмасы, ике йөздән артык шигыре басылып чыга, аларның кайберләре җырга әйләнеп китә: «Син сазыңны уйнадың», «Туган ил», «Бормалы су», «Уракчы кыз»—болары халык үзенеке дип санаган җырлар. Шагыйрьлек сәләте әдипнең Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен Сабантуйга багышлап язылган инсценировкада да, «Түләк һәм Сусылу» исемле опера либреттосында да ачык чагыла. Мәгълүм булганча, соңгысы буенча композитор Нәҗип Җиһанов үзенчәлекле опера иҗат итте.

Н. Исәнбәтнең балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге үзенә бер сәнгать дөньясын тудырды. Аның «Куян мажаралары», «Мырауҗан агай хәйләсе», «Ни өчен ни булган, яки утыз ялган» дигән һ. б. китаплары кечкенә укучылар арасында популярлык казанды. Моңа тагын язучы-галимнең балалар фольклоры буенча төзегән китапларын да кушарга кирәк. Гомумән алганда, ул балаларга йөзгә якын әсәр язган.

Әдибебез иҗатында башка халыкларның иң яхшы әсәрләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгару эше дә лаеклы урын били. Иң саллы тәрҗемәләреннән А. С. Пушкинның «Полтава», «Бакчасарай фонтаны», «Таш кунак» әсәрләрен, А. С. Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясен, У.Шекспирның «Һамлет», «Король Лир» трагедияләрен, тагын да дистәләрчә әсәрләрне күрсәтергә мөмкин. 20-нче еллардан башлап авторның ярты йөзләп әдәби-тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре басылып чыкканын да әйтергә кирәк

Галим буларак та Н. Исәнбәт күпьяклы талант иясе иде. Халык авыз иҗатын җыю һәм эшкәртү өлкәсендә ул куйган хезмәтне, мәсәлән, махсус гыйльми институттагы коллектив эшчәнлеге белән тиңләп була. 20-нче елларда авылдан-авылга йөреп башлаган эшен—халыкның мәкаль һәм әйтемнәрен, мәзәкләрен һәм табышмакларын, җыр һәм такмак-такмазаларын, балалар фольклорын бөртекләп җыю, фәнни эшкәртү, басмага әзерләү һәм дөньяга чыгаруны—ул гомере буе дәвам итә. Фольклор әсәрләре галим кулына килеп кергәнче әле эшкәртелмәгән асылташ кыяфәтендә була. Н. Исәнбәт эшкәрткәч, күптөрле кырлары ачылып, алар чын энҗе-мәрҗән бөртекләредәй ялтырыйлар. Мисал өчен ул әзерләп чыгарган 3 томлык «Татар халык мәкальләре» җыентыгын атап китү дә җитә. (Бу зур хезмәте өчен авторга Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.) Шулай ук табышмакларны татар фәнендә беренче буларак ул зур итеп һәм фәнни эшкәртеп бастырып чыгарды. 1970 елгы бу басма турында дөньякүләм тарала торган фәнни «Үзәк Азия журналы»нда күренекле чит ил галиме Николай Поппе болай дип язды:

«Исәнбәт хезмәте татар табышмакларының иң зур җыентыгы булып тора. Ул, күрәсең, төрки телләрдәге кайчан да булса басылган табышмаклар җыентыклары арасында иң зурларыннан берседер. Сүз бара торган томда табышмакларның гомуми саны 4170 кә җитә... Исәнбәт китабы табышмаклар җыелмасы буларак кына түгел, шулай ук табышмаклар белән бәйле күп кенә проблемаларга кагылышлы хезмәт төсендә дә игътибарга лаеклы». Димәк, Н.Исәнбәтнең мондый китаплары гомуми фәнгә кертерлек югарылыкта торалар.

Әйе, галимнең фәнни хезмәтләр хәзинәсе, аның әдәби иҗаты кебек үк, гаять бай һәм аның проблема офыклары бик тә киң. Телче-галим буларак әле ул татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзеде, татар теленең фразеологик сүзлеген төзеп бастырды. Болар өстенә татар мифлары, ырымнары, им-томнары хакында гыйльми хезмәтләр язды, халык медицинасы турында кульязмалар калдырды; татар халык авыз иҗатының башка тармаклары буенча күп кенә әзерләнгән хезмәтләре барлыгы да

мәгълүм. Әдипнең гомере буена зур тырышлык һәм осталык белән җыйган кульязма борынгы китаплар, документлар һәм тарихи хезмәтләр архивы үзенең байлыгы һәм уникальлеге белән аерылып тора. Бер генә кеше тарафыннан тудырылган һәм тупланган күпме байлык! Болар һәммәсе аның кызы, музыка белгече Йолдыз Исәнбәтнең ышанычлы кулында саклана һәм пропагандалана.

Шуларның һәммәсе өстенә Н. Исәнбәт—драматург, һәм ул халыкка иң әүвәл сәхнә әдәбияты остасы буларак танылды да. Унынчы елларда ук «Әмирхан хәзрәт» комедиясе белән сәхнә әдәбияты ягына башланган сукмак аны 20 нче һәм 30 нчы елларда иҗатның олы юлына алып чыга. Ул—уникаль, ә кайчагында исә берьяклы, шулай да асылы белән бөек гуманизмга хезмәт иткән совет әдәбиятын барлыкка китерүдә, баетуда, алга үстерүдә үзеннән зур өлеш керткән драматург. Әйе, ул әдәби иҗатка инкыйлаб чорларына кадәр, мәдрәсәдә укыган елларында ук килә, «Ак юл» журналында балалар өчен шигырьләрен, «Сукбай», «Укытучы кыз» исемле поэмаларын бастыра. Әмма үзенчәлекле талант буларак ул нәкъ менә совет чорында таныла. Үзгәрешләр чорына килеп кергәч, бездә еш кына совет атмосферасы әдәбиятны һәм сәнгатьне тышаулап торды, торгынлыкка алып килде дигән фикерләр әйтелә. Ләкин бит чын талантны, гәрчә төрле кануннар эченә кертеп, мөмкинлекләрен чикләп куйсан да, бөтенләй дә тышаулап булмый, ул үзенә юлны теләсә нинди шартларда да яра. Матур әдәбият һәм сәнгать тә, фән дә шундый өлкәләр ки, аларны бернинди система эченә дә бикләп куеп булмый. Н. Исәнбәт иҗаты—шуның ачык бер мисалы.

Асылда сыйнфый көрәш идеологиясе шартларында да Н. Исәнбәт күренекле сәхнә әсәрләре иҗат итә. Шул ук вакытта ул бу идеология таләпләренә сукырларча буйсынмый. Шуңа да аның әсәрләренең күп өлеше бүген дә үз кыйммәтен саклый. Игътибар итсәк, әдип бер вакытта да партия таләп иткән колхозлашу, гигант завод-фабрикалардагы хезмәт батырларына багышланган пьесалар язмаган. Берьяклы, еш кына ясалма геройлар урынына ул татарның чын улларына һәм кызларына багышланган әсәрләр иҗат итә. Татарны күтәрү, аны татар иткән традицияләр өчен көрәшкән геройларны сәхнәгә күтәрә: Муса Җәлилләрне, Мулланур Вахитов һәм Сәхипҗамал Вожскаяларны, халык өчен җаннарын кызганмаган «Идегәй» һәм Мәрьямнарны, Спартак һәм Әбугалисиналарны... Ватанга һәм үз халкына бирелгәнлек, аларның язмышы өчен җан ату аның күпчелек драма һәм комедияләрендә сәнгати яктан тулы эшләнгән, җанлы образ-характерлар ярдәмендә чагылдырыла. Әле 60 нчы елларда ук әдәбиятчы Гази Кашшаф драматургны совет чорында милли сәхнәне тотып торган К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәтләр белән бергә дүрт фигураның берсе дип бәяләгән иде. Н. Исәнбәт халык язмышын зур итеп күрә, аның үсеш тарихында хезмәт иясе язган көрәш сәхифәләрен оста итеп, драматик һәм көлкеле вакыйгаларга күчерә белә. Әгәр дә аның трагедия, драма һәм комедияләрен тематика ноктасыннан торып барлап чыксаң, халкыбыз тарихының сәнгати картинасы күз алдына баса. «Хуҗа Насретдин» комедиясендә, мәсәлән, Болгар чорында бабаларыбызның чит ил басып алучыларына каршы да, үз түрәләре белән дә көрәше гәүдәләнә. Бу көрәштә халык коралга һәм тупас көчкә каршы нечкә акылны, зирәклекне, үткерлекне куя һәм җинеп чыга. Менә биш дистә ел инде бу комедия сәхнә тота. Аның мондый уңышын, иң беренче, авторының тарихны, гади халыкның идея-эстетик карашларын, фольклор һәм көнкүреш материалларын, гомумән, татар халкының материаль һәм рухи культурасын тирән белеп, табигый чагылдыру осталыгы билгели. Хезмәт кешеләренең иреккә сусаганлыгын, әллә ниткән кара заманнарда да азатлык-хөрлек хыялы белән яшәвен һәм мөмкин булганча үзенчә көрәшеп яшәвен «Идегәй», «Җирән Чичән белән Карачәч сылу», «Миркәй белән Айсылу», «Хәйләкәр Дәлилә», «Кырлай егете» һ. б. әсәрләрендә дә күрергә мөмкин. Әгәр дә борынгырак чорларны чагылдырган мондый пьесаларда драматург халык авыз иҗаты әсәрләренә һәм легендалар, дастаннар геройларына таянса, беренче чыганаклар итеп шуларны алса, инде якындагырак вакыйгаларны сурәтләгәндә иҗатына тарихи шәхесләрне дә еш кертә. «Гөлҗамал» драмасында туган халкын наданлык патшалыгыннан алып чыгу өчен үзен аямый көрәшкән беренче профессиональ татар актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның

якты образын үзәккә куя. Н. Исәнбәт әсәрләрендә Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы еллары, революционер образлары да чагылыш таба. Андый геройлар авторны үзләрен халык азатлыгы өчен көрәшкә багышлаулары белән җәлеп итәләр. «Мулланур Вахитов» героик драмасында эшче һәм крестьянга сыйнфый бәйсезлек яулап алу юлында үзен корбан иткән каһарман гәүдәләнә. «Болак арты республикасы» пьесасында шул давыллы елларның картиналары, андагы геройлар чагылдырыла. «Спартак» трагедиясендә гладиаторларны һәм колларны изүчеләргә каршы канлы көрәшкә күтәргән легендар юлбашчы образы җанлы итеп күз алдына бастырыла.

Бөек Ватан сугышының авыр һәм аянычлы елларын безнең халык та, башка халыклар белән иңгә-иң торып, намус белән узды, фронтларда һәм тылда батырлык һәм хезмәттә фидакарьлек үрнәкләре күрсәтте. Болар драматургның «Муса» (соңгы исеме «Муса Җәлил»), «Мәрьям», «Мәрди һәм Нәфисә» исемле сәхнә әсәрләрендә чагылды.

Н. Исәнбәт әсәрләре бездәге драматургия төренең кайбер теоретик проблемаларын ачыклау өчен дә җирлек бирә. Әдип иҗатын җентекләп өйрәнгән филология фәннәре докторы Назим Ханзафаров үзенең «Нәкый Исәнбәт драматургиясе» исемле китабында драматургның аерым әсәрләрендәге милли әдәбиятыбыз өчен алып килгән яңалыкларын ышандырырлык итеп раслады. Монда тагын да бер мисалга тукталыйк.

Мәсәлән, «Муса Җәлил» әсәренең жанрын автор «трагедия» дип билгеләгән. Дөрес, ул классик трагедияләрдән үзгәрәк. Мәсәлән, шул ук «Спартак» һәм «Муса Җәлил» әсәрләре үзара стиль җәһәтеннән дә, вакыйгаларның төзелеше һәм үзәк геройның бирелеше ягыннан да аерылалар. Классик трагедияләрдә төп каһарман үз омтылышларында (ә ул омтылыш гүзәл һәм бөек була, еш кына кешелек дөньясының уртак идеалын чагылдыра) нинди дә булса трагик хата ясый. Күп вакыт ул аны, ягъни бу хатаны үзе күрми, күрсә дә, аның зурлыгына бәя биреп бетерми, аны игътибарга алмый. Ә кайвакыт мондый хатаның фаҗигагә китерәчәген герой күрә, ләкин берни дә эшләми, еш кына эшли дә алмый. Аның саф намусы, идеалының бөеклеге аны бу хатаны ясарга мәҗбүр итә. Н. Исәнбәт сурәтләвендә, мәсәлән, Спартак колларның баш күтәрүе җиңү белән тәмамланачагына сак карый торган кеше итеп бирелә. Бигрәк тә соңгы күренешләрдә, гладиаторлар аны Красс армиясе өстенә алып барырга өндәгәндә, Спартак бу сугышның үзләре өчен һәлакәт белән тәмамланачагына яхшы төшенә. Тик шуңа бара. Чөнки каһарман бу хәлдән чыгуның башка юлын күрми. Акыллы кеше, алдан күрә белүчән юлбашчы буларак, ул шуны ачык төшенә: таркау коллар, гладиаторлар, үз җирләреннән ерак китәргә теләмәгән крестьяннардан оешкан отрядлар белән генә Рим кебек бай һәм көчле дәүләтне җимереп тә, хыялланган җиңүне яулап алып та булмый. Хәтта качып котылырга да юл юк. Спартак һәм аның фикердәшләре өчен трагик ситуация шулай туа.

Н. Исәнбәт бу әсәренең стилен трагедия югарылыгына житкерү максаты белән тел-сурәтләү чараларыннан оста файдалана. Персонажларның сөйләү рәвешләре шактый ук чуар: югары катлау вәкилләренеке генә түгел, гади гладиаторларның да бер-берсенә эндәшүләре, репликалары бик күтәренке, урыны белән хәтта һавалы. Автор бу стильгә ирешү өчен җөмләләрне махсус катлаулы итеп төзи, инверсияләр ясый, кабатлауларны, купшы сүзләрне мул куллана.

Инде «Муса Җәлил»гә килик. Монда, киресенчә, сүзләр дә, аларның әйтелеш формасы да гади-гадәти, тормышчан. Ситуацияләр дә, гәрчә сугыш чоры һәм әсирлектәге искиткеч катлаулы мохитне чагылдырсалар да, «Спартак»тагы кебек артык дәһшәтле түгел, аларның реаль җирлеге нык. Ләкин әсәрне трагедия жанрына кертеп карарга мөмкинлек бирә торган сыйфатлар болар түгел. Сәхнә әсәренең төрен-жанрын ачыклауда, мәгълүм булганча, беренче планга конфликт һәм характер куелырга тиеш. Шул яктан килеп караганда, авторның үз әсәрен «трагедия» дип атавы белән, һичшиксез, килешергә кирәк. «Муса Җәлил»дә 20 гасырның олы фаҗигаләреннән берсе—миллионлаган кеше гомерен кискән, йөз меңләгән шәһәр һәм авылларны җир йөзеннән юк иткән икенче бөтендөнья сугышы чагыла. Шушы олы фаҗига талантлы шагыйрьнең иртә өзелгән гомерен, аның соңгы көннәрен

сурәтләү аркылы күрсәтелә. Язмыш тарафыннан зур сынау алдына куела шагыйрь. Ләкин әсирлектә, фашизм кебек дәһшәтле ерткыч алдында, үзенең үлемгә дучар ителүен белә торып та, ул коллыкны түгел, көрәшне сайлый. Нечкә күнелле, кешеләрне һәм тормышны сөя торган, азатлык идеалларына бирелгән шагыйрь—үлемгә дучар! Әле кемнәр аны үтерәләр диген?! Иң адәм актыклары—фашистлар! Моннан да олырак фаҗига, моннан да тетрәткечрәк хәл булырга мөмкинме соң?! Ләкин шул хәлгә таргач та, Спартактан аермалы буларак, Муса Җәлил иртәгәсе көнгә ныклы ышаныч белән карый, илебезнең җинүенә шикләнми. Нәкъ менә шул моментта яңа трагик герой туа, һәм ул традицион трагик геройдан аерыла. Драматург моның белән генә дә чикләнми. Ул башка персонажларның да, аерым алганда, тискәреләренең дә фаҗигале язмышын тиешенчә сурәтли. Бу яктан бигрәк тә чит-ят җирдә үз туган җирен сагынып сызланган Газизә карчык һәм Ватансыз, милләтсез калган Фердинандның кызганыч образлары характерлы. Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Илстан, Гөлгенә, Янгир кебекләрнең гомер юлы палачлар кулыннан өзелсә дә, әсәр азатлык сөйгән кешеләр белән горурлану тойгысы уята. Шуның белән ул оптимистик фикерләр уздыра.

Әсәрнең жанр үзенчәлекләрен ачыклауны көчәйткән тагын да бер як бар. Хәрәкәтнең эчке киеренкелеге көчле, нәкъ менә трагедия жанры таләп иткән дәрәҗәдә. Әсирләрнең яшерен эш алып барулары, тигезсез көрәше, минут саен, сәгать саен үлем куркынычы астында йөрүләре шушы киеренкелекне тудыра. Әйе, «Муса Җәлил»—татардагы беренче оптимистик трагедия!

Сәхнә тормышлары озын, сәнгати эшләнешләре җәһәтеннән югары кимәлдә булулары ягыннан Н. Исәнбәтнең комедияләре аерым игътибарга лаек. Алда «Хуҗа Насретдин» комедиясе турында сүз булды. Яки менә «Һиҗрәт» комедиясен алыйк. Аның үзенчәлеге совет идеологиясен, сыйныфлар көрәшен чагылдырудан гыйбарәт кебек. Байлардан, дин әһелләреннән көлү, акларны мыскыллау... Әмма бу беренче карашка гына шулай. 21 яшьлек автор язган әсәр гражданнар сугышы елларындагы халык тормышының комик-сатирик чагылышын бирә. Чөнки бу сугышта каракаршы торган кешеләр арасында, бер якта, үз иманына тугрылар, намуслылар, икенче якта, бары тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучылар, ялагайлар, койрыксыз-җилкәнсезләр, комсызлар да булган. Драматург нәкъ менә соңгыларын бер урынга җыя, интрига оештыра, шунда аларны, алардагы кимчелекләрне мыскыл итә, андыйларга карата нәфрәт тәрбияли.

Рәсми большевистик идеология «бәхетле, шатлыклы тормышка күчтек» дип раслаган совет шартларында да кимчелекләр күп иде. Аларны беренчеләрдән булып, К. Тинчурин һәм Ф. Бурнашлар белән янәшә торып, Н. Исәнбәт тә күреп алды, камчылады. Андый кимчелекләрне, юньсезлекләрне, гарип рухлы кешеләрне сурәтләү өчен 20 нче елларда материалны драматург НЭП елларыннан, көндәлек хәлләрдән ала. Яшь Совет дәүләтендәге мәгънәсез мавыгулар, нәтиҗәсез чаралар (осовиахим, добрармия, заём кампанияләре, дингә каршы көрәш һ. б.) авторның «Культур Шәнгәрәй», «Пикүләй Шәрәфи», «Портфель» кебек комедияләрендә көлү объекты булып тора. Аларның аерата соңгысы уңыш казанып, сәхнәдә озак яшәде.

Бу әсәрләрдә советның беренче елларындагы хәлләр, искедән яңага күчү чорына эләккән кешеләр үзәктә торса, «Зифа» комедиясендә язучы Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорны гәүдәләндерә. Әсәр Татар дәүләт академия театрында уйналып, сәхнәдә күренекле вакыйга булды. Совет тәртипләре инде ныклы, дөресрәге, көчләп урнаштырылган. Пьесадагы вакыйгаларда совет тәрбиясе алган кешеләр, «социализм төзибез» дип ышанган буын вәкилләре катнаша. Инде аларда кимчелекләр булмаска, һәрхәлдә, азрак булырга тиеш кебек. Юк шул. Кимчелекләр бар: әхлак тәрбиясендә, гаилә мөнәсәбәтләрендә, хатын-кызга карашта, акыл хезмәтенең әһәмиятен аңлаудатәрбияләүдә... Шуларны кызыклы һәм җанлы итеп, югары сәнгатьчә сурәтләве белән «Зифа» сугыш чорында һәм сугыштан соңгы елларда сулуга тәмам йөз тоткан татар комедиографиясендә асыл таш кебек ялтырады.

Башкортстанның халык шагыйре, Н. Исәнбәтнең кордашы һәм аркадашы Сәйфи Кудаш шулай дип язган иде:

«Толпар чапканда, шоңкар очканда, ә егет шашканда (ягъни аптырап калган чагында) сынала һәм чыныга, диләр казакълар. Бу биеклеккә үрмәләгән чакта Нәкый Исәнбәткә авыр юлда тоягы кителгән тулпар, канаты каерылган шоңкар хәленә калырга туры килгәләсә дә, ләкин иң авыр шартларда да шашкан егет хәленә калмады. Чөнки ул хезмәттә кайнап чыныккан... көрәштә җинәргә өйрәнгән һәм авырлыкларны буйсындырырга гадәтләнгән иде. Чөнки бөекләр биеккә башкалардан күтәртеп, этәртеп менмиләр. Таудай йөк күтәреп, кырмыскадай үзләре тырышып үрлиләр».

Әйе, Н. Исәнбәтнең тормыш һәм иҗат юлы такыр гына булмаган, аңа авырлыкларны күп күрергә һәм татырга туры килгән. Үзенең әйтүенчә, ул—тугыз үлемнән калган кеше. Сәнәкчеләр күтәрелеше вакытында аның баш очында кылыч аз уйнамаган. Ике абыйсын үтереп ташлаган кешеләр шагыйрьнең дә җанын кыярга бик ашкыналар, әмма теләкләренә ирешә алмыйлар... Инде житлеккән, танылган язучылык чорында да кыенлыклар очрап тора. Аерым алганда, Н. Исәнбәтнең рәсми оешмалар белән мөнәсәбәте күп вакытта киеренке булды. Партия функционерлары аның популярлыгын чикләргә тырыштылар. Әдип совет тәртипләренә тискәре мөнәсәбәтен үзенчәлекле төстә чагылдыра да алды. Мәсәлән, үзенең 70 яшен бәйрәм итү тантаналары житкәч, ул демонстратив рәвештә Уфага китеп барды, тантаналарда катнашмады. Бу аның хезмәтләрен бастыруга каршы корылган киртәләргә үзенчә реакциясе, аларны кабул итмәве, шуларны яклаган органнарга протесты иде булса кирәк. Әйе, бу—язган әсәрләрен, эшләгән хезмәтләрен вакытында һәм тиешенчә күрсәтеп булмауга, әнә шундый җинаятьчел битарафлыкны «юбилей тантаналары» дигән ялтыравыклы пәрдә белән алыштырып каплап куюга каршы килүнең бер чарасы иде. Мондый «башбаштаклыкны» урындагы партия оешмалары озак вакытлар онытмады. Мәсәлән, Н. Исәнбәт иҗатын диссертация темасы итеп биргән өчен, ул вакыттагы Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренә, диссертантның фәнни житәкчесенә шактый шелтә сүзләре ишетергә туры килде. Әмма да, ничек кенә булмасын, Н. Исәнбәтнең искиткеч талантын танудан, аның үлмәс әсәрләренә тиешле бәя бирүдән башка чара юк иде. Әнә шундый шартларда да: ул Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары белән бүләкләнде, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән дәрәжәләргә, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты дип танылуга лаек булды. Һәм, ниһаять, аңа, чын мәгънәсендәге халыкчан язучыга, «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исем дә бирелде!

Кешелек тарихында гаять көчле иҗтимагый тетрәнүләре, көчешләре-үзгәртүләре, фаҗигаләре, рухи югалтулары һәм техник казанышлары белән кереп калган 20 гасыр тавына Нәкый Исәнбәт бик зур йөк алып менде. Бу—аның үлмәс мирасы. Әлеге мирасны тагын да тирәнрәк һәм җентекләбрәк өйрәнү безнең бурычыбыз булып кала бирә.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН**

# СИНЕҢ САЗЫҢ ДӨРЕС УЙНАДЫ

*Моннан 17 ел элек, Нәкый ага Исәнбәтнең үлеме хәбәрен ишеткән сәгатьтә теркәлгән язма бу. Үлем-китем көннәрендә мин аны беркая да бирмәдем,шуңа күрә көндәлек матбугатта күренмәде дә. Язмада импульсивлык, чарасызлык, гаҗизләнү (әлбәттә, шәхес өчен горурлану да) сизелеп тора. Хис—фикердән алдарак җилдерә кебек. Автор, сулышы капкан кешедәй, бик күпне тиз генә әйтергә теләсә дә, әйткәне тирән һәм салмак ритмда чыкмый. Вакытын, вакыйгасын искә алсаң, бу хәл табигый да дыр... Әдипнең юбилее уңае белән шул язманы укучыларга тәкъдим итәм.*

Нәкый ага вафат...

Үлем дип аталган Илаһи Кара Канатның башларыбыз өстеннән сискәндереп үтәсен сизенгән булсак та, без аның килеп җитәсенә әзерләнеп җитмәгән булганбыз икән... Җан өшеткеч бу хәбәрне ишеткәндә без—бер төркем каләмдәшләр—Язучылар йортында идек. Мәһабәт бинаның (хәзерге Мөштәри урамы, 14) ишегалдында мәш килеп кино төшерәләр. Без тамаша кылып кырыйдан карап торабыз. Сәер очрак: кызык та, кызганыч та. Тирә-якта ясалма төтен, янгынчыларның кызыл машиналарыннан сиптерелгән ясалма янгыр, актерларның (күбесе Н. Исәнбәт спектакльләрендә каһарман рольләрен уйнаган артистлар) ясалма киемнәре, ясалма көлу-елмаюлары... һәм Бөек Шәхеснең фани дөнья белән саубуллашу мизгелләре...

Төтен... Ясалма янгыр... Тотрыксыз сәясәт... Ә чыны—күз. Сирәк була торган кояшлы, җылы көз татарның Бөек улы Нәкый Исәнбәтне (чын фамилиясе—Закиров) мәңгелек юлга озатырга үзенчә әзерләнгән кебек. Тирә-юньдә монсу олпатлык... Шәфәкъ тоташкан шәмәхә кызыллык...

Нәкый аганың, һәр олуг шәхеснеке кебек, тормыш һәм иҗат юлы фаҗигаләр һәм тантаналар белән үрелеп барган. Яшьлек хыялларындагы бөеклеккә үрләткән биеклекләр дә, күңелдә җәрәхәт калдырган абыну-егылулар да; кыерсыту-әзәрлекләүләр дә (заманында КПСС ҮК ул әзерләгән «Идегәй» дастанын тыюга исәпләнгән махсус карарны тикмәгә генә чыгармаган инде!); олы язучы булып саналган елларда кочегар—мич ягучы, ишек алды себерүче кебек тузанлы-корымлы кара эшләрдә йөрергә мәҗбүр булулар да, алкыш һәм чәчәкләргә күмелеп (аның пьесалары буенча куелган кайбер спектакльләр зур сәхнәләрдә берничә мең мәртәбә уйналган!) данда тибрәнүләр дә... Барысы да булган.

Нәкый Исәнбәт—тарихи фигура. Андыйлар сирәк. Табигатьнең асыл заты буларак, дөньялыкта үз миссиясен аңлаган кеше. Халык рухының, халык иҗатының энҗеләрен такыя кебек үреп, килер буыннарга тапшырган зат. «Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгы үзе бер бөек хезмәт. Күләмле кереш сүзе генә дә әллә ничә диссертациягә торырлык. Һәр татар кешесе бу хезмәтләр белән танышып, аны җанына сеңдерсә, без Җир йөзендә бик абруйлы милләт булыр идек... Ә ул төзегән сүзлекләр? Татар әдәбияты һәм мәдәнияты тарихы турында күләмле хезмәтләр? Кызганыч, аларның байтак өлеше әлегәчә дөнья күрмәгән. Ул төзегән «Идегәй» дастаны—үзе бер эпопея. Зур шәхесләр төрле яктан талантлы була шул. Ул—энциклопедик белемгә ия галим, драматург, шагыйрь. «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың», «Илкәем» кебек җырлары гына да ни тора!

Күптән түгел аның 90 еллык юбилее булып узган иде. Тантанада ул үзе катнаша алмады. Кадер-хөрмәт күрсәтеп бирелгән бүләкләрне, «иясенә тапшырырмын» дип, улы Празат Исәнбәт алган иде... Хәзер инде аңа бер нәрсә дә тапшырып булмый. Үзен генә Җир куенына тапшырырга кала... Сүз җаеннан әйтәсе килә: юньледән юньле нәсел кала. Нәкый аганың улы Празат—татар театрының олуг режиссеры, хикмәт иясе; кызы Йолдыз—татар музыка сәнгатенең зур белгече, сәнгатькяр кеше...

Үзеннән соң эшеңне дәвам итүчеләр булу—үзе зур бәхеттер.

Газраилга һәркем тигез. Аңа патша ни дә, мәхлук кол ни! Туганбыз икән, һәммәбез бер юлда, чакрым баганалары гына төрлечә... Әмма һәр Бөек мизгел-акт тетрәндерә: ми генә түгел, бөтен тән кымыржып куырылып ала кебек. Зур Кеше китеп бара. Аны кем алыштырыр? Әлбәттә, беркем дә алыштыра алмас. Шулай да, Хәтерле кешеләр—яшьләр аның эшен дәвам иттерә алалар. Тиешләр. Һәммәбезгә онытмаска иде: ул үзе яшәгән чордагы татар халкының рухи анатомиясен язып-күрсәтеп китте. Үзенә күрә бер күрсәтмә-харита...

Без бу арада митинглар шаукымында яшибез. Гомер үткәч, бу еллар гаҗәеп еллар булып искә төшәр әле! Татар соңгы ничә гасырдан соң үзен «Дөньяда без дә бар!» дип күтәрелеп чыкты, үз тавышын ишеттерә башлады. Ә каян килә соң бу уяну, бу күтәрелеш? Әлбәттә, Тукайлардан, Исхакыйлардан, Нәкый ага Исәнбәтләрдән! Ул, хәл-вәзгыятьне тирәннән аңлауда, замандаш һәм хаким зат буларак, дәүләтчелекне (ата-анасыз йортта тәртип булмый ул!) торгызу юлындагы хәрәкәттә төп фигураларның берсе иде. Таяну нокталарыннан тора бу Дөнья!

Нәкый Исәнбәт вафат. Шул сәбәп белән хисләнеп уйлануларым болар. Менләгән бүтән милләттәшләребезнең фикерләре, бәлки, бүтәнчәрәктер. Тирәнрәктер... Уртак максат юлында барганда һәр нәрсә аклана. Хәтта үлемне дә аңлап була кебек...

...Казан уртасында кино төшерәләр. Литфонд егетләре җеназа хәстәрләре белән йөри. Без, бу сәгатьтә конфузия алган кешеләрдәй гаҗизләнеп, Казан уртасында басып торабыз. Бөек кеше китә. Тарихның асыл бер сәхифәсе ябыла.

Безгә, әлегә исән-сау, сәламәт егетләргә, тамаша кылып торырга гына түгел, саф башындагыларның әләмен алга—алгарышка илтергә кирәк. Бүтән юл юк.

Рухың тыныч булсын, Бөек Татар Улы!

*1992, 15 сентябрь. Казан*

**P. S.** ***Әйе, бу уйлану–мәрсияне язганнан соң байтак вакыт үтте. Бу елларда Нәкый Исәнбәткә бәйләнешле нинди вакыйга–хәлләр булган, аның иҗатын мәңгеләштерү юнәлешендә ниләр эшләнгән, язмамда хисләнеп әйтелгән теләк–юрамаларның күпмесе тормышка ашкан?***

***Беркадәр эш башкарылган. Кайберләрен әйтеп узыйк: әдипнең 100 еллыгы уңае белән (1999) Камал театрында исталек кичәсе үтте. Монысы табигый хәл. 2000 елны 30нчы елларда Н. Исәнбәтләр гаиләсе торган йортка (Мөштәри урамы) мемориаль такта куелды. 2005 елда тыкрык сыман бер урамга (элеккеге Революция урамы. Бер башы Гвардейская урамына тоташа) әдип исеме бирелде. Сирәк кенә булса да (нигездә, төрле юбилейлар уңаеннан) сәхнәдән яки экраннардан спектакльләр күренгәләп ала... Кызганычы шул: соңгы 20 ел эчендә әдипнең әсәрләре басылмады диярлек. Кемгә ничектер, миңа Н. Исәнбәт иң әүвәл бөек галим, фольклорчы, сүзлекләр иясе буларак кадерле. Сүзлекләр җыелмасы—һәр халыкның иң төп рухи байлыгы. Заманында актуаль һәм популяр булган кайбер әсәрләр, әйтик, пьесалар еллар узгач төссезләнергә, әһәмиятен җуярга да мөмкин. Н. Исәнбәт туплаган 3 томлык «Татар халык мәкальләре»—ул үлемсез хезмәт. Беренче чиратта әнә шул хезмәтне (ул 1959–67 елларда төрле тиражда басылды, хәзер инде сирәк очрый торган библиографик басмага әйләнде) халыкка кайтарасы иде! Моны эшләү әдипнең шәхесен мәңгеләштерү юлында конкрет гамәл, үзенә күрә бер һәйкәл салу булыр иде. Моннан 20 ел элек, безнең журналда басылган әңгәмәсендә әдип болай дигән иде: «Сынатмаска кирәк, җегетләр!» Чыннан да бөекләрне онытмаска, сынатмаска кирәк безгә!***

*2009, 7 ноябрь. Казан.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре.*

# ШИГЪРИ ҖАН АҺӘҢЕ

Күренекле әдәбият белгече, мәгърифәтче-педагог, фольклорчы, филология фәннәре докторы, Казан университеты профессоры Марсель Бакиров үзенең 75 яшен халык күнеле җәүһәрләрен—мифларын, әкиятләрен, җырларын, бәетен, хушавазларын—янача шәрехләгән «Татар фольклоры» *(«Мәгариф», 2008 ел)* исемле хезмәте белән каршылады. Югары уку йортлары студентлары, укытучылары, гомумән милли рухлы укучылар өчен язылган бу китап белән хозурланып та, дусларча көнләшеп тә танышып чыккач, уйга талдым: ошбу тикшеренүгә хас булган заманча фикерләү, мәгънәви тирәнлек, бормалы, сыгылмалы, катлаулы вә ягымлы өслүб, композиция өлкәсендәге ачышлар, аңлаган кеше өчен төртмәле фаразлар турында төпле сүз әйтүе җинел түгел. Аннан килеп, фольклор белән шөгыльләнүче галимнәр үз өлкәләренә кысылганны яратмыйлар, тәнкыйть сүзе әйткәндә дә, үзләре генә аңлаган эзоп теленә өстенлек бирәләр.

Заманында аркама биштәр асып, Илбарис абый Надиров җитәкчелегендә халык иҗаты үрнәкләрен җыеп, мәшһүр фольклорчы Хәмит Ярми җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясе язып йөргән, халык иҗатының татар шигърияте үсешенә ясаган уңай тәэсирен шәрехләгән хезмәтләрем искә төшкәч, «Татар фольклоры» китабы турында фикерем белән уртаклашырга хакым бардыр дигән нәтиҗәгә килдем.

Сүз дә юк, «халык иҗаты» дип аталган изге мирасыбызны гыйльми өйрәнү, атамалар, нәзари фикерләр, сәнгатьчә матурлык, тел, сурәтләү чараларын күзаллау, аңлату тарафларыннан фольклор фәнебез нык алга киткән. Анда эчтәлек сөйләүне, социологик анализны, сәяси бәяләүләрне гомумкешелек ихтыяҗларыннан алга кую, матурлык һәм миллилек нокталарыннан килеп өйрәнергә тырышуның өстенлек алуы сизелә. Дәреслек буларак тәкъдим ителгән бу хезмәттә М. Бакиров алдында катлаулы бурыч торганын онытырга ярамый. Ничек һәм ни рәвешле фәнни-нәзари дәрәҗәгә хилафлык китермичә, халык иҗаты фәне белән бөтенләй диярлек таныш булмаган кеше дә рәхәтләнеп укырлык, шул ук вакытта «халыкның мон-зарын, киләчәккә өметен» чагылдыра дигән сүзләр кебек примитив баскычка төшмичә, тиешле югарылыкта кала алырга? Алгарак китеп булса да, әйтик: бередә автор академик белән студент, язучы белән балыкчы, балта остасы белән сыер савучы күңелләренә дә хуш килерлек фәнни тәгълиматларны күп санлы мисаллар белән раслау аша һәммәбез өчен файдалы китап чыгарган.

«Көнләшеп» укыдым дип әйтүем дә тәти сүз өчен генә түгел. Яхшы мәгънәсендә фәнни кимәлдә ярышу, Сибгат Хәким әйтмешли, бер-беренә төрткәләп тору, үпкәләшмичә, дөресен әйткән өчен ачу тотмыйча, этикет саклап аралаша белү—мәдәнилек белән зыялылыкның бер күрсәткече. М. Бакиров фәннилеккә зарар китермичә, вакыты белән сәясәтче-дипломат мантиясен киеп алса да, үз фикерен яклаганда энәләрен тырпайтып куюдан да тартынып тормый. Җөмләдән, озак еллар дәвамында борынгы төрки шигырен, бигрәк тә Орхон-Енисей ташъязмаларын бәяләүдә И. Стеблева фикере соңгы гыйльми сүз булып бәяләнә килде. М. Бакиров исә җиңүчегә каршы мәйданга чыккан батыр кебек күренекле тюрколог белән бәхәскә керә, бу борынгы язмалардан шигырь эзләү, аның төзелеш системасын билгеләргә тырышу урынсыз, ритмик буыннар сизелгәләсә дә (әйтик, нәсердәге шикелле) алар чәчмә белән язылган ядькярләр дип исбатлый.

Һәр милләтнен рухи мирасында мөһим өлешне халык авыз иҗаты алып торуы бәхәссез. Ул—соклангыч эчтәлекле, сәнгатьлелек ягыннан гаҗәеп бер казаныш, һәр халыкның горурлыгы һәм кабатланмас үзенчәлеге. Бездә фольклорны җыю, гамәли вә фәнни өйрәнү эше даими алып барылса да, бу байлыкның фәлсәфи-эстетик бөеклеген, үлемсезлеген ачып, гыйльми тикшеренүләрнең перспективасын билгеләгән һәм уку йортлары өчен дә дәреслек булырдай бер житди хезмәткә ихтыяҗ сизелә иде. М. Бакировның әлеге хезмәте бу җәһәттән сөенечле күренеш булды.

Дәреслек традицион калыпка нигезләнгән булып, жанрлар әзеннән барса да бирелеш рәвеше, фәнни һәм шул ук вакытта образлы теле, күнегелгән стереотиплар «тәртәсенә» дә типкәләп үтүе белән янача, заманча фикерләү җимеше булып кабул ителә. Кыска, әмма мәгънәле керештән соң, автор тарихка сәяхәт ясап, фәннең бу тармагын үстерүгә өлеш керткән фидакарьләргә үзенең тирән ихтирамын белдереп уза. Гадәттә галимнәр теге яки бу фәннең өйрәнелү тарихына тәфсилләп тукталырга яраталар. М. Бакиров исә халык авыз иҗатын өйрәнүнең олы һәм бай тарихын, берәүне дә рәнжетмичә, 4-5 биткә сыйдырган да куйган. Күмәк хезмәтнең беренче үрнәкләре М. Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә үк күренә башлап, ошбу җәүһәрләрне туплау, бастырып чыгару XIX гасырның беренче яртысында башлана (П. Рычков, И. Лепехин, Г. Балинт һ. б.) , XIX йөзнең икенче яртысыннан бу изге эшне М. Иванов, С. Кукляшев, К. Насыйри кебек татар мәгърифәтчеләре үз кулларына алалар, «татар фольклористикасына аерым фән буларак нигез салыну да шушы чорга туры килә»,—дип нәтиҗә ясый галим. Катлаулы фәнни тәгълиматларны автор хәтердә калырдай мисаллар белән үреп бара. Татар җырларын язып алган фин тюркологы Х. Паасонен фольклорыбызның лирик төренә хас мәгънәви тирәнлек, сурәтлелек байлыгы аның, тәэсир көче белән соклануын яшерә алмаган икән. XX йөздә Г. Тукай, Г. Рәхим, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов кебек бөекләребез дә халык иҗаты үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур әһәмият биреп, алар турында күңел түрләреннән ургылып чыккан жылы, тирән мәгънәле фикерләрен әйтеп калдырганнар. Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Г. Сәгъди кебек фидакарьләребез халык иҗатын өйрәнүне башка шөгыльләре белән бергә алып барсалар, үткән гасырның уртасыннан бу тармакка татарның беренче профессиональ фольклорчысы Хәмит Ярми килә. Шулай шул: ихтыяҗ үзенә лаеклы, кирәкле талантны табып ала ул. Әйтик, XX йөз башындагы иҗтимагый-сәяси вәзгыять татар шигыренә ислах (реформа) кирәклекне, аның реализм юлына чыгуын таләп итә. Ходай Тәгалә милләтебезгә шул изге бурычны үти алу сәләтенә ия булган олуг шәхесне, камил инсанны—Тукайны—җибәрә. Сонрак вакыт һәм зарурият Х. Ярмине дә Себердән «эзләп табып», ана халык иҗатын җыю һәм популярлаштыру эшен «куша». Ә бу галим үзенә алмашка И. Надиров, Ф. Әхмәтова, Ф. Урманчиев, Х. Мәхмүтов кебек яңа буын фольклорчылар «кавемен» үстереп калдыра. М. Бакиров урынлы билгеләп үткәнчә, нәкъ менә алар төзеп, нәшер иткән 12 томлык җыентык (1976—1988) Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Киләчәктә фольклор мирасыбызның 25 томлыгын һәм рус телендә 15 томлыгын чыгару буенча житди эш алып барыла икән.

Бу китапта халык иҗатының аерым жанрларын өйрәнүгә керешер алдыннан автор әлеге рухи байлыкларны якынлаштырган гомуми методологик аспектка тукталa. «Башка халыклардагы кебек, татар фольклорының киң тармаклы жанрлар системасы да, һичшиксез, чынбарлыкны мөмкин кадәр тулы һәм күпъяклы итеп чагылдыру ихтыяҗыннан барлыкка килә». Димәк, җиһанның барлык халыклары да якты айны, иртәнге чыкны, яфрак лепердәвен, тирә-юньгә ак каендай ямь сирпеп торган кызлар матурлыгын, кара урманнарда, далаларда, җир асларында югалып калмый торган гаярь егет кичерешләрен, ил картының уй-теләкләрен бер төсләрәк аңлый, образлар ярдәмендә әйтеп бирә икән. Шул ук вакытта һәр халыкның үзен чолгаган табигать (бер якта буран дулый, икенче төбәк халкы эсседән әлсери), иҗтимагый-сәяси система (мөстәкыйльлеге, дәүләтчелеге булу, булмау) белән бәйле үз кабатланмас жанрлары бар. Татарның да үткәненә, фаҗигасына сизгер, шуна бәйле рәвештә хәл-әхвәлләргә мөнәсәбәтен белдергән бәет белән мөнәҗәт жанрлары яши. Әлбәттә, һәр халыкның милли үзенчәлеге, тел аша чагылган менталитеты,

сурәтле фикерләве миф, әкият, жыр, мәкаль-әйтем кебек фольклорның төп, табигый жанрларында да үзенә генә хас үзенчәлекләре белән чагыла. Татар кешесе әнә шуна күрә үзенчә моная, сызлана, әрни, үзенчә шаярта, төрттерә, шомарта.

Авторның нәзари карашлары төпле, уйланылган. Галим, мәсәлән, мифларны уйдырма хыял җимеше дип кенә бәяләүне ялгыш һәм наданнар фикере дип кире кага. «Мифларга ыруглык җәмгыятенең дөньяга карашлары системасы һәм борынгы төре буларак, галәмне, тирәлекне үзләренчә аңлату, танып белергә омтылу функциясе хас»,—ди автор 21 биттә. «Мифларның икенче функциясе—табигатьтә һәм кешелек җәмгыятендә урнашкан тәртипләрне саклау» гына да түгел икән. «...Һәр халык үзенең мифологиясендә кабаттан һәм яңабаштан үз тарихын кичерә» дигән гөманы мина әдәбият белән фольклор әсәрләре арасындагы якынлыкны аңлауга ачкыч кебек тоелды. «Яңабаштан үз тарихын кичерә»—бөек Тукаебыз «Шүрәле», «Су анасы» кебек табигать ямен, аның «җанын» ачып бирергә омтылып, мифологик катлам ярдәмендә кеше асылына, зиһененә дан җырлаган сәнгатьчә нәфис әсәрләрен иҗат иткән. Шагыйрьнең тарихка мифологик ышанулар аша килүен шул чорда ук олуг тарихчы З. Вәлиди дә хуплап чыга. (Мәктәп.—1913.—№4.—118 б.):

*Зур бу урман: читләре күренмидер диңгез кеби;*
*Бинийая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби,*

—дигән бит шагыйребез.

XX гасырның соңгы чирегендә татар прозасында, драматургиясендә (Г. Гыйльманов «Албастылар», Ф. Бәйрәмова «Алыплар илендә», М. Гыйләҗев «Бичура» һ. б.) мифологик образларга, мотивларга мөрәҗәгать итүнең нигезендә дә тарихыбызны яңадан кичерү аша бүгенге халәтебезне аңларга һәм аңлатырга омтылу нияте ята, күрәсең.

Диннәрнең, дини-мифологик атамаларның килеп чыгуына, таралуына да авторның үз карашы бар. Бер мисал китерик. Идел-Урал киңлекләрендә яшәгән төрки кабиләләрнең борынгы ышануын-динен белдергән «Тәнре» сүзенең килеп чыгуы галимнәр арасында әлегәчә бәхәс уята. Якут галиме Н. К. Антонов аны «таң—ир(е)» дип аңлатса, Н. Фәттах бу сүзне «таң—*ра*» (таң алласы) дип шәрехләсә, М. Бакиров исә аны тавыш-яңгырашны белдергән *«таң/тең/тәң»* тамырыннан ясалган дип фаразлый. Минем күңелемә Антонов аңлатмасы якынрак тоелса да, М. Бакировның эзләнү-уйланулары хуплауга лаек, киләчәк эзләнүләр хакыйкатьнең кем ягында икәнен күрсәтер.

Героик һәм тарихи дастаннарда да татар халкының бай һәм олы тарихы турыдан-туры, нәкъ шулай булганча гына чагылыш тапмый, «Түләк—Сусылу», «Йиртөшлек», «Алпамша», «Ак көбәк» кебек әсәрләрдә халык үткән юл читләштерелеп, киная һәм шәхес язмышына бәйләп сурәтләнә, хәтта чын тарихка иң якын саналган «Идегәй», «Чура батыр» кебек дастаннарда да Алтын-Урда һәм Казан ханлыгы оешу, чәчәк ату, юкка чыгу тарихы төрле өстәмә сюжет, көнитеш, мәхәббәт мажаралары белән үрелеп бара. Иҗатчы—халык урын-вакыт, фактлар, еллар, айлар, каһарманнарның исемнәре дөреслеккә туры килү-килмәү белән артык санашып тормаган. Әмма бу әсәрләр татар дәүләтләренең ваемсызлык, хөсетлек, комсызлык, икейөзлелек, хаким сыйныфларның байлык артыннан куу кебек тискәре сыйфатлары аркасында юкка чыгуларын ачынып, гарьләнеп, сабак алыгыз дип ачып бирәләр. Тарихи хакыйкать белән сәнгатьлелек вакыйга-хәлләргә икесе-ике яктан килеп «мөһер сугалар» дип аңлата М. Бакиров. «Идегәй» дастанында катнашучыларның «артларында торган» тарихи затлары азмы-күпме ачык булса, Чура батырның сурәтчәсен ачыклау шактый мәшакатьләр тудыра. «...кем булган соң ул Чура батыр, аның конкрет прототибы булганмы? Фольклорчыларның һәм тарихчыларның кайберләре (мәсәлән, Ф. Урманчиев, Л. Ибраһимова һәм Д. Исхаков) бу сорауга уңай җавап бирәләр һәм әлеге каһарманга өлге-прототип ролен үтәгән шәхес Казан аксөяк-бәге Чура Нарыков булган дигән карашта торалар: хәтта һәр төрки милли версияләренә дә шул шәхес өлге итеп алынган дип исәплиләр». М. Бакиров бу карашның татар тарихын өстән-өстән генә өйрәнү нәтиҗәсендә туган ялгыш, хата караш дип, Чура батыр белән

шул ук исемне йөртүче Нарыковның икесе ике шәхес кенә булмыйча, беренчесенең бөтен көчен, гомерен рус баскынчакларына каршы көрәшкә биреп, икенчесенең, киресенчә, рус князләре кубызына биеп, Мәскәү яклы фирка оештыручыларның берсе булуын, әлеге сатлык җанның Казан ханы тарафыннан үтерелүен исбатлый. Хакыйкатьне аклауда, дөреслекне яклауда галим принципиаль полемист, ул унга-сулга гайрәт чәчә. Аның өчен үз халкының мәнфәгатьләре белән яшәгән һәр зат—изге, яшәеш үрнәге. Шул чорда яшәсә Марсель үзе дә үткен кылычын кулына тотып, дошман өстенә ташланыр иде дип уйлап куясың. Юк, галим үз нәгъррәләрен хискә бирелеп кенә ормый, ә реаль чыганакларга, *«Казанская история» (М.—Л., 1994)*, В. Похлебкинның *«Татары и Русь» (М., 2005)*, Һ. Атласи, М. Әхмәтҗанов, И. Измалов кебек галимнәрнең фикерләренә таяна. Тирән анализ нәтиҗәсендә ясалган йомгагы да ышандыра: «Чура батыр» дастанын тикшерергә алынган фольклорчылар, эклектизм юлына басып, әлеге текстның берьюлы ике өлешенә, ягъни ике версиясенә дә таяналар һәм, фикерләрен кат-кат үзгәртә-үзгәртә, «билгесезлекне билгесезлек» аша исбатларга тырышалар». «Кыскасы,—ди М.Бакиров,—халык иҗатының аерым үрнәкләрендә Чура батыр образы белән сатлык җан Чура бәк шәхесе бер-беренә капма-каршы куеп тасвирлана». Кайбер фольклорчылар, тарихчылар беренчел чыганаклар белән эш итү мәҗбүриятен онытып җибәрәләр икән.

М. Бакировның галим буларак иң көчле ягы: күпләрнең теше үтми торган өлкә—шигырь теориясе, төрки-татар тезмә сәнгатенең килеп чыгу, яшәеш үзенчәлекләрен, метрикасын, строфикасын, рифма-ритм хасиятләренең кабатланмас билге-сыйфатларын—ачыклау, шул ук вакытта фольклордан башлангыч алучы сәнгати образлар, сурәтләү чараларын һәм иң борынгы тезмә жанрлар системасын тарихи поэтика һәм шигъри үсеш яссылыгында тикшерү, киләчәк перспективаны билгеләү. Инде үткән гасырның җитмешенче елларында ук ул, интуиция белән фаразга гына ышанмыйча, татар-төрки шигыренең төп кануннарын өйрәнүне төгәл фәннәрдәге шикелле үк, эксперименталь җирлектә алып барды. 1972 елда кандидатлык диссертациясенең нигезенә яткан *«Эксперименталь тикшеренүләр яктылыгында төрки һәм татар шигырь төзелеше закончалыклары»* исемле китабын бастырды. Бу эзләнүләрнең дәвамы буларак *«Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе»* (А. Яхин белән берлектә, 1981) һәм *«Шигърият дөньясына сәяхәт»* (1999) һәм әлегә тиешле бәясен алмаган капиталь һәм масштаблы фикерләве, офык киңлеге белән үтә кыю хезмәт *«Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары»* (2001) кебек китаплары нәшер ителделәр. Шул рәвешле ул татар шигыренең иң тирәндә, гасырлар түрендә яткан серләрен, чишмә башын эзләүгә гомерен биргән, бик күп тикшерүчеләр кылыч чәкештереп, уртак нәтиҗәгә килә алмаган проблемаларга нисбәтән үз карашын белдереп кенә калмыйча, фәнни табышмакны чишү юлларын да тәкъдим итә, аерым алганда, йола-мифларның поэзия бишеге булуларын исбатлап, татар шигыренең камилләшү, үсү чорында шактый катлаулы юл үтеп, интонацион-синтаксик системаны һәм силлабик ритмны иярләп, гарәп-фарсы телләре аша гаруз үлчәме кабул иткәнче үк, үзебездә «көчәйтелгән басымлы шигырь»нең мөстәкыйль юнәлеш алып, читтән кергән калыпны милли рух белән баетуын дәлилли.

Мифлар кебек үк борынгы, «баба» чорда ук туса да, рухы, кеше күңеленә якынлыгы белән һаман яшь, өлгер һәм хисси жанрның җыр-шигырь «җене» кагылган авторның игътибар үзәгендә торуы табигый. Бу жанрның төрле чагылышларын, эчке хасиятен, бизәкләү, юандыру чараларын өйрәнүгә И. Надиров, М. Нигъмәтҗанов, А. Яхин кебек өлкән буын галимнәре шактый көч куйган. Соңгы елларда К. Миннуллин бу юнәлештә актив эшли («Һәр чорның үз җыры», 1998; «Шигърият һәм җыр» 2004). Ирешелгәннәрне кабатламыйча, киресенчә, элгәрегеләрнең казанышларына таянып, М. Бакиров бу өлкәдә дә үз сүзен әйтә. Җыр мирасын автор кабул ителгән традиция буенча лирик һәм тарихи җырларга бүлеп өйрәнә. Җырның төп үзенчәлек-билгеләре нидән гыйбарәт соң? Аны башка жанрлардан аерып торган сыйфаты—универсальлек, ди галим. Чөнки, әкиятне, мәзәкне хәтерендә тотарга, сөйләргә маһирлыгы булмаса да, мәкаль-әйтемне, тапкыр сүзне кулланмаса да, һиндидер берәр куанычлы йә хәсрәтле халләр белән күңеленә сеңеп калган җыр сүзен, көен,

үзе өчен генә булса да, «мыгырдап» йөрмәгән, хозурланмаган кеше юктыр.

Физик хезмәт башкарганда, ял мизгелләрендә исә ана ихтыяҗ үзеннән-үзе туа. Сүзләрен, көен табучы, башкаручы кешенең кичереш дулкыны меңләгәннәрнең йөрәгенә илаһи нур булып үтеп, барысы өчен уртак уй-хисләрне сурәтле образга күчерә. Җыр чыгару хасияте кешегә тумыштан килә, яшәеш мохите, тормыш тәҗрибәсе аны үстерә, очкыннан ялкын көлтәсе күтәрелә. Җыр чыгаручы галәм, табигать, кан кардәшләре белән «син»гә күчеп серләшә. Анын йөрәге кичерешләр өермәсе өчен ачык. Сызылып таң атканны күзәтәме, ялан тәпи чыктан атлап киләме, гөлләрне чәчәк «аттырамы», кичләрен чибәр кызның оялчанлыгын хуплыймы—ул һәркайда матурлык, яхшылык, күркәмлек эзли. Җыр чыгаручы үзенең хисләре турында «мин» дип сөйләсә дә, шәхесне алга чыгармый, фәнчә әйтсәк, иҗатчы субъектын индивидуальләштерми. Шунар да «фольклор нәфасаты күмәк иҗат җимеше, халык күнеле акчарлагы», дип яза М. Бакиров. Шул ук вакытта лирик һәм тарихи җырларның каһарманы үзенчәлексез, затланышсыз шәхес түгел. Анын тәгаен социаль портреты җырларында, башка жанрларда яши. Менә ачык күренеп торган һәм галим күрсәткән сыйфатларның берничәсе.

Ул—үз милләтенә бирелгән халык баласы;

Ул—матурлыкка гашыйк табигать кыйпылчыгы;

Ул—заманның җан сыкравы авазы;

Ул—үз халкының үгет-нәсихәт, әхлак кагыйдәләренә турылыклы шәхес;

Ул—хыял дөньясында яшәгән гүзәллек алиһәсе;

Ул—галәм улы, мәңгелек кызы;

Ул—көрәшче, намуслы, риясыз зат;

Ул—икейөзлелекне, алдашу, шомарту кебек «житлеккән җәмгыять» кагыйдәләрен кабул итми, байлык артыннан кууны хупламый...

Милли рух халык җырларының һәр күзәнәгендә, тел берәмлегендә яшәсә дә, аларга башка халыкларны кимсеткән (кайбер шаян җырларны исәпкә алмаганда), тар милләтчелек хас түгел. Халык җыры, дөнья ваклыкларына бирешмәгән шикелле, сәяси бүленешләрне, дәүләт чикләрен дә танымый. Әйтик, совет чорында фирка, хакимият җитәкчеләрен мактаган җырлар гайре табигый, тозсыз булып чыктылар, халык андый «табылдыкларны» яки ясалмалыкларны кабул итмәде. Совет хакимияте чорында макталган «Кызыл көрәшчеләр бәете»нең сәнгати яктан йомшак, вакыйга артыннан «тагылып» баруга нигезләнгән ясалма әсәр икәнлеге бер укуда ук сизелә иде.

Халык җырларының мәгънәви офыклары ифрат киң. Анда яшәү белән үлем фәлсәфәсе, әдәп-әхлак нигезләре, әйбәт тормыш турында хыяллар, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, сөю-сөелү, уңышсыз мәхәббәт зарлары, ялгызлык әрнүләре шигъри юлларга агыла. «Мәхәббәт җырлары—халык лирикасының иң нәфис үрнәге, таҗы. Чөнки аларда кешенең иң югары, иң тирән, иң кадерле хисләре—мәхәббәт кичерешләре тасвирлана»,—ди галим. «Халыкның мәхәббәткә—сөюгә бәйләнешле эстетик идеалы инсани һәм демократик рухта: ул нәкъ менә саф һәм тиң, үзара тигез, турылыклы мәхәббәтне генә чын мәхәббәт дип саный»,—дип тәкърарлый ул. Җырның поэтикасына хас төп үзенчәлек итеп сәнгати вакыт-хронотоп алына. «Чөнки вакытның ничек гәүдәләнүе эчтәлекнең ничек ачылуына, әсәрнең поэтикасына зур йогынты ясый... Нәтиҗәдә җырның «мин»е, лирик герое да җырлаучы—башкаручы «мин»е белән бергә кушылып гәүдәләнә». Шул алымны арттыру, күперту һәм символлар көчәйтеп килә. Тормышның иң катлаулы низаглары бер караганда бик гади күренгән үлчәмгә, вәзенгә куела. Әмма җыр-бәетләрнең сыгылмалы, бормалы, бизәкле калыбына сыймаган фикер мәне, йөрәк тибеше юктыр! Җырның һәр күзәнәгеннән моң, сагыш саркып тора. Күбесе халык язмышын, фаҗигале тарихын тирәнтен тоюдан килә. Нәфис җанны ачуга сүз-тел гаять сизгер (күбесен нечкә күнелле хатын-кыз чыгарганы сизелеп тора). Болай караганда халык җырларының күпчелегенә хас 10-9, 8-7 үлчәмнәре бик гади күренсә дә, озын көйләр кушымта, кисәкчә, ымлык h. б. ярдәмче чаралар ярдәмендә сыгылмалы, борылмалы, чуар бизәкле стилистик берәмлек тудыралар. Күп төрле мәгънәви һәм хисси кичерешләрне, уй һәм тойгыларны, тормыш драматизмын, җитдилекне, шаянлыкны, сөю-сөелү шатлыгын, аянычлы хәлләрне дә сыйдыра гадәти күренгән

шигъри калып, дигән нәтиҗәгә килә М. Бакиров.

Катлаулы, нечкә кичерешләрне үзәккә алганда да җырларда, бик ихтыяҗ булмаганда, гарәп-фарсы, төрек, рус теле алынмалары белән мавыгу артык сизелми, иҗатчыга үз ана теле байлыгы, аның сыгылмалы өслүбе бик җитә.

Фольклор әсәрләренең күмәк иҗат җимеше булуы, гасырлар дәвамында чорлана, нәфисләнә килүе аның кабатланмас үзенчәлекләрен югалтмый. Психологик анализ алымнары, кешенең аң төпкелендә бөреләнгән иң тирән серләренә үтеп керүгә омтылыш та, галим фикеренчә, халык җырларында бөреләнә. Автор да, Тукайны куәтләп, халык ул—олы шагыйрь, дигән нәтиҗәгә килә.

«Татар фольклоры» китабында халык иҗатының барлык мәгълүм традицион жанрлары да бертигез дәрәҗәдә, ягъни югарыда китерелгән мисалдан күренгән мифлар, дастаннар, җырлар шикелле үк, җентекләп, күп санлы мисаллар ярдәмендә өйрәнелә.

Табигый, һәр җитди хезмәт «бәйләнәсе килү» теләге уята, төрле тәкъдимнәр, теләкләр туу да табигый. Әмма М. Бакиров каләменнән төшкән бу китапны битараф кына читкә куеп булмый. Ул зиһенне уята, аңны арттыра. Бер теләк. Миңа, шәхсән, аерым бүлекчәгә чыгарылган әкияти—мифологик дастаннар «мифлар» өлешен тәгәлләп куюга дәгъва итеп торалар кебек тоела. Аларның мифлар белән мәгънәви һәм стилистик якынлыгы көчле. Бигрәк тә фольклорда үзара керешү, диффузия процессының бу төр сәнгатьнең төп үзенчәлекләренең берсе икәнен исәпкә алсак. Риваять белән легендаларны аерым-аерым өйрәнү фәнни яссылыктан караганда акланса да, татар күңеле ошбу бүленешне кабул итмәс. Чөнки фольклористика белән махсус шөгыльләнмәгән кешеләр өчен «риваять» шул ук «легенда», тик аның русча атамасы гына.

Китапта туй йолаларына урын күбрәк бирелгән кебек. Беренчедән, күптән түгел генә бу авторның туй йолаларына багышланган югары кимәлле махсус китабы чыкса («Котлы булсын туегыз», 2007), икенчедән, бу синкретик жанр күбрәк этнография фәненә карый. Тагын бер фикер. «Эшчеләр фольклоры» дип бирелгән мирас аерым бүлекне күтәрми кебек тоелды миңа. Чөнки монда зурлап, авыз тутырып сөйләрлек материал юк. Татар җәмгыятендә эшче сыйныфы сәхнәгә чыккан дәвердә традицион фольклорның әйдәп баручы жанрлары үсешнең югары сыйфат үренә күтәрелеп, вариантлар, ясалма өстәмәләр исәбенә генә яшәүләрен дәвам итәләр. Халык иҗатының төп яшәеш чишмәсе, илһам чыганагы —авыл. «Эшчеләр фольклоры» дип аталган төрдә миф, әкият (совет идеологларының «илнең хуҗасы—эшче сыйныф» дигән кыска әкиятен санамаганда), дастан, риваять кебек төп жанрларның бөтенләй булмавы, хәтта тапкырлыкка, сүз уйнатуга, акыл эшчәнлегенә корылган мәкаль-әйтемнәрнең сирәк очравы да ясалмалыкны ача бит. Ә инде «шахта», «зимагур», «җир асты», «эшче», «хуҗа» кебек сүзләрдән башка бу сыйныфның йөзен ачарга тиешле җырларның (дөресе, такмазаларның), бәетләрнең элеккеге әзер калыпларга нигезләнеп чыгарылганлыкларын аңлау өчен фольклорчы галим булуның хаҗәте юктыр дип уйлыйм. Димәк, эшчеләр тормышын «чагылдырган» җырларны «лирик җырлар», ә бәетләрне «бәетләр» бүлегендә өстәмә итеп бирү дөресрәк булыр иде кебек.

Тулаем алганда, татар фольклорының жанр хасиятләрен ачу, сәнгати көчен, матурлыгын күрсәтү аша бу төр иҗатның этник-милли үзенчәлекләренә үтеп керү, укучыда горурлык хисе һәм туган халкының үткәненә, бүгенгесенә мәхәббәт тәрбияләү китапның төп үзенчәлеген һәм юнәлешен тәшкил итә. Галим халыкның сүз сәнгатенә, теленә, менталитетына, матурлыкны аңлавына булган ихтирамын, олылавын үз китабының һәр җөмләсенә сеңдерә алган. Бу инде үзе зур казаныш. Татар фольклористика фәне сикәлтәле үсеш юлында янә бер җитди биеклекне алган!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# ЧӘРДӘН ХАНЛЫГЫ

**Адашкан Атом...**

Без, татарлар, гаять бай тарихлы халык, безнең дәүләтләребез генә дә дистәләгән булган, җирләребезнең очы-кырые күренмәгән, Равил Рахмани әйтмешли, «мен чакрымга—мең чакрым» ара һәм дала җәйрәп яткан... Ул урман-далалардагы, биек ярлардагы курган һәм калалар йөзләгән булган, алар бүген дә тарих туфрагы астында үз ачышларын, үз вакытларын көтеп яталар...

*Тау дип уйлаганым курган булды,*
*Курган дигәннәрем—каберлек.*
*Татар тарихыдай—мәңгелек...*



Ф.Бәйрәмова элек Чәрдән Кремле булган җирдә

Без, татарлар, гаять ярлы халык, тарихта шундый бөек дәүләтләр тотып та, бүген дәүләтсез калган, таланган һәм башкаларга ялланган милләт... Без Казан-Болгар тарихы белән генә чикләнгән, һәрхәлдә, татар тарихы, татар шәһәрләре, татар курганнары бөтен Себер һәм Идел-Уралда таралып ятса да, аларны безгә бирмиләр, безнең анда кендегебез киселгән...

Без, татарлар, инде үзебез дә артыгына дәгъва кылмыйбыз, борынгылыкка өмет итмибез, безнең тамырларыбызны—Болгардан, түбәбезне Казаннан ары җибәрмиләр... Асыл нигезебез булган скиф, һун, сармат чорларына, Атилладай алтын ханнарыбызга, Котыптан кыпчак далаларына кадәр җәелеп киткән, Татар бугазыннан Урал тауларына кадәр килеп җиткән, Иделнең башыннан ахырына кадәр дөнья тоткан бу тарихка, бу туфракка инде башкалар дәгъва кыла, башкалар хуҗа... Алай да бер мизгелдә кан күзәнәкләрендә, хәтер чонгылларында яшен уты ялтырап китә дә, мең еллык тарих төпкелләрен яктыртып үтә, күнелдә мәңгелек хатирәләр янара, терелә, уяна, дөньяга бәреп чыга.

*Ачылып китә тарих төпкелләре,*
*Актарылып чыга бар үткәне,*

*Ханлыклары, бөек калалары,*
*Ат чаптырган чиксез далалары,*
*Татар бугазыннан—Каф таугача,*
*Алып тауларыннан—Кырымгача,*
*Кыйтгадан кыйтгага җирләре*
*Актарылып чыга барысы да...*

Урыс фәйләсуфе Иван Ильин татарны «Блуждающий атом» дип атаган, ягъни, «Алашкан атом»... Дөнья буйлап һәм үз-үзендә бәрелеп-сугылып, эзләнеп йөручe МӘҢГЕЛЕК АТОМ УЛ ТАТАР... Һәм ул үз-үзен янадан тапканчы, үз асылына янадан кайтканчы мәңгелек кучәрендә әйләнәчәк...

Бу язмам Котып карларында, Себер сазлыкларында, Урал ташлары арасында—тарих төпкелләрендә адашып калган татарлар турында, Атлантида кебек җир астына киткән ТАТАР ТАРИХЫ турында...

Бүгенге Россиянен төньяк төбәкләрендә, Пермь краенын ин кырыенда заманында каһарман Атилланың уллары яшәгән, нәселе көн күргән дисән, күпләр моңа ышанмас иде. Мин менә, татарнын адашкан бер атомы, шул җирләрдә булып кайттым һәм моңа инандым. Шулай ук биредә моннан мен еллар элек болгар шәһәре гөрләп торган, бу җирләр Идел Болгарстаны составына кергән дисән дә, күпләр моңа шик белдерергә мөмкин. Мин менә, татарнын тынгысыз бер җаны, шул җирләрдә булып кайттым һәм моңа ышандым. Заманында урыслар тарафыннан «Пермь Великая» дип аталган, ә татарлар «Чәрдән ханлыгы» дип атап йөрткән һәм Казан ханлыгы составына кергән Чердынь шәһәрендә Ибраһим ханнын сугыш киемнәре саклана дисәләр, күпләр моңа ышанмас иде. Мин, татарнын бер тарихчысы, аларны үз күзем белән күреп кайттым һәм милләтебезнең бөеклегенә тагын бер тапкыр иман китердем...

Чердынь...

Татар чыганакларында Чәрдән, Чардин, Чардын, Чырдын дип йөртелүче ерак һәм серле төньяк җирләре...

Ул инде бүгенге татар өчен онытылган, югалган, билгесез дөнья, кулдан киткән дәүләт һәм нигъмәт...

Урыслар өчен—христиан диненен үзәге, милләтнен борынгылыгын саклап торучы изге җирләр, кече Ватан, туган ил...

Шул табу һәм югалту тарихын, гыйбрәт өчен, халыкка да сөйләп бирәсем килде...

## Тарихтагы Чәрдән

Минем Чәрдән белән ныклап кызыксына башлавыма Атилла хан сәбәпче булды. Дөрес, элегрәк тә тарихи һәм әдәби чыганакларда Чердынь-Чәрдән турында аз-маз мәгълүмат очраштыргалады, ләкин аларның берсе дә мине бу легендар урыннарны эзләп ерак юлга кузгалырга этәргеч булмады. Галим Әзһәр Мөхәммәди китабыннан мин узган гасырда Чәрдән янынннан Атилла улынын көмеш савыты табылганлыгын укып белдем, ана кадәр тарихчы Индус Таһировнын да бу якларда Атилланын улы яшәгәнлеге һәм күмелгәнлеге турында әйткәннәрен ишетеп белә идем.

«Атилла үлгәннән соң, уртанчы улы Диккиз һәм кече улы Ирнәк көнчыгышка—төп һун җирләренә китеп баралар,—дип яза Әзһәр Мөхәммәди.—Диккизнен чынлап та искил, суар һәм болгар кабиләләре белән идарә итүен 1893 елда Пермь губернасы Чардын өязе Керче авылы янында табылган алтын йөгертелгән көмеш савытнын арткы ягындагы язу дәлилли. Анын эчтәлеге: «Әгәр кинг /король/ данлы Диккиз кылычласа, сак бул, гүр тәнресенә юлыкма!»—дигән җөмләдән гыйбарәт. Савытнын сул ягына кабан дуңгызын кылычлаган патша рәсеме төшерелгән. Анын башында тәкә мөгезе рәвешендә эшләнгән таҗ, ә таҗ өстендә кояш сурәте тора.» / Мөхәммәди Ә. Һуннар һәм туран язмалары.—Казан, 2000, 40 б./

Ягъни, Кама елгасынын башланган урыннарында, хәзерге коми-пермяк җирләрендә, Пермь һәм Свердловск өлкәләренен төньягында, Урта һәм Төньяк

Уралда моннан мең биш йөз ел элек Атилланың уллары идарә иткән, тарихта һуннар дип аталып йөрткән бу кавем төрки телле булган. Бу исә бүгенге Урал татарларының ерак бабалары Атилла хан нәселенә барып тоташа дип әйтергә тулы нигез бирә. Әлбәттә, мондый данлыклы нәсел нигез салган тормыш, дәүләтчелек системасы, шәһәр цивилизациясе Атилла ханнын улларыннан соң да дәвам итә. Чәрдәннең тирә-ягыннан табылган затлы скиф әйберләре, унбиш гасырлык алтын һәм көмеш савытлар, бихисап болгар чоры табылдыклары, Казан ханнарынын сугыш киемнәре һәм кораллары бу якларнын гомер-бакый югары дәрәҗәдә тормыш алып баруларын сөйли. Иң мөһиме—ул затлы тормышны коручылар һәм алып баручылар төрки болгар-татарлар икәнлеген сөйли ул табылдыклар...

Әйе, борынгы Чәрдәндә төрки дәүләтчелек беркайчан да өзелеп тормый, һуннардан соң аны биредә Идел буе болгарлары дәвам итә. Тарихта бу турыда да мәгълүматлар шактый. Пермь төбәге белән борынгы Болгар иленең бәйләнешләре инде кире кагылгысыз факт, бу яклар тулысы белән Идел Болгарстаны дәүләте составында булган, шәһәр һәм кирмәннәрен тоткан. Әмма безнең сүзебез Чәрдән турында барганга, беренче чиратта Болгар һәм Чәрдән бәйләнешләренә тукталып үтик.

Талантлы язучы һәм җирле тарихчы Мамин-Сибиряк 1888 елда Чәрдәндә була һәм бу якларнын тарихын өйрәнә. Соңыннан анын Чәрдән белән бәйле дистәләгән тарихи очеркы, әдәби язмалары басылып чыга. Мамин-Сибирякнын хезмәтләрен һәм Чәрдәнгә язылган шәхси хатларын өйрәнгән Пермь галиме Г.П.Чагин анын болгарлар турында түбәндәге фикерен мисалга китерә:

«В одном из отчетов Московскому археологическому обществу Д.Н.Мамин-Сибиряк высказал далеко не безосновательное наблюдение: «Для археологии самым интересным является тот угол, где сбегаются три громадные реки—Кама, Вишера и Колва. Здесь когда-то кипела бойкая торговля и стоял богатый булгарский город, составлявший ключ трех волоков—на Северную Двину, на Печору и за Урал. Громадный водный путь, переходивший из Каспийского моря по Волге и Каме до Архангельска, играл в свое время громадную историческую роль, закончившуюся с падением волжских булгар.» */Чердынь и Урал в историческом и культурном наследии России.—Пермь, 1999—С. 275./*

Бу факт үзе үк болгар бабаларыбызнын төньяктан көньяккача бөтен су юлларын үз кулларында тотканлыкларын күрсәтә, ә су юлы ул вакытларда төп тормыш юлы булып саналган. XIX гасыр галиме В.Берх та Чәрдәннең болгар шәһәре булырга тиешлеген әйтә, әмма анын биш тапкыр урыныннан күчерелгәнлеген язып калдыра. */Берх В. Путешествие в города Чердынь и Соликамск. Спб., 1821.—С. 56, 64./* Ягъни бүгенге Чәрдән Колва елгасы буенда торса, борынгы Чәрдән Кама елгасы буенда булган булырга мөмкин. Әмма ни булса да, сүз шушы өч төньяк елгасы турында бара, һәм иң күп болгар хәзинәләре дә—250 әйбер биредән табылган. Биредә алтын һәм көмеш, бронза һәм тимер әйберләрдән тыш күп күләмдә болгар керамикасы, чүлмәк ватыклары да чыкканлыгы билгеле, бу исә болгарларнын биредә утрак тормыш белән, шәһәрләр төзеп яшәвен күрсәтә. Моңа Пермь галимнәре А.М.Белавин һәм Н.Б.Крыласова да игътибар иткәннәр:

«Достаточно широко на современной Пермской области встречена болгарская гончарная керамика,—дип яза алар.—...ее находки уверенно демонстрируют не только торговые связи чердынцев, но и возможности появления в X-XIII вв. в местной этнической среде поселенцев из Волжской Болгарии. Экономические связи с Болгарией и ее приемниками—Золотой Ордой и Казанским ханством сохранялись вплоть до конца XV в. Не без основания в одной из летописей записано, что накануне вхождения Перми Великой в Русское государство «пермяки за казанцев норовили»» */Чердынь и Урал...—Пермь, 1999,—С. 79./*

Әмма бүгенге Пермь галимнәренең күпчелеге болгарларнын биредә шәһәрләр төзеп яшәгәнен таныргә теләми, барлык элемтәне сәүдәгә генә кайтарып калдырырга телиләр. А.Ф.Мельничук һәм П.А.Корчагин Белавиннын «Болгар вассаллары һәм ясак җыючылары Урал алдында һәм Обь алдында Болгар хакимиятенең мәнфәгатьләрен чагылдырган» дигән фикере белән килешмиләр, алар ана каршы: «На наш взгляд эти

крайне слабо обоснованные на источниках построения обусловлены тем, что якобы Волжская Булгария полностью доминировала на территории Среднего и Верхнего Прикамья,—дип язалар.—А.М.Белавин берет лишь общий подсчет встречаемости булгарской посуды в слоях как северных памятников родановской культуры, так и южных, что, на наш взгляд, дезориентирует исследователей и создает иллюзию господства Волжской Булгарии над территорией в два раза превышающей ее.» */Чердынский край: прошлое и настоящее.—Чердынь, 2003.—С. 25-26./*

Урыс тарихчыларынын күпчелеге Пермь төбәгенең, шул исәптән, Чәрдәннең дә Идел Болгарстаны кул астында булуын таныргa теләми, шулай ук бу якларның Алтын Урда һәм Казан ханлыклары составында булуын да танырга теләмиләр. Алар һаман бирeдән табылган шәһәр урыннарын, кирмән-кәлгаләрне, сандык-сандык гарәп акчаларын, алтын-көмеш табылдыкларны шалашта яшәүче комилар белән бәйләмәкче булалар, имеш, бу байлык алардан калган булырга тиеш. Галимнәр ни өчен күрә торып мондый ялганга баралар соң? Беренчедән, әгәр бу җирләрнең борынгы заманнарда һәм урта гасырларда болгар-татарлар кул астында булуын танысалар, ул чагында бирегә бәреп кергән урыслар басып алучылар булып кала. Икенчедән, коми халкы инде бетеп бара, алар инде беркайчан да урысларга тарих буенча дәгъва белдерә алмаячаклар, ә татарларның хакыйкатьне искә төшерүләре бар, ә бу урыслар файдасына булмаячак.

Урыс тарихчыларын үзара бәхәстә калдырып, татар галимнәренең Чәрдән турындагы фикерләрен язып үтик. Күренекле галим Марсель Әхмәтҗанов үзенең «Нугай урдасы» дигән китабының «Пермь өлкәсе татарлары шәҗәрәләре» дигән бүлегендә, «Җавыш би шәҗәрәсе»нә таянып, «Чырдын—Пермь ягының административ үзәге булганга охшый,—дип яза.—Аның аркылы бу як татарлары Мәскәү белән бәйләнешкә кергәннәр. Димәк, Чырдын Кама буенда Казан ханлыгының административ үзәге булып торган, соңыннан, күрәсең, анда Мәскәү воеводасы утыртылган.» */Күрсәтелгән хезмәт, 264 бит./*

Марсель Әхмәтҗанов Чәрдәнгә Болгар һәм Казан кешеләренең турыдан-туры тәэсире турында да яза: «Җавыш бинең улы Инсан Болгар шәһәреннән Чырдынга килеп урнаша, шунда яши,—дип шәҗәрәне бәян итә ул.—Иван Васильевич Казанны Болгар олысы ханы кулыннан алгач, аңа буйсынып ясак түли башлый». */Күрсәтелгән хезмәт, 264./* Марсель Әхмәтҗанов, шәҗәрәләргә таянып, бу якларга татарларның «XIV гасырдан да соң килмәүләрен» яза, ягъни, Алтын Урда һәм Казан ханлыклары чорында Чәрдәннең татарлар кулында булганлыгын исбатлый. «Пермь ягындагы татарларның административ үзәге булып Чырдын каласы саналган,—дип яза галим.—Ул 1472 елда беренче мәртәбә тарихта искә алына. Аны Казан ханы Ибраһим кордырган булса кирәк.» */Күрсәтелгән хезмәт, 266 б./*

Чәрдәннең биш тапкыр урынын алмаштырганны искә алсак, аның берсен Ибраһим хан кордырган булырга да бик мөмкин, бу инде 1467—79 еллар арасы, дигән сүз. Бу инде үзе үк Чәрдәннең хан заманнарыннан татарлар кулында булганлыгын аңлата. Хәер, бу хакта борынгы риваятьләрдә дә бик ачык әйтелгән. Бу якларда бүген дә бик популяр булган «Гайнә шәҗәрәсе»ннән күренгәнчә, Барда татарлары җирләре белән идарә итәргә рөхсәт ярлыгын Чәрдәннән, татар ханнарыннан барып алганнар, алар анда бер телдә сөйләшкәннәр. Риваять: «Гайнетдин: »Бу урманнарның, җирләрнең баш кешесе бармы?»—дип сораган. Әйткәннәр: »Бу җирләр бер падишаһ җире. Аның патшасы Чырдин дигән җирдә, шул Кама суының башында яши, дигәннәр. Бу Гайнетдин Кунгурдан кайткан да, киткән Чырдинга.» */Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар.—Казан, 1987, 175 б./*

Җирле тарихчы Әмир Фатыйховның язуынча, бу легендаларның берничә варианты бар икән. «Бер төрлеләрендә ике бертуган Тол буена Болгар иленнән Чулман /Кама/ буйлап киләләр,—дип яза ул,—икенчеләрендә күктән төшәләр, карлы яклардан боланга атланып килеп чыгалар» */Гайнә белән Әйнә/. /Әмир Фатыйхов. Гәйнә иле.—Барда, 2002, 38 б./* Биредә ут өчен көрәш тасвирлана, бу көрәштә Әйнә үлә, ә Гайнә исә утны коткарып, үз халкына илтә, шулай итеп, Гайнә ыруы башланып китә. Бу риваятьнең тамырлары тагы да борынгырак—мәҗүси чорларга барып тоташканлыгы күренә, күктән төшкән ике туганның ут-яктылык

өчен явыз көчләр белән көрәше тасвирлана. Шунысын да әйтергә кирәк, серле айна ыруының узган гасырларда Сахалин утравының көньягында һәм Япониядә яшәгәнлеге билгеле.

Әмир Фатыйхов үзенең әле 1995 елда Бардада басылып чыккан «Гәйнә иле» китабының беренче басмасында ук Чәрдәнне Пермь татарлары тормышында аерым бер урынга куя: «Безгә атаклы һуннар каганы Атилланың улы Денгиззих турындагы ачыш, «Гәйнә» риваятеннән Гайнетдиннең, Танып авылы турындагы риваятьтән Биккул бабайның Чардин падишаһына барып йөрүләре, аннан үзләре билгән жирләргә ярлык алып кайтулары билгеле,—дип яза ул.—Димәк, Чардин Гәйнә тарихында очраклы гына телгә алынмый, аның аерым кешеләренә генә карый торган урын түгел, ә XV гасырларга кадәр Гәйнә иленең мәркәзе шушында булган, дип әйтә алабыз.» /*Күрсәтелгән хезмәт, 40 б.*/

Әйе, күп төрле чыганаклардан күренгәнчә, Чәрдән шимал төркиләренең, болгар-татарларның мәркәзе, башкаласы булып торган, тирә-юньгә патша ярлыклары таратып утырган, димәк, аның мона вәкаләте булган. Бәлки шуна күрәдер, матбугатта «Чәрдән ханлыгы» турында да язмалар күренә башлады. Мәсәлән, Радмир Фаязов болай дип яза: «Белгәнебезчә, хәзерге Пермь өлкәсенең төньягында урнашкан Чердынь шәһәре тирәсендә Казан ханлыгы белән һәрдаим элемтәдә торган Чәрдан дип аталган татар ханлыгы булган. Кызганычка каршы, унбишенче йөз башында швед юлбасарлары әлеге ханлыкны туздырып ташлыйлар. Һәм бүгенге «Пермь татарлары» /«Ботык» кабиләсе/ төркеменә кергән халкыбыз шул ханлыкның варислары булырга тиеш. Чөнки ошбу кабилә төньяктан көньякка сузылган Урал тавының ике ягына җәелеп утырган. Халык авыз иҗаты, башка чыганаклардан күренгәнчә, алар бу урыннарга төньяктан килеп төпләнгәннәр.» /*«Шәһри Казан» газетасы, 1994 ел, 22 сент.*/

Автор белән Чәрдән ханлыгы һәм «Ботык» кабиләләре мәсьәләсе буенча тулысынча килешергә була, чыннан да бу диалект-шивәдә сөйләшүче татарлар хәзер Пермь краеның Көнгер, Октябрь, Орда, Уинск, Лысева, Березовка, Суксун районнарында яшиләр. Әмма Радмир Фаязов «унбишенче йөз башында Чәрдәнне җимергән швед юлбасарлары» турында мәгълүматны кайдан тапкандыр, анысын әйтә алмыйм. Чәрдәнгә баргач, мин бу хакта музей хезмәткәрләреннән дә сорадым, алар биредә әсир шведларның чиркәүләр төзүен генә әйтә алдылар. Чәрдән өчен, нигездә, ике гасыр буе урыслар белән татарлар сугыша, кайвакытта бу сугышларга вогуллар, башка жирле халыклар да кушыла, алар турында алда язармын, иншаллаһ!

Себер татарлары турында зур хезмәтләр язып калдырган тарихчы Габделбәр Фәйзрахманов та Пермь жирләрен болгар-татар халкының яшәгән һәм дәүләт тоткан урыннары итеп карый. Галимнең язуынча, болгар-татарлар Чәрдәндәге су юлын үз кулларында тотканда, урыслар аңа якын да килә алмаганнар: «Долгое время Камский путь был закрыт для русских, т.к. могущественное Булгарское государство держало в своих руках торговые пути в Сибирь,—дип яза ул.—После падения Булгарского государства в XIII в. этот путь принадлежал преемнику Булгарии—Казанскому ханству. Со времен Булгарского государства в Пермской земле жили булгары, потом волжские татары, продолжившие свое проникновение на северо-восток. После завоевания Казани русским открылась возможность пользоваться Камской дорогой. Русские пользовались двумя ветвями Камского пути: через Чердынь и по р. Чусовой.» /*Файзрахманов Г. История Сибирских татар.—Казань, 2002,—С. 183.*/

Башка татар чыганакларында да Чәрдәннең милли үзәк, мөһим бер стратегик урын икәнлеге ассызыклана. Әйтик, тарихчы Рөстәм Нәбиев Чәрдәнне Чуртан дип атый һәм аның төньякка хәрәкәт итүдә бик әһәмиятле урын булганлыгын әйтә: «Ключевым пунктом пути на север являлась Чердынь /Чуртан/, стоявший на пересечении речного пути на север и сухопутной—в Зауралье,—дип яза ул.—Местные краеведы на основе археологических данных утверждают, что населенный пункт существовал уже в VIII-IX вв.» /*Р.Набиев. Булгар и Северная Европа. Древние связи.—Казань, 2001,—С. 67.*/

Әйе, бу тирәдә Чуртан дигән авыл да бар, әмма ул Кама буена урнашкан, ә бүгенге Чәрдән Колва елгасы буенда, Колва 5 чакрымнан Вишерага коя, ә

Вишера—Камага. Кыскасы, бөтен болгар-татар шәһәрләре, кирмән-кәлгаләре, калалары шушы өч елга арасындагы өчпочмакка урнашкан булган, һәм бөтен затлы табылдыклар, болгар-татарларның сугыш һәм эш кораллары да шушыннан чыга. Мона Пермьдә яшәүче һәм милләттшләребез турында бай эчтәлекле китап язган Данир Закиров та игътибар иткән: «Таким образом, период X—первой трети XIII века характеризуется как период активного взаимодействия Волжской Булгарии и народов Верхнего Прикамья,—дип яза ул.—Волжская Булгария к XI—XII векам фактически присоединила земли Предуралья. Это дало право правителю булгар собирать в Прикамье налоги: джизью и харадж.» /*Закиров Д. Татары и башкиры Перми.—Пермь, 2008,—С. 79.*/

Тарихи чыганакларга нигезләнеп, Д. Закиров югары Камада борынгы болгар мәчетләре дә булганлыгын яза. Әлбәттә, мөселманнар шәһәрләр салып яшәгән урыннарда мәчетләрнең булуы гаҗәп түгел, әмма шул җирләрдә бүген исламның эзе дә булмау бик гаҗәп һәм кызганыч... Данир Закиров Каманың югары агымында болгарларның ювелир үзәге булган, дип бара һәм моны күп санлы мисаллар белән исбат итә. «На наличие в Прикамье булгарского ювелирного центра указывают и находки здесь ювелирного инструментария,—дип яза ул.—В Прикамье найдены две булгарские матрицы для тиснения, в деревне Ручиб Чердынского уезда—медный штамп для поясных бляшек с изображением двух львов в восточном стиле XI—XIII веков.» /*Күрсәтелгән хезмәт, 77 б.*/ Автор шулай ук бу якларда күпләп болгар сугыш кораллары—булат кылычлар, балта һәм чукмарлар табылуын да яза, әйтик, шул ук Чәрдән районының Пянтег авылында көмеш белән бизәлгән затлы болгар балтасы табыла. Соликамски һәм Березники шәһәрләре тирәсеннән табылган дала сукаларын да җирле тарихчы болгар игенчелек техникасы белән бәйли һәм : «Таким образом, тот факт, что пашенное земледелие возникло и развивалось у жителей Пермского Предуралья под воздействием булгар, не вызывает сомнений», дип нәтиҗә ясый. /*Күрсәтелгән хезмәт, 79 б.*/

Бүгенге көндә Чәрдән тирәсендә чәчелмәгән кырларны, янадан урман басып киткән иген басуларын күрәсең дә, урман төпләп иген иккән болгар-татар бабайлар искә төшә... Әмма алар хәзер биредә юк инде, үзләре дә, шәһәрләре дә, авыллары да юк...

Урал татарлары турында язып та, Себер татарлары турында дәшмичә калсаң, дөрес булмас иде, чөнки аларның язмышлары да, тормышлары да бик тыгыз бәйләнгән була. Чәрдән өчен барган күпчелек сугышларда, бигрәк тә XVI гасырда, нигездә Себер татарлары катнашкан, алдагы бүлекләрдә без әле мона тукталырбыз. Шулай ук Себер һәм Урал татарларының сөйләмнәрендә дә уртак яклар шактый, бу аеруча «кый»лаштыруда һәм «ц» лаштыруда, «а»ны «о» белән алыштыруда ачык сизелә. Ни гаҗәп, Чәрдән тирәсендә кайбер урыс авылларында бүген дә «чәй»не Себер татарлары кебек «цой» диләр! Мона урыс галимнәре дә игътибар иткән, әмма бу күренешне «Чердынские говоры—характерные для северно-русских говоров древнерусского языка» дип аңлаталар. /*Чердынь и Урал...—С. 24.*/ Ә сүз бит күп гасырлар элек чукындырылган татарларның урыс милләте составына күчкәч тә кайбер тел үзенчәлекләрен саклап калулары турында бара!

Омскида яшәп иҗат итүче тарих фәннәре докторы А.Н.Томилов та Пермь татарларының формалашуында Себер татарларының роле зур булуын һәрвакыт ассызыклап тора. /*Томилов А.Н. Тюркоязычное население Западно-Сибирской равнины в конце XVI—первой четверти XIX в.—Томск, 1981,—С. 30-33.*/ Мона Пермьдә яшәүче галимнәр дә игътибар иткәннәр: «Кроме «остяцкого» компонента в формировании пермских татар принимали участие другие тюркские компоненты,—дип яза алар.—А.Н.Томилов отстаивает положение об участии в этом процессе сибирских татар. По его мнению, Сылвенско-Иренское междуречье в прошлом являлось зоной контакта поволжских и сибирских тюрков и в составе населения поречья в XVI—XVII вв. кроме угров /манси/ были тюрки—сибирские татары, продвинувшиеся в Предуралье еще в период Сибирского ханства.» /*Этнокультурная самобытность и особенности татарского и башкирского населения Пермского края.—Пермь, 2006,—С. 16.*/ Шулай ук Чәрдән һәм аның тирәсеннән табылган хәзинәнең

бер өлеше Себергә генә хас җәнлек мотивларын чагылдыруны да әйтеп үтәргә кирәк, бу бизәнү әйберләре Себер татарлары арасында да киң кулланылган.

Мин Чәрдән турында ел буе мәгълүмат тупладым, ел буе анда барырга җыендым, бу тарихи җирләрне үз күзем белән күреп кайтырга теләдем. Атилладан башлап Ибраһим ханга кадәр татар тарихын үз кочагына алган Чәрдән җирләре хәзер нинди икән, борынгы бабаларыбызны бирегәниләр тарткан икән, монда безнең эзләребез сакланып калганмы—мине шулар кызыксындыра иде. Һәм мин июль аеның җәйге чилләсендә ерак юлга кузгалдым...

## Тормыштагы Чәрдән

Чаллыдан Пермьгә автобус белән ун сәгатьлек юл, Пермьнән Чәрдәнгә исә тагы алты сәгатьлек сәфәр икән. Юл гел урман эчләреннән бара, ара-тирә каршыга Кама елгасы килеп чыга, Чәрдәнгә җитәрәк башка зур төньяк елгалары да очрый башлый. Элек безнең бабайлар бу юлны су белән айлар буе үткәннәр, бу турыда жирле тарихчы Әмир Фатыйхов: «Оса—Болгардан Чердыньга илтүче /корыдан 20 көнлек, су буйлап 90 көнлек/ сәүдә юлының нәкъ уртасында урнашкан тукталыш урыны /мәнзил/» дип яза. /*Әмир Фатыйхов. Гәйнә иле. Беренче китап.—Барда, 1995, 50 б.*/ Оса-Усадан Чәрдәнгә ярты юл булгач, Болгардан тулысынча бу юлны бик озак үткән булып чыгалар. Галим Мирфатыйх Зәкиев ул якларда көмеш чыккан булырга тиеш, дип яза, әмма бу хакта башка чыганаклар юк кебек. Атилла улларыннан башлап, Ибраһим ханга хәтле бу якларны үз итүенең төп сәбәбе башкада булырга тиеш, ул заманда Чәрдән тирәсе төньяктан Урал тауларын әйләнеп үтеп Себергә, Көнчыгышка, Азиягә үтә торган төп юлда булган, бу юлны кем үз кулында тоткан, шул дөньяны тоткан. Тарихтан күренгәнчә, бу юл башта төрки скиф һәм һуннар кулында, аннан аларның дәвамчылары болгарлар кулында булган, аннан инде закон буенча татарлар кулына күчкән. Әлбәттә, урыслар да иң төньяк чикләрдән, Котып ягыннан Уралны әйләнеп үтәргә тырышканнар, үз сукмакларын да салып караганнар, әмма дөнья сәүдәсе барыбер Чәрдән аша барган, кыйтгаларны, Азия белән Европаны ул тоташырган. Шуңа күрә төньякта иң зур сугышлар да Чәрдән өчен барган...



*Чәрдән төбәге Пермь өлкәсенең иң төньягында*


Картадан карасаң, Чәрдән Пермь өлкәсенең иң төньяк чигендә, моннан соң инде цивилизация юк кебек. Чәрдәнгә барам, дигәч, кайберәүләр миңа, «Анда төрмәләрдән башка берни юк бит инде», диделәр. Әйе, бу якларда төрмәләр шактый икән, әмма төрмәләрдән башка нәрсәләр дә бар булып чыкты. Әйтик, искиткеч матур табигать! Биредә ул пычранмаган, чөнки Чәрдәндә бернинди промышленность юк, үзен урманнар чорнап алган, аяк астында Колва елгасы җәелеп ята... Күк йөзе биек һәм зәп-зәңгәр, ә җәйләрен—ак төннәр, Чәрдән Петербург белән бер киңлектә ята икән. Чәрдәнгә Әби патша заманында шәһәр статусы бирсәләр дә, ул хәзер зур авылны хәтерләтә, анда нибары 5-6 мең кеше яши, төзелешләр юк, хөкүмәт учреждениеләре барысы да дип әйтерлек революциягә кадәр салынган байлар йортында. Кыскасы, үзәк урамнар ике катлы таш йортлардан торса, кырый-кырыйда агач өйләр тезелеп киткән...

Мине Чәрдәндә беркем дә каршы алмады, чөнки без, алдан күпме эзләтсәк тә, биредән бер татар да тапмадык. Дөрес, 2002 елгы халык саны алу нәтиҗәләре буенча Чәрдән районында 513 татар яши, дип язылган, әмма Чәрдәннең үзендә без

хәтта телефон кенәгәсе буенча да татарлар тапмадык. Без дигәнем—мине Пермь шәһәрендә олылап каршы алган һәм бирегә озатып калган милләттәшләребез—шәһәрнең милли-мәдәни мохтарияты җитәкчесе Данир әфәнде Закиров һәм аның ярдәмчесе, сәнгатькәр ханым Әлфинур Тюмисева. Аларның үзләренең дә Чәрдәндә булганнары юк икән, бирედә татар оешмалары да, мәчет тә юк булып чыкты. Аның каравы чиркәүләр...

Чиркәүләр турында аерым әйтеп үтәсем килә. Әле бирегә килгәнче үк, миңа Бардада Чәрдән чиркәүләренең фоторәсемнәрен биргәннәр иде. Аларны карый башлагач, тетрәнеп киттем—алар барысы да мәчетләрне хәтерләтә, яшел гөмбәзләре өстеннән тәреләрен алсаң, Казанның Мәрҗани мәчете дип уйларлык иде. Кызыл кирпечтән салынган җиде яруслы бер чиркәү исә Сөембикә манарасын хәтерләтә иде... Әлбәттә, музейга кереп чыккач һәм кунакханәгә урнашкач, мин Чәрдәнне карарга чыгып киттем һәм шәһәр уртасында бер-бер артлы тезелеп киткән чиркәүләр каршында, абынгандай, туктап калдым. Бу чиркәүләр барысы да, мәчетләр кебек, маңгайлары белән көньяк-көнчыгышка—кыйбла тарафына карап торалар иде...

Икенче көнне мин эшемне крайны өйрәнү музееннан башладым, миңа ярдәм итәргә биредә эшләүче, ихластан христиан динен тотучы Марина Ивановна Ветчакова алынды. Бу музейга инде йөз ел икән, аны 1899 елны шәһәрнең зыялылары, байлары бергәләп Пушкинның йөзьеллыгы унаеннан оештырган булганнар, кешеләр хәтта үзләренең алтын-көмеш табылдыкларын да музейга бүләк итеп биргәннәр, бүгенге көндә биредә 120 мең экспонат саклана диделәр. Шул вакытта ук шәһәр китапханәсе дә ачылган, аңа да беренче китапларны байлар һәм зыялылар китергән, китапханә хәзер дә эшчәнлеген дәвам итә. Бу музей һәм китапханәләрдә татар тарихы белән бәйле әйберләрне дә очратырга мөмкин, бигрәк тә—музейда. Гомумән, ерак төбәкләрдәге провинция музейларында һәм аларның китапханәләрендә, иркенләп эзләсәң, татар тарихына кагылышлы күп кенә кызыклы нәрсәләр очратырга була. Бу сәфәремә чыгар алдыннан да миңа галим Марсель абый Әхмәтҗанов: «Соликамск яки Чәрдән музеенда Ибраһим ханның сугыш киемнәре булырга тиеш, карап кайт әле», дигән иде. Һәм менә беренче табыш, беренче могҗиза—мин Коръән аятьләре язылган сугыш киемнәре каршында басып торам! Бу, һичшиксез, Марсель абый әйткән Ибраһим хан киемнәре булырга тиеш—тимер боҗралардан үрелгән көбә, тимер очлым (шлем), калкан һәм кылыч, түтәсенә бисмилла язылган айбалта һәм тимер терсәкчә...



*Чәрдән музеенда сугыш киемнәре һәм кораллары*

Агач баскычтан икенче катка күтәрелүгә, бу экспонат сине башта үзенең кырыс дәһшәте, тимер салкынлыгы белән каршы ала. Ул үзенең серен теләсә кемгә ачарга ашыкмый, сугыш киемнәренең астына бик кыска гына итеп: «Снаряжение воина. Железо. XV-XVII вв. Поступила из собрания В.Н.Алина в 1918 г.» дип язылган. Монда татар сүзе дә, хан сүзе дә юк. Мине озата йөргән Марина Ивановнадан бу экспонатның тарихын сорыйм, ул исә, мине гаҗәпләндереп: «Сөембикә-ханбикә заманыннан калган булырга тиеш», дип җавап бирә, әмма моны берни белән дә исбатлый алмый. Ярый, сүздә булса да, Казан белән, татар белән бәйләве дә яхшы. Мин дә бу сугыш киеменең татарныкы икәнлеген әйтәм, анда язылган Коръән аятьләрен далил итеп китерәм. Әлбәттә, беренче барганда ук мин бу сугыш киемнәрен пыяла шкаф артыннан чыгартып, әйләндерә-әйләндерә карый алмадым, алар кагылгысыз, әмма булдыра алганча җентекләп тикшердем, өйрәндем, хәзер шул хакта башкаларга да җиткерергә телим.

Тимер көбә бик яхшы сакланган, бары тик утыртма якасында гына кызгылт күгәрек табы күренә. Ул зур гәүдәле ир-атныкы булырга тиеш, озынлыгы—тездән түбән, итәге бераз ерык, күлмәк җиннәре шактый озын. Мангаена Коръән аятьләре язылган тимер очлым—аның артында һәм янак янында тимер боҗралардан үргән челтәр япма, аларның кайберләре сүтелгән. Тимер калкан—ул бик яхшы сакланган, шактый авыр һәм саллы күренә. Калканның бизәлеше бик сәер—ислам һәм мәҗүсилек билгеләре бергә кушылган дигән фикер калды. Түгәрәк калканның нәкъ уртасында—бөке кебек калкып чыгып торган кеше йөзе, аннан тирә-юньгә кояш нурлары таралган, моны кояш-кеше дип тә кабул итәргә мөмкин. Калкан өстен тутырып кош һәм җәнлек рәсемнәре ясалган, алар бер-берләре белән аралашып, уралышып беткәннәр. Ә түгәрәк калканның ин читенә, калкып чыгып торган шакмакчыклар эченә Коръән аятьләре язылган... Бер кырыйда—агач саплы тимер кылыч, аның йөзлеге бераз күгәргән, шактый калын һәм саллы күренә, озынлыгы бер метр тирәсе булыр. Аста—сугыш айбалтасы, аның сабы шактый озын, ул тимердән сырлап ясалган, түтәсенә Коръән аятьләре язылган. Тимердән ясалган сынар терсәкчә, терсәк башында—калку кеше йөзе, калкандагы рәсемнәр биредә дә кабатлана кебек.

Инде бу киемнәрнең хуҗасы булырга тиешле Ибраһим хан турында да бераз мәгълүмат биреп үтик. Ул—Чыңгыз хан нәселеннән, Казан ханлыгына нигез салучы Олуг Мөхәммәтнең оныгы, татар иле 1467-1479 елларда идарә итә. Бу чор эчендә урыслар берничә тапкыр Казанга һөҗүм итеп карыйлар, әмма теләкләренә ирешә алмыйлар. Ибраһим ханның шулай ук урыслар кулына күчкән төньяк өлкәләрне кире кайтару өчен сугышлар алып баруы да билгеле. */Ризаэддин Фәхреддин. Казан ханнары.—Казан, 1995, 58-61 б./* Татар тарихына ул иле өчен кулына кылыч тотып көрәшкән каһарман хан булып кереп калган. Марсель Әхмәтҗановның: «Чырдынны Казан ханы Ибраһим кордырган булса кирәк» дигән сүзләрен дәлилләү җиңел булмас, әмма эзләнүләр алып барырга кирәк, дип уйлыйм.

Бу сугыш киемнәренең шулай ук Ибраһим ханның улы Илһам ханныкы да булуы мөмкин, тарихи чыганакларда аның икенче исеме—Гали хан. Ул 1479-1487 елларда Казан ханлыгын идарә итә. Бу чорда Мәскәү инде ачыктан-ачык татар дәүләтенен эчке эшләренә тыкшына башлый, хан тәхете өчен туганнар арасында астыртын көрәш башлап җибәрә, бу көрәш 1487 елның 9 июлендә урысларның Казанны алуы һәм Илһам-Гали ханны урыслар кулына тотып бирү белән тәмамлана. Ул гаиләсе белән төньякка сөргенгә сөрелә һәм шунда үлә, исән калган нәселен исә чукындырып, урыс ясыйлар. /Бу хакта төгәлрәк мәгълүматны Михаил Худяков һәм Р. Фәхреддин хезмәтләреннән табарга була./

Татар ханының сугыш киемнәрен Чәрдән музеена тапшырган кеше—урыс купецы Алин. Алиннар—бу якларда бик билгеле, бай, халыкка күп ярдәм иткән, пароходлар тоткан, чиркәүләр салдырган нәсел. Әмма аларның нәсел тарихы 1770 елдан гына билгеле, аңа кадәр кем булулары, кайдан килүләре турында мәгълүмат юк. Музей хезмәткәрләре үзләре үк бу фамилиянең урысныкы түгеллеген әйтәләр. Монда фамилиясе татарныкы булган байлар шактый булган—Алиннар, Надымовлар, Юргановлар... Шушы Алиннар бу якларда—Вологдада сөргендә үлгән Гали ханның нәселе түгелме икән дигән фикер бар. Югыйсә Казан ханнарының сугыш кием бу гаиләгә кайдан килергә һәм гомер буе сакланырга мөмкин? Кайбер чыганаклар буенча, бу сугыш киемнәрен Василий Алин үзе музейга тапшырган, кайберләрендә исә аларны большевиклар тартып алган, дип язылган. Мөгаен, соңгысы дөрестер, әгәр Алиннар бу сугыш киемнәрен музейга бирергә теләсәләр, 1899 елда, музей ачылганда ук биргән булырлар иде. Ул вакытта алар музейга 49 борынгы көмеш табылдык тапшыралар.

Хакимияткә большевиклар килгәч, совет власте Алиннарны кычкыртып талый, бар байлыкларын тартып ала, үзләрен йортларыннан куып чыгара. Алиннарда сакланган сугыш киеме дә шул вакытта тартып алынган булырга бик мөмкин. Соңыннан Алиннар Колчакка ияреп көнчыгышка китәләр, гаилә башлыгы Николай Алин Читада үлеп кала, хатыны һәм уллары Бразилиягә барып урнаша, шунда яшәп, шунда вафат булалар. Василий Николаевич үлгәнче Чәрдән белән хат алышып тора,

музей өчен акча җибәрә, гомер буе туган якларын сагынып яши, бу хакта аның Чәрдәндә басылып чыккан хатлары сөйли. Кем белә, бәлки татар ханнарының ерак нәселе, инде урыс кешесе булып, ерак Бразилия илләрендә бу дөньядан китеп баргандыр... Кем белә...

Мин Алиннарның нәселе белән бик кызыксынгач, бөтен документларның Чәрдәндә 1792 елгы янгында юкка чыгуын әйттеләр. Гаҗәп, шул ук вакытта музей китапханәсендә борынгы урыс кулъязмалары, XV-XVI гасыр христиан дине китаплары сакланып калган. Әмма берәдә татар тарихы белән бәйле язмаларны табу мөмкин түгел, урыс чыганакларыннан берәмтекләп эзләп тапсаң гына инде...


Татар ханының сугыш киемнәрен һәм коралларын өйрәнүне тәмамлагач, Атилла улының көмеш касәсе турында соравымны бирдем. Әлбәттә, мин аның монда түгеллеген, ә Петербургның Эрмитаж музеенда саклануын белә идем инде, Чәрдән музеенда эшләүчеләр дә шуннан артыгын белмиләр булып чыкты, Атилла турында да беренче ишетүләре икән. Хәер, бу тирәдән нинди генә борынгы нәрсә табылса да, аны иң беренче индоиранлылар белән бәйлиләр, унбиш мең еллык алтын-көмеш табылдыкларны барысын да фарсыларныкы дип язып куйганнар. Менә алтын йөгертелгән көмеш тәлинкә, ана атка атланган патша рәсеме ясалган, ул кылычы белән аюларны чәнчи... Җиденче гасырда ясалган бу хәзинәне 1967 елда Чәрдәннән ерак түгел урнашкан Зур Аниково /Әнәк?/ авылында тапканнар һәм астына «иранныкы» дип язып куйганнар. Менә шундый ук көмеш тәлинкә, монысында патша бәрәннәргә уктан ата, унбиш гасырлык бу табылдыкка да «иранныкы» дип язганнар, ул исә 1936 елда Кече Аниково авылында табылган. Шулай ук «иранныкы» дип язылган ике көмеш тәлинкә дә бик хикмәтле рәсемнәргә бай. Аның берсе 1936 елны Кече Аниково авылында табылган һәм бишенче гасыр хәзинәсе, дип билгеләнгән. Көмеш савыт өстенә әкиятләрдәге Сәмруг кош рәсеме ясалган, ул тәпиләре белән курчак хәтле генә хатын-кызны кысып тоткан. Аста исә ике бәләкәй ир-ат йөгереп йөри, аның берсе Сәмруг кошка уктан ата, икенчесе җилкәсенә чукмар салган, каядыр йөгерә. Ян-якка ике озын агач рәсеме ясалган, тәлинкә тирәсен үсемлек бизәкләре сарып алган... Менә тагы бер «иранныкы» дип язылган көмеш савыт, монда кирмәнгә һөҗүм сурәтләнгән. Бу савыт та Аниково авылыннан, 1909 елда табылган.

Өстенә һәм сабына Коръән аятьләре язылган, алтын йөгертелгән савытны XII-XIII гасырлар табылдыгы дип билгеләгәннәр, ул 1959 елда Кече Аниково авылы янында табылган. Монда инде «иран» сүзе юк, шул ук вакытта «төрки-татар» яки «мөселман» дигән сүз дә юк, һәрхәлдә, берәдә ислам дине тотып көн күрүчеләр безнең болгар-татар бабаларыбыз булган бит! Кыскасы, Кама белән Колва-Вишера елгалары арасыннан 18 борынгы заман хәзинәсе табылган! Борынгы курганнардан исә кешесе-ние белән савыт-сабалар, сугыш һәм эш кораллары чыккан, боларның да хуҗалары билгесез. Хәер, югарыда «иранныкы» дип язып куелган табылдыкларны да, курганнардан чыккан борынгы байлыкны да мин үзем төрки скифларныкы, һуннарныкы дип исәплим, шул исәптән, Атилла улының көмеш савытын да. Кайсы яктан килеп карасаң да, бу байлык—безнең борынгы бабаларыбызныкы, төрки халыкныкы, болгар-татарларныкы, әмма бу хакта язмыйлар да, сөйләмиләр дә.

«Недалеко от с. Редикор находится маленькая деревня Аниковская,—дип яза җирле тарихчылар.—В плане каких-либо достопримечательностей она ничем не выделяется. Но вот если бы предположим в нашем Пермском крае издавалась книга рекордов, то эта информация о деревне Аниковской попала бы на ее страницы. Здесь найдено самое большое количество древних кладов /арабских, иранских серебряных украшений, сосудов, монет/ на всей территории Пермского края.» */Бординских Г.А., Власов Ю.С. Пянтег Праведный. Китапның кайда чыгуы һәм елы күрсәтелмәгән./*

Музейда шулай ук 200 көмеш тәңкә саклана, аны гарәп акчалары диделәр, IX-X гасырныкы икән. Бу хәзинә 1949 елны Горбунов авылы кырларын сөргәндә табыла. Миңа калса, болар гарәпчә язылган болгар тәңкәләре булырга тиеш, әмма аны Казаннан белгечләр килеп укуы кирәк. Алай да, ачыктан-ачык Идел Болгарстаныныкы дип язылган экспонатлар да бар һәм музейда алар шактый. Менә

Шәһри Болгардагы кебек чигә алкалары, алар көмештән ясалган, экспонатның астына «Волжская Болгария. Серебро. IX-XIII вв.» дип язылган, бу алкалар Кече Аниково авылыннан табылган. Шулай ук бу авылда бронзадан ясалган болгар көзгесе кисәкләре табылуын да әйтергә кирәк. Мин көмештән эшләнгән муенса янында да озак басып тордым. Аның ясалу урыны «Поволжье», ягъни, Идел буе дип кенә күрсәтелгән, чоры—X-XI гасырлар. Аның астына нигәдер «Гривна» дип язганнар, бу инде урысларда борынгы акча берәмлеге. Музей хезмәткәре дә шулайрак аңлатты, имеш, акчалары беткәч, шушы муенсаның баш-башын кисеп түләгәннәр. Урысларда, бәлки, шулай да эшләгәннәрдер, әмма борынгы болгарларда бармак яссуы бу божра-муенсалар серле көчкә ия дип исәпләнгән һәм аны югары дәрәҗәдәге кешеләр генә кигән.


*Һун-болгар-татар истәлекләре*

Болардан тыш та музейда болгар әйберләрен шактый очратырга мөмкин, әмма аларның күпчелеге шкаф асларында, аерым махсус урыннарга кертеп куелган. Мин биредә авызына туфрак капкан бронза үрдәкне дә, ат рәвешле йозакларны да, борынгы болгарларның эш һәм сугыш коралларын да, пыяла мәрҗәннәр, бизәнү әйберләрен дә күреп кайттым, алар барысы да Шәһри Болгарныкына тәңгәл иде. Музей хезмәткәрләре аларны бирегә Болгардан китергәннәр, дип баралар, ә кайбер нәрсәләр Чәрдәннен үзендә ясалган булырга да мөмкин бит! Данир Закиров үзенең югарыда телгә алган китабында бу якларда болгар ювелир үзәге булган, дип яза һәм Чәрдән янында бизәнү әйберләре ясый торган кораллар һәм калыплар /матрица/ табылганлыгын хәбәр итә. Бәлки галим Мирфатыйх Зәкиевнең, бу якларда көмеш табылган, дигән сүзләрендә хаклык бардыр, чөнки Чәрдәннән ерак түгел башланып киткән Төньяк Урал тауларында алтын да, көмеш тә табылып тора. Алай булганда, болгар бабаларыбызның Чәрдәнне бер сәяси һәм сәүдә үзәге итүләре аңлашыла, күпчелек көмеш әйберләрнең биредә ясалуы да бик мөмкин хәл.

Музей хезмәткәрләре һәм җирле тарихчылар үзләре дә Идел Болгарстанының Чәрдәнгә, Югары Камага тәэсирен берничек тә әйләнеп уза алмыйлар һәм бу экспонатларда да ачык чагыла. Дөрес, алар биредә болгарларның шәһәрләр төзеп яшәп ятуларын ничек тә йомшартып күрсәтергә тырышалар, барысын да сәүдәгә генә кайтарып калдырырга телиләр, ә инде Чәрдәннең, Югары Каманың Идел Болгарстаны составында булуын бөтенләй әйтмиләр.

«Особенно устойчивыми были связи с населением Волжской Болгарии, существующей с VIII по XIII вв. на Нижней Каме и Волге,—дип язылган музейдагы болгар чоры экспонатлары янына.—Болгары основывали в Прикамье торговые фактории, через которых к родановцам в обмен на пушнину и соль поступали бытовые вещи и предметы роскоши, ювелирные украшения из серебра, бусы из стекла и камня, бронзовые зеркала и ткани. Часть изделий изготавливали в Болгаре и Биляре—столице Волжской Болгарии, а некоторые предметы болгарские купцы привозили в Верхнее Прикамье из Средней Азии и Китая.»

Алай да, болгарларның бу якларда сәүдә нокталары булганлыгын таный җирле тарихчылар, әмма шуннан ары китмиләр. Безгә, ни булса да, үзебезгә Чәрдәнгә барып, болгар-татар тарихы белән бәйле табылдыкларны, истәлекләрне җентекләп өйрәнергә һәм җирле матбугатта чыгышлар ясарга кирәк. Бу темага Казанда яки Пермьдә фәнни конференцияләр уздырсаң да яхшы булыр иде. Безнең тарихта иң аз өйрәнелгән урын—төньяк икән, урыслар язганга ышанып, без Төньяк Уралны, Каманың югары агымында урнашкан җирләрне тулысы белән аларга бирдек, ягъни, урыс тарихы итеп язарга мөмкинлек тудырдык. Ә ул җирләрдәге скиф, һун,

болгар, татар тарихын кая куясын? Дәшмәскәме? Әмма биредәге урыслар, безнең дәшмәүдән файдаланып яки белем-мәгълүмат җитмәү сәбәпле, татарларга канэчкеч бер кыргый халыкка караган кебек карыйлар, бөтен матбугатлары, китаплары, хәтта сәхнә күренешләре «явыз татар»ны тасвирлау белән тулган...

Шуна күрәдер, мине музейда һәм шәһәрдә озата йөрүче Марина Ивановна, гафу үтенгәндәй, әйтеп куйды: «Сез безне дөрес аңлагыз, биредә без, урыслар, татарларга караганда җирле коми-пермякларны якынрак күрәбез, чөнки алар безгә татарлар кебек яу белән килмәгән, ә татарлар унбер тапкыр Чәрдәнгә һөҗүм иткәннәр!» Мин дә аның соравына сорау белән җавап бирдем: «Ә сез беләсезме, ни өчен татарлар Чәрдәнгә һәм бу тирәдәге кала-салаларга шулай һөҗүм итеп торганнар соң?—дидем мин.—Чөнки алар, татарлар, үзләренекен кире кайтарып алырга теләгән. Чөнки биредә сезгә, урысларга кадәр татарлар яшәгән, урыслар басып алганнан соң, биредә аларның кол ителгән туганнары калган, ата-бабаларының каберләре калган, урыс кул астында мәчет-мәдрәсәләре калган, ә сезнекеләр ул мәчет-мәдрәсәләрдән чиркәү-монастырьлар ясаган... Менә ни өчен татарлар Чәрдәнгә һөҗүм итеп торган, алар аны кире кайтарып аласыларына ышанганнар, өметләнгәннәр... Безнең урында сез булсагыз, нәкъ шулай эшләр идегез...»

Марина Ивановна уйга калды, аннан әкрен генә әйтеп куйды: «Узган тарихка беркайчан да бу күз белән караганыбыз юк иде... Димәк, дөньяда башка төрле караш та була ала икән...»,—диде ул.

Ә музей диварыннан безгә Төньяк Уралны чукындырырга килгән урыс попларының сурәтләре карап тора иде, ә елгага җирле халык, татар ирләре куып кертелгән...

## Чәрдән өчен сугышлар һәм чукындыру тарихы

XV-XVI гасырларда Чәрдән һәм тирә-юньдәге кала-салалар өчен урыслар һәм татарлар арасында 11 сугыш була. Дөрес, аларның кайберләрендә җирле халыклар—вогул-остяклар, комилар да катнаша, әмма аларның да күпчелеге татар ягыннан торып сугыша, чөнки алар бу вакытта инде татар дәүләтләре составында булалар. Урыс тарихи чыганакларында һәм елъязмаларда «Пермь Великая» дип аталган Чәрдән җирләре өчен көрәш Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларына туры килә. Ана хәтле урыслар бу тирәләргә борын тыгарга куркалар, тагы да төньяктарак булган Усть-Вымьнан ары уза алмыйлар. Бу хакта урыс тарихчылары үзләре дә ачыктан-ачык яза, бары тик татарлар хуҗа булганга гына бөтен Төньяк Уралны басып ала алмауларын әйтәләр:

«Пермская земля издревле привлекала к себе внимание русских князей, и только монголотатарское иго тормозило ее колонизацию,—дип яза алар.—После распада Золотой Орды происходит бурный рост Московского княжества за счет присоединения уделов Северо-Восточной Руси и земель северного Приуралья.» */Защитники Перми Великой.—Чердынь, 2007,—С. 4./*

Урыс чыганакларында Чәрдән беренче тапкыр 1451 елда искә алына, Вычегда-Вымь елъязмасында князь Михаил Ермоличның Мәскәү князе Василий Темный тарафыннан Чәрдәнгә «наместник» итеп билгеләнүе хәбәр ителә. Әмма билгеләнү—ул әле идарә итү дигән сүз түгел, бигрәк тә—башка халыклар яшәп яткан ерак ил-җирләр белән... Урыс тарихчылары монда да үз-үзләре һәм бер-берләре белән каршылыкка керәләр. Әйтик, «Пермский край. Чердынь» дип аталучы китап-юлкүрсәткечне чыгаручылар */Петербург, 2009/* бу борынгы җирләрдә электән коми-пермякларның ата-бабалары гына яшәгәнлеген язалар: «Разумеется, история земли Чердынской гораздо древнее: первые поселенцы этих мест, предки коми-пермяков—родановцы, еще VIII—IX вв. основали свое городище на Троицком холме и селище на Вятском», дип хәбәр итә алар /11 б./, әмма монда электән болгар-татар шәһәре булуы турында дәшмиләр. Икенче җирле тарихчы Г.Н.Чагин дөреслеккә якынрак килә, Чәрдән һәм тирә-яктагы башка шәһәрләрнең бары тик 1472 елда гына урыслар тарафыннан яулап алынуын, ана кадәр бу якларда вогул-остяклар һәм татарлар яшәгәнлеген яза: «Собирание земель и присоединение к Москве все новых и новых территорий



5.*

привело московских князей на верхнюю Каму. Отряд, посланный в 1472 г. Иваном III, успешно выполнил поставленную задачу. Взял городки Чердынь, Покчу, Искор, Урос и привел всю землю ту за великого князя». / *Чагин Г.Н. Народы и культуры Урала в XIX—XX вв.—Екатеринбург, 2003,—С. 4./*

Алай да, сорау туа—1451 елда Чәрдәнгә Мәскәү тарафыннан урыс кнәзе билгеләп куелган икән, нигә бу якларны, шул исәптән, Чәрдәнне дә 1472 елда тагы сугышып яулап алырга иде? Һәм урыслар Чәрдәнне һәм башка тирә-яктагы шәһәрләрне кем кулыннан тартып алалар соң? Моңа җавап итеп, уйлап чыгарылган роданов кабиләләрен, ягъни, җирле комиларны, мансиларны күрсәтәчәкләр. Әмма бу кабиләләрнең беркайчан да үз дәүләтчелекләре булмаган, алар нигездә татарлар кул астында яшәгәннәр, шулай ук аларның калалары да булмаган, алар күпчелек очракта урманнарда яки су буендагы сала-авылларда яшәгәннәр. Димәк, 1472 елда урыслар Чәрдәнне татарлар кулыннан тартып алган булып чыга? Ул вакытта кем басып алучы соң—үз җирләре һәм дәүләтләре өчен көрәшүче татарлармы, әллә инде бу җирләрне, шәһәр-авылларны канга батырып сугышып алучы килгән-килмешәк урысларммы?

1472 елгы «Россиягә кушылу» сугышы турында югарыда телгә алган «Чердынь. Путеводитель» китабы тагы да ачыграк яза: «Окончательное присоединение Перми Великой к Московскому государству завершилось в 1472 г. военным походом князя Федора Пестрого и воеводы Гаврилы Нелидова. Поход начался зимой 1471 г. из Великого Устюга. Войска, разделившись у Анфалова города, один за другим захватили укрепленные пермяцкие городки Урос, Покчу, Чердынь и Искор. Князь Ф.Пестрый резиденцию московских наместников перенес в Покчу. 26 июня 1472 г. Великий князь московский Иван III получил весть о взятии Пермской земли. Князя Михаила и его воевод вместе с военными трофеями отправили в Москву. Михаилу сохранили княжеский титул, и он продолжал оставаться наместником Москвы в Перми Великой.» */Күрсәтелгән хезмәт, 11-13 б./*

Тагы сораулар туа—ни сәбәпле үзәкне Чәрдәннән Покчага күчергәннәр, ул бит шактый җайсыз җирдә, тагы да төньяктарак урнашкан? Әллә Чәрдәнне алулары барып чыкмаганмы? Шулай ук Чәрдәнне чукындыру һәм анда беренче христиан храмын салу да күп сораулар тудыра. Бөтен урыс тарихчылары бертавыштан, Чәрдәндә яшәүче коми-пермякларны урыс побы Иоан-Богослав 1462 елда чукындырган дип язалар, ә аның исемендәге ирләр монастыре, имеш, 1463 елда ук салынган. Чәрдәнне 1472 елда гына басып алгач /әллә алганннар, әллә юк/, ничек анда ун ел алдан монастырь салып куеп була икән? Мөгаен, Чәрдән ул елларда кулдан-кулга күчеп йөргәндер, шул бер арада урыс миссионерлары, хәзерге Сыктывкар якларындагы Усть-Вымьнан килеп, берничә кешене чукындырып та киткәннәрдер. Әмма ничек шул арада хан сараедай таш чиркәү төзеп куярга мөмкин? Мондый ашыгыч эш бары тик мәчетне чиркәүгә әйләндергәндә генә мөмкин. Кыйблага карап торган бу монастырь-чиркәүне мин дә барып карадым һәм элек монда мәчет булган дигән фикергә килдем. 1451 елда ук Чәрдән белән идарә итү өчен билгеләнгән кнәзь Михаил 1472 елга хәтле кайда качып яткан соң, ни эшләгән, нигә аның хезмәтләре турында урыс чыганакларында берни юк? Хәер, кайбер хезмәтләрдә Мәскәүнең кнәзь Михаилга ышанып бетмәве турында, аны татарлар белән бергә эш йөртә, дип шикләнүләре дә әйтелә. Һәм нигә аны 1472 елда Мәскәүгә кайтарып җибәрәләр, ә үзәкне Чәрдәннән әллә кайдагы Покчага күчерәләр һәм Чәрдән 50 ел буе башкала булудан туктап тора? Бу сорауларның берсенә дә җавап юк, урыс тарихчылары аны эзләми дә, чөнки артык төпченү һичшиксез, татар тарихына китереп чыгарачак...

Шунысын да әйтергә кирәк, җирле халыклар беркайчан да урыс басып алуына да, көчләп кертелгән христиан диненә дә риза булып тормаганнар, гасырлар буе моңа каршы көрәш алып барганнар. Әйтик, 1455 елда ук, Мәскәү кнәзе бирегә үз наместнигын куеп азапланганда, вогул юлбашчысы Асык үзенең улы Юшман белән Вычегдага барып, «Пермь атакае» Питиримны үтереп кайта. Бу хәл Мәскәүне тагы да ярсытып җибәрә, урыслар җирле халыкларга каршы канлы сугышлар һәм суешлар оештыралар. «Московские власти начинают карательные военные действия против непокорного и незащищенного населения Приуралья и Зауралья,—дип яза болар

турында татар тарихчысы Габделбәр Фәйзрахманов.—Наиболее жестокие походы на вогулов, остяков и других племен Москва предпринимает в 1465, 1485 и 1499 гг.» */Күрсәтелгән хезмәт, 181 б./* Әлбәттә, болар барысы да көчләп чукындырулар, тәре үптерүләр аша бара. Әмма урыс тарихчылары боларны куертырга яратмый, бирелә бөтен матбугат «татар басып алучыларының явызлыклары» белән тулган...

Урысларның Төньяк Уралга 1472 елгы яулары аерата рәхимсез була, 4 мен кешелек жәза отряды белән Великий Устюгтан бирегә килеп, алар 41 шәһәр һәм авылны утка тоталар, канга батырып, басып алалар, жирле халыкларның 58 юлбашчысын кылыч астында Россиягә баш иярга мәжбүр итәләр, коллык белән ризалашмаган бик күп татарларны үтерәләр. */Бу хакта мәгълүматны табарга була: Алексеев М.П. Сибирь в известиях западно-европейских путешественников и писателей.—Иркутск, 1941,—С. 134; Устюжеский летописный свод.—С.167, 168, 189, 209; Фәйзрахманов Г. Күрсәтелгән хезмәт, 181 б./*

Бу сугышта урыс воеводасы Гаврила Нелидовның жирле халыкка карата кылган явызлыкларын елъязмачылар да яшереп калдыра алмыйлар, теркәп куялар, бу хәлләр халык хәтерендә дә яхшы саклана. Шушыларга нигезләп, Чәрдән язучысы Светлана Володина үзенең «Легенды и сказания Чердынской земли» китабында «Легенда об Уросе» дигән очеркын да урнаштыра: «Что и говорить—грозовою тучею налетел Нелидов на уросцев. Всех, кого в деревне нашел, лютой смерти предал. Ни младенцев в люльках, ни стариков немощных не пощадил. За огонь ночной полил землю северную горячей кровушкой.» */Володина С. Легенды и сказания Чердынской земли.—Пермь, 2004,—С.146./*

Әмма язучы ханым Урос авылында кемнәр яшәгәнен әйтми һәм бу урыс белән урыс арасындагы сугыш кебек аңлашыла. Ә бу авылда бит татарлар һәм ислам динен кабул иткән жирле халыклар яшәгән! Менә кемнәрне авылы белән суеп чыккан урыс гаскәриләре, язмадан күренгәнчә, ана хәтле алар инде Искор-Искәрне ут төртеп яндырган булганнар: «Где там им с москвитами сладить! Они уже к Покче подбираются, а Искор весь до тла пожгли, окаянные!» */Күрсәтелгән хезмәт, 143 б./*

Әлбәттә, татарлар да моңа жавапсыз калмыйлар, бераз тернәкләнү белән, Себер ягыннан килеп Юграны туздыралар. «В начале XVI в. тюменские татары под руководством царевича Кулук-Салтана, сына Ибака повоевали всю нижнюю землю, разорили Усолье на Каме, русских вывели и перебили» дип яза Г. Фәйзрахманов югарыда телгә алган китабында. /Күрсәтелгән хезмәт, 187 бит./ Эш шуңа барып житә ки, Себер татарлары 1535 елда урысларның Уралдагы башкаласы булып торган Покчаны ут төртеп яндыра, шуннан соң үзәк Чәрдән шәһәренә күчерелә. Урыс чыганакларында Чәрдәндә шушы вакыттан агач кремль салына дип язылган, ләкин безгә калса, ул кремль татарлар идарә иткән заманнардан ук булган һәм урыслар әзер кирмәнгә кереп утырганнар. Ни өчен шулай дип язам, чөнки кремль берничә көн эчендә генә төзелә торган нәрсә түгел. «Кремль был спланирован по рельефу местности, имел шесть башен, глубокий ров и высокий вал,—дип яза Чәрдән буенча юл күрсәтү китап-брошюрасы.—В укрепленном городке находился гарнизон стрельцов, хранилось вооружение. Чердынская крепость выдержала 11 осад со стороны татар и вогул.» */Күрсәтелгән хезмәт, 13 б./*

Тарихчылар әйтүенчә, Чәрдән кремле XVIII гасырда янып юкка чыккан. Әмма ничек кремль хәтле кремль юкка чыгарга мөмкин икән—анысы билгесез. Мин Чәрдән кремле урынын күрдем, Колва елгасы ярында тау башына урнашкан булган ул. Анда археологлар казу эшләре дә алып барганнар, әмма ни сәбәпледер, эшне туктатканнар, мөгаен, «жайсыз» әйберләр чыга башлагандыр. Алай да, жир астыннан казып чыгарган таш нигезне кире күмеп куя алмаганнар, ул Чәрдәндә татар тарихының тере шаһиты булып, маңгае белән кыйблага карап инрәп ята... Мөгаен, бу урында да мәчет булгандыр...

Чәрдән уртасында бер храм-часовня бар, ул 1547 елда татарлар тарафыннан үтерелгән 85 урыс гаскәрие хөрмәтенә ачылган. Бирелә бу вакыйгага һич онытылырга ирек бирмиләр, үлгән урыслар хөрмәтенә тәре йорешләре уздыралар, татарларны хурлап китаплар язалар. Менә нигез булып урыс елъязмаларындагы «В сем году /1547/, января 6-го, бысть побиение, от набега ногайских татар, Чердынского

уезда, Кондратьевой слободе, над Вишерою рекой, 85 человек...» дигән сүзләр тора. Ягъни, татарлар белән бу сугыш Чәрдәндә түгел, Вишера елгасы буендагы Кондрат бистәсендә була һәм шунда 85 кеше үлә. Имеш, боларның мәетләре җәйге челләдә боз белән агып килгән һәм аларны Чәрдәнгә алып кайтып күмгәннәр, иртән 85 кешенең исеме язылган такта кисәге пәйда булган икән... Икенче бер урыс галиме И.Я.Кривощеков исә, әле XX гасыр башында ук Чәрдән өязен һәм бу сугышны бик нык өйрәнеп, бөтенләй башка төрле фикер әйтә. Ул Кондрат бистәсе янындагы сугышны татарлар белән бәйләми, ә җирле мәҗүси халыкларның үз диннәре өчен христианнарга каршы, көчләп чукындыруга каршы сугышлары, ди: «Нападение в 1547 году на Кондратьеву слободу и уничтожение в ней 85 человек, в числе их инока-миссионера, ясно говорят, что это мщение соседних некрещенных инородцев пермичей и вогул, живших в окрестностях Кондратьевой, а не нашествие Ногайских татар, которым, как магометанам, было также мало дела до обращения пермичей-язычников в христианство, как их соплеменникам башкирам и другим монгольским народностям.» /*Кривощеков И.Я. Словарь географическо-статистический Чердынского уезда Пермской губернии.—Пермь, 1914. Кн.I.—С.39.*/

Әмма шунысын да әйтергә кирәк, бу вакытларда җирле халыкларның бер өлеше, вогул-остяклар, коми-пермяклар, бигрәк тә аларның юлбашчылары инде ислам динен кабул иткән булалар һәм төркиләшәләр. Һәм алар алга таба ислам динен дә яклап урысларга каршы сугышалар, Себер һәм Казан татарлары да аларга ярдәмгә мөселман кардәшләрен коткару өчен дип киләләр. Әмма күпчелек урыс галимнәре нигәдер мәсьәләнең бу ягына игътибар итмиләр, киресенчә, үзләренең басып алуларын аклау өчен, җирле халыкларны үтә кыргый һәм авызларыннан кан тамып торган мәҗүсиләр итеп күрсәтергә тырышалар. Әмма бу һич кенә дә алай түгел, төрки-мөселманнар белән бергә гасырлар буе аралашып, берләшеп яшәгән җирле халыклар инде аларның мәдәниятен дә үзләштерә башлаган була.

Бүгенге тарихчы Г.А.Бординских 1547 елгы урыс-татар сугышына башка төрлерәк карый, ул татарларның Пермь якларына бу һөҗүмнәрен Казан вакыйгалары белән бәйли. Билгеле булганча, Мәскәүдәге урыс хөкүмәте Казанны беркайчан да тынычлыкта калдырмый һәм 1545 елда аның өстенә Түбән Новгородтан, Вяткадан һәм Чәрдәннән гаскәр җыеп җибәрә. Әмма казанлылар бу өч отрядны да чорнап алып юк итәләр, кайбер тарихчылар исә аларның Казанда күп татарларны харап итеп өлгерүен яза. 1546 елның гыйнварында Казан ханы Сафа Гәрәй тәхетеннән төшерелеп тора, әмма июль уртасында, нугайлардан гаскәр туплап, ул яңадан Казанга кайта һәм хан тәхетенә утыра. Менә шушы чорда Казан ханы, нугай гаскәриләре ярдәмендә, Пермь җирләрен кире кайтарып алырга омтылып караган булырга да мөмкин, чөнки 1545 елда Казанны юк итәргә Чәрдән урыслары да килгән була бит!. Тарихчы Бординскихның язуынча, нугай-татар гаскәрләре Кама буйлап югары күтәреләләр, урысларны Соликамскида туздыра башлап, Чәрдәннәрне үтеп, төньяктагы Искорга хәтле барып җитәләр. Бу сугышлар берничә ай барган булырга тиеш.

«Насколько позволяют судить летописи, ни позже, ни раньше Великопермская земля таких потерь не несла,—дип яза тарихчы Бординских.—У Кондратьевой слободы погибло 85, а у Верх-Боровой 40, в Соликамске и его окрестностях 886 человек. То есть всего летописи зафиксировали гибель 1011 человек. Плюс погибшие в Вильгорте, под Искором и, может быть, еще в других местах. Большие территории Перми Великой были опустошены.» /*Защитники Перми Великой.—Чердынь, 2007, стр.10.*/

Чәрдән урысларынын 1545 елда Казанга килеп күпме татарны үтергәннәрен без белмибез, ә биредә һәр кеше санаулы. Әйткәнемчә, Чәрдәндә бу вакыйгага онытылырга ирек бирмиләр, ул милләтне күзгә күренмәгән дошманга каршы берләштерергә ярдәм итә, ахрысы. Хәтта балалар өчен әкият рәвешендә язылган китапларда да татарларны эт итеп сүгәләр, сабый күңеленә аларның куркыныч образларын салып калдыралар. Сүзем дәлилле булсын өчен, шундый китапларның берсеннән мисал китереп үтәм:

«В те времена, когда Чердынь Пермь Великая в православную веру обращалась,

когда открывался чудскому народу свет Христова, не было покоя древней земле от набегов вражских. Нападали на чудь татары казанские, сибирские да ногайские, жгли нещадно селенья мирные, убивали без жалости всех, кто ко Христу взоры свои обращал. Не по нутру пришлось, видно, татарам, что селился в Прикамье русский люд, единого Бога знавший, а не идолов резных деревянных.» /*Светлана Володина. Легенды и сказания Чердынской земли.—Пермь, 2004, стр.34.*/

Автор бу китабында татарларнын тетмәсен тетә, аларны «лютый враг», «недруг», «несметная орда», «черная лавина» дип тә атый, «злые вороги и головы свои поганые здесь сложили» дип тә өстәп куя. «Не на жизнь, а на смерть бились ратники с неприятелем, грудью стрелы татарские принимая, и пали защитники все до единого в жестоком сражении, но ни на шаг не отступили пред силою грозною, не пустили орду на Чердынь-град», дип нәтиҗә ясый ул. /*Күрсәтелгән хезмәт, 35 б.*/ Бу юлларны укыгач, урыс баласының татарга мөнәсәбәте нинди буласы билгеле инде—ул ана тарихи дошманы итеп карый башлый һәм һәр адымда аннан үткәннәр өчен үч алырга тырыша. Татарларга бүгенге тискәре мөнәсәбәт еллар буе менә шундый китаплар аша да тәрбияләнде инде...

Тагы урта гасырлар Чәрдәненә кайтыйк әле...

Урыслар Пермь җирләрен басып алсалар да, монда татар тормышы тиз генә юкка чыкмаган, татарлар әле шактый еллар Чәрдән, Искәр, Урос, Гайнә, Покча, Ныроб, Соликамски һәм башка кала-салаларда яшәүләрен дәвам иткәннәр. Бу елларда Чәрдән кремленә ясалган 11 һөҗүм—ул читтән килгән татарларның гына явы түгел, ә туган туфракларында яшәүче милләттәшләребезнең һәм башка җирле халыкларның да урыс басып алуына, көчләп чукындыруларга каршы көрәшләре булган. Әмма Казан һәм Әстерхан ханлыклары юк ителгәч, Пермь җирләрендәге татарларның да хәле авырая, алар дошман белән бергә-бер калалар. Ул арада Явыз Иван, алга таба Себер ханлыгын басып алу хыялы белән, Строгоновларга Урал һәм Себер җирләрен тарата башлый—1558 елда ул аларга 20 ел салым түләмәү хисабыннан бу якларда зур җир биләмәләрен бирә. 1570 елда инде Строгоновлар 8 миллион дисәтинә Урал җирләренә хуҗа булып алалар, анда Конкор, Орел-Каргедан, Нижний Чусовой, Верхний Чусовой калаларын төзетеп куялар.

«Во время первой переписи Перми Великой в 1579 г. в Чердынском, Соликамском уездах и в вотчине Строгоновых насчитывалось 220 сельских поселений с 514 дворами и 1985 человек мужского пола. Самыми крупными поселениями были уездные города Чердынь и Соликамск и Орел-городок—центр вотчины Строгоновых»,—дип яза тарих фәннәре докторы Георгий Чагин. / *Чагин Г.Н. Народы и культуры...—С. 4* /

Строгоновларның тимер базларында, чуен заводларында, тоз шахталарында, төрмә-утарларында күпчелек кол ителгән җирле халык—вогуллар һәм комилар, татарлар бил бөгә, аларны чылбыр-богауларга бәйләп егылып үлгәнче эшләтәләр. Строгоновларның җир биләмәләре, тимер һәм тоз базлары арткан саен коллар да күбрәк кирәк була бара, ул колларны сакларга һәм камчылап эшләтергә юлбасар казакларны яллыйлар. Менә шул башкисәр казаклар, инде Уралның аргы ягына да чыгып, Себер ханлыгы биләмәләрен, ханты-манси җирләрен талый башлыйлар, Самар каласында моңа кадәр тиңе булмаган суеш оештыралар, җирле халыкны кол итеп, көчләп чукындырып, Строгоновларның базларына китереп ташлыйлар.

Әлбәттә, бу хәлләр Себер татарларын нык тетрәндерә һәм алар, җирле халыклар белән берләшеп, Уралны үтеп чыгып, Строгоновларның кала-салаларына һөҗүм итәләр, аларның төп максаты кол ителгән милләттәшләрне, дин кардәшләрне коткару була. Тарихка кереп калган татар яуларының берсе 1573 елда була, Күчем ханның улы Али солтан һәм абыйсының улы Мөхәммәткол, 10 мең кешелек гаскәр белән килеп, Чусовой буйларында Строгоновларның утарларын туздырып ташлыйлар, бик күп колларны азат итәләр, төрмәләрен җимерәләр. Строгоновлар исә үзләре Соликамскига качып котыла.

Урысларга каршы шундый ук яуны 1581 елны вогул князе Кихек оештыра, ул Соликамскины яндыра, урысларның күп кенә кала-салаларын юк итә. «В 1582 году вогулы напали на Чердынь, многие жители были убиты, имущество

разгромлено», дип яза Г. Фәйзрахманов, Миллерның «История Сибири» хезмәтенә таянып, югарыда искә алынган китабында. /187 б./ Бу елларда Пелым кнәзе Аблай-Гәрәйнең дә урысларның кала һәм салаларына көчле һөҗүмнәр ясавы билгеле. Әйе, җирле халыклар беркайчан да урыс басып алуы белән килешмәгәннәр, үзләрен һәм диннәрен яклап гасырлар буе көрәшкәннәр, инде чара калмагач, үз эчләренә бикләнгәннәр...

Нәкъ шушы елларда, Ермакның Себергә һөҗүмгә әзерләнүен белеп, Күчем хан да аңа каршы Уралга үзенең гаскәрен җибәрә. Элеккеге тарихчылар бу датаны 1581 елның җәе дисәләр, бүгенгеләре 1582 елның җәе, дип язалар. Кыскасы, Күчем ханның олы улы Али солтан җитәкчелегендәге зур татар гаскәре, атларга атланып, Урал тауларын үтеп чыгалар, Чусовойдан башлап, Чәрдәнгә хәтле җирләрне яулап алалар, урысларның кала һәм салаларын туздыралар, бик күп кол татарларны һәм җирле халыкны азат итәләр. Бу хәлләрдән соң Чәрдән воеводасы В.Пелепелицын Мәскәү патшасы Явыз Иванга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була, ул Строгоновларны үзләренең казакларын Себергә җибәрү сәбәпле, Чәрдәнгә ярдәм итә алмауда гаепли. «...Строгоновы послали своих казаков 1 сентября в Сибирь, и в тот же день на Пермь Великую напали кучумляне и пелымские манси, осадили город и многих людей побили», дип яза ул Мәскәүгә Строгоновлар һәм Ермак өстеннән. /*Чердынь и Урал...—Пермь, 1999, стр.110.*/

Али солтанның бу хәрби сәфәрдә шактый озак—елга якын булганлыгы билгеле. Моның сәбәпләре дә бар—беренчедән, урыс кул астындагы татар җирләрен һәм кол ителгән җирле халыкны тулысынча азат итү максаты булса, икенчедән, кышка калгач, Урал аша атлы гаскәргә юл юк. Тарихта гаҗәп хәлләр була, бу очракта да шулай килеп чыга—анда, Себердә, Ермак татарларның кала һәм салаларын туздырып йөри, ханлыкның башкаласы Искәрне ала, монда, Уралда, Али солтан урысларның кала һәм салаларын туздырып йөри, борынгы Искорны яулап ала... Бер-берләреннән мең чакрымнар ераклыкта яткан ике Искәрнең бер исем белән аталуы да бик гаҗәп. Хәзер икесе урынында да буш кыр... Әмма Себердә дә, Уралда да Искәргә онытылырга мөмкинлек бирмиләр, татарлар—дога кылып, урыслар—тамашалар куеп, бу вакыйгаларны гел искә алып торалар.

Минем кулыма 2001 елның 14 сентябре көнне Чәрдәннән ерак булмаган борынгы Искор-Искәр җирләрендә уйналган театраль тамашаның сценарие килеп керде. Ул Чәрдән җирендә булган тарихи вакыйгаларны театрлаштырган рәвештә торгызу—«Набег ногайских татар из Сибири на городок Искор в 1581 г.» дип атала. Тамашаны бөтен Россиядән җыелган галимнәр, сәнгатькәрләр һәм миңа якын кеше карый, ул ачык һавада, борынгы Искәрдән ерак булмаган Бастарып кырында уздырыла. Әлбәттә инде, урта гасыр урыслары һәм татарлары булып үзешчәннәр уйнаган, татарларның башында—төлке койрыгы, өсләрендә—чуар үзбәк халаты, урысларда—тимер көбәләр һәм очлымнар...

Ә тамаша мондый: тыныч кына яшәп яткан урысларга нугайлар һөҗүм итә. Урыслар белән нугайлар арасында сугыш башлана, ике яктан да күп кеше үлә. Ниһаять, урыслар татарларны җинә, урманнан монахлар чыгып, чиркәү җырларын җырлый башлыйлар. Шунысын да әйтергә кирәк, бу тамашада монахлар булып җырлап торучылар—Татарстанның Раифа монастыреннан махсус килгән «Притча» вокаль квартеты була.

Инде тексттан бер өзек китерик:

«1581 г...на поляне—рубленная крестьянская изба, обнесенная изгородью. В ней живет семья: мать, отец, трое сыновей и дочь. Мирная картина...скромный крестьянский быт...Вдруг из леса выбегает младший сын и кричит, что неподалеку ногайцы. Слышны свист, крики. Из леса мчится лошадь, на которой убегает от ногайцев дочь. Семья укрывается в избе. Один из ногайцев забегает в избу, учиняет страшную расправу над семьей. Ногайцы поджигают жилище...» /*Чердынский край: прошлое и настоящее.—Чердынь, 2003, стр.71.*/

Менә шулай язылган һәм сәхнәгә куелган. Сценарийның авторы—Чәрдән районы иҗат үзәге директоры Е.Н.Дьякова, консультанты—тарихчы Г.А.Бординских, икесе дә хакимият кешеләре. Инде тарихтагы Искор-Искәр турында да бераз

чын мәгълүмат бирел үтик. Биредә бу сүзне комичадан «ис»—таш, «кар»—торак урыны дип тәржемә итәргә тырышалар, әмма ул татарчадан «иске жир», «борынгы жир» кебек тә аңлашыла. Урыс елъязмаларында Искәр 1472 елдан искә алына, әмма ул тарихта IX гасырлардан ук билгеле, бу хакта тарихчылар В.Н.Берх һәм В.А.Оборин җентекләп язалар. Чәрдәннән тагы да төньякта, зур сулардан бераз читтә, урман-таулар арасына урнашкан Искор-Искәр жирле халыкларның һәм болгар-татарларның уртак шәһәре булып торган булырга тиеш, ул ин нык саклана торган кирмән булган һәм Пермь жирләрен Печора һәм Вычегда якларыннан килгән яулардан каплап торган. Биредә Кор /Кар/ исемле легендар патша идарә иткән, борынгы легендаларда аның вогул һәм югра кабиләләренә каршы көрәше тасвирлана, димәк, ул алардан булмаган. Мина калса, риваятьләрдәге Кор ул болгар-татарларның төньяк олыслары белән идарә итүче атаклы Кара бик морза яки аның нәселеннән булырга тиеш.

Заманында мин Кара бик шәжәрәсе, Кар иле татарлары турында үземнен «Таралып яткан татар иле» китабымда язган идем инде. */Казан, 2003.—102-158 б./* Татар тарихында бу нәселдән дә серле токым юктыр, мөгаен. Алар язып калдырган дистәләгән шәжәрәләрдән күренгәнчә, бу Нухрат татарлары үзләрен Сократ хәким нәселеннән дип баралар, тагы да ерак нәсел башында исә Нух галәйһиссәлам тора, аның углы Яфәстән туган буын арасында КОРы хан, КОРЛУ ханнар да бар, әлбәттә, КАРАГЫЛ-КАРА хан да теркәп куелган. Әйткәнемчә, алар төньяк олысларда яшәгәннәр һәм идарә иткәннәр, бу—хәзерге Киров өлкәсенең төньягы ягъни Нократ һәм Кама елгалары буенча барып, төньяктагы Гайнә иленнән, Чәрдәннән һәм Искор-Искәрдән кул сузымында гына. Кем белә, бүген урыс галимнәре бик тырышып күтәргән серле Кор патша, бәлки, шушы Кар иле татарларыннан Кара бик яки Кор, Корлу ханнар булгандыр... Шул ук вакытта угыз дастаннарындагы Коркут ата һәм Күр углы да аңа шактый якын. Кор патша турында урысча шигырьдә //предание/ исә аның Урал тауларына гына түгел, Обь, Иртыш, Тубыл буйларына да хуҗа булганлыгы әйтелә:

*Наш могучий Кор прекрасный,*
*Богатырь рыжебородый,*
*Золотой кудрей блистает.*
*Некогда он шел войною*
*На вогулов и на йогра...*

*.......................................*
*Покорились царю Кору*
*Остяки, вогулы, угра,*
*Обь река, Иртыш прекрасный,*
*И Тобол узнал о Перми,*
*О владеньях царя Кора*
*У истоков светлой Камы...*

*/Чердынь. Путеводитель...—С. 12./*

Әмма бүгенге кайбер урыс тарихчыларының Кор-Карны бик тырышып «татарларга каршы көрәшкән» фин-угыр халкы вәкиле итеп күрсәтәселәре килә, болгар-татар дип әйтә алмыйлар бит инде! «Древний Искор был крупным военно-оборонительным центром, что подверждается находками предметов вооружения,—дип яза алар.—Центральная часть Искорского городища, около 400 кв.м., ограниченная вторым и третьем валами, является основным местом святилища... Местным населением это место называлось княжим местом, что связано с именем легендарного царя Кора, оказавшего сопротивление татарам.» */Чердынь. Путеводитель.—Петербург, 2009,—С. 90./*

Борынгы Искор-Искәр урынында инде хәрабәләр генә калган, ә бүгенге Искор авылы аннан 5 чакрымда урнашкан һәм үзенең чиркәүләре белән данлыклы. Ни гажәп, биредә дә Сөембикә манарасына бик нык охшаган, кызыл кирпечтән салынган жиде яруслы чиркәү бар. Ә борынгы Искәр шәһәре урынына урыслар

часовня салып куйганнар, часовня имеш нугай татарлары тарафыннан җәберләнгән изге Параскева Пятница исемен йөртә һәм анда җирле халыкларны чукындыру һәм татарлар белән сугыш рәсемнәре ясалган. Искәр часовнясы открыткасының артына язылган текст та татар темасын әйләнеп үтмәгән: «На северной стороне изображена сцена крещения жителей Перми Великой в XV веке. Над входом запечатлен момент защиты городка Искор от набега татар», дип язылган. Шулай, синең өеңә кереп утыралар да, син аны кире кайтарып алырга омтылгач, сине үк юлбасарлыкта гаепли башлыйлар...

Алай да, бу якларда меңнәрчә ел яшәгән болгар-татарлар кая киткән соң, алар барысы да үлеп беткәнме, яки килгән татарларга ияреп китеп барганмы, әллә эш бөтенләй башкачамы? Әлбәттә, татарлар үлеп тә бетмәгән, барысы да китеп тә бармаган, исән калу өчен милләтен һәм динен алмаштырырга мәҗбүр булган. Әгәр бер халык, яшәү яки үлем алдында калганда, әлбәттә, нинди хәлдә һәм халәттә булса да, яшәүне сайлый. Инде тирә-яктагы бөтен татар дәүләтләре юкка чыгып беткәч, инде урыслар бу якларда мәңгелеккә тамыр җибәргәч, инде алар арасында татар-мөселман булып сакланып калу алга таба мөмкин булмагач, татарлар әкренләп урыс милләте составына күчеп бетканнәр. Шуңа күрә бу якларда урыс теленең аерым сөйләше бар, ул «ялгыш сөйләм» дип атала һәм Себер татарлары, мишәрләрнең диалектын нык хәтерләтә. Шуңа күрә биредә чиркәү-часовнялар да кыйблага караган, монастырьлар тирәсенә күмелгән борынгы каберләрдән дә кыйблага карап яткан мәетләр чыга, шуңа күрә татарлар белән бәйле урыннарны җирле урыслар үзләре дә сизмичә изгеләштерә, шуңа күрә тирә-яктагы күпчелек кала һәм салалар татар исемнәрен йөртә. Сүзем дәлилле булсын өчен, җирле тарихчы Әмир Фатыйховның «Гәйнә иле» китабыннан Чәрдән ягының татар авылларына кагылган урынны тулысынча күчереп үтәм:

«28. Чердынь өязе. Гәйнә авылы—Гәйнә олысының үзәге. 1905 елда 140 йортта 883 /465 ир-ат, 418 х-к/ исәпкә алынган, аларның 59ы бернинди ширкәттә теркәлмәгән. в. Агафун мыс—3 йортта ун ир-ат, ун х-к, пермяклар дип күрсәтелә. Өяздә бернича Тыла авыллары булган. Тулпан, Курья, в. Кокуй, в. Кукуйские Ключи—1905 елда выселкада 1 йортта 4 кеше /3 ир-ат, 1 х-к/ исәпкә алынган.

Чердынь районы. Татарлар аны Чардин дип йөртәләр, риваятьләрдә дә шулай әйтелә һәм языла. 1969 елгы белешмәдә /*«Адм.-террит.деление Перм.обл.»*/ аның IX йөздән билгеле булуы искәртелә. Татарстан Фәннәр Академиясе академигы М.Әхмәтҗанов аны Ибраһим хан төзеткән кала дип саный. Купчик—1969 елда 264 кеше яшәгән. Салтово, Султанова—беткән авыллар. Остяцково—остяк, истәк сүзеннән икәнлеге күренеп тора. Баяндино /икенче исеме Курья/—1905 елда 63 кеше яшәгән. Казанцево—«поселение на старице Камы», 1905 елда 67 кеше теркәлгән. Искор а/с-да М.Искор—434 кеше. Керчевский—р.п. 1969 елда 5900 кеше. Верх.Керчево—66 кеше /1905/. Нижн.Керчево—1969 елда 231 кеше. Турчанка—26 кеше. Тулпан—село, 1905 елда 122 кеше. Черепан—«Чура+пан», 125 кеше. Талово, Чусовской, Бондюг /Бәнд елгасы/; Крымкор—Чердынь каласының төньяк өлеше. Муртым—беткән авыл. Муртым—татар телендә куыш агач дигән сүз. Юмыш—без бу атама белән Янеч авылында очрашкан идек. Бу авылга нигез салган Юмыш бабай Янеч авылы урнашкан Уба елгасының уң кушылдыгы Юмыш елгасына да исемен калдырган. Кутамыш—Язва буендагы авыл. Шереметьево—беткән авыл, Шеремейка атамасы белән бер тамырдан. Еловка—елга, аның буенда авыл да булганга охшый, ләкин «Список»ларда теркәлгәне очрамады. Вәриз—андый атамалы авыл Барда районында да бар иде. Чусовское озеро—Вишера елгасының башы. Сакиново—1969 елда 60 кеше. Ялпач—тау, таш атамасы.» /*Күрсәтелгән хезмәт, Барда, 2002,—425-426 б.*/

Хәзер бу авылларның күпчелеге юк инде, шул ук вакытта мин бу якларда Бигич /биредә язучы Николай Асанов туган/, Урол, Булат, Урос, Курган, Будым, Чуртан, Кебрат, Солым исемле төрки-татар атамалы авыллар барлыгын да белдем. Тирә-юньдәге елга-су исемнәренең дә нигезендә татарлык ярылып ята—Тимшәр, Шөгер, Килтмә, Улыс, Чу суы, Бигич күле, Кимзил, Мудыл, Сәрдә...

Кайчандыр биредә Татарское дип аталган авыл да булган, әмма ул инде юкка

чыккан. Чәрдән читендә, төньякка чыгу юлы өстендә, урыс зиратына каршы татар зираты да булган, ул да юкка чыккан, соңгы татарларны урыс зиратына күмгәннәр...

Әйе, милләт киткән, башка халәткә күчкән, ә җир-су атамаларында исеме калган...

## Чәрдән чиркәүләре, Кремль һәм истәлекле урыннар

Төньяк өлкәләрдә, Урал алдында һәм Каманың югары агымында христиан диненең йогынтысы һәм чукындырулар шактый иртә башланган һәм гасырлар буе дәвам иткән. Әле 1383 елда ук Вычегда елгасы буендагы Усть-Вымьда Пермь епархиясе ачылуын һәм урыс миссионерларының җирле халыкны чукындырырга тырышуларын да әйтеп үтәргә кирәк. Әмма бу попларның күбесен җирле халык үтерә барган, беркемнең дә үз теләге белән динен бирәсе килмәгән. Бары тик Казанда, Әстерханда, Себердә мөстәкыйль татар дәүләтләре юкка чыкканнан соң гына христиан дине Уралда үзенең тамырларын җибәрә һәм бөтен төньяк өлкәләрне чорнап ала, җирле халык көчләп чукындырыла һәм әкренләп урыслашырга мәҗбүр була.

Җирле халыкны кулда тотуда христиан диненең ролен урыс патшалары да яхшы аңлый һәм моның өчен көчен кызганмый. Моны урыс тарихчылары үзләре дә яшереп тормыйлар: «Важную роль в закреплении власти московских князей на присоединенных землях сыграла Русская Православная Церковь,—дип яза алар.—С принятием христианства в Перми Великой, как известно, начинается процесс вхождения уральских земель в Русское государство.» */Защитники Перми Великой.—Чердынь, 2007.—С. 4./*

Казан алыну белән Явыз Иван күзен Себер ягына төби һәм бу юнәлештә беренче адымнарын Уралны христианлаштырудан башлый. 1552 елда ул Соликамски шәһәренә, татарлардан саклану өчен дигән булып, икона җибәрә, Строгоновларга Казаннан Чәрдәнгә кадәр арада чиркәүләр төзергә рөхсәт бирә. «1552 г.—царь Иван IV Грозный пожаловал жителям Соликамска икону Святителя Николая чудотворца, чтобы она защищала православный город от сибирских татар,—дип яза бу хакта тарих китаплары.—1565 г.—митрополит Афанасий потвердил благословением жалованную грамоту своего предшественника митрополита Макария, по которой разрешалось Григорию Аникиеву сыну Строгонова «церкви божии ставити и игуменов, и попов, и диаконов призывати к нему в слободу на Каму-реку, меж Великой Перми и Казани», а «слободским игуменам и попам крестить по уставу святых отец в нашу православную христианскую веру греческого закона...приходящих иноземцев, татар, вогуличей и югричей.» */Г.Н.Чагин. Курсәтелгән хезмәт, 110 б./*

Шунысын да әйтергә кирәк, 1570 елда Чәрдәндә инде 11 чиркәү булган /Чагин, күрсәтелгән хезмәт, 108 б./, ә 1623-1624 елгы хисаплаулар буенча—бередә инде 16 чиркәү, 2 монастырь эшли башлаган, бу—300 йортлы Чәрдәнгә! Әйтерсең лә бөтен дөнья бөтен эшләрен бер читкә ташлап, чиркәүләр генә төзи башлаган! Юк, әлбәттә, бу чиркәүләрнең күпчелеге әзер биналарга—мәчет өсләренә корылган булырга тиеш. Шуңа күрә алар барысы да кыйблага карап тора, шуңа күрә бу чиркәүләр ике тамчы су кебек мәчетне хәтерләтә. Бүгенге көндә исә Чәрдәндә «Воскресенская» дип аталган төп чиркәү бар, Иоан-Богослав монастыре эшләп тора, бер часовня бар, ә элеккеге Успенски чиркәвендә хәзер «Музей веры», ягъни, праваслау дине музее. Бу—5,5 мең кешегә, ә дүрт гасыр элек мең кешегә егермеләп чиркәү эшләп торган!

Дин музее җитәкчесе Марина Ивановна Ветчакова белән Чәрдән чиркәүләрен карап йөрибез. Менә шәһәрнең төп чиркәве—Воскресенски соборы, ул җиде яруслы, кызыл кирпечтән салынган һәм Сөембикә манарасын хәтерләтә. Мөгаен, Колва елгасы ярына урнашкан бу чиркәү шәһәрдә иң биек бинадыр. Аны 1754 елда салынган дип баралар, эчендәге диварларга җирле халыкларны чукындыру сурәтләре эшләнгән. 1930 еллардан 1990 еллар башына кадәр бу чиркәүне Мәдәният сарае итеп файдаланганнар, хәзер исә ул янадан үз вазифаларын башкара. Без чиркәүнең побы белән дә очраштык, халыкның

ни дәрәҗәдә дин тотуы белән кызыксындык. Поп зарланып алды, аның әйтүенчә, Чәрдәндә аена 30-35 кеше үлсә дә, җеназага /отпевать итүгә/ чакырса 1-2 кеше чакыра икән, ягъни, мәетләрне попсыз күмәләр дигән сүз. Халык чиркәүгә дә бары тик зур христиан бәйрәмнәрендә генә йөри икән, башка көннәрдә чиркәү буш тора, керсә дә, староверлар /иске христиан дине тотучылар/ гына кагылырга мөмкин.

Чәрдән побын да, староверлар кебек ихластан дин тотучы Марина Ивановнаны да тагы бер нәрсә борчый икән—Чәрдән җирендә янадан мәҗүсилек баш калкыта башлаган. Бу хәлләр Пермь язучысы Алексей Иванов «Чердынь—княгиня гор /*«Сердце Пармы»*/» китабын чыгаргач бигрәк тә көчәеп киткән диләр. Биредә ел саен «Сердце Пармы» дип аталган фестиваль уздырыла башланган, шунда бөтен Россиядән унышар мең кеше җыелып, барабаннар кагып, шаманнар белән бергә мәҗүси ритуаллар башкарып, куныш-төнеп яталар икән. Моңа христиан дине әһелләре бик борчылалар, әмма берни эшли алмыйлар—халык шуна тартыла. Ә ни өчен тартыла—алар моның сәбәбен белми дә, эзләми дә. Ә сәбәп бик өстә ята—биредәге урысларның күпчелеге көчләп чукындырылган вогуллар, коми-пермяклар һәм татарлар, аларның һәрберсе христиан диненә үзенең гореф-гадәтләре белән килгән. Җай чыгу белән, ирек килү белән алардан христианлык коелып төшкән, аның астыннан мәҗүсилек килеп чыккан, бары тик староверларда гына дин нык калган. Минем уемча, көчләп чукындырылган татарларның да бер өлеше староверлар ягына күчкән булырга тиеш, чөнки аларның дин тотулары безгә якынрак, алар попларны танымыйлар, хатын-кызлары баштан-аяк капланып киенә һәм гыйбадәт кылганда, мөселманнар кебек сәҗдәгә китәләр. Староверлар—үз милләттәшләреннән коточкыч зыян күргән, урыс православ дине тарафыннан иң нык эзәрлекләнгән, тереләй утларда яндырылган, суларга батырылган, меңәрләп башлары киселгән, сазлыкларга, кара урманнарга куып кертелгән искечә дин тотучылар алар...

Әмма Чәрдән җирендә христиан дине яшәү рәвешенә әйләнеп китә алмаган. Мин моны Иоан-Богослав монастырь-чиркәвендә дә күрдем. Ул көнне урысларның изгеләре дип йөртелгән Радонежскийны искә алу көне иде, ә чиркәүгә ник бер кеше килсен! Бөтен шәһәрне янгыратып чаңнар сугып та карадылар, урамнарда белдерүләр дә эленеп тора иде, ә халык килмәде, чиркәү чаңнарын басып китәргә теләгәндәй, урамнарга Пугачева, Распутина җырлары агылды, урыслар чиркәүгә килеп вәгазь тыңлауга караганда җырлап-биеп бәйрәм итүне артыграк күрделәр, ахры... Хәер, безнең үзебездә дә шул хәл түгелмени соң?

Иоан Богослав монастырена аерым тукталып үтәсем килә. Ул да кыйблага карап тора, бөтен барлыгы, төзелеше, рәвеше белән татар мәчетләрен хәтерләтә. Урыс тарихчыларының язуынча бу—Чәрдәндә иң беренче салынган монастырь икән. «Чердынский мужской монастырь Иоана Богослава был основан в 1462-1463 г. для того, чтобы служить оплотом и рассадником православия в Перми Великой» дип язылган Чәрдән шәһәре тарихи-мәдәни мирасны саклау идарәсе тарафыннан чыгарылган открыткада. Әйе, монда бу сүзләргә гадәти нәрсә итеп карыйлар, нәкъ шулай булырга тиешле эш итеп кабул итәләр. Монысы—идеология, әмма тарих мәсьәләсенә килгәндә, бу монастырь белән очы-очка ялганмый. Имеш, ул башта агачтан булган, аннан аның янына 1624 елда икенчесен салганнар, аннан, болар янып беткәч, 1718 елда хәзерге монастырь бинасын төзеп куйганнар икән. Табып кара син моннан дөресен, бөтен кешегә бу монастырьны 1462-1463тә салынган дип әйтәләр, шуның белән горурланалар, тирәнрәк казына башласаң, юк, анысы янган, монысы җимерелгән, ә соңгысы 1718 елда гына төзелгән, диләр. Әмма үзенең кем нигезендә утыруы турында бина үзе сөйләп тора—бөтен рәвеше, кыяфәте, кыйбла тарафка карап торышы белән...

Болардан тыш, Чәрдәндә тагы берничә чиркәү бинасы бар, әмма алары үз вазифаларын башкармый. Борынгы кремль урынында да чиркәүләр булган, әмма хәзер анда инде берни калмаган. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Чәрдән җиде калкулыкка урнашкан, шуның берсендә, Колва ярындагы иң биек урында кремль булган. Дөрес, урыс тарихчылары аны 1535 елда, Покча татарлар тарафыннан яндырылгач кына төзелгән дип баралар. Миңа калса, бу кремль элек-электән—татар заманыннан ук булган, чөнки урысларда кремльнең үзе дә, сүзе дә булмаган, алар

күбрәк кәлгә-крепостьлар белән саклангannnар. Бу кремль XV гасыр урлары белән чорнап алынганлыгын да әйтергә кирәк. Урыс тарихчылары исә үзләре үк биредә урнашкан борынгы шәһәрлекнең моннан унбиш гасыр элек булганлыгын язалар, ә X-XV гасырларда биредә фин-угыр кабиләләре яшәгәнлеген әйтәләр. Гаҗәп, монда барысына да урын бар, тик болгар-татарга гына берни каралмаган! Тагы бер ачыкланып бетмәгән нәрсә кала—урыс тарихчылары язганча, Чәрдән кремле 1535 елда төзелгән, ул ничек татарларның 11 явына каршы тора алды икән? XVI гасырда татарларның Чәрдәнгә берничә явы гына билгеле бит. Димәк, Чәрдән кремле өчен бу сугышлар XV гасырда ук башланган, димәк, кремль ул вакытта ук булган?

Урысларның 1535 елда ашык-пошык агач кремль салып ятулары да бик гаҗәп, саклану чаралары, әлбәттә, таштан булырга тиеш иде! Агач версиясе исә урысларга соңыннан бу кремльнең янып юкка чыгуын исбатлау өчен кирәк булгандыр, мөгаен. Шунысы гаҗәп, бүгенге көндә кремль урынында берни калмаган, әгәр аны чыннан да урыслар төзегән булган икән, алар ана тарихларының бер өлеше, архитектура истәлеге итеп карарга тиешләр иде. Ә монда—үлән үсеп утыра торган буш кыр, галимнәр бер таш нигезне казып чыгарганнар да, эшне туктатканнар. Әстерханның урысныкы дип йөргән кремле астыннан да татар кабер ташлары чыга башлагач, эшне туктатып, ябып куйганнар иде. Монда да шундыйрак хәл, ахры. Ләкин без Чәрдәндә тиз генә дөресен белә алмабыз, мөгаен, могҗиза белән башка җирдә болар хакында берәр борынгы чыганак тапсак кына инде...

Шушыларны уйлап, мин Чәрдән кремле урынында шактый утырдым...

Җәйге йомшак җил, тынычландырырга теләгәндәй, битләремне сыйпап үтте, күзем елга аша җәелеп яткан урманга, урманнар аша күккә үрләгән кыя-тауларга текәлде... Колагымда Атилла улларының, Кара хан, болгар-татар морзаларының гайрәтле авазлары яңгырап киткәндәй булды, җирне—татар яугирләренең ат тояклары тавышы, күкне азан моңы күмеп киткәндәй тоелды... Мин, гасырлар тәсбихен тартып, мең ел узганнарга, мең ел киләчәккә киттем, Аллаһтан яңадан бу җирләргә иман нуры индерүен сорадым, ил-җирне саклап шәһит киткән бабаларыбыз рухына дога кылдым...

Китәр алдыннан тагы бер тапкыр ялгызым гына Чәрдәнне әйләнеп чыктым...

Менә бу йортта 1888 елның җәендә язучы Дмитрий Наркис (Нәркис?) улы Мамин-Сибиряк тукталган һәм бераз яшәгән. Чәрдән төбәген, якын-тирәдәге авылларны өйрәнеп, ул дистәләгән хикәя, очерклар, тарихи күзәтүләр язып калдырган. Бу як материалыннан файдаланып балалар өчен язган «Серая шейка», «Емеля-охотник», «Зимовье на Студенной» әсәрләреннән тыш, Мамин-Сибиряк Чәрдән тарихына караган «Старая Пермь», «Три конца» хезмәтләрен дә иҗат иткән. Шулай ук аның биредә яшәүче әнисенә һәм сеңелесенә язган йөзләгән хаты да бар, алар Мәскәүдә, дәүләт китапханәсендә саклана. Шуларның берсендә Мамин-Сибиряк Чәрдән якларында борынгы болгар шәһәре булганлыгын әйтә. Үзе дә биредән ерак булмаган Висимо-Шайтански заводында туган әдип чукындырылган татарлар нәселеннән булса кирәк, шунлыктанмы, ул урыс булмаган халыкларга карата бик хәерхаклы, аның иҗаты әле бу күзлектән чыгып өйрәнүне сорый.

Менә хастаханә бинасы—аның икенче каттагы биек тәрәзәсеннән 1934 елның җәендә шагыйрь Осип Мандельштам сикергән. Аны «Мы живем, под собою не чуя страны» шигыре өчен Сталин палачлары кулга алалар һәм өч елга Чәрдәнгә сөргенгә сөрәләр. Башта—конвой астында күп көннәр поезд белән, аннан пароходта килеп алҗыган, бөтен нәрсәдән өметен өзгән Мандельштам саташа башлый, ул гел үзен атарга алып чыгып китүләрен көтә һәм алардан качу өчен тәрәзәдән сикереп, кулын сындыра. Анна Ахматова һәм Борис Пастернакның ярдәме белән, бу хәлләрдән соң аның сөргенурынын Воронежга алмаштыралар. Әмма Мандельштамны сөрген срогы тулганнан соң, 1938 елның маенда икенче тапкыр кулга алалар һәм ул шул елның декабрь азагында Себер төрмәләренең берсендә үлеп кала... Сталин аңа беркайчан да үзе турында язган шигырь юлларын кичерми...

*Мы живем, под собою не чуя страны,*
*Наши речи за десять шагов не слышны.*

*А где хватит на полразговорца,—*
*Там припомнят кремлевского горца...*

Кызганычка каршы, Чәрдән жире бүген дә төрмәләр иле булып тора, иман китү белән, бирегә золым килә һәм үз халкына да китереп суга, хәтта урыс патшаларының нәселен дә бирeдәге зинданда юк итә. Чәрдәннән 45 чакрымнар төньякта Ныроб исемле бер бистә бар, шунда 1601 елның көзендә, урыс патшасы Борис Годунов әмере белән, булачак патша нәселе вәкиле Михаил Романовны аяк-кулларын богаулап китереп ташлыйлар, чөнки Годунов бу нәселнең хакимияткә килүеннән курка. Михаил Романовны биредә базга ыргыталар һәм эт кебек, тимер чылбыр белән агач баганага бәйләп куялар. Аңа өстән бик аз күләмдә ипи-су ташлыйлар, катып үлмәсенә утын ыргыткалыйлар, ә жирле халыкны чокырга якын килүдән тыялар. Алай да жирле халык бу бичара тоткынга ярдәм итәргә тырыша, шуның өчен аларның барысын да тотып җәзалыйлар. Шушы коточкыч авыр шартларда Михаил Романов кыш чыга, 1602 елның августында исә аны үз сакчылары буып үтерә, чөнки аларның тизрәк Мәскәүгә кайтып китәсе килә. Романовны шул тирәдә күмәләр, ә инде Мәскәүдә хакимият үзгәргәч, сөякләрен шунда алып кайтып китәләр, ә Ныробта исә ул үлгән урынга чиркәү һәм часовня салып куялар.

Михаил Романовның өч потлы тимер богаулары бүгенгесе көндә Чәрдән шәһәренең крайны өйрәнү музеенда саклана. Әлбәттә, аңа карарга да куркыныч, ул адәм баласы күтәрерлек түгел, әмма шушы богаулар бүгенгесе көндә дә табыну объекты булып торалар, аны килеп үбәләр, нидер сорыйлар, авырулардан терeләбез дип ышаналар. Биредә газап күреп үлгән «мученник» Михаил Романов хөрмәтенә фәнни конференцияләр, тәре йөрешләре үткәрелә, китаплар языла, фильмнар төшерелә. Гаҗәп ил инде бу—башта газаплап үтерәләр, аннан шуңа табына башлыйлар. Югыйсә тәүбә итеп, шушы явызлыкларны башка кабатламаска гына кирәк бит инде... Ныробта бүген дә зур төрмә бар, бу тирәләр хәзер «зона» дип атала. Чәрдәннән 100 чакрым ераклыкта, Соликамскида «Белая лебедь» дип аталган төрмә бар, анда гомерлеккә хөкем ителгәннәрне бикләп тоталар, Салман Радуевны шунда кыйнап үтерәләр...

Минем Чәрдәнгә килүем дә миңа каршы җинаять эше ачылган һәм мин «гаепләнүче» дип игълан ителгән вакытка туры килде, шуңа күрә бу якларга прокуратураның махсус рөхсәте белән генә чыгып киттем. Шунлыктан, музей архивларындагы һәм китапханәләрдәге борынгы китаплар һәм кульязмалар белән дә тиешенчә танышып өлгерә алмадым, кайбер тарихи урыннарга да барып житеп булмады. Әмма мин биредә күргән кадәремнән дә бик канәгать калдым, чөнки татар тарихы буенча дөнья кадәр яңа нәрсә белдем!.. Мин биредә татарларга басып алучы явыз кавем итеп карауларын теләмим, ә үз жирендә, үз илен, телен һәм динен яклап көрәшкән төп халык итеп кабул итүләрен телим.

Шулай ук мин Казанда яки Пермьдә тарихи татар Чәрдәне темасына фәнни конференцияләр үткәрелүен телим, чөнки безнең дәлилләребез күп, хакыбыз зур, без дә бу җирләрдә үз каһарманнарыбызны күтәрергә тиеш... Тарихта 1430 еллардан ук билгеле булган, татар белән урыс арасында кулдан-кулга күчеп йөргән Соликамски шәһәре дә Чәрдәннең дәвамы кебек, ул үзе аерым өйрәнүне сорый. Шунысы куанычлы, 100 мең урыс арасында яшәүче 500 милләттәшебез биредә «Кардәшләр» дип аталган татар-башкорт оешмасын төзеп куйганнар, инде менә ничә ел гөрләтеп Сабан туйлары уздыралар, концертлар күрсәтәләр! Чыгышы белән Кукмара районыннан булган Лотфия ханым Нургалиева үзенең шәхси кибетенең зур бер өлешен мәчет итеп биргән, аны рәсми рәвештә мөселман мәхәлләсе итеп теркәткәннәр, хәзер бу мәчеттә Лотфия ханымның улы Рөстәм хәзрәт Галимов имамлык итә. Заманында Явыз Иван бу шәһәрне татарлардан саклау өчен Мәскәүдән махсус икона җибәргән булган, әмма милләттәшләребез дүрт гасырдан соң булса да биредә мәчет ача алганнар, намаз укыйлар, башкаларга да Аллаһның сүзләрен житкерәләр. Мин ышанам, Чәрдәндә дә шулай булыр, иншаллаһ! Рөстәм хәзрәт Чәрдәнгә үзе барып кайтырга булды, ул анда татарларны да эзләп табар, аларга иманга кайтырга да ярдәм итәр дип уйлыйм.

Пермь шәһәренең татар милли-мәдәни мохтәриятендә дә Чәрдән хәлләре белән нык кызыксындылар, чөнки аларның үзләренең дә Чәрдәндә булганнары юк икән. Үзе дә бу яктагы татарлар турында берничә китап язган Данир әфәнде Закиров һәм

милли концертлары белән Соликамски, Березники, Губаха татарларын уята алган талант иясе Әлфинур ханым Тюмисева Чәрдәнгә дә барып чыгасыларын әйттеләр. Без Чәрдән хәлләрен Пермь шәһәре мәчетендә мөфти Хәмит хәзрәт Гәләветдиновка да сөйләдек, аның туганнары да шәхес культы елларында Ныробка сөрелгән булган, Красновишерски төрмәсендә үлгән икән. Кыскасы, ул елларда Чәрдән зонасына күп татарлар сөргенгә сөрелә, урман кисүләрдә үлеп кала, аларның каберләре дә билгесез. Менә бу тема үзе әле аерым өйрәнүне сорый, бу торткын татарларның рухлары безнең килеп өйрәнүне һәм дога кылуыбызны көтеп ята...

## Мәңгелек Атом...

Менә мин, килгән юлым буйлап, тагы мең чакрымнар ара үтеп, мең еллык тарихны кичеп, өйгә таба кайтып барам...

Кама суы башланган җирдән—койган урынына кайтып барам...

Татар тарихының башланган урыныннан—бүгенгесенә кайтып барам...

Тирә-якта—татар тарихы кебек ерып чыкмаслык кара урманнар, милләт фаҗигасе кебек төпсез сазлыклар, кыйтгаларны һәм чорларны урталай бүлгән Урал таулары...

Бу—минем Ана Ватаным, милләтемнең кендек каны тамган җирләр, ата-бабаларым кулларына кылыч алып саклаган мөкатдәс урыннар—Татар Иле...

Урал тауларының ике ягында да кинәнеп җәйрәп ята ул—мең чакрымга мең чакрым сузылган...

Бу юллардан, мина кадәр, дөньяның хуҗасы булып, каһарман Атилла уллары, болгар Кара бик балалары, Чыңгыз хан яугирләре узган, Казан, Себер, Әстерхан, Кырым ханнары мәйдан тоткан...

Моны бар дөнья белгән, бар дөнья таныган, бар дөнья ТАТАР белән хисаплашкан...

Бары тик XVIII гасырда гына, Петр патшаның теләге һәм Ломоносов кебек галимнәрнең тырышлыгы белән, татар тарихы талана башлаган, чөнки урысларның үзләренә бөек тарих кирәк булган, һәм ул татар тарихы хисабына үзенә исем ясарга тотынган...

XVIII гасырда яшәгән олуг швед биологы Карл Линней дөньяның килеп чыгышы, борынгы тарих белән дә нык кызыксынган һәм бу турыда үзенең хезмәтләрен язып калдырган. Шуларның берсендә ул туфаннан соң Нух пәйгамбәрнең көймәсе Котыпта, ягъни, Урал тауларының башланган урынында туктаган дип яза. Шуңа нигезләп, аның тарафдары Николай Карамзин, үзенең «История государства Российского» дип аталган хезмәтендә бу урыннар—монгол, татар, чуд кабиләләренең Ватаны, дип яза:

«...Неизмеримое пространство Северной Азии, огражденное Каменным Поясом /Урал таулары.—Ф.Б./, Ледовитым морем, Океаном Восточным, цепию гор Алтайских и Саянских—отечество...племен Монгольских, Татарских, Чудских... Там, на ГЛАВНОЙ ВЫСОТЕ ЗЕМНОГО ШАРА, было, как угадывал великий Линней, первобытное убежище Ноева семейства после гибельного всемирного наводнения, там воображение геродотовых современников искало ГРИФОВ, стерегущих золото.» */Человек пришел на Урал.—Екатеринбург, 1998.—С. 13./*

Урал тавының ике ягыннан төшеп, кыйтгалар буйлап таралган татар кемнәргә генә канын, җанын, малын, данын бирмәде дә, нинди генә милләтләргә ашлама булмады! Һәм шуларда эреп сеңде... Татар—заманында үз бөек куәре тирәсеннән ычкынган һәм дөнья буйлап адашып йөрүче мәңгелек атом ул... Әмма ул үзенең кемлеген белә, бөек тарихын хәтерли, кан күзәнәкләрендә ул милләтнең асыл өлгесен—матрицасын саклый...

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА,**
*язучы, тарих фәннәре кандидаты.*
*2009 ел, июль ае.*
*Чаллы—Пермь—Чәрдән—Соликамск—Пермь—Чаллы.*

## ДОШМАННАР АРАСЫНДА ДҮРТ АЙ

*1919 елның май-август числоларында Г. Ибраһимов «исемне, төсне, өс-башны» үзгәртеп, йөкче (извозчик) крестьян сурәтенә кереп дүрт ай Колчак тылында йөреп кайта. Маршруты Красноуфимск, Екатеринбург, Төмән, Ишим, Петропавловск. Соңгы пунктка җиткәч, «Башта, подводчик... ямщик, иң соңыннан, Петропавел казначействолсыннан сатучылык шаһәдәтнамәсе алып, авылдан авылга ураклар, чалгылар сатып йөрүче сыйфаты белән...» «һәр сәгате бер гомер... һәр көн үлем көтеп... тирән, үткен тәэсир белән кичергән бу дүрт ай», күренә ки, ниндидер җитди максатлы, яхшы уйланылган сәфәр булган. Әдип аның килеп чыгу сәбәбен әйтми: «Колчак Волгага якынлашып килгән көннәрдә... шул көчле контрреволюциянең артына төшергә карар бирдем», дип әйтелсә дә, чынлыкта бу шул чакта, шундый шартларда кача-поса яшисе (сукбайлык итәсе) иттем дигәнне генә аңлата кебек.*

*Хәзерге язмаларда әдип биографиясендәге бу табышмак булып калган хәл «дошман тылына разведкага җибәрелгән» дип аңлатыла. «Нинди разведкага? Кем җибәргән? Ник нәкъ менә аны? Хәрби белгеч булса бер хәер иде. Г. Ибраһимовны рәсеме буенча да, болай да татар арасында танучы кешеләр аз түгел. Хакимиятнең бөек әдипне мондый эшкә тартуыннан, бәлки, мондый мәгънә дә чыгарып буладыр әле: синең безгә инде кирәгең юк. Без үтереп гөнаһланганчы, үзеңне анда тотып бугазласыннар! «Разведкасы» турында хисап докладының кыскасында шул чор совет газеталарында басыла торган агитацион хәбәрләргә охшаш мәгълүматтан башка бер яңа нәрсә дә күренми. Шул ук аклар үз армияләренә халыкны, янәсе, куркытып, көчләп ала. Аклар солдатлары исә Совет ягына чыгып, акларга каршы сугышыр өчен кызылларның килгәнен генә көтәләр. Татар мәркәз Милли Идарәсе әгъзалары—Колчак ялчылары, һәм алар иң аяныч хәлдә көн кичерәләр һ. б. Хәрби разведка булмаганы кебек, бу сәфәрнең максаты «Милли идарәне» фаш итәргә компромат (яманатларын чыгарырга чын материаллар) җыю да түгел. Ни генә булмасын, бу гаҗәеп эш-гамәл турында олуг әдип үзе язган әлеге документ белән танышу укучыларга татар әдәбияты тарихы җәһәтеннән дә, милли тарихыбыз җәһәтеннән дә кызыклы дип уйлыйм.*

**Мәсгуд ГАЙНЕТДИН**

Колчак бандаларының куркыныч кара болыт рәвешендә Волгага якынлашып килгән көннәрендә мин исемне, төсне, өс-башны алмаштырып, шул көчле контрреволюциянең артына төшәргә карар бирдем. Олаучы (подводчик*) буларак ... нче дивизиябез аркылы Бикбарды заводы төбәгендә сугыш сафыннан кичеп,

* Г. Ибраһимов аңлатмасы. Җәя эчендә бирелгән тәрҗемә сүзләрнең калганнары К.У.ныкы.

дошман аяк астында ыңгырашкан халык эченә чыктым. Башта подводчик, аннан соң теләсә кемне теләсә кая ялланып илтүче ямщик, иң соңыннан Петропавел казначейвосыннан сатучылык шаһәдәтнамәсе алып, авылдан авылга ураклар, чалгылар сатып йөрүче сыйфаты белән Уралны, гарепне, Сибирияне әйләнеп Курган шәһәре аша янадан ... нче дивизиябез фронты аркылы совет туфрагына исән-сау кайтырга муаффәкъ булдым.

Йөреп чыккан сызыгым—Красноуфим, Екатеринбург, Камышлы, Төмән, Ишим, Ялуторски, Петропавел һәм Курган булды.

Һәр көн үлем көтеп, һәр көне, һәр сәгате бер гомер дияр дәрәҗәдә тирән, үткен тәэсир белән кичергән бу дүрт ай бер художник революционер өчен елларча язганда да бетерә алмаслык материал бирде, чишелүе өчен елларча эшләргә мохтаҗ булган мәсьәләләрне алга китереп куйды.

Хәзерге көндә тәфсыйлатка керергә, анда кичергәннәрне бер-бер язарга һичбер имкян (мөмкинлек) юк. Гомер вафа итсә, бераз хәл алу белән мөмкин булганы язылыр. Бу җирдә тик биреләчәк докладымның кыскасының кыскасын гына язып үтәм.

***

1. Мина Колчак гаскәренен бик күп төрлесен, төрле урында, төрле вакытта, бик күп төрле хәлләрдә күрергә, ярлы мазлум олаучы, яки ямщик, яки фәкыйрь сатучы буларак аларның йөрәкләренә камил керергә туры килде.

Бу муаффәкыйтьле (уңышлы) тәхлил (тикшерү) аркасында алган тәэсирем шул: Сибирия контрреволюциясенең оештырган армиясен бер бөтен итеп алсак, шунын зур бер өлеше, яшьрәк-аңлыраклары, бигрәк тә эчке Россиядән, Уралдан алынганнары, ничек кенә булса да, нинди генә авырлыкка төшсә дә, бер чара, бер җай табып Кызыл Армия ягына чыгарга, анда бераз хәл җыйгач, янадан корал алып Сибирия тупрагына оялаган буржуазиягә каршы китәргә омтыладыр.

Икенче бер өлеше—сибириялеләр, бигрәк тә олыраклары, гаиләлеләре, авыллардан, шәһәрләрдән чигенгән вакытта халыктан талап ат, арба алган да, юл буенча киемнәр, мендәр, одеаллар, шикәрләр җыеп, Русиядән урлап төялгән шул нәрсәләр белән үзенең туган җиренә таба тик китеп утыралар. Болар сугышны уйламыйлар да, теләмиләр дә, Кызыл Армиягә каршы тору кирәк дип хис тә итмиләр. Якыннан туп, мылтык тавышы ишетелү белән, буе әллә ничаклы чакрымнарга сузылган бу караклар кәрваны ашыгып атларын җигә дә, тагы шул зур юллар буенча Сибириягә кузгала.

Шулай бара да бара.

Буржуазиянең иң зур таянычы булган казачиларнын да элекке дәртләре, элекке бердәмлекләре юк.

Мин Петропавелга килеп төшкән көннәр шәһәрнең буржуазиясе: бер яктан Күкчәтау казаклары белән фронтовиклар, икенче яктан карт казаклар арасында булуы көтелгән бәрелешү хәбәре белән гадәттән тыш куркуга калган вакытлары иде; беренче груһ (төркем) ачыктан-ачык сугышка барудан баш тарта. Аңар каршы, картлар: «Бармасагыз, барыгызны монда кырабыз!»—дип куркыта икән диләр иде.

Бер яшь казачи үз халыклары арасындагы рухны шулай тасвир итә.—Әгәр,—ди,—большевиклар казачиларны кисеп бетермәячәкләренә сүз бирсәләр иде—без фронтны ачып, кызылларны Омскида зыяфәт ясап (хөрмәт күрсәтеп) кызыл байрак белән каршы алыр идек,—ди.

Агитация өчен яна матур сүз итеп әйтмим, бик күп урында, бик күп солдаттан ишеткәнемне үз сүзләре белән китерәм:

—Заводым юк, фабригым юк, банкым, гәзитем юк: мина большевик белән ник сугышырга?—диләр. Гомумән, ак армия алдына «Ни өчен сугышабыз?»—дигән сөаль (сорау) үзенең бөтен дәһшәте белән баса.

Шул сөаль эшче белән крестьяннан көчләп җыелган солдатның да, үз

көче белән яшәүче казачиның да Кызыл Армиягә каршы этәргән кулын кире төшерәдер.

Казачины фронтта тоткан, аларны бераз сугышырга мәҗбүр иткән сәбәпләрнең берсе «кызыл»ларның үч алуыннан, большевик кулына эләксә, барын да кырып бетерүеннән куркудыр.

Контрреволюция исә бу куркудан бик нык файдалана, аны көчәйтергә тырыша. Сибириядә Русияне гөнаһсыз үтерелгән балалар, хатыннар, картларның гәүдәләре җыелмый, каннары туфан кебек агып яткан бер каберстан итеп тасвир итәргә тырышалар.

Моның нәтиҗәсе шул: Русиядән таланган байлык белән тутырылган эшелоннарны, обозларны күчереп алып китәргә форсат булыр кадәрле фронт тотудан үтмидер. Гүя караклар мал талап кәрван белән качалар, артларыннан куа чыккан халык үзләрен тотып кырып бетермәсен өчен коралланып, атышкалап баралар.



Айлар буенча араларында кайнавым нәтиҗәсендә алган тәэсирем буенча Сибирия контрреволюциясе оештырган армия хәзерендә миңа фалич (паралич) суккан бер гәүдә кебек күренәдер.

Солдат юк түгел. Обозлар да зур. Киендереп, ашатып та карыйлар, приказлар да бирәләр, һич юк өчен яткырып камчылыйлар да, ләкин боларның һич бере фалич зәхмәте кагылган әгъзаны кузгата алмый. Куллар җибәрелгән, сугышырга, Кызыл Армиягә каршы корал күтәрергә кул бармый, шуңа күрә туктаусыз чигенәләр. Бу сугышны башлаган Колчакны сүгә-сүгә чигенәләр һәм чигенәчәкләр.

2. Уралда, Сибириядә яшәүче халыкның «кызылларга, советка, большевикларга мөнәсәбәте исә сөйләсәң, үзе күрмәгән кеше ышанмаслык» бер хәлдәдер.

Уфа губернасының шималендә (төньягында), Пермь губернасында халыкның байтагы, советка каршы бераз кирелек саклаганы, «кызыл»дан курыкканы «сизелә иде». Сибириянең эченә барган саен—мин халыкның йөрәге генә түгел, бөтен һава «кызыл»га, большевикка мәхәббәт, Сибирияне басып торган ак гвардия хакимнәренә дошманлык ялкыны белән кызган, эчкәрәк киткән саен бу ялкынның артканын күрдем.

15 сыеры, 20-30 аты булган «чалдон» Сибирия крестьяны келәтенә 2-3 мең пот иске бодайны тутырганда сабырсызлык белән «кызыл»ны көтә, иге-чиге булмаган түләүләре, крестьянны кешегә дә санамыйча, аны ат урынына камчылап йөртүе, ачыктан-ачык сыйнфый хакимиятне гамәлгә куюы белән гадәттән тыш туйдырып, биздереп беткән ак гвардияне «кайчан дөмегә инде бу этләр» дип кабахәт тел белән сүгә-сүгә большевикны көтәдер.

Азат рухлы, көчле каһарман йөрәкле «чалдоннар» гына түгел, иң гади авыл хатыннарының, «кызыл» бөтен дөньяны ала, имеш, дип сөйләүләрен бик еш ишетергә туры килде.

Бер яктан Кызыл Армиянең каһарманлыгы халыкта гаҗәп матур әкиятләр тудырсалар, икенче яктан кызыл гвардия турысында «Аркаларыбыз челтәрләнеп бетте инде бу этләрнең камчылавыннан» дигән сүз каһәрле бер мәкаль урнында йөридер.

Чалдон ниндидер бер иман белән «кызыл»ның килүенә иман итә, иртәгә кояш чыгуына ничек ышанса, большевик килүенә дә шулай ышанадыр. Коры ышану

белән түгел, «күрсәтербез без бөтен дөньяга!!» дип гайрәт белән күкрәк сугып үтәдер.

Һәммә нәрсәне көчләп алу, көч белән коммунага кертү, хатын, бала-чаганы гомуми ясау, чиркәүләрне абзарга әйләндерү, бала-чаганы, хатын-кызны, картларны үтерү хакындагы хәбәрләрне сөйләүчеләргә «Ялган!» дип кычкырып көлеп кенә каршы аладыр.

3. Сибирия тормышына бу сугыш ике төрле яңа нәрсә бирде. Берсе: качаклар, икенчесе: чигенгән вакытта алып кителгән олаучы-подводчиклардыр. Казаклар үзе бер дөнья, тарихка керергә тиешле хәдисәдер (вакыйгадыр).

Болар әчке Русиядән, Уралдан атлары-арбалары, бала-чагалары, табак-савытлары белән зур юллар буенча өзлексез агалар—көн баралар, төн баралар, атналар, ничә айлар буе баралар. Болар минем җаныма бик тиделәр. Кая гына барсам да каршыма чыгып, йөрәгемне әрнеттеләр.

Контрреволюция башта боларга зур өмид баглады. «Кызыл»ларга каршы җанлы агитаторлар дип карады. Һәм элегрәк болар бераз «хезмәт» тә күрсәттеләр. Шулар һәр авылда, һәрбер кергән кешегә большевик, совет, коммуна хакында дөньяда булмаган ялганнар, кабахәтлекләр тараттылар.

Ләкин Сибириянең эченә кергән саен боларның базары бетә барды. Ахыр чиктә шул хәлгә җиттеләр ки, боларны халык та, солдатлар да ачыктан-ачык сүгә башладылар. Күп акчалылары тимер юл белән Шәркый Сибирия шәһәрләренә барып, кунаклый алдылар. Ләкин авылдан ат белән күчкәннәрне икешәр, өчәр ел буенча киң Сибирия сахрасы буенда аптырап пәришән (таркау хәлдә), сәргәрдән булып (сагышка батып, кангырап) йөрделәр.

Алып чыккан 5-10 мең акчасы беткәч, итеге тузгач, тагып чыккан сыерларын, ике-өч атның бердән артыгын саткач, бара торгач актык арбасын да сатып, хәерчегә әйләнәләр. Бигрәк тә Пермь, Вятка, шималь, Уфа качаклары эштән чыктылар. Татар качакларын әйтергә дә юк инде.

Зур юл буенда мөселман авыллары бер дә булмаганга, ябыгып эштән чыккан атлары, майсызлыктан шыгырдап, адәм көлдереп барган арбалары белән берәр кәләпүшле баш, берәр айлы манара күренмәсме дип, кая барачакны, алда ни булачагын белми аптырап, шул зур урманнарга, салкын боз дингезләренә таба ябыгып, саргаеп беткән гаиләсең иске чүпрәкләргә урап акрын гына өстерәләләр. Акыллыраклары Төмән, Петропавел кебек мөселманлы җирләрдә тукталып калгалыйлар. Болар белән очрашу, сөйләшү минем өчен танысалар үлем димәк булса да, кайбер вакыт туктап сорашкалый идем. Берсенә шаярып:

—Ник монда каласың? Кызыллар килсә, бетерәләр бит үзенне, дигән идем. Аптырап баш селекте дә:

—Сибирия большевиклары бигрәк яман бит... Анда киткән саен...[1]

Һәм чыннан да барган саен эшләре начарлана иде. Качакны сүгәләр, кунарга, чәй эчәргә кертмиләр, кертсәләр дә өй хакын түләтәләр. Мин «ярлы подводчик татарин» һәркайда җылы сүз, якты йөз күрә. Ә өч айдан бирле зур юл буенча өстерәлеп килгән гаиләле качак исә капкадан капкага фатир тапмый йөри.

Сибирия халкының ачулы хыялы болар хакында әллә никадәр әкиятләр дә тудырып өлгергән.

—Семенов качакларны начар авыру таратасыз дип атлары, бала-чагалары, арбалары, нәрсәләре белән бер җиргә өйдергән дә ут төртеп яндырган, имеш. Омскидан үткәч, качакларның үзләрен сугышка, атларын олауга алалар, имеш. Иртышта качаклары тулы ничә пароходны солдатлар юри батырганнар... Белмим, тагы ниләр.

Болар һәммәсе Сибирия халкының советтан качучыларга каршы булган ачуыннан туган хыяллар, ләкин мәгънәле хыяллар.

4. Усак агачыннан алма, иблистән иман өмит иткән ахмаклар дөньяда бармы икән? Әгәр булса, «милли азатлык», милли мохтарият өмит итеп ак

[1] Текстның бу төше кыршылган,берничә сүзне танып булмады. М. Г.

патшачы, тәрече кара урыс Колчак койрыгына тагылган, шуның артыннан Сибириянең карангы тайгаларына кадәрле өстерәлеп барган бичара татар милләтчеләре, мәшһүр «милли идарәче»ләр шиксез ул ахмакларның берсе, бәлки беренчесе булачактыр, мәсьәләгә вакыты белән озак тукталырга туры киләчәк. Хәзергә бик артык күзгә ташланып, бөтен Сибириягә мәгълүм булган бернича гыйбрәтле хәлне әйтеп үтү белән канәгатьләнәм. Гаяз Исхаковлар, Г. Терегулов, З. Кадыйри, Әхтәм мирза, Мамлиев, Туктаров кебек татар буржуазиясенең ялчылары папкаларын күтәреп Колчак вәзирләренең ишекләрен күпме таптасалар да, баш вәзир Вологодскийның швейцарына күпме чәйлек бирсәләр дә әле һаман үзләрен тәсдыйк иттерә (таныта) алмаганнар. 1905 елларда Оренбург-Каргалы мөселманнарының «прошение»ләрен күтәреп, граф Витте швейцарына чәйлек биреп дини-милли теләкләрен алырга йөргән вәкилләрнең ирешкән нәтиҗәләре күпме булса, безнең милли идарәчеләрнең хәле дә шулдыр. Боларны Колчак хөкүмәте танымый, кәгазьләрен, мөһерләрен бер тиенгә дә санамыйдыр. Гади спекулянт советтан качканда аерым вагоннар белән файдалана икән—безнең «милли вәзирләребез» пычрак юлларда, начар арбаларга кәнсәләрияләрен төяп, үзләре яланаяк ат янышнан җәяүләп качарга мәҗбүрләр. (Уфа-Златоуст арасын шулай барулары бөтен Уралга, Сибириягә мәгълүм бер факт). Качканда бер шәһәргә барып житәләр икән дә, нә хөкүмәт, нә җирле мөселманнар квартир бирми, урынлашырга ярдәм итми. Әйберләрен үзләре күтәреп вокзал буйларында хур-зәлил (кадерсез) булып йөргәннән сон иске ташландык мәдрәсәләргә барып урнашалар. Август башында «мәркәз милли идарә» дигән нәрсәнең кәнсәләриясе Омскида, икенче мәхәллә мәдрәсәсенең тузанлы почмагында иде.

Колчак «хәзрәтләре» боларны шул дәрәҗәдә үги күрәдер ки, Сибирия хөкүмәте янында «консул» булып торырга җибәрелгән Солтан бәк Мамлиевны, Туктаровларны солдатка алганнар. Бичара «консуллар» Алаш Урдага китеп, шунын канат астына сыенырга мәҗбүр булганнар.

Боларны үзләре дә яшермиләр. Сибириядәге татар гәзитәләрендә «милли вәзирләрнең мосахәбәләре» (әңгәмәләре) басылып чыккалый. Анда алар: «тәсдыйк ителүебезнең ихтималы барлыгы аңлашылды» диләр. Бу җөмләнең һәрбер сүзе аз гына намусы булган кешене үтерергә җитәрлектер.

Сибирия мөселманнарының мөнәсәбәте исә тагы да ямандыр. Болар «милли идарә»не чынлап танымый, боерыкларына колак салмый, милли салымны түләми, ваклап сәдака бирми.

Байтак акчаларын дини идарә алганга, кулындагы акчаларыннан 60 меңне «милли вәзирләре» картада оттырганга, башкасын спекуляциягә тыгып, вакытында кайтарып ала алмаганга, матди яктан да эшләре бик начардыр. Теге вакытта берәр-икешәр йөз мең вәгъдә иткән байлар исә хәзер сәлам дә бирмиләр.

Шулай татар-башкорт пролетариатының тәненә бер чир, бер бәла булып утырган милли идарәчеләр Сибирия контрреволюциясенең кара дулкыннары арасында да батып, һәлак булып көймәнең сынык такталарында актык сулышларын алып яталар икән, икенче яктан, ике мөселман провокаторның базары көннән-көн күтәрелә барадыр. Боларның берсе—мәшһүр провокатор Вәгыйз Нәүрүзов, икенчесе аксак ишан Корбангалиевтер.

Вәгыйзне Россиядә чагында ике мәртәбә тотып япкан булсам да, ул ничектер котылып колчакстанга барып чыккан. Хәзер гарби (көнбатыш) армия штабы янында «Ватан-ватан» исемендә татарча гәзитә чыгара. «Ватан»нын рухы, мәсләге Мәскәүдәге «Ил», Уфадагы «Тормыш», Казандагы «Корылтай», «Алтай» гәзитәләренең нәкъ үзедер. Петропавелда бу явызга очрап һәлак була яздым.

Гомер бетмәгән икән, язмыш коткарды. Бу әле яңа күтәрелеп бара.

Аксак инде бик нык урнашкан. Татарлар әйтмешли, бу Колчак хәзрәтнең уң кулыдыр. Төп теләкләре бергә кайтса да, ишан хәзрәт белән «милли вәзирләр» бик килешеп бетә алмыйлар. Ишан боларны бик еш камчылап тора. Кайчандыр революционер-социалист булып, ахыр көндә буржуазиягә сатылган Гаязлар,

Туктар, Садрыйлар, милли дини теләкләренә ирешәселәре килеп, аксакның кулын үбеп фатиха алырга тиешләр. Юкса Колчак каршында теләкләре кабул булмаячак. Капиталның, буржуазиянең кечек мәхкүм милләтләргә, милләт мәсьәләсенә нинди мөнәсәбәте саклаганлыгы Европа капиталы тарафыннан оештырылып, башына караучы генераллары менеп утырган контрреволюциянең татар-башкорт халкының мохтарияте, азатлыгы юлында ни-нәрсә бирәчәге үзеннән-үзе ачык эш иде. Моны тик тәгассыптән (фанатизм), кирелектән күзләре сукырайган татар милләтчеләре генә күрә алмады. «Милли идарә» дигән нәрсә баштарак төпсез-тамырсыз бер нәрсә, начар исе белән адәм башын авырттырып торган бер төтен тавы иде. Шуның өчен дә аны татар-башкорт пролетариаты тудырган иде. Безнең милли ахмакларыбыз Колчак ярдәме белән шул чирле туган баланы янадан тергезмәк булдылар.

Шиңгән саен куыгын янадан кабартырга уйлап тагын көчәнепме-көчәнергә тотындылар. Ләкин бар да әрәмгә, бар да юкка.

Без Октябрь революциясеннән элек Уфа урамнарына унар мең мөселман солдаты белән чыгып:

—Бөтен хакимият советларга күчсен!

—Яшәсен иҗтимагый революция,—дип демонстрацияләр ясаган татар-башкорт пролетариат вәкилләрен күп үткәрү өчен әллә ничаклы көч түккән учередилканы ташлап чагып, ачыктан-ачык совет социальный революция оешмаларын тудыра башлаган көннәрдә чехословак бандалары Волганы аша кичеп советның хәле бик артык мөшкелгә калган минутларда да, ничаклы авыр көннәр килсә дә, ахырда һаман пролетариат белән крестьян җиңеп туктаячагына, капитал җимерелеп, хезмәт патша булачагына иман иткән идек. Шул вакытларда ук буржуазиянең җиңеләчәгенә ышанычыбыз зур, тирән иде. Дүрт ай контрреволюциянең, иҗтимагый сугышның эчендә кайнау—бу иманны бергә мең мәртәбә арттырды гына.

Сибириягә оялаган контрреволюция шөбһәсез пролетариат аяк астында изеләчәк. Бәлки, тагы бер җирдә баш күтәрерләр, погонын югалткан ак офицерлар, заводыннан, фабрик-банкасыннан, җир-суыннан аерылган алпавыт-капиталистлар, бәлки, тагын берничә мәртәбә крестьян азатлыгына һөҗүм ясарлар. Бәлки, тагы безгә бик авыр көннәр кичерергә туры килер. Ләкин соңгы сүз безнеке, ахыргы җиңү пролетариатныкы, эшче-крестьян, барча мазлумнарныкы—советларныкы булачак.

Иртәгә кояш чыгачагына ничек ышансак, менә да шулай ышанабыз. Сибириядән алган нәтиҗәләремнең мөһимнәреннән берсе шулдыр. Тәфсилат (җентеклелек, тәгаенлек) исә вакыты белән чыгачак.

**Галимҗан ИБРАҺИМОВ.**
*1919, сентябрь. Чиләбе.*

*«Кызыл Армия» газетасының 1919 елгы 19 сентябрь саны.*
*Хәзерге хәрефләргә күчереп басарга әзерләүче—*
***М. Гайнетдин.***

# МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ ЯКТЫ БЕР ЙОЛДЫЗЫ

ГАБДУЛЛА ШАМУКОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ



***Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 100 еллык тарихын күз алдына китергәндә, минем каршыма берсеннән-берсе гүзәл якты талантлар килеп баса. Шулар арасында иң үзенчәлекле, иң укымышлы, иң талантлы шәхесләрнең берсе—Габдулла ага Шамуков.***

Габдулла Рухулла улы Шамуков 1909 елның 11 декабрендә Сембер губернасы Мәләкәс өязенең Әсән авылында туа. Яшь чактан ук укырга, шигырь ятларга хирыс була. Сүзнең кадерен, мәгънәсен белеп үсә. Әнисе авыз эченнән көйләгән мөнәҗәтләрне сәгатьләр буе тыңлап утыра. Кечкенә Габдулла күңелендә татар халкының моны әйтеп бетергесез тирән эз калдыра. Мәләкәстә укыган елларында ук аңа «китап чире» кагылган була. Кызыклы китапны ятлап, туган авылы Әсәнгә кайткач, бик тә килештереп, рухланып авылдашларына сөйли. Тегеләр шаккатып, исләре китеп тыңлый торган булалар. Мәктәптә драма түгәрәге оештырылгач, Габдулла анда иң тырыш, иң оста «артистларның» берсенә әйләнә, алай гына да түгел, шул түгәрәкнең житәкчесе дә булып китә. Кыз бала ролендә дә чыгыш ясый. Шуннан соң дуслары: икенең берсе, ул йә шагыйрь, йә артист була диләр. Шул сүз житә кала, ул театр белән женләнә башлый, мавыгып пьеса арты пьеса укый. Ничек артист булырга икән дип сорашып, Уфада театр техникумы барлыгын белгәч, Уфага юл тота. Ләкин имтиханнарга соңга кала, нишләргә, кире кайтырга оят, юлга акча да юк. Шунда ул эш эзләп «Яңа авыл» газетасы редакциясенә керә. Редакция хезмәткәрләре зәңгәр күзле, шат күңелле егетне репортер итеп эшкә алалар. Шәп эшкә урнаша, әмма монда мәкаләләр башкорт телендә язылырга тиеш икән бит. Габдулла абый чын мишәр булгач, башкортча белми, язу турында әйтеп тә торасы юк. Шуңа күрә ул бик тырышып башкорт әдәби телен өйрәнә башлый. Кыен була, әлбәттә, мәкалә-репортажларны беренче көннән үк язарга кирәк була бит. Житмәсә, торырга урыны да юк, редактор бүлмәсендә, газетлардан түшәк ясап, идәндә йоклап йөри. Бер вакытны редакциягә Мәжит

ага Гафури килеп керә дә: «Габдулла, бәхетең бар икән, чап тизрәк сәнгать техникумына, анда өстәмә урыннар бирелгән»,—ди. Габдулла абый имтиханнарны бик яхшы тапшырып, артистлыкка укырга керә. Аның беренче укытучысы татар-башкорт театрының күренекле режиссеры Мәкәрим Мәһдиев була. Әле беренче курста укыганда ук аңа Башкорт академия театрында Нәкый Исәнбәтнең «Портфель» исемле комедиясендә самогончы Сәмигулла Фәсмәгулов ролен ышанып тапшыралар. Шушы кечкенә роль белән ул тамашачы мәхәббәтен яулап өлгерә. Бу турыда «Башкортстан» газетасы: «Яшь артист Шамуковка җаваплырак рольләр бирүдән дә курыкмаска кирәк,»—дип, яшь артистка бик зур ышаныч белдерә. Хәзер инде аны дуслары «бәләкәй комик» дип йөртәләр. Ләкин артист шундый бит ул, аның җитдирәк рольләр уйныйсы килә. «Җитди рольләр синең кыяфәтеңә туры килми, син халыкны көлдерәсең»,—дип, аңа зур рольләр бирмиләр, шуңа күрә Габдулла абый режиссерлар янында каш җыерып, җитди кыяфәткә кереп басып тора. Ләкин аңа карап кына барыбер үзе теләгән җитди рольләрне бирмиләр. Габдулла абый җанын шигырь сөйләү белән тынычландыра. Бәләкәй чагында ук нәфис сүзгә булган сәләте ачылганнан-ачыла бара. Шулай да бер вакытны аңа да бәхет елмая. Башкорт академия театрында Әхмәт Фәйзинең «Тукай» трагедиясен куялар. Менә шушы спектакльдә Тукай роле Габдулла абыйның Ходай Тәгалә биргән бөтен мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итә. Ул үзенең чын талантлы артист икәнлеген шушы эше белән раслый. Тамашачы күңеленә кереп калган иң көчле рольләренең берсе бу. Халык күңеленә мәңге онытылмаслык булып кереп калган образ белән артист тудырган образ тәңгәл килергә тиеш. Шунсыз син тамашачыны ышандыра алмыйсың! Габдулла абый бу турыда менә болай дип яза: «Мин бит гади бер артист. Габдулла Тукай исә гади кеше түгел, сәхнәгә чыгып, халык хыялындагы нурлы сурәтне бозармын, халкыбызның шагыйрьгә булган изге хисләрен рәнҗетермен дигән уйлар минем җанымны борчый башладылар. Сәхнәгә килүем дә бәлки саташу гына булгандыр? Театрда ирешкән уңышларым да чын иҗади уңышлар түгелдер? Соныннан үземә бер нәтиҗә ясадым: бу эчке канәгатьләнмәвемнең сәбәбе—бөек Тукай турындагы идеалым белән үзем иҗат иткән образ арасында зур аерманы сизүем булса кирәк. Шундый авыр рухи кризис кичергән чагында, миңа Тукайны күреп белгән «Сәйяр»нең күренекле артисткасы Фәхерниса апа Сәмитова: «Сиңа Тукай ролен биргәннәр дип ишеттем, бик әйбәт, ләкин син уйнарга тырышма, сәхнәдә үзең булып кал, табигый килеш хәрәкәт итсәң, шул җитә. Гримны да җинел генә сал, чөнки син болай да Тукайга охшагансың»,—диде. Фәхерниса апаның шушы сүзләре минем күңелемне күтәреп җибәрде, мин терелеп киттем. Тукайны күреп белгән кешенең миңа карата әйтелгән җылы сүзе шагыйрь образын ачарга шул кадәр ярдәм итте, минем җаным тынычланды, җинел чыгармын сыман тоелды».



*Г. Шамуков Тукай ролендә.*

Минемчә, Габдулла абый гомере буе шушы рольне уйнарга әзерләнгән булган. Әнисе бала чагыннан ук Габдулла Тукай шигырьләрен аның җанына, күңеленә, рухына шундый итеп сеңдергән ки, ул сәхнәгә чыгу белән тамашачы алдына чын шагыйрь килеп баса, чөнки аның Тукай булуына ышанмый мөмкин түгел! Габдулла абый Шамуковның бу эше турында театр тәнкыйтьчеләре искиткеч матур итеп зур-зур мәкаләләр язганнар, тирәнтен өйрәнеп, җитди төстә тикшергәннәр.

Габдулла абый Шамуковның артист буларак сәхнә язмышын хәл иткән рольләренең тагын берсе—Ленин роле. 1941 елда Башкорт академия театры Николай Погодинның «Мылтыклы кеше» әсәрен сәхнәгә куярга алына. Төп роль булган

Ленин ролен Габдулла абыйга ышанып тапшыралар. Бу инде артист өчен иң зур сынауларның берсе була. Йә син шушы рольне уйнап үзеңнең бөек артист булуыңны исбат итәсең, яки шуның белән бөтенләйгә сүнәсең. Мондый рольне театрның иң талантлы актерлары гына уйнарга тиеш, бу—язылмаган закон. Әгәр уңышлы башкарсаң, сиңа исемнәр, дәрәҗәләр явачак, «зур ишекләр» ачылачак. Ленинны уйнар өчен Габдулла абый үзенә үрнәк итеп В. Щукин тарафыннан тудырылган Ленин образын ала. Чөнки Щукин тудырган Ленин образы халык күңелендәге бөек юлбашчы образы белән тәңгәл килә. Ленинны халыкның сәхнәдән шундый итеп күрәсе килә. Менә хәзер күз алдына китерегез башкортча сөйләшә торган Ленинны.


*Г. Шамуков Ленины. Камал театры.*

Моңа тамашачыны ышандыру чиксез авыр. Мескен Габдулла абый Ленинны бик нык өйрәнә, аның күп кенә томнарын укып чыга. М. Горькийның «В. И. Ленин» дигән очеркын һәр көнне сәхнәгә чыгар алдыннан укый торган була. Бигрәк тә Ленинга хас хәрәкәтләрне, рус теленә хас интонацияне өйрәнә. Житмәсә, Ленин сакау бит, «р» авазын әйтә алмый. Башкорт белән татарда һәр сүз саен очрый торган «р»ны әйтми сөйләсәң, тамашачы эче катып көләчәк кенә. Шуңа күрә ул Ленинны сакау итеп уйнарга алынмый. Аның өчен иң кадерлесе—Ленинның фикере һәм эчке темпераменты. Ул үзенең бөтен көчен, сәләтен, акылын шуңа җигә. Тагын шунсы да бар, Габдулла абыйның тышкы кыяфәте Ленинныкына бик якын: зур баш, җыйнак гәүдә, кысылыбрак торган күзләр, борыны, эчтән бәреп торган мөлаемлыгы аны Ленин ролендә кабул итәргә бик нык ярдәм итә. Житмәсә әле Ленин үзе дә кыяфәте белән татар-башкортка бик якын. Габдулла абый РСФСРда милли театрда Ленин образын сәхнәгә менгезүче беренче артист. Габдулла абый Шамуков юлбашчы ролендә сәхнәгә килеп чыгуга, бөтен тамашачы аягүрә басып кул чаба башлый. Сүзен сөйләргә дә ирек бирмиләр, кыяфәте шулкадәр охшаган була ки, хәтта бергә уйнаган артистларга кадәр шакката. Габдулла абый «Шул кадәр каушадым, ничек уйнаганымны хәтерләмим дә»,—дип әйтә торган иде. Мин Мәскәүдә В. Ленин ролендә уйнаган артистларны күрдем, ләкин тамашачының аягүрә басып, алкышлап каршы алганын хәтерләмим. Спектакль Башкорт академия театрының уңышы, башкорт милли культурасының, совет театр сәнгатенең казанышы булып кабул ителә.

Габдулла абый иҗатының гөрләп чәчәк аткан чагында Башкорт академия театрын ташлап, Казанга, Татар академия театрына күчеп килә. Моның сәбәбен белмим мин, хәер, татар артистларының татар театрында уйнарга теләве табигый бит инде. Әмма артист өчен бу бик зур сынау. Белеп әйтәм, чөнки бездә Илшат агай Йомагулов та эшләп карады. Башкорт академия театрының иң талантлы артистларының берсе иде ул. Ә менә бездә үзенә урын таба алмады, кире Башкорт академия театрына кайтырга мәҗбүр булды. Бу—артист өчен зур фаҗига! Чөнки татар-башкорт артисты өчен театрны алыштыру—хатын алыштыру белән бер! Габдулла абый Шамуковның Татар академия театрындагы язмышы киресенчә бик уңышлы башлана. Монда ул үзенең сәхнә эшчәнлеген Ленин роле белән башлап җибәрә (шул ук «Мылтыклы кеше»дә). Габдулла абыйның Татар академия театрында эшләгән эшләре турында театр тәнкыйтьчесе Дания ханым Гыймранова үзенең «Габдулла Шамуков» дигән китабында шундый да тирәнтен тикшереп, аңлатып язган ки, болар хакында янадан язуны кирәк дип санамадым. Мин бары тик үзем белгән, үзем күргән, күңелемә, җаныма кереп калган Габдулла Шамуков турында гына язачакмын. Аны бүген ничек күз алдына китерсәм, шундый итеп тасвирларга тырышачакмын.

Мин Габдулла абыйны артист буларак иң матур чагында күрдем, хәтта бергә уйнарга да насыйп булды. Без итальян язучысы Эдуардо де Филиппо әсәре буенча куелган «Бәйрәм киче» спектаклендә, режиссеры Марсель Сәлимҗанов, ул минем әтием Купьелланы, ә мин аның улы Ненилло ролен уйнаган идем. Репетиция вакытында бер нәрсәгә игътибар иттем. Без артистлар күп вакыт режиссердан ярдәм көтеп ятабыз, ул нәрсә кушса, шуны эшләргә тырышабыз. Режиссер үзе дә шундый артистларны үз итә. Габдулла абый исә рольне үзе күргән-тойганча эшләргә ярата, шуның аркасында режиссерлар белән низагка да кергәли. Аның фикере, дәлилләре шулкадәр дә көчле ки, режиссерлар аны берничек бөгә алмый иде. Үзе тапкан холык-фигыльгә сабый бала кебек куана торган иде ул. Габдулла абыйның бу роле минем күңелемә гомерлеккә кереп калды. Әле дә хәтеремдә, «доктор» Хөсәен абый Уразиков үлеп ятучы синьор Купьеллога: «Бүген сез бик әйбәт күренәсез»,—ди. Габдулла абыйның:—«Сезгә дә шуны телим»,—дип көч-хәл белән, пышылдап кына әйтүе, бөтен залның кычкырып көлүе һаман әле колагымда яңгырый.



*Ш. Хөсәенов. «Әни килде». Г. Шамуков Максуд ролендә.*

Нинди генә сорау бирсәң дә, һәммәсенә җавап таба иде абзый. Таңнар кала идем. Укымышлы кеше иде шул. Кайвакыт юри, бу нәрсә әйтер икән дип тә сорау бирәбез. Берсендә мин: «Габдулла абый, «Канаш» станциясенә килеп җитәбез»,—дип көлеп кенә әйткән идем. «Канаш» ул безнеңчә «Кинәш»не аңлата»,—диде —бу сүзнең дә хикмәтен белә икән бит абзабыз!

Төннәр буе Тукайны, Такташны сөйли, С. Есенинны яттан белә, үзенең мәсәлләре турында әйткән дә юк инде. Гаҗәеп кеше, бер минут вакытын юкка сарыф итми, ихтыяр көче шундый да зур ки, көне-төне эшли, үзенә эш таба белә. Кирәк икән, чын мәгънәсендә гыйльми мәкаләләр яза. Аның татар шигырь төзелеше турындагы хезмәте барыбызны да шаккатырды. Мин бу турыда аерым бер язармын әле. Эсхилны, Софоклны, Еврипидны шундый камил тәрҗемә иткән иде. Шул хәтле дә телгә һәм күңелгә ятышлы ки, моны һич тә мен еллар элек язылган әсәр дип укымыйсың, бүген дә синең җаныңны кузгата торган мәңгелек фаҗига дип кабул итәсең. Башта мин бу титаннарның әсәрләрен рус телендә укыган идем, театрда да карадым, мине бигрәк тә Эдип патшаның язмышы тетрәндергән иде. Габдулла абыйның тәрҗемәләрен укыгач, аларны шул хәтле уйныйсым килде, «Әйдә, Габдулла абый, радиога кереп яздырыйк әле» дип теңкәсенә тиеп беттем.

Миңа В. Шекспирның Габдулла абый тәрҗемәсендә «Чамасына күрә чарасы» спектаклендә уйнарга туры килде. Ул Академия театрында Празат абый Исәнбәт куйган иң гүзәл спектакльләрнең берсе иде: беренчедән, тәрҗемә әсәре кебек түгел, ә бәлки татар язучысы язган пьеса сурәтендә кабул итәсең, икенчедән, ул гүяки елмаеп-көлеп тора, тапкыр сүзләргә шул кадәр бай, шигъри ритм, эчке бер мәгънә белән эшләнгән, уйнаган саен уйныйсы килә. Әгәр артист матур итеп әйтә алмаса, Габдулла абый җөмләне янадан төзеп бирә. Без Габдулла абыйның, «әйдә, бу җирен үзгәрт әле дип теңкәсенә тиеп бетә идек. Ни гаҗәп, ул һич иренми. Берәү булса, мин яздым инде, калганы сезнең эш дияр иде.

Габдулла абый безгә Шекспирның бөеклеген ачкан тәрҗемәчеләрнең берсе. Талантлы кеше бар яктан да талантлы була диләр. Бу сүз Габдулла абыйга бик туры килә. Габдулла абыйның мәсәлләре турында шуны гына әйтә алам: әгәр син мәсәлләр тәрҗемә итәсең яки язасың икән, әнә шулай чын сәнгати үрнәктә яз!

Талантлы булуы өстенә Габдулла абыебыз белемле дә иде. Ул—татар халкы

өчен, аның якты киләчәге, теле, мәктәпләре өчен заманында үз язмышын гаять катлауландырган, бик күп авырлыклар кичергән зат, бу җәһәттән ана тиннәр сирәк иде. Сөембикә манарасы турында иң беренче булып ул язып чыкты. Без шуны аңладык: безнең гүзәл шәһәребез, искиткеч мәчетләребез, үзебезнең кремлебез булган. Безне исә надан татарның бернәрсәсе дә булмаган, сезгә бар нәрсәне дә урыслар төзеп бирде дип өйрәттеләр. Без Сөембикә манарасы турында укып, Явыз Иванның нинди дәүләтне, нинди матур шәһәрне яндырган-җимергәнлеген аңладык. Габдулла абый безгә милли җәүһәрләребез барлыгын исбатлады, моның өчен, әлбәттә, милләт җанлы һәм гыйлем кеше булудан тыш, бик зур кыюлык, тәвәккәллек тә сорала иде.

Бер вакытны ул миңа үзенең Константин Симоновка язган хаты турында сөйләде. Ул вакытта К. Симонов Советлар Союзының бөек шагыйре, драматургы, житмәсә, КПСС Үзәк комитеты әгъзасы иде. Габдулла абый аңа Казанда татар мәктәпләренең ябылуы, Татарстан өлкә комитетының шушы хәлгә түзеп торуы турында әрнеп, борчылып хат язган икән. Мөмкин булса, шушы мәсьәләне кирәк урында күтәреп чыкмассыз микән, дигән. Ул тагын, «Живые и мертвые» романындагы төп герой—генерал Серпилинның үләр алдыннан әнисеннән сабый чакта ишеткән татар җырын көйләгәнен елый-елый укыдым, дип, татар кешесен зурлаган өчен авторга бөтен халкыбыз исеменнән зур рәхмәтләр дә әйткән.


Н. Фәттах. «Кол Гали».
Г. Шамуков Актай ролендә.

Инде зур вакыйга булып күңелемә кереп калган бер вакыйганы кәгазьгә төшерәсем килә. 1970 елда Мәскәүдә безне, Татар академия театры коллективын, гастрольләр вакытында КПСС Үзәк комитетының мәдәният бүлегендә кабул иттеләр. Мондый хәл татар театры тарихында беренче мәртәбә булды. Анда Фоат абый Халитов, Габдулла абый Шамуков, Фатыйма апа Ильская, Шәүкәт абый Биктимеров, Наил Дунаев, Рәшидә Жиһаншина, Марсель Сәлимжанов һәм мин бар идем. Рәшидә апа, директор буларак, академия театрына яңа бина кирәк булуы турында бик дулкынланып, дәлилләп сөйләде. Марсель Хәким улы да, театрның баш режиссеры буларак, чит илләргә гастрольләргә чыгу турында, театрның хәзерге дәрәҗәсе шундый, аны теләсә нинди илдә дә күрсәтергә мөмкин дип, шулай ук бик дулкынланып сөйләде. Мин дә артистларның ачы язмышы турында бик дулкынланып сөйләдем. Шуннан Габдулла абый сүз сорады. Сүзен ул миңа ничек башлап җибәрде: «Мин әле генә ЗИЛ заводында татарлар белән китапханәдә очрашуда булдым. Анда 5 меңгә якын татар кешесе эшли, ә менә завод китапханәсендә бер татар китабы да юк, заводта татарча бер сәнгать-театр түгәрәге дә эшләми. Бер татарча газета-журнал күрмәдем. Бу ни хәл, әгәр Мәскәүдә милләтләргә шундый караш икән, бүтән җирдә бу турыда сөйләп торасы да юк. Партия безне нәрсәгә өйрәтә? Советлар Союзында һәр милләт үзенең мәдәниятен, туган телен сакларга, белергә тиеш. Шуна күрә элек Мәскәүдә татар театры, татар мәктәпләре бар иде, татар газета-журналлары чыга иде. Владимир Ильич Ленин безне нәрсәгә өйрәтте? Совет Россиясендә бөтен милләтләр бертигез, зурысы, кечесе юк, аларга үсәр өчен бөтен шартлар тудырылырга тиеш. Без бүген монда ни күрәбез?» Мин шунда үзебезнең артистларга, театр җитәкчеләренә карап алдым, барысы да ап-ак булып катканнар, беркем беркемгә карамый. Марсель Сәлимжанов зәңгәрләнеп бүртенеп чыккан. Бермәлгә үлем тынлыгы урнашты. Куркудан нәрсә эшләргә белмибез. Партия Үзәк комитетында шундый сүзләр сөйләргә мөмкинме? Әгәр мондый хәл 15-20 ел элек булса, моның өчен атарлар яки халык дошманы дип төрмәгә ябарлар иде. 1970 елда шундый сүзләр сөйләр өчен синең фикерең нинди югарылыкта булырга тиеш!

Габдулла агай җанында җыелып килгән милли гамен, хәсрәт-борчуларын әйтте дә салды! Һәм, артист буларак, үзенең язмышын куркыныч астына куйды. Аның бит әле СССРның халык артисты исемен аласы бар иде. Менә шунда инде мин Габдулла абыйның нинди кеше икәнлеген чын-чынлап аңладым. Үз гомеремдә күп язучылар, шагыйрьләр белән очраштым, ләкин Габдулла абый Шамуков дәрәҗәсендә фикер йөртүчене, милли аң, милли гамь тулы, татар халкы язмышы өчен шул кадәр борчылган, янган кешене күрмәдем. Мин бит әле бер генә мисал китердем, аның өлкә комитетында, театрда сөйләгән сүзләрен һич онытасым юк. Сөйләргә хакы бар, үзе укымышлы, эчми, сүгенми, хатын-кызлар белән чуалмый, күңелендә бары тик иҗади эш, шуна күрә аңа берничек тә бәйләнеп булмый.

Ни кызганыч, Габдулла абый татар халкының милли аңы уянган көннәрен күрә алмыйча, 1981 елда вафат булды.

Тагын бер вакыйганы искә төшерәсем килә, Габдулла абый бик каты чирләгәч, без бер төркем артистлар хәлен белергә дип өенә бардык. Бик нык ябыккан, шәүләсе генә торып калган, ләкин күзендә нур бар, үзенең эшлисе эшләрен мавыгып сөйли. Шунда барыбыз да агай әле үлемгә әзер түгел икән дип уйлап куйдык. Шуңа күрә ул безгә бик кызганыч төсле күренде, үлемнең нәрсә икәнен аңламаган төсле тоелды. Чыннан да, ул туп шикелле түп-түгәрәк, энергия ташып тора, мин аның элек авырганын да хәтерләмим, ничек инде шундый кеше үлем турында уйласын ди. Ә бит барыбер уйларга кирәк! Соңгы мәртәбә хәл белергә хастаханәгә баргач исә гел җылады да җылады, көчкә тынычландырдым.

Гомеренең соңгы елларында ул үзе теләгән бер генә рольне дә уйный алмады. Әкрен-әкрен генә артист буларак онытылып та бара бугай. Ләкин татар милләте, татар халкы, Татар академия театры өчен ул хәзерге көндә дә милләтебезнең якты йолдызы булып кала бирә.

Язмамны шуның белән тәмамлыйм. Мондый олы шәхес турында мин генә түгел, безнең хөрмәтле әдипләребез дә язарга тиеш. Казанда берәр урамга Габдулла Шамуков исемен бирү дә бик дөрес булыр иде. СССРның халык артистлары бездә берничә генә бөртек ләбаса!

Шулай да, Аллаһы Тәгаләгә мең рәхмәт. Чын талантны тудырган өчен. Минем күңелдә ул караңгы төндә янган якты бер йолдыз булып саклана. Бар иде бит шундый кешеләр!

**Әзһәр ШАКИР,**
*Татарстанның һәм Россиянең*
*халык артисты, Татарстанның Г.Тукай*
*исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

*2009 ел, 10 ноябрь*

## Харис Якуповка 90 яшь



Харис Якупов Татарстан рәссамнарының иң күренекле осталарыннан санала. Иң әүвәле аның биографиясен кыскача гына күздән кичерик.

Харис Габдрахман улы Якупов 1919 елның 23 декабрендә Казанда эшче гаиләсендә туа. Яңа бистәнең 13нче татар мәктәбендә, аннары Казан сәнгать училищесында укый. Әмма училищесын да, дусларын-туганнарын, каләм-пумала ише иҗади эш коралларын да калдырырга туры килә аңа. Вакыты җитеп, 1939 елда аны армия хезмәтенә алалар, аннары инде дәһшәтле Ватан сугышы башлана. 1941 елның июлендә үк аларның укчы дивизиясен фронтка җибәрәләр. Шуннан бирле ул—Елецтан алып Берлин, Прагага кадәрле дүрт ел буе утлы сугышның гел алгы сызыгында. (Җәяләр эчендә булса да әйтик, Ходай Аны, шөкер, рәсем сәнгатебез һәм халкыбыз өчен мылтык-ядрәләрдән аралап-саклап калган.)

Сугыш тематикасы Харис Якупов иҗатында юкка гына төп урыннарның берсен алып тормыйдыр. Ничек кенә сәер тоелмасын, рәссам иҗади эшен хәтта армия хезмәтеннән дә югарырак санаган ул чакта. Соңрак армия тормышын Чехословакия, Польша, Германиядә тәмамлаганнан соң, ул 1945 елның көзендә Казанга әйләнеп кайта, янадан иҗат эшенә чума...

Инде аның төп хезмәтләреннән кайберләрен санап китик. «Татарстан АССРны төзү декретына кул кую» (1950), әсәргә СССР Дәүләт премиясе бирелә; «Пролог» (1950), «Казан студентлары. 1887 ел» (1980); «Шагыйрьгә истәлек. Г. Тукай» (1986) һәм башка әсәрләр.

Рәссамның «Хөкем алдыннан. Татар шагыйре Муса Җәлил 1944 елда Берлинның Моабит төрмәсендә (1954)» дигән картинасына аерым тукталасы килә. Муса—кырыс, горур, үз-үзенә инанучан. Аның каршында—сорау алырга җыенган өч немец генералы: берсе телефоннан сөйләшә, икенчесе тоткын шагыйрьнең горурлыгына текәлеп-гаҗәпләнеп карый; өченчесе, авызына сигара капканы, җаһил бер кыяфәт, тантана белән әсиргә текәлгән...

Харис Якуповның күпкырлы, халыкчан иҗатына югары бәя бирелде. Ул—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), беренчеләрдән булып РСФСРның һәм СССРның халык рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1958), Репин исемендәге Россия Дәүләт премиясе лауреаты (1976) һ. б. Сүз уңаеннан, аның Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Ватан Сугышы орденнары, күпсанлы сугышчан медальләр, Ленин ордены белән бүләкләнүен дә әйтеп китү урынлы булыр.

Рәссамның бик күп әсәрләре ил күләмендә һәм чит дәүләтләрдә үткәрелгән күргәзмәләрдә күрсәтелде һәм дан казанды. Аның иң уңышлы картиналары Третьяков галереясендә, илебезнең бик күп калаларында, Прага, Пхеньян, Адис-Абеба музейларында һәм АКШ, Франция, Кытай шәһәрләре галереясендә саклана. Күпчелек әсәрләре, әлбәттә, Татарстан дәүләт сәнгать музеенда урын алган.

Аның җәмәгать эшчәнлеге турында аерым бер хезмәт язарга кирәк булыр иде. 25 ел буе Татарстан рәссамнары оешмасын житәкләве генә дә күп нәрсә турында сөйли. Әйе, ул—солдат, рәссам, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе һәм... мәкаләләр, хатирә-истәлекләр язучы автор да.



**—2009 елның кытлык-кризис елы буларак тормышыбызга тәэсире шактый озак сиздерер әле. Ул сезнең өчен дә кырыс булдымы, гомумән, ничек кичердегез?**

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ, *«Мәгариф» нәшрияты директоры:***

—Илдә өстенлек ала баручы сәясәткә мөнәсәбәт белдергән булып, «кыю» фикерләр өстисем килми. Милли мәгариф һәм мәдәният мәйданындагы хәлләр һәркайсыбызның бавырында утыра. Кем әйткәндәй, кар өстендә кайсы тәпие өшегәнен каз үзе генә белә. Шуңа күрә 2009 елга нәшрият «каланча»сыннан гына күз ташлау да бик житкән мина дип уйлыйм.

Дөресен әйтим, елның 365 тәүлектән торганлыгын гомеремдә беренче тапкыр сиздем, һәр таңда җәя җебе кебек тартылган уйлар белән уянып, шундый ук киеренке халәттән чыкмаган көе төнгә керә торган ел булды. Узган еллардагы сыман, киләчәккә карап, ижади планнар корып эшли-яши алмадык. Фикер-идеяләр чишмәсен барыбер томалап булмый ул. Әмма... Әзер килеш, бастыруны көтеп ятучы китаплар киштәне генә түгел, жанны баса...

Шуңа да карамастан, әле бар-булганына шөкер итәм: ирешелгән кадәресен саклап калдык шикелле. Болай расларга беркадәр нигез дә бар: быел 160 исемдәге китапка юл ачарга жыенабыз. Былтыр 170 иде. Гомуми тираж 740 мең тирәсе булачак. Чагыштырып карау өчен: былтыргысы—752 мең данә. Узган елларда Россиядәге иң эре 100 нәшриятның икесе башкортның «Китаб»ы белән безнең «Мәгариф» иде. (Әлеге рейтинг ел дәвамында башкарылган хезмәт күләменнән чыгып төзелә). Алга таба ул дәрәҗәне саклап калырбызмы?..

Килешәм, сан безгә генә бәйле түгел. Үзебездән торганы, ягъни сыйфат ягы да аксамады дип уйлыйм. Бу—әлбәттә, талантлы авторларыбыз һәм булдыклы хезмәттәшләрем ирешкән нәтиҗә.

Быелгы шартларда «Идел-Пресс» басмаханәсенең ярдәме бәһаләп бетергесез зур булды.

«Татмедиа» агентлыгы, Мәгариф һәм фән, Мәдәният министрлыклары аша республика житәкчелегенең яклавын тоеп эшләдек. Дәүләт Советындагы «үз» депутатларыбыз да ташламады.

Барчасына чын күңелдән рәхмәт!

Билгеле булганча, безнең эшнең асылын дәреслекләр билгели. Мәскәү нәшриятлары белән хезмәттәшлектә «Диннәр тарихы» кебек федераль басмаларны да, татар галимнәре язган оригиналь дәреслекләрне дә яратып әзерләдек. Проблемалар юк түгел. Ләкин минем фикерем шундый: проблемаларны кемдер «тудыра»; кемдер аларны «күтәреп чыга»; безгә исә ул проблемаларны хәл итәсе генә кала.

«Мәгариф» нәшрияты житештергәннең гадәттә дүрттән бере—әдәби һәм фәнни китаплар. Алар—безнең «төп эштән тыш төп эшебез». Дәүләт ярдәменә авторлар белән бергә үз тырышлыгыбыз өстәлмәсә, мондый төр басмаларны санарга быел, бәлки, кул бармаклары да житәр иде. Ә бит арада шактый саллылары бар! Әйтик,

ике томны тәшкил иткән (мең битле!) Тукай шигърияте сүзлеге... (Ул нәшриятның 2000 нче китабы да булды.) Шулай ук тарихта беренче тапкыр эшләнгән татар мифологиясе сүзлеге... «Культура России» дигән федераль программага ил күләмендә сайлап алынып дәрәҗәгә ирешмәсән, аларны чыгару кыенрак булыр иде, мөгаен. Татар ПЕН үзәге кәсебенә керешкәнгә генә, ел башында—«Татар акылы»ның инглиз телендәге варианты, җәй ахырында Әмирхан Еникинең 100 еллыгына «Биектән карап...» җыентыгы нәшер ителә алды. Аерым шәхесләр башлап йөрмәсә, Фатих Кәримнең 100 еллыгына ике томлык сайланма әсәрләрен (бер ай эчендә!) әзерләп чыгару мөмкин булыр иде микән... 10 мең татар гаиләсе алдагы Яңа елны да өй түренә традицион «Татар календаре»н элеп каршылый,—бусын үз көчебез белән саклап калдык... Мактанып түгел, куанып әйтү: «Казанский педагогический журнал» дигән, Россия фәнни мәйданында абруйлы басманы чыгару шулай ук «Мәгариф» нәшриятының мөмкинлекләре турында сөйли.

Шәхси тормышны казна эшеннән аерып булмаса да... Ел дәвамында бераз язгаладым-сызгаладым. Студентларым белән (Казан дәүләт гуманитар-педагогика университеты) үткән уку елын төгәлләп, яңасын башлап җибәрдек. Алар, нәшрият коллективы кебек үк, «үз гаиләм» инде.

Гаилә дигәннән, быел кече кызыбыз Гөлназ кияүгә чыкты. Аларның чакыруы белән Берлинда, Парижда кунак булып кайтырга туры килде. Айсылуыбыз, 2009 елны каршыларга өч кенә көн кала, беренче оныгыбыз—Ләйләне алып кайткан иде. Бу ел шундый куанычлы мәшәкатьләре белән дә истә калды.

Тагын... «Аккош күле»ндәге бакчабызда—бездә генә түгел, барча күршеләребездә—алма ишелеп уңды. Алма елы булды бу!

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ТӨРКИЛӘР ШӘҖӘРӘСЕ

1999 елны Лондонда «Дөнья картасы» («Атлас мира») дигән китап басылып чыга һәм анда Россия халыклары арасында төп ике тел дип рус һәм татар телләре күрсәтелгән. Бу—татарларның сан ягыннан икенче урында торуы белән генә түгел, ә бәлки татар теленең Иделдән алып Тын океанга кадәрле җәелгән Тартария кинлекләрендәге төрки телләр төркеменә керүе белән аңлатыла. Төркиләр турында сөйләгәндә, VI-VII гасырлардагы төрки каганатны гына түгел, аның составына кермәгән башка халыкларны да күздә тотарга кирәк. Л. Н. Гумилев болай дип яза: «...аларның кайберләре, әйтик, төрекмәннәр, госманлылар, әзәрбайҗаннар—монгол кыяфәтле булмаганнар. Бүтәннәр—якут, кыргыз, хакасларның борынгы бабалары каганатның явыз дошманы булган. Өченчеләр исә, мәсәлән, балкарлар һәм чуашлар борынгы төркиләргә кадәр үк калыплашканнар.» *(Древние тюрки:—М., 1993).*

Утрак тормышта яшәгән илләрнең көнкүреш мәдәниятенә караганда даладан далага күчеп яшәгән борынгы төркиләрнең тормыш-көнкүреше чагыштырмача азрак өйрәнелгән. «Сәбәп төркиләрнең һәм башка күчмә халыкларның күршеләреннән түбәнрәк булуында түгел,—дип дәвам итә Гумилев,—хикмәт шунда, тимер яисә ташка караганда киез, тире, агач һәм мехлар бик начар саклана. Менә шуңа күрә дә Европа галимнәренең күбесендә күчмә халыкларга карата «кешелек калдыклары» дигән тискәре караш туган».

Истәлекле һәйкәлләрнең ничек сакланышын ике тарихи истәлек—Вавилон һәм Пальмира мисалында күрергә мөмкин. Багдадтан 90 чакрым ераклыкта урнашкан легендар Вавилон кирпеч чималыннан эшләнгән, шунлыктан ул дымлы-юеш шартларда акрынлап югалуга дучар. Әгәр Гыйрак хөкүмәте һәм халыкара оешмалар кайгыртучанлык күрсәтмәсә, анардан инде күптән гигант балчык өеме калган булыр иде. Дәмәшыкътан 240 чакрым читтәге Сүрия сахарасына урнашкан гранит-мәрмәр Пальмира исә Рим девереннән исән сакланып калган сирәк шәһәрләрнең берсе. Аның сурәте борынгы тарих дәреслекләренең тышлыгында бирелә, шагыйрьләр исә Санкт-Петербургны Төньяк Пальмира дип атаганнар.

Төрки халыкларның ватаны—Алтай; алтай телләре гаиләсенә әле тагын монгол, тунгус-манчжур, корея һәм япон төркемнәре дә керә. Алтай гаиләсенә урал-юкагир, эскимос-алеут һәм чукот-камчат тамырлары да килеп тоташа.

Галимнәр телләр арасындагы генетик бәйләнешләрне 3 мең еллык вакыт үлчәме арасында гына дөрес итеп бәяләргә мөмкин, чөнки алга таба телнең төп сүзләре «коела» бара яки танымаслык булып үзгәрә. Бу очракта, беренчедән, сүз күбрәк һинд-европа телләре турында һәм, икенчедән, телнең структур төзелеше түгел, сүзлекнең тулаем составы, лексикасы турында бара. Асылда структура—телнең скелеты, грамматик күрсәткечләре. Мәгълүм булганча, скелетлар исә меңәр елларча саклана. Әйтик, археологлар безнең эрага кадәр яисә соңрак яшәгән динозаврларның кече фрагментларына—арка сөягенә, тешенә, койрыгына, кабырчыкларына карап аның тән төзелешен, килеш-кыяфәтен шактый тулы итеп күз алдына бастыра алалар.

Грамматик күрсәткечләргә килгәндә, телнең төп үзенчәлекләреннән булып килешләр системасы санала. Латин һәм рус телләрендә 6 падеж санала, венгрда исә 25, борынгы төрки һәм шумерларда 11 исәпләнә. Шунысы игътибарга лаек:

әлеге искә алган унбер килешләрдәге кушымчаларның азагы бер-беренә тәңгәл килә. Борынгы һәм хәзерге төрки телләр арасында «кече фрагментлар»ның үзара бәйләнеше биш мең еллар аралыгында әле дә булса сакланып калган. Кыскасы, лингвоархеологлар өчен өйрәнү, чагыштыру, кайбер нәтиҗәләр ясау өчен тарихи материал җитәрлек.

Узган гасыр башында кайбер тел белгечләре шумерны алтай телләре семьялыгына кертканнәр иде. 70нче елларда бу хакта Олҗас Сөләйманов та мәгълүм китабында язып чыкты. (Җәяләр эчендә булса да әйтим, 2004 елны Казанга килгәч, мин аңа Татарстан фәннәр академиясенең «Шумер һәм төрки телләрдәге килеш системасы мәсьәләләре» дигән җыентыкны бүләк иткән идем). Күчмә халыклар өчен Месопотамия бер дә ят булмаган; ә еврейлар, шушы Месопотамия, Фарсы һәм Каф таулары аша Иделгә килеп җиткәннәр һәм, төркиләр белән берлектә, шанлы-кодрәтле Хазария дәүләтен төзегәннәр.

Көнбатышта төркиләр Месопотамия һәм Европа халыклары белән үзара багланышта яшәсәләр, көнчыгышта исә аралашыр мөмкинлекләр бик күренмәгән: чөнки Америка кыйтгасына әле халыклар күчеп өлгермәгән, ә соңрак Америка изоляциядә кала.

XX гасыр азакларына кадәр шулай дип исәпләнде: янәсе, америка индеецлары—Тын океанны салларда кичеп чыккан полинейзий утравы токымнары. Икенче вариант—Атлантик океанда адашып калган корабльләре белән очраклы рәвештә кыйтгага килеп эләккән африкалылар, яһүдләр, викинглар. Өченчесе—Беринг бугазы аша Себердән Америкага күчкән аучы-сунарчылар. Әмма XX гасыр азагындагы ДНК анализларыннан соң мондыйрак хәл ачыклана: Америкага караганда Полинейзиядә кешеләр берничә мең ел элек инде яши башлаганнар. Европа һәм Африка кораблары Америкага шулкадәр сирәк килеп эләккәннәр ки, андагы алҗыган һәм аз санлы экипаж кешеләре индеецлар цивилизациясенең калыплашуына бернинди йогынты ясый алмаганнар. Аннары килеп, Америка кыйтгасын безнен эрага кадәр ук, 1600 чакрымга сузылган Беринг бугазы аша үтеп, читләр үзләштерә башлаган. Бу хакта әле күптән түгел энциклопедик сүзлекләрдә сүз әйтелә башлады.

Бу вакыйгаларны болайрак күз алдына китерергә мөмкин: Атлантик океан ярларыннан Хоккайдо утрауларына кадәрге Берингия аралыгында ул чакта «Бөек мамонт даласы» урнашкан була. Андагы эре үләннәр саваннасын башка бер җирдә дә очрату мөмкин түгел. Анда үлән белән тукланучы эре хайваннар көтүенең иге-чиге булмаган. Аучылар өчен бу дала чын мәгънәсендә оҗмах почмагы булган. *(Чыганак: Стивен Оппенгеймер. «Изгнание из Эдема. Заселение мира». М., ЭКСМО, 2004).*

Шулай итеп, берничә мең еллар буе Беринг аша кешеләр һәм хайваннар ташкыны бертуктаусыз Америка кыйтгасына күченә килгәннәр.

Безнең эрага кадәр 9нчы гасырдан соң бозлыклар эреп, климат нык җылыну сәбәпле, дөнья океанында сулар күтәрелә һәм Америка Беринг бугазы белән читтә аерылып кала. Ә анда «монгол һәм кавказлы халыклар»ның катнашмасы үзләренчә яши башлый. *(«Заселение мира»).* Сорау туа: хәзерге төрки токымнар, чыннан да, борынгы Тартария вәкилләреме соң? Антрополог Стивен Оппенгеймер болай яза: «Безнең дөньябыз кайнамакта булган гигант бер казан булуына карамастан, анда халыкларның үзара кайнашып-буталып яшәүләре, аралашу гамәлләре шуны күрсәтә, хәзерге диаспора вәкилләренең күпчелеге ерак бабалары сайлаган, урнашкан урыннарда яшәп ята». Миңа калса, бик тә уйланырлык фикер бу.

Колумб дәверенә кадәр 10 мең еллар дәвамында Америкада, аңлашылганча, нигездә, алтай телләрендә сөйләшүче «монгол һәм кавказлы» кыяфәт затлары, катлы-катлы һәм катнаш булып яшәгәннәр. Америкада индеецларның меңнән (!) артык тел һәм диалектлары бар, ләкин алар барысы да америнд—ягъни америкалы индеецларның уртак тел төркеменә керә. Америнд сөйләмендә алтай һәм иске Европа телләрендәге бик күп үзенчәлекләр чагылыш таба һәм, әйтергә кирәк, аларның төп фрагментлары төркидәге күрсәткечләргә барып тоташа. Тюркологларга бу хәл билгеле, әмма көнбатыш Европа галимнәре гаҗәпкә кала: «Үзенең төзелеше-төзеклеге белән аймара гаҗәеп дәрәҗәдә төрек телен хәтерләтә.» *(Лун Боден. Инки.—М.; Центрполиграф. 2004).* Аймара—Боливия һәм Перудагы төп халыкның

теле. «Төрекләр» дигән сүзне бу очракта, һичшиксез, төркиләр дигән мәгънәдә анларга кирәк.

Һәрхәлдә, төркиләрнең Америка кыйтгасына күчеше, һәм америнд теленең калыплашуындагы роле бәхәссез. Моннан ун мең еллар элек Месопотамия һәм Патагения кинлекләрендә борынгы төрки телләрнең булуы фәндә инде исбатланган диярлек. Мезоамерикадагы корылмаларны, пирамидаларны татар-монголлар түгел, аларның Америкага килеп төпләнгән бик тә борынгы бабалары, ягъни Тартария һәм Монголия токымнары төзегәннәр. Майя индеецлары буенча белгеч Майкл Ко әнә шул хакта бәхәсле фикерләрен тәфсилләп яза. *(Майя—М.; Центрополиграф, 2004).*

Мәкаләдә китерелгән кайбер фактлар ерак тарихны яктырту ДНК анализларына таяну белән бәйле. Алынган мәгълүматлар кат-кат тикшерелә, зур сынаулар аша уза. Мәсәлән, Девистагы Калифорния галимнәре төньяк-америка индеецларындагы ДНК «чылбырлары»ның Россия көнчыгыш районнарында яшәүче борынгылар белән туры килүен Интернет аша хәбәр иттеләр. Тикшерүчеләр берничә мең ДНК-анализ ясыйлар, гәрчә Американың беренче археологы, инде дә килеп АКШның өченче президенты Томас Джефферсон, индеецларның борынгы бабалары Себердән килгән, дип инде әллә кайчан әйтеп өлгергән булуга карамастан.

Америнд мәсьәләсендә кызыклы бер хәл күзәтелә: аны өйрәнү эшендә америкавпар һәм Көнбатыш Европа, шулай ук Мәскәү һәм Санкт-Петербург белгечләре шөгыльләнә, ләкин алар арасында тюркологлар бер дә күренми. Шулай итеп, Иске һәм Яңа Дөнья арасындагы ун мең еллар элек нинди аерымлыклар булса, алар әле хәзер дә әнә шул рәвешлерәк яшәп килә. Әлбәттә, академик Әбрар Кәримуллин (1925-2000) шикелле аерым ялгызак-энтузиастлар бар барын, ләкин америндның систематик-планлы рәвештә, бюджет акчалары хисабыннан дәүләти өйрәнелгәне юк. (Әбрар ага Кәримуллин чит ил конференцияләрендә спонсорлар ярдәме белән генә катнаша алды).

Тарих дәреслекләрендә, нигездә, халыкларның көнбатышка Бөек күчеше турында гына сөйләнә диярлек. Ә бит борынгы заманнарда Көнчыгышка, Америкага күченүләр булган. Бу процесс бик акрын һәм озак вакытлы дәвам иткән. Ләкин нәкъ менә шушы хәлләр Колумбка хәтле үк булган һәм америнд телен формалаштырган.

Бу теманы ныклап өйрәнүче академик Әбрар Кәримуллин болай дип яза: «Әлеге фәнне тирәнтен өйрәнүче галимнәр кирәк безгә. Телләрнең якынлыгын һәм аның параметрларын методик рәвештә өйрәнү сорала. Бу фәнни хезмәтне бүгенге компьютерлар технологиясе ярдәмендә башкарып булыр иде.»

Бу сүзләр унбиш еллап элек әйтелгән. Хәзер инде сүз компьютерлар хезмәтен яхшы белгән шәрык белгечләре кулында.

Россия мәгариф системасында милли-төбәк компонентларның кысрыклануы нәтиҗәсендә шундый хәл килеп туа ки, төрки халыкларның теленә, мәдәниятенә һәм тарихына игътибар бетәргә-сүнәргә мөмкин. Менә юл куймас өчен тюркологлар һәм америнд белгечләренә бергә җыйналып, бу тарихи мәсьәләләрне уртага салып сөйләшергә бик тә вакыт! Әлеге халыкара конференцияне Татарстаныбыз башкаласы Казанда үткәрү бик тә дөрес һәм урынлы булыр иде. Казан—төрки дөнья өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә дөньяви бер башкала. Моның өчен безнең Пирамида дигән үзәк бина-йортыбыз бар. Ул символик рәвештә Месопотамия зиккуратларын, Мезоамерика пирамидаларын, ягъни Бөек төрки дөньябызның олуг багланышларын хәтерләтә. Казаныбыз әнә шундый олуг эшкә чакыра безне.

**Сәйдәш ГАРИФУЛЛИН,**
*филология фәннәре кандидаты.*

## Фирдәвес Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Ибрай һәм Яңа Ибрай авыллары

Бу ике авыл Аксубай районына керә. Иске Ибрай район үзәге Аксубайдан—13, Яңа Ибрай исә 25 чакрымда урнашкан.

Бер тарихи чыганакта (XIX йөз) әлеге авыллар телгә алына. Икесендә дә 2500дән артык татар яшәгәнлеге, 2шәр мәчет һәм борынгы шәһәрлек урыннары булу ассызыклана.

Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң, халык изүдән һәм чукындыру сәясәтеннән котылу максаты белән урман-сулы урыннарга таралышкан. Нәкъ шушы чорларда Ибрай авыллары да нигезләнгән.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, Иске Ибрай элек урман буендагы бер калку җиргә утырган булган. Хәзер ул урында каберлекләр саклана. Анда татарлар һәм чуашлар яшәгән. Татар каберлеге суның уң ягында, ә чуашныкы суның икенче ягында урнашкан.

Авыл урынында элек зур урман булган. Урман арасыннан тирән, чиста, саф сулы Кече Сөлчә елгасы аккан. Шул елганың төньяк ярында авыл оеша, ә көньяк ярында сазлык булган. Әле хәзер дә әрәмәдә берничә урында сазлык бар һәм ул шактый гына мәйданны алып тора.

Авылга иң беренче булып Ибрай исемле кеше нигез салган, авыл да аның исеме белән аталган. Шуннан соң бирегә халык шактый күпләп күчеп утыра.

Килеп утырган халык урман төпләп басу-кырлар ясаган.

Табигать шартлары яхшы булганга, хуҗалыклар һәм кешеләр саны да бик тиз арта. Ләкин сәнәгать үзәкләреннән ерак торганлыктан, авыл сәяси һәм мәдәни яктан шактый артка калган була.

Авылга беренче мәртәбә пыялалы лампа 1867 елда, ә тимер сабан 1900 еллар тирәсендә генә алына.

Авылда натураль хуҗалык өстенлек иткән, хуҗалыклар үз продуктларын читкә аз чыгарган һәм читтән дә аз керткән.

1913 елда авылда 700ләп хуҗалык булган һәм авылның бөтен байлыгы байлар кулында тупланган. Авылдагы 2 су тегермәне, 2 җил тегермәне, бодай һәм тары яргычлар, уру, сугу машиналары да алар кулында булган.

Авылдагы 700гә якын өйнең 10сы калай белән, ә калганнары салам яки чыбык белән ябылган.

XX гасыр башына авылдагы мәхәлләләр саны бишкә җиткән, һәр мәхәлләгә үз мәчете хезмәт күрсәткән.

Аның берсе, хәзерге яңа балалар бакчасы урынындагысы, урталык мәчете яки баш мәхәллә дип аталган. Ул 1936 елгы янгында харап булган.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Чавал мәчете беренче мәхәллә дип аталган. Бу мәчетнең манарасы 1943 елда киселә һәм анда намаз уку туктатыла. Ул 1949 елга кадәр склад булып хезмәт итә. 1949 елда урта мәктәп ачылгач, чит авыллардан килеп укучы кыз балалар өчен интернат булып тора. Мәчет 1960 елда сүтелеп, мәктәп йортына күчерелә һәм остаханә итеп  җайлаштырыла.

Икенче мәхәллә мәчете агач кибет янында, хәзер яна мәчет салынган урында була. Сугыш башлану белән аны башлангыч мәктәп итеп файдаланалар. 1983-84 уку елына кадәр бу бина мәктәпнең филиалы булып хезмәт иткән. Анда Чавал очы, Түбән оч, Тимерәй очы балалары башлангыч белем алганнар. 1984 елда таш мәктәп төзелгәч, аны сүтеп утын итеп якканнар.

Өченче мәчет Тимерәй урамында булган. 1955 елга кадәр ул да мәктәп хезмәтен үтәгән. Монда Тимерәй урамы балалары 2 класска кадәр белем алганнар. Аларны читтән килгән Мафруза исемле хатын укыткан. Бу бинаны 1955 елда сүтеп, больница йортына күчерәләр һәм ул участок больницасы булып тора. Соңыннан аны да сүтеп кирпеч заводына утынга ташыйлар...

Дүртенче мәчет сугыш елларында һәм 1950 елга кадәр «Партизан» колхозы идарәсе булган. Анда колхоз бухгалтериясе эшләгән. 1950 елда аны сүтеп өч класс бүлмәсе ясап куялар. 1983 елга кадәр биредә балалар укый.

Бу биш мәчетнең дә манаралары 1943 елда, төнлә киселә. Бер кисүченең кем икәнен халык белә, ә 4се чуашлар булганын халык бер буыннан икенчесенә әйтеп, колакларына салып калдыра.

Хәзерге вакытта авылда 4 мәчет эшли. Халык аларны Чавал мәчете, Урталык һәм Түбән оч мәчетләре дип йөртә. Аларның икесе ике катлы, икесе 1әр катлы. Алар бик матур итеп җиһазландырылган.

Авылда элек 2 бүлмәле мәдрәсә эшләгән. Ул хәзерге идарә каршындагы күл буена урнашкан була. Монда егетләр генә белем алган. Аларны баш мәхәллә мәчете мулласы Вәлимөхәммәт мулла укыткан.

1927 елда мәктәп төзелгәч, барлык балалар да зур мәктәптә укый башлыйлар, кечкенә мәктәпләр бетерелә. 1949 елда ул урта мәктәп итеп үзгәртелә. Берничә авылга бер генә мәктәп булганлыктан, монда күрше авыллардан да балалар килеп укый.

Авылда оешкан колхозда беренче рәис булып Сөләйман Мотыгуллин эшли.

Иске Ибрай авылы бик матур урынга урнашкан. Авыл тирәсе урман. Аерым урыннарда зирек, карама агачлары күп булып үсә.

Авыл тирәсендә елга-инеш, чишмә-кизләүләр җитәрлек. Кече Сөлчә (халык аны Инеш дип атый) авылның уртасыннан ага. Хәзер ул саеккан, суы да саф, чиста түгел инде. Ул Олы Сөлчәгә кушыла.

Урманнар авыл тирә-юнендә шактый, исемнәре дә кызыклы: Таш аланы, Пузырь, Ыштансыз чирәме, Кыек фартал, Алан башы, Чавал башы, Калиновка урманы, Каенсар һ. б.

Ташбилге каберлегендә ике изге кыз мәете күмелгән дип сөйлиләр.

Авылда 3 катлы таш урта мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы эшли. 1970-80 елларда мәктәптә уку елында 1200 дән артык бала белем алган. Хәзер ел саен 300 тирәсе бала укый. Авылда медпункт, больница, аптека, берничә кибет халыкка хезмәт күрсәтә.

Хәзер Иске Ибрайда 700ләп йорт исәпләнә, 2000ләп кеше яши.

Авылда Керәшен очы дигән урам бар. Чукындыру сәясәте вакытында авыл халкы чукындырылган булган. Хәзер авылда татарлар гына яши. Элек анда чуашлар да яшәгән. Алар икенче урынга күчеп киткәннәр һәм чуаш авылына нигез салганнар.

Авылда ике зират бар. Берсе Акан тегермәне янындагы зират дип, икенчесен Оч зираты дип атыйлар. Зиратларны авыл кешеләре яхшылап карап тора, һәр ел саен өмә була, зират чүп-чардан чистартыла.

***

Иске Ибрай авылыннан ерак түгел Яңа Ибрай авылы утырган. Аны беренче нигезләүче кеше, халык сөйләве буенча, Иске Ибрай авылыннан булган.

Яңа Ибрай авылын икенче төрле Чәтрән дип тә йөртәләр.

Авыл оешу вакыты XVI гасыр ахырына—XVII йөз башларына туры килә. Чәтрән башта бик кечкенә булган. Иң якын урыс авылы җиде-сигез чакрым ераклыкта урнашкан. Алар да калкулыклар, урманнар аръягында. Бер вакытта да чиркәү чаңнары тавышы Чәтрәнгә килеп җитмәгән. Монда торган кеше гомерендә дуңгыз күрмәгән. Әллә ничә елга бер адашкан дуңгыз килеп керсә, бүре үтергән кебек, малайлар аны күсәкләр белән кыйнап үтергәннәр. Авылда бер генә урыс—тимерче яшәгән. Ул татарча бик оста белгән. Старшина—чуаш, ул да татарча белгән.

Чәтрәннең ул замандагы мужигы искиткеч авыл сөйгән, читкә чыгып йөргән кешегә җирәнеп караган.

Яңа Ибрай халкы җыелма була. Аңа Яңа Чишмә районының Чертуш авылыннан тагын бер нәсел килеп утыра һәм алар ишәеп китәләр.

Христианлаштыру сәясәте вакытында авылның бер өлеше чукындырыла. Керәшен татарларының зираты аерым була һәм алар яшәгән урам да Керәшен очы дип йөртелә. Соңыннан аларның барысы да мөселманлыкка чыгып бетәләр. Авылда тагын Кыргыз очы урамы бар. Авыл халкы эш беткәч кыргыз якларына акча эшләргә бара торган була. Дуңгыз атавы урамында исә күрше рус авылы кешесе дуңгызын килеп тапкан һәм шуңа күрә урам дуңгызга мөнәсәбәтле булып калган. Су тегермәнен эшләтә торган авыл кешесе тегермән буасыннан авыру аккошны тотып өенә алып кайтып тәрбияләгән һәм ул яшәгән урам Аккош урамы дип атала башлаган. Челтер чишмә урамы дигән атама, әлбәттә, урам янындагы суда күпләгән чишмәләр челтерәп акканга кушылган.

XX йөз башында Яңа Ибрайда ике мөстәкыйль мәхәллә була. Яңа Ибрай авылы кешеләренең күпсанлы булуы авыл халкын яңа мәхәллә төзү үтенече белән губерна идарәсенә мөрәҗәгать итәргә этәрә. 1898 елның ноябрендә Казан губерна идарәсе төзеләчәк өченче гыйбадәтханәнең проектын раслый.

Авыл халкы телендә «ч», «ж» урынына «ц», «з» авазлары актив кулланыла. Мәсәлән: «Цирмешән», «кецкенә», «цегендер», «пецән цапкан вакытлар», «зыен» (җыен урынына), «Цаллы» елгасы һ. б.

Авыл халкының беришесе озын, нәзек, зәңгәр күзле, ак йөзле, чәчләре сарырак. Икенчеләре кыскарак буйлы, зәңгәр-соры күзле, аксыл йөзле.

Авылда морза нәселе дә бар. Шадиевлар нәселен морзалар дип сөйлиләр, ул нәсел Яңа Кармәт авылыннан килгән. Авылда аю бабайлар нәселен дә морзаларга бәйләп сөйлиләр. Алар таза, эре гәүдәле.

Авылда урта мәктәп, китапханә, мәдәният йорты, медпункт, балалар бакчасы, элемтә үзәге, кибетләр эшли. Мәктәп гимназия итеп үзгәртелгән һәм аңа профессор Мансур Абдрахманов исеме бирелгән. Гомере буе Казан университетында укыткан мөхтәрәм шәхес исемен авылдашлары шулай мәңгеләштергән.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# К

**КАМАЛ** (Камалетдинев) Галиәсгар Галиәкбәр улы (25.12.1879, Казан—16.6.1933, шунда ук), драматург, публицист, театр һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Батыры (1924), ТАССРның халык драматургы (1926). Милли журналистикага нигез салучыларның һәм татар профессиональ театрын оештыручыларның берсе. 1880 нче елларда «Госмания» һәм «Халидия», 1890 нче елларда—«Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем ала, бер үк вакытта өчеллык рус мәктәбендә укый. Атасы улын мулла итеп күрәсе килсә дә, аның теләген кире кагып, К. халыкны мәгърифәт юлыннан алып баруны максат итеп куя. 1901 дә «Мәгариф көтебханәсе» исемендә бастыру һәм сату ширкәте оештыра һәм 1905 кә кадәр бу ширкәтнең эшенә житәкчелек итә. 1905 тә беренче татар газетасы «Казан мөхбире»ндә, 1906 да «Азат» газетасында эшли һәм аның фактик житәкчесе була. Шул ук елда бу газетаның исеме «Азат халык» дип үзгәртелеп, К. нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә чыга башлый. Унбиш саны чыккач, рев-цион эчтәлекле материаллар бастырган өчен газета туктатыла, К. штраф түләргә хөкем ителә. 1908-09 да «Яшен» исемле сатирик журнал нәшир итә һәм аның рәсми мөхәррире була, 1917 гә кадәр «Йолдыз» газетасында (1912-13 тә Балкан сугышында Төркиядә корреспондент була), 1917 дән соң «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия» газеталарында эшли.

К.ның беренче әдәби тәҗрибәләрен «Бәхетсез егет» (1900, 2 нче вариант 1908), «Өч бәдбәхет» (1900, икенче исеме «Уйнаш», 1910) пьесалары һәм Н.Кемальның «Кызганыч бала» (1900) пьесасы тәрҗемәсе тәшкил итә. Драматург буларак, К. мәгърифәтчелек реализмы традицияләрендә чыгыш ясый. Әлеге әсәрләрнең лейтмотивы—татарның патриархаль яшәү рәвешен тәнкыйтьләү. Алдагы елларда К.ның таланты комедиограф буларак ачыла. Ул милли драматургияне һәм театр сәнгатен «Беренче театр» (1908), «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) комедияләре б-н баета. Бу пьесаларда К., сатирик караштан чыгып, 20 йөз башы татар тормышын сурәтли, аталар һәм балалар мәсьәләсен, ир-хатын һәм гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләрен яктырта, искечә тәрбия алган милли сәүдәгәрләр һәм мещаннар образларын тудыра. Иҗат тематикасының гомум юнәлеше—искелекнең җимерелүе, яңа мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүе, искелек б-н яңалык арасындагы каршылыклар һәм аларның үзара көрәше. Пьеса персонажлары (Фатих, Насыйр, Гариф, Кәрим) «җәмгыяви» һәм «мәдәни» эшләр б-н мәшгуль, яңалыкка каршы көрәш алып баралар («Беренче театр»дагы Хәмза бай), үз мәнфәгатьләрен барыннан да өстен куялар («Бүләк өчен»дәге Хәмидә), гади партнерлык кагыйдәләрен, намуслылыкны бозалар («Банкрот»тагы Сиражетдин). Г.Тукай тарафыннан югары бәяләнгән «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасында шәһәр халкының төрле катлам вәкилләре бар (зыялылар, руханилар, түрәләр, приказчиклар, хезмәтчеләр һ.б.). К. комедияләренә конфликтның киеренкелеге, хәрәкәтчәнлек, вакыйгаларның тулылыгы хас; аларда геройларның эчке дөньясы оста чагылдырыла, милли йолалар, гадәтләр, көнкүреш детальләр (өй җиһазлары, милли ашамлыклар) дөрес тасвирлана. Автор үзен диалог остасы итеп күрсәтә, комедияләренең теле халык юморы б-н баетылган.

К.ның шигъри иҗаты 1905-07 нче елгы Рев-ция чорында татар җәмгыятендә хөкем сөргән идея һәм рухны чагылдыра. Ул милләтнең ихтыяҗлары, ирек яулауга, халык мәгарифе, мәдәнияте һәм фәненең үсешенә өмете турында яза («Азатлык», 1905; «Өндәү», 1905; «Безнең кирәк», 1906; «И, мөселман, йокламагыл!», 1906 һ.б.). К.ның публицистика тематикасы да күпкырлы: Дәүләт Думасы һәм 1905 елгы манифестына мөнәсәбәт («3 нче ноябрь манифесты ни бирә?», 1906; «Дума, дума, дума», 1906; «Депутатлар озату», 1907 һ.б.), татарның иҗтимагый тормышы мәсьәләләре («Кем гаепле?», 1905; «Искелек сакчыларына ачык хат», 1906; «Ачларга ярдәм эшләре», 1907; «Иван Николаевич Харитонов», 1909;

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

«Кыз сату», 1912 һ.б.). Хикәяләрендә К., вакытны мәгънәсез бушка уздыруны тәнкыйтьләп, бөтен көчне халыкка, җәмгыятькә файдалы хезмәт итүгә чакыра («Сабир хәзрәт яки гыйбрәт», 1903; «Күгәргән алтыннар», 1909). К. татар әдәбиятының һәм театрының үсешен гел күзәтеп бара, күпсанлы әдәби—тәнкыйди мәкаләләр һәм рецензияләр бастыра («Татарча театр», 1907; «Габдулла Тукаев шигырьләре», 1907; «Ачлык кушты»,1908; «Яңа әсәрләр», 1909, «Саран» пьесасы хакында», 1915 һ.б.). Гражданнар сугышы елларында ул, революцион эчтәлекне традицион шигъри формага төреп, илдә һәм республикада барган вакыйгаларны яктырта («Декламацияләр», 1921). К.ның 1917 дән соңгы иҗаты сәнгати яктан октябрьгә кадәрге иҗатыннан бераз калыша. Соңгы чор драматургиясендә җәмгыятьтә социализм төзү юллары пропагандаланыла. Совет органнары хезмәткәрләре һәм алар яклылар гадәттә уңай геройлар итеп күрсәтелә, үзгәрешләргә каршы чыгучылар көлке утына алына («Хафизәләм иркәм» комедиясе, 1922; «Өч тормыш» драмасы, 1930 һ.б.). К. татар теленә күп кенә рус һәм чит ил драматурглары әсәрләрен тәрҗемә итә: Н.В.Гогольның «Өйләнү»—«Женитьба»сы һәм «Ревизор»ы, Н.А.Островскийның «Гроза»сы, Ж.Б.Мольерның «Саран»—«Скупой»е һәм «Ирексездән табиб»—«Лекарь поневоле»се, Г.Хәмиднең «Һинд кызы» һ.б.

К. рәсем ясау сәләтенә дә ия була. Ул Г.Тукай әсәрләренә беренче булып иллюстрацияләр ясый, «Яшен» (1907-08) һәм «Ялт-Йолт» (1908-10) ж-лларында актуаль иҗтимагый һәм сәяси темаларга сатирик рәсемнәр бастыра. График—рәссам буларак, Татарстанда китаплар бастыру эше культурасына үзеннән зур өлеш кертә: Казандагы И.Н.Харитонов типографиясе өчен яңа шрифт рәсемнәрен, беренче театр афишаларын эшли. Ул татар театрында берничә спектакльне рәссам буларак бизи. 1920 нче елларда татар каллиграфиясен камилләштерә, «Чаян» ж-лы һәм «Кызыл байрак» газетасы өчен шрифтлар эшли.

Әсәр.: Әсәрләр: 3 томда. К., 1978—81.

Әд.: Гайнуллин М. Галиасгар Камал // Татарская литература XIX в. К., 1975; Ахмадуллин А. Основоположник татарской драматургии // Горизонты татарской драмы: Лит.—крит. статьи. К., 1983.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**КАМАЛ** (чын фам. Байгилдиев) Шәриф Камалетдин улы (27.2.1884, Пенза губ., Инсар өязе, Татар Пешләсе а.—22.12.1942, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ сәнгать эшлеклесе (1940). Башта авыл мәдрәсәсендә укый, 1900-03 тә Төркиядә белем ала. Тулаем белем алырга матди хәле мөмкинлек бирми. Ватанына кайтып, Донбасс шахталарында, Каспийдагы балыкчы артельләрдә, Одессада, Крымда, Кавказда эшли. 1905 кә кадәр мөгаллимлек итә, «Нур» газетасы (Петербург) редакциясендә эшли. 1907-10 да туган авылы мәдрәсәсендә укыта. 1917 дән Оренбург шәһәрендә яши, укытучылык итә, «Шура» ж-лында, «Вакыт» газетасында язышa. 1918-19 да «Эшчеләр дөньясы», «Кызыл йолдыз», «Юксыллар сүзе» (Оренбург ш.) газета редакцияләрендә эшли. 1920-21 дә Оренбург өлкәсе Чебенле авылында коммуна оештыруда катнаша, 1924 кә кадәр Оренбургның төрле оешмаларында эшли, «Юл» газетасы мөхәррире була. 1925 нең көзеннән К. Казанда: «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә; 1928 дә Татар мәдәнияте йортында гыйльми сәркәтип; 1929-32 дә Әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча баш идарә (Главлит) хезмәткәре, 1933-35 тә Татар академия театрында әдәби бүлек мөдире. 1934 тә СССР язучыларының 1 нче съездында катнаша.

К. беренче әдәби тәҗрибәләре 1905 кә карый. «Нур» газетасында, эшчеләр хокукын яклап, шигырьләр һәм мәкаләләр бастыра. 1906 да «Садә» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә. 1907 дә «Шура» ж-лында басылган хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләсенә багышланган «Уяну» новелласы җәмгыятьтә киң яңгыраш таба. Хатын-кызның хокуксызлыгы темасы «Буранда» (1909), «Күнелсез эш» (1910), «Эч пошулы» (1912) исемле хикәяләрендә дәвам ителә. К. хикәяләре сыйдырышлылыгы, кыскалыгы һәм аныклыгы, детальләрнең төгәллеге, пейзажларның матурлыгы, гүзәллеге б-н аерылып тора. Аларда билгеле дәрәҗәдә А.П.Чехов һәм М.Горький новеллалары тәэсире сизелә. К. татар әдәбиятында беренчеләрдән булып хезмәт кешесе образларын тудыра, шахтёрлар, балыкчылар, сезонлы эшчеләр, сукбай-зимагурлар тормыш-көнкүрешен тасвирлый. Каспий балыкчылары тормышына багышланган «Акчарлаклар» (1941) автобиографик повесте хезмәт кешесенең эчке рухи дөньясын реалистларча ача. Шул елларда ук К. татар әдәбиятында «кечкенә» кешенең рухи даирәсенең мәгънәсен ачып бирү рәвешен билгеләде. Ул салып калдырган традицияләр замандашлары һәм киләчәк буын язучылар әсәрләрендә үсеш алды. К.ның мөһим сәнгати ачышы дөрес һәм оста итеп кеше һәм табигатьнең үзара тыгыз бәйләнешен күрсәтә алу булды. Чөнки бу бәйләнеш фон гына булып калмыйча, кешенең гомере буена хезмәт процессы б-н янәшә бара, аның эчке тормышына

тәэсир итә. Акчарлак тавышы—повестьнең күп кенә урыннарында үзенә күрә бер сәнгати үзәк булып тора. 1917 дә К. драматургия өлкәсендә «Хажи әфәнде өйләнә» комедиясе б-н дебют ясый. Анда ул төп геройдан—фанатик һәм тар фикерле кешедән сарказм б-н көлә.

Октябрь рев-циясен К. иҗатын багышлаган хезмәт кешесенә чын ирек бирүче яңа эра башы дип кабул итте. Язучының рев-циядән соң язылган әсәрләрендә чынбарлык киң колачлап тасвирлана. Җәмгыятьтә барган зур социаль үзгәрешләрне аңларга теләп, К. кыска әдәби формаларга мөрәҗәгать итә. Беренче «Таң атканда» (1927) романында ул геройлар язмышын («Акчарлаклар»да да шулай) тарихның хәлиткеч моментларында, 1917 нең Февраль рев-циясе тудырган социаль һәлакәт барышында күзәтә. 1930 нчы еллар башында К. биш томнан торачак эпик әсәр турында уйлана башлый, ләкин бу киң колачлы ният тормышка өлешчә генә аша. 1937 дә аның 1920-30 нчы еллар авыл тормышына багышланган «Матур туганда» романы чыга. Әсәр, булачак эпопеяның беренче китабы булып, авылда барган катлаулы, каршылыклы социаль үзгәрешләрне күрсәтергә тиеш иде. Роман сюжетын Оренбург тирәсендәге авыл—хуҗалык коммунасы тормышындагы вакыйгалар тәшкил итә. 1921 дә К. үзе ул коммуна оештыручыларның берсе була. Кешеләр арасында яңа мөнәсәбәтләр һәм мораль нормалар тууына багышланган романның исеме дә символик мәгънәгә ия. Эпопеяның «Ныклы адымнар» исемле икенче китабы язылып бетми кала. 1930 нчы елларда К. актив драматургия өлкәсендә эшли: «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1932), «Габбас Галин» (1934) пьесаларын яза. Алар характерларның ачыклыгы һәм үзлеге, конфликтның кискенлеге, тематиканың актуальлыгы б-н аерылып торалар. Бөек Ватан сугышы башлангач К. иҗатында публицистик юнәлеш үсеш ала.

Татар әдәбиятында К. исеме социалистик реализм үсеше, гуманизм традицияләре, хезмәт кешесенә хөрмәт раслау б-н бәйле. Новеллист буларак, ул татар әдәбиятына, бу жанрның классик үрнәкләрен тудырып, үзеннән зур өлеш кертте. К.ның алдагы иҗатында совет власте казанышларына дан җырлау өстенлек ала. Еш кына ул яңа тормышны, җәмгыятьне идеаллаштыра, аерым унай геройлар образын тудырганда схемачылыктан азат булмый. Шуна карамастан К.ның совет чоры иҗаты, татар әдәбиятының бер якты сәхифәсе булып, аны шактый баетты. К. Ленин ордены б-н бүләкләнде (1940). 1950 дә Казанда К.ның Музей-фатиры ачылды.

Әсәр.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1952—56; Избр. произведения: В 2 т. К., 1983—84.

Әд.: Хисматуллин Х. Шариф Камал // История татарской советской литературы. М., 1965; Нуруллин И.З., Кашшаф Г. Шәриф Камал. К., 1940; Шәриф Камал иҗаты. К., 1963.

*В.Х.Ганиев.*

**КАМАЛИЕВ** Әмир Аман улы (псевд. Аманулла) (29.5.1960, Апас р-ны Шигай ав. туа), актёр, язучы. М.С.Щепкин исем. театр уч-шесын (Мәскәү, 1988) тәмамлый. 1988-95 елларда Татар академия т-ры актёры. 1995-2000 дә «Казан» милли мәдәни үзәктә режиссер, 2000 нән Казан татар яшь тамашачылар т-ры баш режиссеры. Аеруча уңышлы дип: Татар академия т-ры сәхнәсендә—Исмәгыйль (М.Фәйзинең «Галиябану», 1991), Закир (Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», 1989), Сәлимҗан (Г.Исхакиның «Зөләйха», 1992), Парис (У.Шекспирның «Ромео һәм Джульетта», 1991) рольләрен; телевизион спектакльләрдә—Муса (Ш.Камалның «Уяну», 1993), Рамай бай (Н.Сайярның «Хан кызы Нурсолтан», 1999) рольләрен атарга була. Аның пьесалары буенча сәхнәләштерелгән «Җәйге кырау» (1992), «Әлепле әртисләре» (1994), «Кылый Кирам баллагы» (1996), «Әле кичә генә яз иде» (1998), «Кыйбла кая?» (1998), «Мактанчык әтәч» (1996), «Моңлы ядкәр» (2002) спектакльләре Татар академия т-ры, Чаллы, Әлмәт татар драма т-рларында, Уфа «Нур» т-рында, Казан татар яшь тамашачылар т-рларында зур уңыш белән бара. «Кайсыгызның теше сызлый?» (2002) исемле хикәяләр һәм шигырьләр, «Әле кичә генә яз иде» (2003) һәм «Моңлы ядкәр» (2005) дип исемләнгән пьеса җыентыклары дөнья күрде.

Әд.: Закирҗанов Ә. «Моңлы ядкарь» // Казан утлары. 2007. №9.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**КУТУЗОВЛАР.** Александр Ярославович Невскийга «пруслылардан» килгән, Чуд сугышының танылган батыры Гаврилның турунының малае һәм Новгородлы Прокшаның оныгы Федор Александрович Кутуздан (ОГДР IV, 31; V, 17). С. Б. Веселовский (1969, 484-485), аңа ияреп А.А.Зимин (1980, 258), Федор Кутузнын XIV-XV йөзләрдә яшәгән реаль шәхес икәнлеген әйтәләр. 1448 елда Василий Федорович Кутузов (ПСРЛ 25, 267) һәм шулай ук башка Кутузовлар, шул исәптән төрки исемлеләре дә, мәсәлән, Булыга, Бурдук һ. б., теркәлгән ( Веселовский 1974, 174). Н.А.Баскаков (1979, 92) фамилия төрки-болгар *кутуз-кутур* «котырган» сүзеннән ясалган булырга тиеш, дип уйлый. (Голенищев-Кутузовларны да кара).

**ЛЕОНТЬЕВЛАР.** 1408 елда Урдадан Рязань кенәзләренә чыккан Батур морза малаенын туруны Леонтийдан (ОГДР IV, 30). XVI-XVII йөзләрдә Тамбов өязендә һәм губернасында дворяннар, дьяклар, боярлар (РБС X, 226). Соңыннан—галимнәр, экономистлар (ЭС 1987, 703).

**МАМИННАР.** XVI йөзнең урталарында һәм икенче яртысында берничә Мамин билгеле, ихтимал, Казан мохитеннән чыгучылардыр: 1554 елда Мамин Байгонь (Мамун Байгун) Нагайга илче булган (Савва 1917, 171) һәм Боровскига яна күченгән Мамин Игнатий Истомин (1596—Веселовский 1974, 193).) Фамилия мамун «яклана, саклана торган» дигән гарәп-мөселман сүзеннән ясалган (Гафуров 1987, 162).—Нәселләреннән танылган язучы Мамин (Сибиряк) Дмитрий Наркисович чыккан, әтисенең исеме (Нәркиз) дә төркиләрдән булганлыкларын күрсәтә.

**МИНИННАР.** Билгеле булганча, «мин» ыруы кыпчак-урда нәселләренең иң атаклыларының берсе һәм аннан күп кенә танылган Урда кешеләре, мәсәлән, Урда кенәзе, Мәскәү «даругасы» Мин-Булат (ПСРЛ 25, 249). Бу нәселдән чыкканнар Мининнар яисә Минчаклар булып киткәннәр.

**МУСИННАР—ПУШКИННАР.** ОГДРда (I, 17; IV, 22) фамилиянең 1118 елда Руська күчкән Муса исеменнән ясалганлыгы әйтелгән. С. Б. Веселовский (1969, 39-87) һәм А.А.Зимин (1980, 162-165) бу дата белән ризалашмыйлар. Беренчесе, Пешковлар һәм Сабуровлар (к.) белән тугандаш Мусин-Пушкиннар XV йөзнең икенче яртысында яшәгән Михаил Тимофеевич Муса Пушкин белән бәйле дип карый (Веселовский 1974, 208). Бер үк вакытта Мусиннарның башка ырулары булу мөмкинлеген дә әйтә, мәсәлән: 1569 елда Новгородта теркәлгән Дмитрий Мусин—

*Дәвамы. Башы 5, 6, 8, 9, 11 саннарда.*

Телегин ыруы. Мусин-Пушкиннар А. С. Пушкинның туганнары, соныннан—галимнәр, язучылар, Казан губернасының генерал-губернаторы.

**НАРБЕКОВЛАР.** «Нарбековлар нәселенең башы Ибраһим морза (чукынгач Илья исеме бирелгән) Олы Урдадан Бөек кенәз Василий Васильевичка чыккан һәм зур биләмәләр белән бүләкләнгән,»—дип язылган ОГДРда (IV, 45). 1551 елдан дворяннар итеп язылганнар. С.Б.Веселовский (1974, 212-213) фикеренчә, Нарбековларның нәселе XV йөз уртасында яшәгән татар морзасы Бәһрим улы Дмитрий Ильич Нарбектан башлана. Нарбековларда соңрак та төрки исемнәрен саклаганнар: к. Шандан, Чуаш һәм Юмран Нарбековлар. Акинфовлар, Державиннар, Теглевлар белән туганлыкта.

**НАРЫКОВЛАР.** XVI йөз урталары тирәсендә Казандагы мәшһүр кенәзләр фамилиясе (ПСРЛ 29, 28). 1546 елда Чура Нарыков белән энесе Шах Галине Васильсурскта каршы алганнар (ПСРЛ 34, 27). 1546-1552 елларда Нарыковлар Казан тормышында күренекле роль уйнаганнар. 1551 елда Чура Нарыков Иван IVне тыңламаганы өчен «кыйналган», ә энесе Алексей морза Нарыков 1552 елда Иван Грозныйга хезмәткә күчкән (ПСРЛ 29, 12, 47-49, 146, 170). Нарыковлар шуннан киткәндер, мөгаен.

**НАРЫШКИННАР.** ОГДРда (II, 60) Нарышкиннарның 1463 елда Бөек кенәз Василий Васильевичка чыкканлыклары язылган. XV-XVI йөзләр арасында Нарышкиннар христиан диненә күчәләр, ләкин үз фамилияләрен саклап калганнар. Иван Иванович Нарышкин 1552 елда Казан янында үтерелә (Веселовский 1974, 213). XVI йөзнең икенче яртысында да Нарышкиннар төрки дөнья белән бәйләнешләрен саклыйлар, моны аларның исемнәре раслый: 1564 елда Яныш Нарышкин, ә 1573 елда Нарышкин Мурза Яныш улы теркәлгән (Веселовский 1974, 207, 381). Россия тарихында Нарышкиннар дипломатлар, декабристлар буларак һәм Алексей Михайлович патшаның Наталья Кирилловна Нарышкинага өйләнүе белән мәгълүм.

**НЕПЛЮЕВЛАР.** XV йөз башында яшәгән һәм «пруслардан» Александр Невскийга чыккан легендар Гланд Камбил нәселеннән булган Федор Иванович Неплюй-Кобылиннан (ОГДР IV, 9; Веселовский 1974, 218; Зимин 1980, 177-179). Төрки чыгышлы Колычевлар, Стеребеевлар, Кобылиннар (к.) белән туганлыкта.

**ОГАРЁВЛАР.** Алтын Урдадан Александр Невскийга чыккан һәм чукынганда Пантелеймон исемен алган Котлымәмет Огар морзадан (ОГДР V, 20; БК II, 6). XVI йөздә билгеле булган Огаревлар: 1506-522 елларда дьяк Андрей Владимирович, XVI йөз уртасында Яков Афанасьевич Елман-Огарев (Веселовский 1974, 108, 227); Федор Огарев 1537-1538 елларда Иван IVнең Казанга илчесе (ПСРЛ 29, 29). Н. А. Баскаков (1979, 172-173) фикеренчә, фамилия төрки огар «биек» сүзеннән ясалган. А.И.Герценның дусты Н.П.Огарев та шушы нәселдән.

**ПАВЛОВЛАР.** Дмитрий Донскойга хезмәткә күчкән Алтын Урда морзасы Осланның (Арсланның) Павел исемле улыннан (ОГДР Y, 28; БК II, 101). Арсеньевлар, Ждановлар, Ртищевлар, Сомовлар (к.) белән туганлыкта. XVI йөздә Павловлар арасыннан казаклар Федка һәм Трукан (ПСРЛ 29, 230-250), 1646 елда Казанда татарлар эше буенча подъячий Кузьма Павлов билгеле (ПКК, 116). Болар барысы да—төркиләр белән нинди дә булса бәйләнешнең саклануы.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Локман Бадыйкшанга 90 яшь



Яшүсмер вакытыннан ук каләм тибрәтә башлаган Локман Әхмәтхан улы Бадыйкшан 1919 елда Татарстанның район үзәге булган Әлмәт авылында туа. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, белемгә тартылу аны Казанга алып килә, унбиш яшьлек Локман Казан химия-технология институтының рабфагына укырга керә. Күңелендә әдәбиятка, халык авыз иҗатына омтылыш булу биредә татар теле һәм әдәбияты буенча Нәкый Исәнбәттән дәресләр алу аның бу теләген тагын да көчәйтә төшә. 1938 елда «Туган ил» исемле альманахта «Дуслар» исемле хикәясе дөнья күрә. (1934 елда Норлат районы газетасына әдәби кушымта итеп чыгарылган «Күтәрелеш» дигән җыентыкта «Сөтле комган» хикәясе басылган була инде). Сугыш алды елларында аның «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында, «Пионер каләме» («Ялкын») журналында күп санлы хикәяләре чыга, Татарстан радиосы аша яңгырый.

1937-1939 елларда Л. Бадыйкшан Казан укытучылар институтында укый. Аны тәмамлагач Татарстанның Сарман районы Иске Минзәләбаш авылы мәктәбенә тел-әдәбият укытучысы итеп җибәрелә. Күп тә үтми, ул янәдән Казанга «Яшь ленинчы» газетасына әйләнеп кайта, хәрби хезмәткә Ерак Көнчыгышка—флотка җибәрелә.

Ерак Көнчыгыш Хәрби диңгез флотында Л. Бадыйкшан җиде елдан артык хезмәт итә, биредә дә язудан туктамый, матрослар тормышын яктырткан язмалары Хабаровск шәһәрендә татар телендә чыга торган «Тревога» исемле газетада дөнья күрәләр. «Матрос бирелми» хикәясе исә «Совет әдәбияты» (1944, № 11, 12) журналында басыла.

Сугышлар тәмамланып, шактый гына тормыш тәҗрибәсе туплаган, туган якларга кайтып иҗат белән ныклап шөгыльләнергә хыялланып йөргән егеткә язмыш тагын да аяусызрак сынаулар әзерләп куйган булып чыга: 1947 елда аны, Советка каршы нахак гамәлләр кылуда гаепләп, кулга алалар, 58нче маддә нигезендә ун елга Колыма лагерьларына озаталар. Бик күп авырлыклар җәбер-золымнар күргән Л. Бадыйкшан алты елдан соң, Сталинның шәхес культы фаш ителеп, заманалар үзгәрә башлагач кына (1953 елда) туган якларына кайта ала.

Локман Бадыйкшанның 1959 елда Татарстан китап нәшриятында хикәяләрен һәм әкиятләрен туплаган «Атау кызы» исемле беренче, 1971 елда «Атау егете» дип аталган икенче китабы дөнья күрә.

Тормышның күп авырлыкларын, гаделсезлекләрен яктыртып язылган «Мөртәд» романы 1994 елның 5-6 саннарында «Казан утлары» журналында, 2001 елда «Мирас» журналының 7-8 саннарында «Колымадан кайткач» исемле күләмле әсәре басылып чыга. Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен күпсанлы орден-медальләр белән бүләкләнә.

Л. Бадыйкшан—1998 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2002 елда ул язучыларның Кол Гали премиясенә лаек була.

## Рифат Сәлах



Рифат Сәлах (Рифат Гали улы Сәлахов) 1987 елның 8 июлендә Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында эшче һәм укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылларында урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый һәм 2004—2009 елларда Казан дәүләт университетының юридик факультетында белем ала.

Р. Сәлах тел-әдәбият белән мәктәптә укыганда ук кызыксына. Унынчы-унберенче сыйныфларда белем алганда, район газетасында шигырьләре басыла башлый. Тел һәм әдәбият буенча олимпиадаларда катнаша.

Ул 2004 елдан актив иҗат итү белән шөгыльләнә. Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә чыныгу ала. 2007-2009 елларда әлеге берләшмәнең студентлар ягыннан җитәкчесе була. Студент чагында Казан дәүләт университетының татар студентлары газетасы «Тәрәзә»не чыгаруда катнаша. 2006-2009 елларда әлеге газетаның баш мөхәррире урынбасары булып эшли. Татарстан Республикасы Яшьләр, спорт һәм туризм министрлыгының «Идел» яшьләр үзәге оештырган «Иделем акчарлагы—2005» конкурсында шигърият буенча беренче урынга, «Иделем акчарлагы—2006»да «Гран-при»га, Казан дәүләт университеты үткәргән Идел-Урал төбәге студентларының иҗат бәйгесе «Шигъри Сабантуй—2006»—икенче, «Шигъри Сабантуй—2008»дә беренче дәрәҗәдәге дипломга лаек була. Шигырьләре матбугатта даими басыла. Шул исәптән, безнең «Казан утлары» журналында да берничә мәртәбә шигырь бәйләмнәре дөнья күрде. 2007 елда Татарстан китап нәшриятында «Күнел бөртекләре» дип исемләнгән беренче китабы, быел исә «Яшел ай» исемле икенче китабы чыкты. Яшь шагыйрьнең иҗатын хуплап һәм ышаныч белдереп, иҗаты турында Р. Батулла, Ә. Рәшит, Р. Зәйдулла һәм башка әдипләр матбугатта да үз фикерләрен әйттеләр.

Үткән елның ахырында Рифат Гали улы Сәлахов Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

Хәзерге вакытта Рифат Сәлах «Идел» журналында бүлек мөхәррире булып эшли.



Шагыйрьләр Хәсән Туфан, Тимер Арслан һәм башкорт язучысы Сәгыйть Агиш. Уфа. 1958 ел.



Лондонда яшәүче татар шагыйре Рөстәм Султи.



Җыелышта нотык тыңлыйлар: сулдан уңга—Шәйхи Маннур, Фаил Шәфигуллин, Илдар Юзеев, Эдуард Касыймов. 1978 ел.



*Татарстан Язучылар берлеге (ул вакытта Союз дип йөртәләр иде) хезмәткәрләре: сулдан уңга—Дания Хәмидуллина, Мәдинә Минҗанова, Рәмзия(?), Сафия Абдуллина, Мария Перегудова. Алгы планда—Союзның оештыру эшләре буенча секретаре, язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин. 1977 ел.*



*Шагыйрь һәм галим. Рифат Җамал (Рифат Корбанов). 1995 ел.*



*Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбай Казан шагыйрәсе Лилия Газизова белән. Казан. 2007 ел.*

Хөрмәтле «Казан утлары» редакциясе!

Гөлчәчәк Галиеваның 7, 8 саннарда дөнья күргән «Газзәбану» исемле романын бик тә кызыксынып, үзенә бер ләззәт һәм рәхәтлек табып укыдым. Авторның элегрәк китап булып чыккан әсәрләре белән танышмын, бу роман исә тагын да уңышлырак, ул зур осталык белән иҗат ителгән.

Әсәр тулаем үтә кызыклы, бай эчтәлекле, әмма аның кайбер якларына аерым тукталып үтмәкче булам.

Беренчедән, ул асылда чын тормыштан алынып язылуы һәм вакыйгаларның ышандыргыч дөреслеккә туры килүе белән укучының игътибарын беренче битләреннән үк җәлеп итә. Һәм азагына кадәр үзенә бәйләп, сине тәмам әсир итә. Укучы бар дөньясын онытып, укып бетергәнче аннан аерыла алмый. Моның тагын бер сәбәбе—романның гаҗәеп матур, бай тел белән язылган булуы. Өстәвенә, романда яшь буын тарафыннан инде онытыла барган мәкальләр һәм әйтемнәр күп. Һәм алар кайбер әсәрләрдәгечә тырпаеп тормыйлар, текстка бик тә «мач килеп», аны форма ягыннан да, эчтәлек ягыннан да көчәйтәләр. Безнең өлкән буын бала чагыннан ук ата-ана тарафыннан шушындый үткен һәм акыллы мәкальләр һәм канатлы сүзләр ярдәмендә тәрбияләнгән бит инде.

«Газзәбану» әсәре бүген һәр татар гаиләсе өчен тәрбияви яктан өстәл китабы булырлык дәрәҗәдә дип әйтәсем килә. Романда тасвирланган ул вакыттагы татар гаиләсенең әлегә бозылмаган, ят гадәтләр белән буталмаган тормышы-яшәеше, бер-беренә игътибарлы һәм ихтирамлы мөнәсәбәттә гомер кичерү, әхлакый һәм дини яктан саф, чиста булу, гаиләдә урнаштырылган тәртип, пөхтәлек—болар барысы да гореф-гадәтләребезнен ни дәрәҗәдә югары, дөрес, бай вә файдалы булганлыгын күрсәтә бит.

«Газзәбану» бер генә укучыны да битараф калдырмастыр. Әсәрне укып чыккач, аның тәэсирендә уйланырга, үткән белән бүгенгене чагыштырырга һәм ниндидер нәтиҗә-фикер чыгарырга мәҗбүр буласың. Әгәр милләтебезгә чын мәгънәсендә ирек, хөррият, үз мохитендә үз тәртибе, үз менталитеты белән яшәү мөмкинлеге бирсәң, һәрбер татар гаиләсе, үзенең булдыклылыгы, тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге нәтиҗәсендә, нинди муллык белән тулы тормышта яшәр иде кана.

1920-21 елларда дәүләт тарафыннан оештырылган ачлыктан интеккән һәм фаҗигале югалтуларга дучар ителгән авыл кешесенең яшәүгә сәләтле булырга омтылуы вә чиксез тырышлыгы нәтиҗәсендә бары берничә ел дәвамында аякка баса алуы һәм тормышын рухи яктан да баетырга омтылуы романда бик тә ышандырырлык итеп бирелгән. Чөнки «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән эчүчелек, тәмәке төтене суыру, ялкаулык, хөрәсәнлек, кояш чыккач та сәрхушлектән айный алмыйча йоклап яту, өстәвенә, таһарәтсез яшәү һәм башка шундый тискәре «уңышлар» элек үз мохитенә, үз диненә тугры чын татарда һәм аның гаиләсендә булмаган бит ул.

Сүземне йомгаклап, һәрвакыт яратып укыла торган авторыбызга үземнең теләк вә тәкъдимнәремне дә әйтәсем килә: бу олуг хезмәтен дәвам итсә иде ул. Әсәргә кергән гаиләләрнең колхозлашу чорындагы, утызынчы елларда оештырылган дәүләти вәхшилек һәм сугыш елларындагы кичерешләре дә язылса иде. Персонажлар чын тормышыбыздан алынган булу сәбәпле, аларның дәвамы—яшь буыннарның бүгенге язмышлары турында да язып, романны зур бер китап итеп чыгарса иде Гөлчәчәк ханым. Аның яратып укылачагына иманым камил, чөнки «Казан утлары»нда басылган кадәресен халык укып туймады һәм түземсезлек белән әсәрнең дәвамын көтә. Ә журналның үзен табу, аеруча район һәм авылларда, мөмкин булмаган хәлгә әйләнде.

Форсаттан файдаланып, «Газзәбану»ны түкми-чәчми басып чыгарганы өчен журнал редакциясенә олы рәхмәтемне белдерәм.

*Ихтирам белән,*
**Габбас МӨХӘММӘДШИН.**

# 2010 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

## (мөселман ай календаре буенча 1431–1432 һиҗри еллар)

**1 гыйнвар (җомга)**—Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**16 гыйнвар (шимбә)**—Сәфәр ае башланган көн.

**26 февраль (җомга)**—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**13 июнь (якшәмбе)**—мөселман календарендә изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**17 июнь (пәнҗешәмбе)**—Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич—Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**8 июль (пәнҗешәмбе)**—Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**13 июль (сишәмбе)**—дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбан ае башлану көне.

**26 июль (дүшәмбе)**—Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**11 август (чәршәмбе)**—чират изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

**9 сентябрь (пәнҗешәмбе)**—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**15 ноябрь (дүшәмбе)**—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**16 ноябрь (сишәмбе)**—Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**17,18,19 ноябрь (чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)**—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**7 декабрь (сишәмбе)** 1432 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**16 декабрь (пәнҗешәмбе)**—Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

*Төзүче-мөхәррир*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

## Эштән чыгарылган түрә зары

Үрмәләдем үрләргә,
Урным булды түрләрдә.
Түрдән төшмәс кебек идем,
Керми торып гүрләргә.

...Эшемә килә идем,
Эшләпәм элә идем.
Китерә белгән кешене
Күтәрә белә идем.

Баҗаларым, дусларым,
Үзем бүлдем постларын.
Инде хәзер яңа башлык
Утыртыр үз дусларын!

Безнең инеш тирәндер,
Тирән җире билдәндер.
Күршемнең биле турайды,
Төшәсемне белгәндер.

Йортлар салды якыннарым,
Чыгарып балконнарын.
Инде кем тартып чыгарыр,
Батканда якыннарым?

Биек-биек баскычлардан
Тотынмый менми идем.
Жалу язган кешеләрдән
Котылмый тынмый идем.

Карыйм Арча якларына,
Иркәм Арчаларныкы.
Мин баш чакта минеке иде,
Хәзер башкаларныкы.

Биек тауның башларында
Чияле чыбык кына.
Портфелемне бирегез дип
Кычкырмыйм чыгып кына.

**Маннур САТТАРОВ**

## Алма бакчасы

*Төне буе тын бакчада кемдер*
*Алма коеп йөрде*
*шыбыр-шыбыр.*
*Ә мин яттым төнге күккә карап—*
*Йөрәккәем дәште:*
*«Сабыр. Сабыр...»*

Рәмис Аймәт

**Тын бакчада кемдер йөри,**
**Алмалар булды харап—**
**Шыбыр-шыбыр коелалар...**
**Мин ятам күккә карап.**

**Якасынаябышмадым.**
**Кыланмыймын артыгын—**
**Бүлмәмдә мин әйбәт кенә**
**Сүгәм адәм актыгын.**

**Йолдызларга бер карыйм да**
**Уйлап куям каты сүз—**
**Ләкин аны ычкындырмыйм.**
**Йөрәк дәште: «Рәмис, түз...»**

**Тик мондый хәл кабатланмас,**
**Үчен алам алмамның!**
**Иртәгә ике көпшәле**
**Мылтык сатып аламын,—**
**Бәлки.**

## Кул бирү

*Кайтып төштем дә авылга,*
*Тукталдым таныш ярда.*
*Хәл-әхвәлне белешкәндәй,*
*Кул бирдем арышларга.*

Рашат Низами

**Хәл-әхвәлне белешкәндәй,**
**Кул бирдем арышларга.**
**Ничек инде кул бирмәскә**
**Иң якын танышларга.**
**Аннан ары киттем, әйе,—**
**Ике-өч чакрымнар бар,—**
**Бодайларыма кул бирдем.**
**Алар да сагынганнар.**
**Аннан төшеп киттем аска.**
**Анда үсә чөгендер.**
**Кул бирдем һәммәсенә дә**
**Иелеп ни өчендер...**
**Кәбестә басуына да**
**Шул ук көнне җитештем.**
**Кишерләр янына инде**
**Караңгы төшкәч төштем...**
**Яхшы булды.**
**Үсемлекләр**
**Канәгатьтер дим.**
**Бардым...**
**Терлекләр калыр иртәгә.**
**Бүгенгә җитәр. Ардым.**

**Ринат МӘННАН**

# ДӨНЬЯ КӨТМЕШ...

### Мөгезне үзем куям

Безгә утызга якынлашып килүче, әле бер дә кияүдә булмаган Роза исемле кыз эшкә керде. Коллективта урнашкан гадәт буенча, яңа кеше белән танышу өчен чәй табыны көйләдек. Көлешә-көлешә тәмләп чәй эчтек. Шунда Фәнзия исемле хатын:

—Роза, син озаклап йөрмә инде, әйдә, кияүгә чык, туенда күнел ачарбыз, балалар табарга, аларны үстерергә соңга каласың бит,—диде.

—И-и, Фәнзия апа, утызга җитәм, үзем таба алмадым, менә сез табып бирсәгез генә инде бирәр ир,—диде Роза.

—Табабыз, табабыз,—диешеп, табында утырганнар гөрләшеп алды.

Шунда ире үлеп озак вакыттан бирле ялгыз яшәүче Илгизә телгә килде:

—Роза, ышанма боларга, алар миңа да ир табып бирәбез дигәннәр иде, менә ун елдан артты инде, әле дә булса табып биргәннәре юк.

Фәнзия дә җавапсыз калмады:

—Һе, синә ничек ир табасың, тегенди-мондый гына ярамый, сина бит мөгезле булсын.

—Юк,—диде Илгизә,—мөгезле булмаса да ярый. Сез миңа ир генә табып бирегез, мөгезен үзем куярмын.

### Бияләр

Шәһәр клубларының берсендә дискотека бара. Яшьләр рус һәм чит ил музыкасына дөньяларын онытып биилəр. Кичәнең иң кызган минутларында гына милиция формасы кигән ике яшь егет килеп керде. Күрәсең, егетләр күптән түгел генә татар авылыннан килеп, шәһәргә эшкә урнашканнардыр, чөнки залга күз йөгертеп чыгып, тәртип булуына инангач, якында гына биюче кызларга сорауларын саф татарча бирделәр.

—Кызлар, биисезме?

—Бияләрбез,—диде бер кыз. Аңа иптәшләре дә кушылды:—Бияләр без!

Милиционерлар ни көләргә, ни еларга белмәделәр, бер сүз дә әйтмәделәр, борылып чыгып киттеләр.

И туган тел, и матур тел. Көлеп булмый. Еласаң гына инде...

### Стакан сораганга бала

Балалар бакчасында эшли башлаган чак. Кичен кунакка барасы. Балалар төшке йокыдан уянгач та әби-бабайлар—оныкларын, эштән иртәрәк китә алганнар балаларын ала башлый. Бу көнне дә сәгать бишләр тирәсенә бер малайдан кала барлык балаларны алып бетерделәр. Менә алты да тулды, җиде дә тулды, теге малайны алучы юк. Киендердем дә, кизү торучыга адресымны язып калдырып, баланы алып кайтып киттем. Сигез тулып килгәндә ишекнең кыңгыравына бастылар. Мин йөгереп барып ишекне ачтым. Ишек төбендә иң яхшы танышын очраткан кешедәй балкып бер ир басып тора. Ул авызын ачарга өлгергәнче мин тезеп киттем:

—Сез нәрсә, тәрбиячене кешегә дә санамыйсызмы әллә? Үзегезгә кирәкмәгән бала безгә кирәк дип уйлыйсыздыр...

Ир кеше бер агарып, бер күгәреп, күзләрен челт-челт китереп мине

тынлап тора. Тиз генә бүлмәгә кердем дә рәсем ясап утырган баланы алып чыктым. Мин баланы теге иргә сузам, ул чәбәләнә-чәбәләнә баланы кире мина этә. Баланы бер-беребезгә этешеп басып торабыз. Аптырадым бит моның алай кылануына.

—Нәрсә, әллә балагыз бөтенләй дә кирәк түгелме?—дим.

—Минем бала түгел бу,—ди теге ир, көчкә ушына килеп.

—Кемнеке соң?

—Белмим. Мин бер ун гына минутка стакан биреп тормассызмы дип кергән идем.

Ни кыләргә, ни еларга белмичә, баланы кочаклап ишек төбендә басып калдым. Теге ир исә артыннан кугандай атыла-бәрелә подъездан чыгып йөгерде. Кая булсын, күршедәге аракы кибетенә инде. Ә мин ана чак кына бала тоттырып җибәрмәдем.

**Илүсә НӘБИУЛЛИНА**
*Әлмәт*

## «А» хәрефенә башланган җөмләләр

*Ак аракы йөз каралта.

*Атлаган саен эчем ашлары уздырып аяктан язабыз, онытканда бер Коръән укытып, савапка кул сонабыз.

*Аш бүлмәсе—киленгә эш бүлмәсе.

*Акча киендерә дә, чишендерә дә.

*Араны сүз, буаны су ера.

*Ачык дәрестә укытучы да укучы хөкемендә.

*Аракы телне, карангы күзне ача.

*Аш калудан эш калу яманрак.

*Алтын—табылган, шагыйрь күмелгән жирендә кадерле.

**Наилә МИҢНЕХАНОВА**
*Башкортстан.*

## Кәҗәгә көлке!

Камил Кәримовның кап-карак, кып-кысыр кара кәҗәсе күрше карчыгының кишер кишәрлегенә кереп, кып-кызыл кишерләрне карун корсагын кинәндергәнче керт-керт кимерде. Кич кенә кайтып, капкадан кергәндә каләмен кабып, карачкы күк күккә карап каткан караучысын күргәч, кинәнепләр көлде: «Камил Кәрим кушаматлы койрыксыз куркак кәҗә котсыз корсагын, кызын, катынын караклашмыйча, кәгазь кыштырдатып кына кайгыртмакчы! Кәҗәгә көлке! Кәмит!»

**Риф БӘДРИ**

# 2009 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2009 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Еллар узган саен гамь арта. №1

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНӘ 75 ЕЛ**

Бергә булыйк, берәгәйле булыйк! *(Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов белән Р. Юныс әңгәмәсе).* №10

Галимуллин Ф. Тыныч һәм эшлекле еллар. №10

Имамов В. Татарстан язучыларының Чаллы оешмасы. №10

Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда. №10

Кеше китә, җыры кала... *Шигырьләр.* №10

Миңнуллин Т. Минем эшем түгел иде ул. №10

Мостафин Р. Беренче идарә. №10

Мөхәммәдиев Р. Иң бәхетле елларым. №10

Рәхим Г. Күңелгә уелган хатирәләр. №10

Салихов Д. Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасы. №10

ТР халык язучылары һәм халык шагыйрьләре, әдәбият өлкәсендә ТР Г. Тукай исемендәге дәүләт, М. Җәлил исемендәге республика премияләре лауреатлары. №10

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге премияләре лауреатлары. №10

Тимергалин А. Тикән-тигәнәкләр аша—рушан йолдызларга табан. №10

Фәйзуллин Р. Үзебезнең союз, үзебезнең берлек. №10

Хәмидуллин Л. Берләшеп, аралашып яшәү еллары. №10

Хәсәнова Ф. Татар шигърияте: үткәне һәм бүгенгесе. №10

Шамов А. Шук хатирәләр. №10

Ширмән Х. Татар прозасы: югалтулар һәм табышлар. №10

Яруллин Ф. Берлек бердәм булса гына. №10

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әмирхан М. Гәүһәршад. *Тарихи бәян.* №№6, 7

Әхмәдиев Н. Мөнирстан. *Роман.* №№1-4

Баттал Ф. *Сатирик хикәяләр.* №2

Баттал Ф. Ка-аш-мар!.. *Хикәят.* №11

Бәйрәмова Г. Үз хәлемне үзем беләм. *Хикәя.* №6

Галиева Г. Газзәбану. *Роман.* №№7, 8

Галиев Ф. Нигә киттең, эти?.. *Хикәя-истәлек.* №7

Галиуллин Т. Итле пәрәмәч. *Хикәя.* №8

Ибраһим-Вәлиди Л. Өстән карап. *Хикәя.* №2

Ибраһим-Вәлиди Л. Яңгыр кызы. *Хикәя.* №12

Мирхәйдәров Р. Җәяүле сәйран. *Роман.* №12

Мөхәммәдиев Р. Кош булып очар идем... *Роман.* №1

Нәбиуллина И. Гөлҗиһан өянкесе. *Хикәя.* №1

Низами Р. Бомж. Ике көтүче. *Хикәяләр.* №3

Поварисов С. Утлы дуга кыңгыравы. *Роман-хатирәдән өзек.* №8

Харисов М. Майорны өркеттем. Көчкә табыштык. *Кыска язмалар.* №3

Хафизов С. Сәрви-Сәрвиназ. *Повесть.* №4

Хәбибуллина Р. Зәйтүн илендә. *Повесть.* №12

Хәким З. Легионер. *Роман.* №№9-11
Хәлим А. Хунвейбин. *Роман-эпопея. Икенче китап.* №№9-12
Хәсәнова А. Нокта. *Хикәя.* №7
Шәрипов С. Кавыштырам дигәч кавыштырам. *Хикәя.* №9
Шәфигуллин Р. Гайсә йозагы. *Кыйсса.* №11
Ширмән Х. Кыргыйлык. *Хикәя.* №6
Яхин Ф. Күке фалы. *Хикәя.* №11

**ШИГЪРИЯТ**

Әхтәмова Г. Киң илдә. *Шигырьләр.* №4
Баян Ә. Соңгы аккош җыры. *Шигырьләр.* №4
Бәйрәмова Г. Сынадың, тормыш, сынадың... *Шигырьләр.* №1
Бәшәр Р. Ил гаме, татар гаме бу... *Шигырьләр.* №10
Булатова К. Язгы уйлар, яңа шигырьләр. №3
Вафин М. Кеше атлы туганнарга... *Шигырьләр.* №11
Габдерәхим Ф. Иң назлысы — «татар» дигән сүз. *Шигырьләр.* №9
Гаделша Ш. Көзнең киеренке минутлары. *Шигырьләр.* №9
Гыйбадуллина Л. Хәтерлим, хәтерлим... *Шигырьләр.* №1
Гыйләҗев И. Шатлыкларым булды, җиңүләрем. *Шигырьләр.* №1
Дәрзаман Ж. Тормыш — сәхнә. *Публицистик поэма* . №12
Җамал Р. Күңелгә килми кышлар. *Шигырьләр.* №4
Җиһангирова Ш. Йөрәгемә учак яктым. *Шигырьләр.* №7
Зәйдулла Р. Иңгә-иң. *Шигырь.* №10
Идиятуллин Р. Күңел сердәшләре. *Шигырьләр.* №6
Имаев Р. Нәрсә булган бу җилләргә? *Шигырьләр.* №4
Латыйф Х. *Дүртьюллыклар.* №11
Мансуров З. Кайтавазы кайта көй-моңнарның. *Шигырьләр.* №7
Маннапов Ш. Аргамагын тыймый җайдагы. *Шигырьләр.* №12
Мингалим Р. Гөлләр анда гел чәчәктә... *Шигырьләр.* №2
Мирза М. Адәм баласы. *Бишьюллыклар.* №1
Морат Г. Дүңгәләктәй үтеп бара дәвер... *Шигырьләр.* №8
Мостафин Ш. «Җанҗиләк»ле гомерем мизгелләре. *Шигырьләр.* №12
Мөхәммәтшин Г. Үзем җирдә, күңелем күктә минем. *Шигырьләр.* №10
Низами Р. Мењәр яфрак — урман күзләре... *Шигырьләр.* №8
Рәхимова Б. Бик кадерле ил бит бу!.. *Шигырьләр.* №10
Рәхмәтулла С. Минем тавым. *Шигырьләр.* №7
Рәхим Г. Алма бакчасында уйлану. *Шигырьләр.* №11
Сабиров И. Ә уйларым — зарлы һәм ачы... *Шигырьләр.* №3
Садә Г. Мин кабыздым гомер шәмнәрен... *Шигырьләр.* №2
Сафина Н. Җанда — гамьле моң. *Шигырьләр.* №3
Сәлах Р. Җәйсылуның яшел толымы. *Шигырьләр.* №6
Ситдыйкова Ә. Эзләп тапкан бәхет кадерлерәк... *Шигырьләр.* №4
Суфиянов А. Таң йөрәге — сандугач. *Шигырьләр.* №9
Тукай Г. Татар яшьләре. *Шигырь.* №4
Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №5
Фәтхетдинова Л. Канат чыгарган йөрәк. *Шигырьләр. (Р.Фәйзуллинның кереш сүзе белән)* №12
Хәйруллина В. Авыр тынлык. *Шигырьләр.* №6
Шагыйрьҗан Л. Шигырь тажы. *Шигырьләр.* №11
Шәех Л. Дөнья хозурында. *Шигырьләр.* №1
Янсуар Л. Дөньялыкта, фани мәңгелектә... *Шигырьләр.* №8
Яруллин Ф. Кояш оясыннан нурлар җыям. *Шигырьләр.* №2

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Гыйльманов Г. Бәхет көлмәгә. *Тамаша.* №6
Сабыр Р. Абага алмасы ачы була. №3

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Асылов Д. Без дә нефть чыгарыштык. №9
Без килмешәк түгел! *(Рамил Бигнов белән Фәнис Фәтхи әңгәмәсе)* №2
Вафин Т. Мәкруһлар. №№1-4
Галиева Ф. Вазифа. №7
Гариф Н. Гыйбрәтле хикәятләр. №12

Зарипов Р. Уйланулар. №12
Илдарханов И. Ул бөек иде, лəкин... *(көрəшче Шəзам Сафинның күтəрелү һəм төшү тарихы)* №6
Тимергалин А. Алла. *Фəлсəфи уйланулар.* №2

**МИЛЛИ ГАМЬ**

Таһиров И. Сөт калса, Ватан кайтыр. №6

**ƏДƏБИ ТƏНКЫЙТЬ**

Галимуллин Ф. Сембер шагыйрəсе. *(Иделбикə иҗатына бер караш).* №4
Галиуллин Т. Шигъри җан аһəңе. №12
Нəҗмиев Т. Сабаның суында бар... №6
Хатипов Ф. Өр-яңа эчтəлек. №1
Хатипов Ф. Укучы ышанырмы? №9
Хəзерге хикəя. *«Түгəрəк өстəл» сөйлəшүе.* №5
Хəйруллина Г. «Кыр казы исе килə». №9
Хəсəнова Ф. Өченче хакыйкать. №7
Хисамов Н. Газинур—батырлар исеме. №8
Фəизов Р. Вəзенгə сыймаган уйлар. №1
Шəрəфиев Р. Төп геройлар—шəүлəлəр, кортлар. №6

**ФƏН**

Бакиров М. Чура батыр. №7
Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №№1, 4, 6, 9, 11, 12
Гарифуллин С. Төркилəр шəҗəрəсе. №12
Миңнегулов Х. Төрки сүз сəнгатенең тажы. №11

**ТАРИХ**

Бəйрəмова Ф. Чəрдəн ханлыгы. №12
Ибраһимов Г. Дошманнар арасында дүрт ай. *(М. Гайнетдиннең кереш сүзе белəн.)* №12
Фридерих М. Козгын өнчыгышка оча. №4
Халиков А. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. №№5, 6, 8, 9, 11, 12

**ƏДƏБИЯТ ТАРИХЫНА**

Галиуллин Т. «Гаяз əфəнде шагыйрьдер». №3

**ƏДƏБИ МИРАС**

Давыдов Ə. Төрле иллəрдəн. *Шигырьлəр.* №3

**СƏНГАТЬ**

Абдуллин М. Псевдоним—кушамат түгел. №8
Əбдрəшитов А. Безнең күргəзмə. №8
Гыйммранова Д. Сəхнə—илһам мəйданы. №6
Мөхибуллин Н. Сəхнəдəн—фронтка. №8
Низамова Ф. Сəхнəдə ул—аккош, сандугач... №7
Садыйков К. Үзебезнең рəссам. №3
«Уян, əйдə, татар киносы!» *(Түгəрəк өстəл материаллары.)* №7
Хəмидова М. Еракка төшкəн якты. №9
Шакир Ə. Миллəтебезнең якты бер йолдызы *(Габдулла Шамуковның тууына 100 ел)* №12
Шаһиева Р. Мəңгелек белəн тоташу *(Əхсəн Фəтхетдиновка 70 яшь).* №6

**«АГЫЙДЕЛ» ЖУРНАЛЫ БЕЗДƏ КУНАКТА**

Акбулатова Ф. Атай икмəге. *Хикəя.* №5
Əбүзəр С. Гулливер. *Шигырьлəр.* №5
Əминев Ə. Рухиятебез елъязмасы. №5
Əминев Ə. Танкист. *Повесть.* №5
Ганиева Т. Минсез дөнья. *Шигырьлəр.* №5
Гыйниятуллин Т. Суга баткан кеше. *Хикəя.* №5
Котыева Г. Əй, моңым... *Шигырьлəр.* №5
Уразголов Р. Сандык. *Хикəя.* №5
Шəрипов С. Карак. *Хикəя.* №5
Якупова Г. Күгəрченем. *Шигырьлəр.* №5
Янбəк Р. Яңа буын. *Шигырьлəр.* №5

**КАРДƏШ ƏДƏБИЯТЛАР**

Жумабаев М. Пəйгамбəр. *Шигырьлəр.* №6
Кутлу Ф. Ике китап һəм бер хикмəт. №5
Тарханова Ф. Казакъның шигъри пəйгамбəре. №6

**ХӘТЕР**

Акбулатов Я. «Киттек!»—диде Гагарин. №7
Әхмәтҗанов М. Нәкый Исәнбәт турында хатирәләрем. №5
Бәйрәмова Г. Сагынмаска аны мөмкин түгел! №6
Бәширов Г. Күңел дәфтәре. №№1, 3, 8, 9, 11
Вәлиев М. Гыйбрәтләр аласы бар. №4
Госманов М. Бирелмичә калган сораулар. №5
Госманов М. Режиссер хыялы һәм кырыс чынбарлык. №11
Күпрелезадә. Габдулла Тукаев. №4
Лавришко В. Хәтер төеннәре. №7
Миңнегулов Х. Тукайны Питер дә онытмый. №4
Мостафин Ш. Бабам васыяте. №5
Нажар Нәҗми хатлары. №9
Нәҗмиев Т. Әбрар Кәримуллинның туган ягына язган хатлары. №4
Рәшит Ә. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр.* №№1, 2, 4
Фәттах Н. Беренче шигырь күк балачак... *Истәлекләр.* №№1, 2, 3
Хәбибуллин М. Гумилев сабаклары. №6
Хәмидуллин Л. Ерактагы ак җилкәннәр. *Тарихи өзек.* №6

**ЮБИЛЕЙЛАР**

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Хәйри Ә. Бөек галимебез. №1

ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Дәрдемәнд. Шигырьләр. №11
Хәмидуллин Л. «Милләт уянсын дисәң..» №11
Фазлетдинов И. Дәрдемәнд иҗатының мифологик тамырлары. №11
Дәрдемәндкә тәкълид-нәзыйрәләр, багышлаулар. №11

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Сверигин Р. Гүзәллеккә юл ярганда. №2

ГАБДРАХМАН СӘГЪДИНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Миңнегулов Х. Олуг мөгаллим һәм әдәбиятчы. №3

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ. №8

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Әхмәдуллин А. Милләт каһарманы. №12
Фәйзуллин Р. Синең сазың дөрес уйнады. №12

ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Кәрим Ф. Моң һәм көч. Төрле еллардан шигырьләр. №1
Фатих Кәрим турында әдипләр. №1

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Күңел азатлыгы *(Ә. Еники турында каләмдәшләре).* №3
Мотыйгуллина Ә. Әдип бәхете. №3
Юныс Р. Җиз кыңгырау татарны алга дәшсен! №3
Еники Ә. Тигезлек аша татулыкка. №3
Еники Ә. Фактлар дәфтәреннән. №№1—3
«Миннән «Матурлык» кала...» *(Әдипнең төрле кәгазь кисәкләренә язылган уй-фикерләре).* №3

НИГЪМӘТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ. №12

ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Шекспир В. Сонетлар. №11
Ш. Мөдәррис тәрҗемәсендә. №11

ФӘТХЕРАХМАН ӘХМӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Шамова Ә. «Татар сәнгате күгендә атылган йолдыз». №11
Ф. Әхмәдиев турында замандашлары. №11

РОЗА ХАФИЗОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. №2

КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. №6

ШАМИЛ РӘКЫЙПОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. №9

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Хәмид Р. Язылмаган драма. №5
Шәфигуллин Ф. Түзә шагыйрь башлары. *Хикәя.* №5

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

ХАРИС ЯКУПОВКА 90 ЯШЬ

Редакция котлавы. №12

ЛОКМАН БАДЫЙКШАНГА 90 ЯШЬ

Редакция котлавы. №12

ЯХЪЯ ХАЛИТОВКА 80 ЯШЬ

Редакция котлавы. №8

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВКА 75 ЯШЬ

Гыйләҗев И. Миңнуллин Ж. Эш күрсәткән ирне ил онытмас! №5

ӘМИРХАН МОТАЛЛАПОВКА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №6

ЧЫҢГЫЗ МУСИНГА 75 ЯШЬ

Редакция котлавы. №8

РӘФЫЙК ШӘРӘФИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Кәримов К. Татар эзләүче дустыбыз. №2

ФЛҮН МУСИНГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №2

ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВКА 70 ЯШЬ

Ганиева Р. Күренекле галим-педагог, чын хатыйп. №5

ДАМИР ГАРИФУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №5

ИЛДАР ЗАРИПОВКА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №11

ӘХӘТ ГАФФАРГА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

ЭСФИР ЯҺУДИНГА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

РАВИЛ РАХМАНИГА 60 ЯШЬ

Юныс М. Чакрымнарын югалткан мең чакрым. №5

ХӘМИТ ЛАТЫЙПОВКА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №3

МАНСУР САФИНГА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №5

КИМ МИҢНУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Вәлиев Мөд. Кем ул Ким Миңнуллин? №1

ГАФУР КАЮМОВКА 50 ЯШЬ

Хәмзин А. Ул үзе бер театр... №4

РӘМЗИЯ ГАБДЕЛХАКОВАГА 50 ЯШЬ

Редакция котлавы. №11

**«ИДЕЛ» ЖУРНАЛЫНА 20 ЯШЬ**

Әсхатова А. «Татнет—татар халкын һәртөрле бәладән коткара торган дәва түгел». №7

Гыйматдинова Н. Менә без дә үсеп життек. №7

Гыйматдинова Н. «Зинһар, мине дә калдырма...» №7

Зәйдулла Р. Ташка ордым башны. №7

Сиражи И. Нәфисә Хәйруллина: «Артистка булмасам—бәхетсез булыр идем». №7

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Закиржанов Ә. «Күңелләрне уятыр». №2

Гайфиева Г. Догалы корт тылсымы. №4

Гайфиева Г. Зәйдулла ташы. №9

Мөхәммәтҗанова Л. Амазонкалар ирдәүкәме? №8

Низами Р. Сугышларны кичкән догалык. №4

Шәрәфиев Р. Уйландыра да, кисәтә дә. №4

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Мәһдиев М. Бер моң. *Хикәя.* №4

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Галиев Г. Кәчтүм. №6

Фәизов Р. Хуҗин, ашарга нык син! *Хикәяләр.* №9

**ЮМОР-САТИРА**

Абзалов Р. Тафтограммалар. №1

Аманулла. Джентельмен. №5

Бәдри Р. Кәҗәгә көлке! №12

Галиев М. Өмә. Күршеләр. *Хикәяләр.* №10

Гаффар Р. Манзаралар. №4

Гомәр Г. Без нинди кавем? №2

Гыйсметдин Д. Чәйне чәйнегеннән..., Телевизоры гына булсын! *Хикәяләр.* №1

Идрисов Р. Таштабан. *Хикәят.* №6

Мәннан Р. Алма бакчасы. *Шигырьләр.* №12

Мәхмүдов Ә. Кем башына бу сөмсез таш?.. №6

Миңнеханова Н. «А» хәрефенә башланган җөмләләр. №12

Нәбиуллина И. Дөнья көтмеш. *Шаян этюдлар.* №12

Саттаров М. Эштән чыгарылган түрә зары. *Шигырь.* №12

Хәмзин А. Шаян хикәяләр. №4

Хәмзин А. Ур-ра кычкырып!.. *Сәхнә монологы.* №9

Шәйхрамов Ә. Каламбурлар. №6
Шәле К. Мин дә булдым... *(«Тынгысыз каләм» сәхифәләреннән)* №10

**АК ҖИЛКӘН**

Кәримов К. Яшел читлек. *Хикәя.* №5

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Вәлиева Л. Сәфәрдә җан. Сүздән сурәт... *Шигырьләр.* №9
Ибраһимов Б. Йөрәк. *Шигырьләр.* №7
Майорова Р. Ярты йөрәкле өмет. *Шигырьләр.* №7
Мөхәммәтшин Р. Ирек мәйданы. Әрнү һәм өмет. *Шигырьләр.* №9
Һадиева Э. Тәрәзләрне ачтым. *Шигырьләр.* №2
Фидаил. Йолдызлы болытларда. *Шигырьләр.* №8

**БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ**

Әхмәтҗанова С. №7
Галиуллин Р. №11
Имаев Р. №2
Ишмөхәммәтов Н. №6
Кәбиров М. №4
Кутлу Ф. №5
Минһаҗева З. №8
Сәлах Р. №12
Ситдыйкова Ә. №2
Остудин А. №6

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Гомәр Г. Кремльгә җыенам. №5
Гомәр Г. Кеше китә, җыры кала. №9
Гомәр Г. Татар җанлы Вараксин. №11

**КАЙТАВАЗ**

Бәйрәмова Ф. Һәр кеше укысын иде. №5
Юныс М. Батып барган карабны кем, ничек коткара алыр? №8

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№2, 4, 5, 6, 7, 9, 11, 12
Укучы сүзе. №№2, 4, 9, 11, 12
Бер сорауга – бер җавап. №12
Төртмәле бит. №№4, 8
Хушлашу сүзе. №6
«Казан утлары» архивыннан. №№1-12
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12
Яңа китаплар. №№1-12

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнен фәкать машинкала басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнен бер ягы буш кала. Машинка текстынын беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянен электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

**СПОРТ ДЕРЖАВАСЫ ФОРУМЫ—КАЗАНДА**

22-25 октябрь көннәрендә Казанда «Россия—спорт державасы» дигән ил күләм форум уздырылды. Бу I Бөтенроссия җыенында Россия Президенты Д. Медведев та катнашты. Шул уңай белән форумга федераль министрлар, халыкара спорт федерацияләре президентлары килде. Чит илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән дә мәртәбәле кунаклар күп иде.

Дмитрий Медведев РФ Президенты каршындагы физик культура һәм спорт, югары казанышлар спортын үстерү, 2014 елда Сочида узачак XXII кышкы Олимпия уеннары һәм XI кышкы Паралимпия уеннары, 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына әзерлек һәм аны үткәрү Советы утырышын уздырды. Шулай ук яна корылмаларның берсе—Казан теннис академиясендә булды.

Теннис академиясе Универсиада авылы янәшәсендә һәм Җиңү проспекты белән Оренбург тракты чатында урнашкан. Аның гомуми мәйданы 85 мең кв метр тәшкил итә. Билгеле булганча, төзелеш эшләре 2007 елның 29 августында ТР Президенты Минтимер Шәймиев һәм Россия теннис федерациясе президенты Шамил Тарпищев аның нигезенә беренче ташны салгач башланган иде. Академиядә 8 ябык корт һәм ачык һавада 18 корт бар. Трибунага 3 мең кеше сыешлы. Халыкара теннис федерациясе житәкчесе Риччи Битти әйтүенчә, комплекс бөтен таләпләргә дә җавап бирә.

Дмитрий Медведев республикадагы иң алдынгылардан саналган 177 нче мәктәптә дә булды. Әлеге мәктәп Яңа Савин районында урнашкан һәм анда 1029 укучы белем ала. Мәктәп күнегүләр, хореография заллары, тир, бассейн, футбол кыры, баскетбол һәм волейбол мәйданчыкларын да үз эченә алган.

—Әгәр һәр төбәктә дә шундый мәктәпләр булса, без дөньядагы иң көчле спорт иленә әйләнер идек,—диде Д. Медведев.

Аннары Президент «Корстон» сәүдәкүңел ачу үзәгендә «Россия—спорт державасы» I Бөтенроссия форумының тантаналы ачылышында катнашты.

—Бернинди финанс авырлыкларына да карамыйча, теләсә кайсы төбәк бюджетында физик культура һәм спортка кагылышлы маддәләр өстенлекле булырга тиеш. Бүген без беренче форумга старт бирдек. Ул ел саен уздырылачак, шулай итеп без Россия спортындагы яна традициягә нигез салабыз. Соңгы елларда Россия хоккейдагы титулларын кабат кайтарды, футбол буенча уңышларыбыз бар. Һәм спортның башка төрләрендә дә яхшы нәтиҗәләргә куанабыз. Спорт белән шөгыльләнү өчен шартларны яхшыртырга теләк бар икән—алар гади күз белән караганда да күренә. Мисалга Казанны китерер идем. Әлеге форумның Казанда—2013 елдагы Универсиада башкаласында—үзенең спорт традицияләре белән атаклы шәһәрдә узуына шатмын.

Бу шәһәр үзенең спорт традицияләре белән танылган, XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасы да шушы калада узачак. Форум эчтәлекле доклад һәм бәхәсләргә бай булды дип уйлыйм, яна эшлекле элементләр урнаштырырга, булганнарын тагын да киңәйтергә ярдәм итәр дип ышанам. Әлеге чара барышында әзерләнгән тәкъдимнәрнең исә гамәлдә дә кулланылыш табачагына өметләнәм,—диде Дмитрий Медведев.

**БЕРДӘМ БУЛСАК—БЕРЛЕК ЯШӘР!**

«Казан» милли мәдәният үзәгендә Татарстан Язучылар берлегенең 75 еллык юбилеена багышланган «XXI гасыр татар әдәбияты, татар әдәби теленең сакланышы һәм үсеш тенденцияләре» дигән фәннигамәли конференция булды. Аны Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге һәм Татарстан Фәннәр академиясе оештырды.

Әдипләр җыенында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К. Миннуллин һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов котлау сүзе белән чыкты. Аерым алганда, Берлек җитәкчесе үз чыгышында болай диде:

—Тарихның дисталәрчә гасырын ко-

лачлаган татар әдәбияты өчен 75 ел—кешенең уртача гомеренә тиң вакыттыр. Шул кыска гына вакыт аралыгында да гасырларга тиң вакыйгалар булып үтте. Никадәр ачышларга ирешелде. Безнең күз алдында сука белән башланган гасыр космосны яулау, янадан-яңа нанотехнологияләр үзләштерү белән төгәлләнде. Глобальләшү киң колач ала бара. Шул шартларда һәр милләтнең үз этник мәдəниятен, үз мәсләген саклап калу өчен көрәш бара. Бөтен дөнья әдәбияты һәм мәдәнияте мохитендә милли әдәбиятлар үз йөзен, үз төсен саклап калу, барыннан да бигрәк, үз халкында, үз милләтендә үз-үзен саклап калу һәм үстерү өчен рухи җаваплылык тәрбияләү кебек үтә катлаулы мәсьәләләрне хәл итәләр...

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты доценты Ф. Хәсәнова—«Татар шигърияте: үткәне, бүгенгесе, киләчәге»; Казан дәүләт университеты доценты Х. Ширмән—«Татар прозасы: сюжет, композиция, тел үзенчәлекләре»; ТР Фәннәр академиясенең гыйльми сәркәтибе Д. Заһидуллина «XXI гасыр башы татар әдәбияты: перспективалар һәм проблемалар» дип исемләнгән докладлар белән чыгыш ясады.

Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, фәнни-гамәли конференциядә чыгыш ясап, матбугатта поэзиянең урыны турында сөйләде, туган телебезне саклау мәсьәләләренә тукталды. Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты профессоры Р. Сверигин, «Мәгариф» нәшрияты директоры М. Вәлиев, КДУ доценты, шагыйрә Р. Харрасова: «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, Татарстан Язучылар берлегенең шигърият остаханәсе җитәкчесе, шагыйрь З. Мансуров, КДУ доценты Н. Нәбиуллина, «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире, Татарстан Язучылар берлегенең проза, публицистика остаханәсе җитәкчесе, прозаик К. Кәримов, Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәрҗемә һәм рус әдәбияты остаханәсе җитәкчесе, шагыйрә Л. Газизова, «Идел» журналының баш мөхәррир урынбасары, тәрҗемәче Г. Хәсәнова, Татарстан Язучылар берлегенең драматургия остаханәсе җитәкчесе, шагыйрь Р. Зәйдулла, Татарстан Язучылар берлегенең балалар әдәбияты остаханәсе җитәкчесе, шагыйрь Р. Корбан; шагыйрә Л. Янсуар, Татарстан Язучылар берлегенең тәнкыйть остаханәсе җитәкчесе, шагыйрь Р. Рахмани, шагыйрә Ф. Тарханова, язучы З. Зәйнуллин, шагыйрә Н. Сафина һ. б. чыгыш ясап, татар әдәби теленең чисталыгы, татар әдәбиятының киләчәге, әсәрләрне тәрҗемә итү үзенчәлекләре, татар әдәбиятын дөньяга таныту юллары, милли әдәбиятка яңа гасыр таләпләре, әсәрләрдә әдәби стиль үзенчәлекләре хакында сөйләделәр.

Язучыларның бу зур җыенында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева чыгыш ясады һәм бер төркем каләм әһеленә хөкүмәт бүләкләрен тапшырды.

Соңыннан фәнни-гамәли конференциядә Язучылар берлеге алдында торган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән махсус резолюция кабул ителде.

***

Кичен С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында Язучылар берлегенең 75 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Әдәбият һәм мәдәният бәйрәмендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин да катнашты һәм тантанада чыгыш ясап, Язучылар берлеге тарихына, үткән юлыбызга, тарихи шәхесләргә тукталып, иҗат берлегенә нигез салган, аның үсешендә хәлиткеч роль уйнаган зыялыларыбызны олылап искә алды. Парламент җитәкчесе әйтүенчә, үткән гасырның 90 нчы елларында, катмарлы чорда, кайбер иҗат берлекләре, авырлыкларга birешеп, таркалган чакта да безнең Язучылар берлеге үз йөзен, бердәмлеген саклап кала алды, диде ул.

Аннары парламент җитәкчесе Язучылар берлегенең 75 еллыгы уңаеннан оешмага Татарстан Президентының Рәхмәт хатын тапшырды. Ул шулай ук мәдәният һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәннәре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен бер төркем язучыларга мактаулы исем дипломнары һәм Президентның Рәхмәт хатларын тапшырды (Аларның исемнәре хрониканың соңгы битендә бирелә). Шагыйрь Зөлфәткә вафатыннан соң бирелгән «Фидакяр хезмәт өчен» медален аның хатыны Фирая ханым кабул итеп алды.

Бәйрәм кунагы—«Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры урынбасары Р. Мөхәммәдиев бер төркем каләм әһелләренә шагыйрә С. Сөләйманова исемендәге премияләрне тапшырды.

Тантаналы кичәдә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Р. Борһанов катнашты.

Кичәдә кунаклар—Халыкара Язучылар берлекләре берләшмәсе идарәсе һәм Россия язучылары Әдәби фонды рәисе И. Переверзин, шагыйрь, «Наш современник» журналының баш мөхәррире С. Куняев; Удмуртия Язучылар берлеге идарәсе рәисе Е. Загребин, Мари Иле Язучылар берлеге идарәсе рәисе В. Крылов, Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары К. Аралбаев катнашты һәм чыгыш ясады.

## ИДЕЛ БУЕ ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ—КАЗАНДА

21 октябрьдә РФ Президенты Дмитрий Медведев Россия Федерациясенең дүрт федераль округында федераль университетлар төзү турындагы Указга кул куйды. Әлеге Указ «Төньяк-көнбатыш, Идел буе, Урал һәм Ерак Көнчыгыш федераль округларында федераль университетлар төзү турында» дип атала Аның нигезендә Идел буе федераль университеты Казан дәүләт университеты базасында төзеләчәк.

ТРның мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов, КДУ базасында Идел буе федераль университетына Казан дәүләт финанс-икътисад университеты, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетын берләштерү мөмкин, дип белдерде. Әлегә башка вариантлар каралмый. «Бу вузларның өчесе дә булачак Идел буе федераль университеты составына керерме, яки берсе, икесеме—бу мәсьәлә ачык кала»,—дип ассызыклады Альберт Гыйльметдинов. Идел буе федераль округының булачак ректоры мәсьәләсе әлегә хәл ителмәгән. Ректор Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнәчәк.

## ПЕН-ҮЗӘК ХӘРӘКӘТТӘ

Халыкара ПЕН-клуб кысаларында үткәрелгән 75 нче Бөтендөнья язучылар конгрессы делегатлары быел Австриянең Линц шәһәрендә очрашты. 107 ил вәкиле арасында Татарстаннан Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Әхәт Мушинский да бар иде. Мәскәүдә аларга Татар ПЕН-үзәгенең башкаладагы вәкиле Борис Пантелеев кушылды. Конгресста халыкара ПЕН-клубның яңа президенты итеп Канада язучысы Джон Релстон Сэйул сайланды. ПЕН-клубка яңа әгъзалар—Албания һәм Монголия язучылары кабул ителде. Форумның пленар утырышында Татар ПЕН-үзәгенең яңа президенты, шагыйрь Разил Вәлиев тәкъдим ителде. Конгресс китапханәсенә татар авторларының инглиз телендәге китаплары тапшырылды.

Татар ПЕН-үзәге делегациясе алтай телләре гаиләсенә керүче төрки, монгол, тунгус-маньчжур төркемнәрен берләштергән «Урал-Алтай» секциясе эшендә катнашты. «Урал-Алтай» берләшмәсенең беренче конгрессы быел Истанбулда үткәрелде, икенчесе киләсе елда Бишкәктә уздырылачак.

Безнен делегация конгресста рус телендә сөйләшүчеләрне берләштергән секция төзү тәкъдиме белән чыкты. Быел аңа рус, татар, казакъ, украин, чех һәм словак үзәкләре кертелде.

Чех коллегаларыбыз чакыруы буенча безнен делегация Прагада булды. Чехиянең Россия фән һәм мәдәният үзәгендә «Казан альманахы» һәм «Прага графоманы» редколлегияләре очрашты. Баш мөхәррирләр Әхәт Мушинский һәм Сергей Левицкий альманахларының үзара хезмәттәшлеге турында меморандумны имзалады. Очрашуда «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе хезмәткәрләре—директор Рим Гыйльфан, мөхбирләр Алсу Кормаш, Гали Гыйльми, Дилбәр Исламова, Индира Биктимерова да бар иде. Соңыннан Т. Миннуллин һәм Р. Вәлиев «Азатлык» радиосында татар әдәбияты, мәдәнияте, мәгарифе мәсьәләләренә багышланган сөйләшүдә катнашты.

## ӘДӘБИЯТНЫҢ ӘМИР-ХАНЫ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында бөек әдибебез, Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Әмирхан Еникинең тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

«Жиз кыңгырау» дип исемләнгән кичәдә (сценарий авторы—Ләбиб Лерон) татар әдәбияты классигы белән аралашып яшәгән каләмдәшләре, иҗатташ дуслары, үзе туып-үскән Башкортстан якларыннан килгән кунаклар, җәмәгать эшлеклеләре, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, әдипләр, шул исәптән Ә. Еникинең улы Альфред, кызлары Резеда һәм Флера катнашты.

Әдәби кичәне ачып, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов болай диде:

—Әмирхан Еники—матурлык тудыручы, дигәндә, әлбәттә, без аның затлылыгы, олпатлылыгының ана сөте белән күчкәнлеген һәм морзалыгы—мирзалыгына бәйле булуын әйтәбез. Әмирхан аганың жиде буын бабалары җаһиллек җилләре искән чакта да үзләренең затлылыкларын югалтмыйлар. Тирән тамырдагы затлылык буыннардан-буыннарга күчә икән, сутлап мантып китә икән дә, бөтен кешелекнең уртак куанычы булырдай матурлыкка әверелә икән... Еники тудырган матурлык—аның үзе кебек гап-гади дә, олпат та.

Тантаналы кичәдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова катнашты һәм чыгыш ясады. «Әмирхан аганың шәҗәрәсе Тиниш морза нәселенә барып тоташа,—диде ул.—Тиниш морзаның ике углы булган. Аның берсе—Еники, икенчесе—Колынчак. Белгечләр әдипнең шәҗәрәсен рус әдәбияты классигы Александр Куприн белән бәйли. Ә. Еникине А. Куприн белән янәшә куйганнарын

элеграк тә ишеткәнем бар иде. Ләкин аны символик рәвештә, ижатларын, әдәбиятта тоткан урыннарын күздә тотып кына янәшә куйганнардыр, дип уйлый идем. Ә алар, баксаң, чын-чынлап кардәшләр, туганнар да икән.

Кичә Татарстан сәнгать осталарының чыгышлары белән үрелеп барды. Шулай ук экраннан әдип үзе исән чагында төшереп алынган кадрлар җанланды, үзенең кабатланмас тавышы яңгырады.

Кичәдә шулай ук Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Марсель Галиев, танылган шагыйрь Ркаил Зәйдулла, шулай ук Әмирхан аганың якташы, Башкортстанда чыга торган «Һәнәк» журналының баш мөхәррире, язучы Марсель Сәлимов чыгыш ясады.

### БЕЗ—БЕР АНА БАЛАЛАРЫ

Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов чакыруы буенча Бөтендөнья татар конгрессы башкарма кометиты рәисе Ринат Закиров ут күршеләребездә булып кайтты. Казанга кайткач, ул журналистлар белән очрашты.

Аның әйтүенә караганда, бер сәгать буе барган сөйләшү вакытында күп кенә мәсьәләләргә ачыклык кертелгән. Мәгълүм ки, бер ел элек Башкортстан татарлары конгрессының вәкаләте чыккан иде. М. Рәхимов конгрессның корылтаен 2010 елның март-апрель айларында үткәрергә күрсәтмә биргән. Татарстанда—Башкортстан телевидениесе каналы, Башкортстанда «Татарстан—«Яңа Гасыр» каналы сигналларын бернинди тоткарлыксыз кабул итү мәсьәләсе хәл ителгән. М. Рәхимов: «Үзара мөгамәләләрне ничек тә җайга салырга, ныгытырга, үстерергә кирәк»,—дип кат-кат ассызыклаган.

Аннары Р. Закиров Башкортстан педагогия университеты бинасында татар зыялылары белән очрашкан. Алар Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисенең Башкортстан Президенты белән очрашуын тарихи вакыйга, дип бәяләгән.

—Бернинди элемтә булмауга караганда, нинди дә мөгамәлә урнаштыру, һичьюгы Татар конгрессы белән Башкорт корылтае кысаларында булса да хезмәттәшлек итү, ниятләгәнчә барып чыкса, киләсе елда Башкортстанда—Татарстан көннәрен, Татарстанда Башкортстан көннәрен үткәрү ике республика өчен дә файдалы булачак. Милли үзенчәлекләребезне саклап калу өчен, әлбәттә, карагруһчыл көчләрнең басымына бирелеп каршы торырга кирәк,—диде Р. Закиров.

### ДИРЕКТОРЛАР СОВЕТЫ РАСЛАНДЫ

«ТАТМЕДИА» ААҖнең яңа Директорлар советы расланды. Аның составына түгыз кеше кергән: ТР Президенты аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, ТР Президентының эчке сәясәт буенча идарәсе җитәкчесе Александр Терентьев, матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чаралары буенча республика агентлыгы җитәкчесе Марат Моратов белән аның урынбасарлары Фәрит Шаһиәхмәтов һәм Сергей Журавлев, ТР Министрлар Кабинетының матбугат хезмәте җитәкчесе Андрей Кузьмин, ТР Дәүләт Советында мәдәният, фән һәм мәгариф, милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе Разил Вәлиев, ТР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары Айрат Нуретдинов, «Татмедиа» ААҖ генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев.

### СПОРТ КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ

23-24 октябрь көннәрендә Казанның «Корстон» кинотеатрында «Россия—спорт державасы» дип аталган I Бөтенроссия Халыкара спорт киносы фестивале үтте. Конкурс программасына Россия, Италия, Иран, Сербия, АКШ, Франция, Румыния, Португалия, Испания, Кытай һәм Украина кебек илләрдән 40 фильм тәкъдим ителде. Аларда Елена Исинбаева һәм Юрий Борзаковский, Алексей Ягудин һәм Иван Ярыгин, Диего Марадонна һәм Криштиан Рональдо, Ирина Винер һәм Шамил Тарпищев, Валерий Лобановский һәм Давид Тышлер, Юрий Семин һәм Николай Валуев кебек дөньякүләм танылган спортчылар хакында сөйләнелде.

### КАЗАНДА ПРЕЗИДЕНТ КИТАПХАНӘСЕ

Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм Б. Ельцин исемендәге Президент китапханәсе генераль директоры Александр Вершинин Санкт-Петербург шәһәрендә узган Бөтенроссия кинәшмәсендә Казанда Президент китапханәсенең филиалын төзү турындагы килешүгә кул куйды.

Кинәшмәдә Россиянең 79 төбәгеннән хакимият, Мәдәният министрлыгы һәм үзәк китапханә вәкилләре катнашты.

Президент китапханәсе филиалларын ачу буенча Омск, Төмән һәм Улан-Удэ вәкилләре белән дә хезмәттәшлек килешүләре төзелгән.

Россия Президентының күрсәтмәсе нигезендә Б. Ельцин исемендәге Президент китапханәсенең филиаллары Россия Федерациясенең барлык субъектларында да оештырылачак.

Казанда Б. Ельцин исемендәге Прези-

дент китапханәсе филиалын шәһәр үзәгендә 1825 елда төзелгән ике катлы бинада урнаштыру күздә тотыла. Әлеге тарихи йортта баштарак республика Югары суды эшләгән иде.

## «ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ» КАНАТ НЫГЫТА

Казан янындагы «Чишмәкәй» лагеренда IX «Иделем акчарлагы-2009» республика бәйгесенең йомгаклау туры булып үтте. Конкурсны Татарстан Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, «Идел» яшьләр үзәге һәм Язучылар берлеге оештырды.

Быел бәйгедә 180нән артык яшь иҗатчы катнашырга теләк белдерде. Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Вакыйф Нуриев, Илсөяр Иксанова, Марат Закир һәм Рәдиф Сәгъди составындагы жюри шулардан иң лаеклыларын сайлап алды, һәм алар конкурсның соңгы турында катнашу хокукын яулады.

Быелгы бәйгедә шигърият буенча 1 нче урынга Ләйсән Фәтхетдинова (Балык Бистәсе), 2 нче урынга Айгөл Габдрахманова (Кайбыч), 3 нче урынга Булат Садретдинов (Чаллы) лаек булды. Проза буенча 1 нче урын Ләйлә Гатауллинага (Теләче), 2 нче урын Линар Закировка (Чаллы), 3 нче урын Энже Ибраһимовага (Казан) бирелде.

Драма әсәрләре арасында 1 нче урынга лаек пьеса юк дип табылды. 2 нче һәм 3 нче урыннарны исә Чулпан Гобәйдуллина (Арча) белән Рузилә Абдушева (Аксубай) бүлеште.

Татарстан Язучылар берлегенең махсус бүләге яшь шагыйрә Айгөл Закировага (Актаныш) тапшырылды.

Гран-прига Ләйсән Фәтхетдинова (проза) һәм яшь шагыйрь Булат Ибраһимов (Лаеш) лаек булды.

## ТУКАЙ ФРАНЦУЗЧА ДА ЯҢГЫРАР

Габдулла Тукай шигырьләрен француз теленә тәрҗемә итәргә мөмкиннәр. Бу хакта «Альянс Франсез-Казан» үзәгенең еллык җыелышында хәбәр ителде. Очрашуда Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева да катнашты. Үзәк директоры Р. Гобәйдуллин сүзләренә караганда, быелгы ел оешма өчен аеруча уңышлы булган. Алар күпсанлы француз язучылары, шагыйрьләре, актерлары белән очрашкан. Үзәк киләсе елга да зур өметләр баглый. Башкалага Франция балалар симфоник оркестры килер дип көтелә. 2011 елда Г.Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан, шагыйрьнең иҗатын француз теленә тәрҗемә итәргә дә җыеналар.

## МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВНЫ ИСКӘ АЛУ

Камал театрында мәшһүр режиссер Марсель Сәлимҗановны искә алу кичәсе булды. Артистлар гаиләсендә туып, шушы театрда тәпи баскан, сәхнә исен, рухын сеңдереп үскән, шунда 40 ел иҗат иткән атаклы режиссерга быел, үзе исән булса, 75 яшь тулыр иде. Марсель Хәким улының рухын яд итеп, олы иҗатына тагын бер кат баш ияргә зал тутырып тамашачы килде. Залда әдәбият-сәнгать әһелләре, режиссерның күпсанлы шәкертләре арасында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Мәскәү кунагы, танылган язучы һәм тәнкыйтьче Борис Покровский да бар иде. Сәхнәдә бу кичне М. Сәлимҗанов куйган спектакльләрдән өзекләр уйналды, маэстро хакында истәлекләр сөйләнде. Аның юмор хисенә бай, яшәү көченә ия, искиткеч талантлы шәхес булуы кабат-кабат искә алынды. Кичә, хәтер кичәсеннән бигрәк, режиссерның юбилей кичәсен хәтерләтте. Әйтерсең лә остаз үзе безнең арада, театрда—яраткан актерлары вә тамашачылары белән бергә иде.

## ЛЕГЕНДАР ШӘХЕС ХАКЫНДА

Күптән түгел «Идел-Пресс» нәшриятында республиканың «баш хәйриячесе» Әсгать Галимҗанов эшчәнлегенә, тормышына бәйле китап дөнья күрде. «Легендар Әсгать Галимҗанов» дип исемләнгән басмада төрле елларда газета-журналларда дөнья күргән рус һәм татар телендәге язмалар, истәлекле фотолар урын алган. Китаптан бер өзек: «Яшьлегегезгә кире кайтсагыз, кем булыр идегез?»—дип сорыйлар аннан. «Шул ук кеше булыр идем. Тик бер кимчелекне төзәтәсем килә: бик әйбәт итеп телләр өйрәнер идем»,—ди Әсгать Галимҗанов. «Табадан төшкән» китап ятимнәргә автобуслар бүләк итүче хәйриячегә бәйле бик күп сорауларга җавап табарга ярдәм итәчәк.

## «КОЗГЫННАР ОЯСЫНДА»

Шәриф Камал әдәби музее ремонтка ябылу сәбәпле, экспозиция Г. Тукай музеена вакытлыча күчеп торды. Биредә 30 октябрьдә (Габдулла Тукайның әдәби музеенда) сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне уңаеннан «Козгыннар оясында (Шәриф Камал һәм репрессияләнгән татар язучылары)» дигән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

Шәриф Камал репрессия елларының дәһшәтле өермәсе эченнән ничек итеп исән-имин кичеп чыкты икән? Бу хакта архив материаллары ни сөйли? Кичәгә килүчеләр әнә шушы сорауларга җавап таптылар.

Милли музей фондында әдипнең бай архивы саклана. Кызганыч, фондта Ш. Камалның әлеге чор тормышын һәм иҗатын тасвирлаган материаллар күп түгел. Ләкин аның даирәсендәге репрессия корбаннары—Кәрим Тинчурин, Шамил Усманов, Гомәр Гали, Кави Нәҗми, Фатих Кәрим кебек язучыларның архивларында сакланган кайбер документлар Ш. Камалның «болытлы» көннәрендәге кичерешләрен күзалларга ярдәм итә.

Чарада шулай ук репрессияләнгән татар язучыларының Милли музей фондында сакланган шәхси әйберләре, документлары да тәкъдим ителде. Алар арасында—Сәгыйть Сүнчәләйнең шигырьләре, хатларының кульязмалары, фотосурәтләре; Фатих Кәрим тарафыннан эшләнгән агач тартмачык, фронттан язылган хатлары, куен дәфтәре; Һади Такташ, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш әсәрләренең кульязмалары...

Кичәдә сүз Ш. Камал һәм аның даирәсе генә түгел, гомумән, репрессия корбаны булган татар язучылары турында барды. 70кә якын татар язучысы нахакка гаепләнеп репрессияләнә. Шуларның 46 сы тоткынлыкта үлә.

Кичәдә Г. Тукай премиясе лауреаты язучы Р. Мостафин, галимнәр академик И. Р. Таһиров, тарих фәннәре кандидаты Т. Ә. Биктимерова, РФ һәм ТР Журналистлар берлеге әгъзасы Мөбарәк Мусин, шагыйрә Салисә Гәрәева чыгыш ясадылар.

## ЧАЛЛЫДА ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

***

Чаллы шәһәренең татар җәмәгатьчелеге күренекле балалар язучысы Рәшит Бәшәрнең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Дистәдән артык китап авторы, бүгенге көндә «Мәйдан. Чаллы» журналының җаваплы секретаре булып эшләүче әдипне котларга татар әдәбиятында үз урынын алган күренекле каләм әһелләре—Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов, сабакташы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров, «Сүз» нәшриятының баш мөхәррире Шаһинур Мостафин, «Мәйдан. Чаллы» журналының баш мөхәррире Вахит Имамов, рухи мирасны өйрәнү төбәк фәнни-методик үзәге җитәкчесе Факил Сафин, язучы Айдар Халим һәм башкалар килгән иде. Һәр әсәрен балаларга әхлакый тәрбия бирүгә, аларда милли горурлык хисе уятуга багышлаган шагыйрьне Чаллы шәһәренең мәгариф һәм мәдәният идарәләре җитәкчеләре, татар теле укытучылары, якташлары, туганнары да тәбрикләде.

Юбилей кичәсе шулай ук шагыйрьнең Туган авылы Янилдә (Кукмара районы) зур тантана белән үтте.

***

Чаллының «Энергетик» мәдәният сараенда шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, дистәләгән популяр җыр авторы Галиәхмәт Шаһинның 60 яшьлек юбилее унаеннан тантаналы кичә уздырылды. Юбилярны котларга шәһәр хакимияте вәкилләре, шагыйрьнең туганнары, иҗатташ дуслары, татар җәмәгатьчелеге, предприятие җитәкчеләре, сәнгать әһелләре, мәдәният хезмәткәрләре, аның иҗатына мөкиббән укучы-тамашачылар килгән иде. Чыгыш ясаган һәркем Галиәхмәт аганың әсәрләрендә халыкчанлык өстенлек итүен, бер карашка гади генә тоелган шигырьләренең тирән, бай эчтәлекле һәм халык игътибарын җәлеп итә торган булуын ассызыклады.

## ШӘҖӘРӘНЕ НИЧЕК ТӨЗЕРГӘ?

Кеше үзенең нәсел-нәсәбен, гаилә тарихын белергә, өйрәнергә тиеш. Ә нәрсә соң ул нәсел шәҗәрәсе, аны ничек төзергә? Бу сорауларга җавапны Фәйзелхак Ислаевның әле шушы көннәрдә генә «Мәгариф» нәшриятында дөнья күргән «Я и моя родословная» китабыннан да табарга мөмкин.

Ул—гомуми урта белем бирү мәктәпләрендәге югары сыйныф укучылары өчен генеалогия нигезләрен өйрәтүче уку әсбабы. Китапта генеалогия терминына билгеләмә бирелә, 11 бүлекнең һәрберсе бик күп схемалар, таблицалар, фотолар белән баетыла. Нәсел шәҗәрәсен төзү методикасы, генеалогик чыганакларның архивы, тарихы, һөнәр сайлау үзенчәлекләре һәм башкалар буенча кызыклы мәгълүматлар да бирелә. Шулай ук әлеге китап милләтебезнең күренекле шәхесләре бертуган Рәмиевләрнең, Р. Фәхреддиннең, Г. Тукайның һәм пәйгамбәребез Мөхәммәтнең (с.г.в.) нәсел-нәсәбе белән таныштыра.

Бу теманы тагын да тирәнрәк белергә теләүчеләр өчен китап ахырында төрле авторларның газета-журналларда чыккан язмалар исемлеге һәм федераль, республика, өлкә архивларының адреслары, электрон сайтлары да күрсәтелә.

***

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә лаеклы өлеш кертkәне өчен «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге җәмәгать

оешмасы»ның рус әдәбияты буенча әдәби консультанты **Газизова Лилия Рифкать кызына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Әдәбият-сәнгать өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен шагыйрә **Ахунова Наилә Гарифҗан кызына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЛАРЫ

Татарстан Республикасы хакына нәтиҗәле хезмәте, татар халкының рухи мирасын саклап калуга, хәзерге әдәбиятны үстерүгә керткән лаеклы өлеше өчен **Татарстан Республикасы Язучылар берлеге коллективы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, хәзерге татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен язучы **Гаффаров Габделәхәт Габдрахман улы** (Әхәт Гаффар) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, хәзерге татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен язучы **Моталлапов Әмирҗан Закирҗан улы** (Актаныш районы) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Татарстан Республикасының иң яңа тарихы буенча күп томлы китаплар сериясен әзерләүгә һәм нәшер итүгә лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы баш белгече **Хәсәнов Әнәс Хәсән улы** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

## ЮГАЛТУЛАР

2009 елның 6 октябрендә галим, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, филология фәннәре докторы **Бәширов Фәрит Кәрим улы** 51 яшендә вафат булды.

***

2009 елның 14 октябрендә 84 яшендә язучы, Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Насыйбуллин Мәгъсүм Нәҗип улы** вафат булды.

***

2009 елның 23 октябрендә каты авырудан соң, 98 нче яшендә «Азат хатын» (хәзерге—«Сөембикә») журналын янәдән торгызуга зур өлеш кертеп, унтугыз ел буе аның баш мөхәррире вазифасын башкарган Россия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Хәсәнова Асия Фәрид кызы** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Аккош күлендә кыш. Алгы планда—заманында язучылар С. Хәким, И. Гази, Н. Дәүлиләр яшәгән йортлар.

*Дүртенче биттә:* язучы-галим **Әнвәр Шәрипов**.

# Яңа китаплар




**«Гаташнамә». Рәдиф Гатауллин-Гаташ иҗаты турында сәхифәләр.** Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты. 2009.—440 бит. Тиражы—400 данә.

Җыентыкка күренекле шагыйрь, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ (Гатауллин) иҗатын яктырткан, 1965—2009 елларда язылган мәкаләләр, эсселар, иҗат портретлары, шагыйрьгә багышланган шигырьләр, күпсанлы фотосурәтләр тупланган. Китапка кереш сүз язган, аның фәнни редакторы галим, әдәбият белгече Х. Миңнегулов билгеләгәнчә, «язмалар соңгы дәвер сүз сәнгатен, андагы төп тенденцияләрне, үсеш-үзгәрешне, бәхәс-көрәшләрне аңларга ярдәм итә, кыскасы, бу җыентык шәхси кысалардан чыгып, киң җәмәгатьчелек өчен файдалы, кызыклы рәвеш алган, ул киләчәк гыйльми тикшеренүләр өчен дә мөһим бер чыганак булып хезмәт итәчәк».

Төзүче-редакторы Г. Бәйрәмова.




**Фәйрүзә Мөслимова.** Алтын йозак: шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.—192 бит. Тиражы—2000 данә.

Фәйрүзә Мөслимова—бүгенге татар шигъриятенә хезмәт итүче күренекле шагыйрәләребезнең берсе. Шигырьләре үткән гасырның 90нчы елларыннан бирле көндәлек матбугатта басылып килсә дә, аерым китаплары чыгу бу гасырга насыйп була: «Ярату яралары» (2001), «Апрель кары» (2004). Әлеге китабы исә быел дөнья күрде. Аңа Ф. Мөслимованың соңгы елларда иҗат иткән фәлсәфи-лирик шигырьләре тупланган. «Гомер—диңгез, төсләр уйный...», «Төшләремә керәсең дә...» кебек бүлемнәрдә бирелгән шигырьләр шигырь сөючеләрне битараф калдырмыйдыр.



Әнвәр Шәрипов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZANUTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)